ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

9.2008





Абдулла Алиш (1908–1944)

# Казан утлары
# Qazan utlarì

2008

**9**
**(1031)**

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

**НАШИРЕ:**
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎: *Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.*
**Факс**—*(843) 541-38-77.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Муса ЖӘЛИЛ. Дуска. *Шигырь* ........ 5
Айдар ХӘЛИМ. Хунвейбин. *Роман-эпопея* ........ 6
Әхсән БАЯН. Ак күңелле, серле дөньядан. *Шигырьләр* ........ 27
Әхәт САФИУЛЛИН. Сынаулар аша. *Повесть* ........ 32
Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Үз җиремнең җиләге мин. *Кыска шигырьләр* ........ 68
Вакыйф НУРИЕВ. Кара бишмәт. *Хикәя* ........ 97

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Юныс САФИУЛЛИН. Акмулла ........ 74

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Алинә БИКМУЛЛИНА. Бәхет ул ишек шакымый. *Шигырьләр* ........ 90
Рүзәл МӨХӘММӘТШИН. Өмет–иң якты уй. *Шигырьләр* ........ 92

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Альберт КАШАЕВ. Сагышларны җилләр тарата. *Шигырьләр* ........ 95

**ТАТАРСТАННАН ЧИТТӘ ЯШӘҮЧЕ КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ. УЛЬЯНОВ (СЕМБЕР) ӨЛКӘСЕ.**

Иделбикә. Яшә, Казан! *Шигырьләр* ........ 102
Рифкать ХИСМӘТ. Шагыйрьгә. *Шигырьләр* ........ 104
Равил ШӘФИГУЛЛИН. Язасы иде былбыл бәетен. *Шигырьләр* ........ 105
Абдулла МАРАТ. Каенсарда. *Шигырьләр* ........ 108

Татарстан язучыларының XVI корылтае материаллары ........ 112

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Себер иленә сәяхәт ........ 169

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ........ 174

**ХӘТЕР**

Ләбибә ИХСАНОВА. Зөлфия хатлары ........ 176
Әхмәт РӘШИТ. Һәркемнең... үз сукмагы ........ 179

"Казан утлары" архивыннан ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 192

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман-эпопея А. ХАЛИМА "Хунвейбин" (окончание); повесть А. САФИУЛЛИНА "Через испытания", рассказ В. НУРИЕВА "Черное пальто"; стихи М. ДЖАЛИЛЯ, А. БАЯНА, Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ.
"Драматургия": Ю. САФИУЛЛИН. "Акмулла".
"Творчества молодых": стихи А. БИКМУЛЛИНОЙ, Р. МУХАМЕТШИНА.
"Новые имена": Альберт КАШАЕВ. Стихи.
"Творчество татарских поэтов Ульяновской обл.": стихи ИДЕЛЬБЕКИ, Р. ХИСМАТОВА, Р. ШАФИГУЛЛИНА, А. МАРАТА.
Материалы "XVI съезд писателей Татарстана".
"Публицистика": Ф. БАЙРАМОВА. "Путешествие в Сибирь".
"Наука": Ф. ГАРИПОВА. "История наших деревень".
"Память": Л. ИХСАНОВА. "Письма Зульфии"; воспоминания А. РАШИТА "У каждого свой путь".
Наши юбиляры.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурный жизни.
На наших обложках: "Осенний лес"; литературный критик Альфат ЗАКИРЗЯНОВ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

"Prose and poetry": novel-epopee by A. HALIM "Hunveybin" (termination); story by A. SAFIULLIN "Through experience", story by V. NURIEV "Black coat"; verses by M. JALIL, A. BAYAN, E. SHARIFULLINA.
"Dramatic art": Yu. SAFIULLIN. "Akmulla". "Youth creativity": verses by A. BIKMULLINA, R. MUHAMETSHIN.
"New names": Albert KASHAEV. Verses. "Creativity of Tatar poets in Ulyanovsk region"; verses by IDELBEKA, R. HISMATOV, R. SHAFIGULLIN, A. MARAT.
Materials of "XVI Tatarstan writers congress". "Publicism": F. BAYRAMOVA. "Travel to Siberia". "Science": F. GARIPOVA. "History of our villages". "Memory": L. IHSANOVA. "Zulfia's letters"; memoirs by A. RASHIT "Everyone has his way".
Ours jubileers.
From magazine photoarchive.
Diary of social-cultural life.
On our covers: "Autumn forest"; literary critic Alfat ZAKIRZYANOV.

---

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.06.2008 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Т–1045 Тираж 5182.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2008 ел.

## ДУСКА

*А.Алишка*

Кайгырма, дус, яшьли үләбез дип,
Без алмадык сатып гомерне,
Үзебезчә яшәп, үзебезчә
Без чиклибез аны түгелме?!

Билгеләми гомер озынлыгын
Еллар саны, картлык җитүе.
Бәлки, менә шушы үлем безгә
Мәңге бетмәс яшәү китерер?!

Мин ант иттем җанны кызганмаска,
Саклар өчен халкым, илемне.
Йөзәү булса гомрең, син барсын да
Шушы юлга бирмәс идеңме?

Шатландыра безне көн дә илнең
Бер-бер яңа уңышын ишетү;
Нинди зур көч читтә үз-үзеңне
Халкың белән бергә хис итү!

Мин тиремне саклап исән калсам,
Үлем миннән аша сикерсә,
Шул яшәүме булыр, «хаин!» диеп,
Ил битемә минем төкерсә?!

Юк, теләмим мин бу «исәнлекне»,
Йөрәк минем моңа үчекмәс.
Кешеме мин илем үги иткәч,
Җирдә миңа эчәр су беткәч?!

Юк, кайгырма, дускай, безнең гомер
Ил гомренең тик бер чаткысы,
Без сүнсәк тә, безнең кыюлыктан
Арта бары аның яктысы.

Батырлык һәм илгә турылыкны
Шушы үлем белән белдерик.
Безнең яшьлек шушы хисләр белән
Данлы иде, көчле иде бит!!

Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең
Эзсез сүнә диеп уйлама!
Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда!

*1943*

Айдар
Хәлим

# ХУНВЕЙБИН

РОМАН-ЭПОПЕЯ

IV

Ресторанда тамак ялгаганнан соң ул, урынына ятып, Лотфрахманны көтте.

Ниһаять, ишек шакыдылар.

Иркен ага эндәшергә өлгермәде, аннан, гадәтенчә, майланып беткән калын постау костюмын һәр сәдәфенә кадәр каптырган, ак күлмәктән, муенына һаман да шул кызгылт муенчагын чалшайтып бәйләгән Лотфрахман күренде.

Сүзсез күрешкәннән соң, ванна бүлмәсенә титаклап барып, салкын су белән битләрен чылатып маташкан арада, саплам калмыйча артыннан ияреп, Лотфрахман, гадәтенчә, перфокартасын чыгарып, чираттагы лекциясен укый башлады:

—1843 елда Казан губернасына сәяхәтеннән соң, миссионер барон Гаксенхаузен: "Казан татарлары, борынгы болгар нәселеннән буларак, бик тә затлы халык... Әмма алар монголлар белән кушылган..." дип язган. Ишеттегезме, татарлар болгар нәселеннән булган, әмма монгол белән кушылган. Фу!..Ялган бу.. Менә мин...сез... монгол булабызмы инде?.. Без бит—Европа!..Э-э-э...Татарларның, гафу-мәгъфирәтләре, болгарларның, дип яза бу католикос, кыяфәтләре шундый: йөзләре җәенке, күзләре кара, теремек, кәлтә борыннары бераз бөгелгән, иреннәре нәзек, тешләре ак, яхшы җитлегеп үскән, битләре ак, Кафтау кавемнәренеке шикелле аз гына алсуланып тора, ди...

Иркен ага Лотфрахманның сүз ташкыныннан котылырга теләгәндәй, тәрәзәдән тышка күз ташлады. Кичкә таба салкынайтыр, бәлки яңгыр да булыр, дип иңенә кыска макинтошын салды, саквояжыннан чатыр да чыгарып, ишеккә таба юнәлде.

—"...татарлар, гафу-мәгъфирәтләре, болгарлар, бик акыллы, укымышлы халык, әмма ислам дине аларны бик тә чикләп, кирәгенчә генә үстерә, аларның һәр авылда мәдрәсә-мәптәкләре бар, барысы да укый-яза белә..."

Иркен ага ишекне бикләп, ачкычын кизүдә утырган хатынга тапшырды да, лифтка китте.

—"... урыс счетларында саный белә, аларның билгеле дәрәҗәдә—әдәбиятлары да бар, шәригатьне нык тота, Коръәнне бирелеп укый..."

Иркен ага лифт янына килеп, басмакка басты. Лифт килеп җитте. Карынын ачты. Керделәр.

*Ахыры. Башы журналыбызның 5 санында.*

—"... татарлар...э-э-э... гафу-мәгъфирәтләре ... болгарлар холыклары белән йомшак күңелле, уртак сүзгә килүчән, иплe, үзләрен ихтирам иттерә белә, чиста һәм ифрат та... "—дип укуын дәвам итте Лотфрахман.

Лифт төшеп житте, лып итеп урынына утырды. "...Мөлаем һәм тырыш халык..." дип, сикереп куйды болгарчы. Чыктылар. Иркен ага тышкы ишеккә юнәлде. Лотфрахман күзен һаман катыргысыннан алмыйча, абына күрмим дигәндәй, штиблетларын, Буратино кебек, күтәрә-күтәрә агасы артыннан мыгырданды:

—"... дөньяның иң алга киткән халыкларының берсе булган булырлар иде... ...әгәр бу табигатьтән бик тә сәләтле татар...гафу... болгарлар христианлыкны да кабул иткән булсалар..."

Алар кунакханә күтәрмәсеннән төштеләр дә, фонтан яныннан үзләрен көтеп торган автомобильгә кереп утырдылар. Утырган унайга Иркен ага, саруы кайнап, Акмулланы укыганын сизми дә калды:

Йорты болгар улса улсын,
Йортны болгар улмасын!...

Шигырьгә игътибар итүче булмады.

—Концертлар залына!...—дип боерды шоферга Лотфрахман.

Автомобиль Жәлил проспектына чыкты. Хәзер Чаллы аңа күптән таныш шәһәр булып күренде. Үзе бая гына янында булган Беляев һәйкәле, КамАЗ офисы, Ил-ана корылмаларын күрү аңа көч өстәгәндәй булды.

—Тукталыз. Кичә дә, бүген дә онытып...Рәис кардәшем белән ул куйдырган "Ил-Ана" һәйкәлләре арасында дога кыласым калган...

Туктадылар. Салоннан чыгып, "Ил-ана" һәйкәленең итәгенә килделәр. Иркен ага таш нигезгә утырды һәм Чаллы каберлекләре өстендә төзелгән электр станциясе диңгезенең тынчу дулкыннары астында калган, сөякләре моннан чит-ят туфракларга илтеп аткарылган, шушында, әнә каршыдагы зиратта жирләнгән, әнә, исемнәре шундагы таштактага язылган меннәрчә әрвахларга багышлап, "Ясин" укыды. Мөһажирнең унбиш минутлык илһамлы гыйбадәте Лотфрахманга сәгатьтәй тоелды. Иркен аганың тирә-ягын әрвахларның фәрештәгә әйләнгән жаннары уратып алгандай күренде. Партия әһеле һәм сынчы Чаллыдагы беренче һәйкәлне кулларына кеше үтерү кораллары тоткан шушы битабигый гыйфриткә түгел, ә бәлки су астына киткән авыллар, югалуга дучар тоташ бер милләт, аның тарихы, сәнгате, иманы—татар Атлантидасына куйганнар дип фараз итте...

Автомобиль Яңа Шәһәргә юл алды. Чаллы урамнарында милисиләрнең күплегенә һәм аларның нишләптер өелешеп торуларына игътибар итте Иркен-ага.

—Берәр күрше район түрәсе яшь сөяркәсе белән ресторанга тыгынырга киләдер,—диде шофер. Урамнар кызарган...

Автомобиль борылып туктады. Баксаң, тагын да шул кызгылт баскычлы хакимият бинасына килгәннәр икән. Алар тамган машина мае, машина ягулыгы белән чуар зәңгәрләнеп беткән асфальт буйлап киттеләр.

—Һәркайсының мотор төбе тишелгән,—дип, чалыш елмайды Лотфрахман һәм Иркен аганы кешеләр агымына борды.

Матурлык өчен генә утыртылган гөлжимеш куаклары, озак вакыт каралмый, дөрес тәрбияләнми торганлыктан, берсен-берсе басып китеп киңәйгән, нәселсезләнеп, рәвешен бозган иде.

—Хакимиятнең Концертлар залы. Хакимебез Алтынбаевка рәхмәт, милли хәрәкәтнең үтенечен екмады—һәр дүшәмбедә халык жыенын шушында үткәрергә рөхсәт итте...

—Жыенга рәхим итегез!...Бүген бәйрәм!..

—Бер, ике өч—бездә көч!..—диде берәүсе.—Влачны алабыз!..

—Син влачны җинел генә аласың, чөнки син—ахмак,—диде аңа икенчесе.—Менә безгә, акыллыларга, нишләргә?

Атлаган уңайдан очраган кешеләр белән күрешә-сөйләшә салып, Лотфрахман аны як-якка эленгән афиша-чакырулар, шигарь-плакатлар, “Жыен”, “Азатлык”, “Алтын Урда” гәзитәләре, “Аргамак” журналы куелган өстәлләр рәте буйлап дини догалыклар саткан вә тараткан агай-энеләр кулыннан кирәкләрен кулга төшерә-төшерә, бина эченә алып керде. Алар шундый ук кызгылт гранит баскычлар буйлап югарыга күтәрелделәр, уң канатка борылып, ярым караңгыда межмелдәп янган утлары гына шәйләнгән аралыкта тышта калган күзләрен эзли-эзли, түбәнгә, амфитеатрга төштеләр һәм алдагы рәтләрнең берсен сайлап, уртаданрак утырдылар.

Менә күзе дә өйрәнә төште. Әллә аның үзенә шушы залдан, әллә залга аның үзеннән нур инде—Иркен агага бу даирә нурлы күренде. Бер-берсен яхшы белгән бар җәмәгатьнең күзе аңарда—я н а к е ш е д ә иде. Игътибарны җәлеп иткәне өчен унайсыз да булып китте. Зал тулып килә икән.

—Утырыштык, җәмәгать!..

Иркен ага аваз яңгыраган тарафка карады. Сәхнә уртасындагы озын өстәл артына утырып алган зат мөрәҗәгать итте:

—Милләттәшләр!.. Рәистәшләрне, сәркәтипне президиумга чакырам!.. Бирегә шулай ук хакимиятнең милли мөнәсәбәтләр һәм дини оешмалар бүлеге мөдире Стомат әфәнде Жиһаншин һәм Казан кунагы—Бөтенрәсәй татар иҗтимагый үзәгенең качаклар буенча комиссия рәисе Юныс әфәнде Заһретдинов күтәрелсен иде!..

—Иҗтимагый үзәк рәистәше Гаяз Салихов була.—Лотфрахман Гаяз кардәше күрсен дигәндәй, утырган җиреннән кулын болгады.—Мин монда!.. Без, рәистәшләр, барыбыз алты кеше. Алтышар ай эшлибез. Әлегә ул рәислек итә. Бик акыллы адәм. Техник фәннәр кандидаты. Политехник институтта укыта. Менә дигән оратор-публицист!.. Тумышы белән Себер болгары. Чаллыда милли хәрәкәтне оештыручыларның берсе. Хыяллары бихисап аның. Жанын җәфалаган проблема—кешене энергиясен бушка сарыф итүдән коткару. Гомере буе изелгән халкыбызның бушка түгелгән физик көчен сонлап булса да үзенә кире кайтару. Алты миллиард халык өчен бер перпетуум мобиле эзли!.. Алексий IIдән татар алдында гафу үтендерергә дип хыяллана. Бүгенге көндә тулысы белән автоматикага корылган яңа кирпеч сугу заводын юлга салып маташа!.. Милли хәрәкәтнең авызы зур, ул акча сорый...

Иркен ага Гаяз әфәнде Салиховны, ни-нәрсәсе беләндер, мәшһүр сәясәтче Садри Максудиның яшьрәк чагына охшатты.

Залдан өч рәистәш әфәнде күтәрелеп, рәис белән рәттән урын алды. Аларның өчесе дә, пресс астыннан саман кирпеч кебек, бер-берсенә охшап, бертигез кыска буйлы, какча гәүдәле, ач яңаклы иде. Стомат Сибгатуллович белән Казан кунагы да, чакыруны гына көтеп утырган булсалар кирәк, дельфин сыман шома гәүдәләре белән алга елыша биреп, сәхнәгә күтәрелделәр. Бер сылукай, сәркәтип булса кирәк, өстәл читенә урнашып, алдында яткан кәгазен сырлый башлады.

Залга халык әле һаман керә, кергәннәре, унга-сулга карамый, очрашу шатлыгыннан таныш-белешләре белән күрешә, сәлам бирә, сәлам ала, судагы чөгермәкләр сыман, тегендә дә, монда да бөтерелеп, урын эзли, утырыша, шуның белән дә сихри божралар тудырып, бергәлек казанында кайнаша иде.

—Барыгыз, кардәшем,—диде Лотфрахманның Иҗтимагый Үзәктә

рәистәш икәнлеген белгән Иркен ага.—Сезнең урын өстә, ю г а р ы д а...

—Юк-юк, сезне калдыра буламмы соң!..—диде Лотфрахман кулын селтәп, күзен кысты.—Минем урын т ү б ә н д ә, сезнең янда... Рәистәшләребез барысы да югары белемле. Зыялылар. Әмма соңгы чорда Шиһаповларның Стомат Сибгатуллович әйткән теге "пролетар-сәнәкчеләре" безнең өскә менә башлады...

—Шау-шуны туктатыйк !..—дип кычкырып җибәрде бер чиелдек тавыш.—Шушында килсән—бардак!..

—Тынычландык, җәмәгать!—Рәис залны сөзеп алды һәм көрәя төшкән тавышы белән гавамны тәртипкә китерә башлады..—Рәхимҗан, Шамил, Сәлимгәрәй, туктагыз, яппунски гарадавай, соңыннан сөйләшерсез!.. Дамир Первый! Дамир Иттифакский! Бармак Дамир, игътибар! Милли хәрәкәттә Дамирлар күп булса, идарә итүе кыенлаша, җәмәгать!..

Салихов шаян да икән, житмәсә. Көрәштәшләренә кушаматлар белән генә сиптерә, әмма тегеләр үпкәләргә уйламыйлар да. Зал бер булып көлде—һәм шундук тынычланды да.

—Башлыйбыз, җәмәгать. Киләсе кешеләр, эчке һәм тышкы агентлар да килеп беткәндер... Җыен үзенең эшен, гадәттәгечә, ике сәгать дәвам итәчәк. Көн тәртибенә өч мәсьәлә чыгарыла.—Рәис кәгазьгә күз йөгертеп алды.—Беренче. Тышкы мөнәсәбәтләрдән. Ичкерия республикасындагы сәяси-хәрби хәл. Икенче. Татарстанга кайткан качак милләттәшләр һәм аларга ярдәм чаралары. Өченче. Латинга күчү буенча Бөтендөнья Татар Конгрессы карарын хуплыйбызмы, юкмы? Көн тәртибе буенча кемдә нинди тәкъдимнәр бар?.. Юкмы? Кем дә кем шушы мәсьәләләрне карарга ди, шулар...

—Нигә "Төрлеләр" юк? Иң кызыгы "Төрлеләр"!

—Безнең әбжитидә кайнар су юк!..

—Учында җылыт!..Кандала талатып ятма!.. Ха-ха-ха!..

—Бех-Коммнар бандасы КамАЗда тагын кыскартулар башлады, күбесе—татарлар!.. КамАЗ түгел бу, КоммАЗ!..

—Атнага бер җыелып та, җәелеп сөйләшмәгәч, нигә кирәк сезнең ТОЦыгыз?!

—Кайт та, хатының белән җәелеп сөйләш!..

—Кайсы хатыны белән? Аныкылар дүртәү...

—Петр Первыйны татар дошманы итеп игълан итик! Главный чукындыручы!

—Илле алтынчы кумплекстә татар детсадын ачтырмыйлар... "Йолдыз" мәдрәсәсен налог белән буып, яптыралар... ФСБ Габделнур хәзрәткә эшләргә бирми!..

—Казанны яклаганда һәлак булган корбаннар хакына Казанга җәяүле поход оештырыйк!

—Транспортта тукталышларны һаман татарча игълан итмиләр!..

Рәис тәкъдимнәр ташкынын көч-хәл белән туктатты.

—Иптәш кешеләр, үткән җыенда без өчтән артык мәсьәләне күтәрмәскә дип килешкән идек түгелме? Әгәр без хәзер "Төрлеләр"не дә чыгарсак, сазлыкка батабыз.. Зал ике сәгатькә генә бирелгән, онытмагыз. Килештекме?

—Килешмәдек!.

—Минем урынга утырып алгач, килешмәссез.—Салихов чыбыркысын көтү өстендә шартлаткан көтүче сыман кырт кисте.—Юк, дидем. Беренче сүз Рәсәйнең Ичкерия республикасындагы хәрби җинаятьләрен Халыкара Гаага хөкеменә әзерләү буенча ТИҮ комиссиясе рәисе, "Азат Чулман" газетасы мөхәррире Йосыф кардәшебез Сүнчәләйгә бирелә!..

—Туктагыз, тәкъдимем бар!..

Иркен агадан ерак түгел генә утырган, акбурга буялгандай ап-ак йөзле, тузынган чәчле хатын урыныннан сикереп торды һәм аңа күрсәтеп сөйли башлады:

—Безнең арада сирәк кунак—Америкадан кайткан татар Иркен ага!.. Алкышлыйк!..

Залны кул чабулар басты:

—Фамилиясе Сәлахов! Менә утыра ул!..—Хатынкай бу юлы аңа төртеп үк күрсәтте, аннан, уңга карап, кемнендер карашы белән кинәшеп алгандай итеп, урысчага күчте.—...президиумга просят!.

—Америкадан?!.. Сор-рый-быз!.. Сор-рый-быз!..

Дулкынлануыннан шыбыр тиргә баткан Иркен ага, балтасы суга төшкән кешедәй, нишләргә дә белмичә, урыныннан күтәрелеп, залга баш иде. Янә шаулатып кул чаптылар. Көтелмәгән алкыштан Иркен аганың башы чатный башлады—каян, кемнәр, ничек белеп алганнар аның Чаллыда һәм мотлак халык җыенында икәнлеген?! Бу хакта Лотфрахман, Стомат Сибгатуллович, кунакханә администрациясеннән һәм теге төнгә каршы шылтыратучы тәтәй хатыннан башка беркем дә белми бит!..

Ул нишләргә белмичә кардәшенә караш ташлады.

—Лотфрахман, алып менегез кунакны бирегә,—диде рәис тыныч кына.—Без ишетмәгән дә идек... Рәхим итегез, Иркен ага. Америкадан кайткан ватандашыбызны сәхнәдән каршылыйк!..—Рәис кул чаба башлау белән, зал янадан алкышларга чумды.

—Лотфрахманны предидиумга кирәкми, ул—болгарист, татарны яратмый!—дип аваз салды кемдер .—Шуңа да аны Тел үстерү фондында дабидующий итеп тоталар!..

—Болгаристларның атасы, диген!.. Телне үстермиләр, үтерәләр!..

—Менегез!..—Стомат Сибгатуллович аларга кул болгый иде.—Җыен сорый!..

Иртәнге очрашуны исәпкә алмаганда, бөтенләй таныш булмаган хатын башлаган бу акция Иркен ага өчен көтелмәгән нәрсә иде, ул, күзләрен чылт-чылт йомгалап, теләр-теләмәс кенә урыныннан күтәрелде һәм халык ихтыярына каршы киләлмичә, урыныннан чыга башлады.

—Әй, зимагур, кайт иленә, илдә иген игәрсең!..

Иркен-ага, артыш таягы белән паркет идәнне тукылдатып, залны яктыртып, җай гына сәхнәгә артылды, халыкка таба борылып, башын иде, җыендагы халык исә, очынып, сәхнәдә фил күргәндәй онытылып, янә дә кул чапты, талпынды, зурлау авазларына күмелде, мөһаҗир исә, кешеләрне болай урынсыз, мәгънәсез вә, аңа калса, урынсыз борчыганы, вакытларын биләп, бер мантыйксыз үзенә игътибар иттергәне өчен оялып, кызарынды-бүртенде, аннан, тәмам югалып калып, ике-өч адым атлагандай итте дә, тагын башын иде—зал янә дә җилкенебрәк алкышларга чумды.

Иркен ага мөнбәргә якын да бармады, артыннан Лотфрахманны да ияртеп, озын өстәл артындагы буш урындыкларның берсе янына үтте дә, кулын күкрәгенә куеп, залга янадан баш иде.

—Рәхим итегез! Халык сорый!...—Рәис кулы белән мөнбәргә ишарәләде.

—Кирәк имәс!..—Уңайсызлануыннан тавышы калтыранган Иркен ага куллары белән залга кат-кат ишәрә ясады.—Җыенны дәвам кылың!..

Кире залга төшәргә итте, бирмәделәр. Ул, аптырап, таягын урындык артына элде һәм чарасыздан утырды.

—Тынычландык, җәмагать! Онытып торабыз икән,—дип төзәтте үзен рәистәш.—Гадәттәгечә, җыенбызга фатыйха өчен сүз "Йолдыз" мәдрәсәсе

ректоры Габделнур хәзрәт Айгушевка бирелә...

Татарстан туграсының тушәмнән, нәкъ баш очындагы уттан төшкән яктысыннан да кызарыбрак янып, алгы уң аягы белән бар дөньяны сыйпарга маташкан кызыл барсы сыны төшкән мөнбәр артына дин әһелләренә хас тыйнаклык белән һавага сенешеп, тоташтан соргылт киемле инсан күтәрелде.Ул чак-чак ишетелерлек аһән белән аятьләр укып, дога кылды да, зәгыйфь аһән белән вәгазен дә сөйләп китте. Залны сыйпап, юатып аккан сүзләр агымында сүз "иманга килүнең шартлары" турында барды. Хәзрәтнең бу кадәр хәлсез тавыш белән сөйләгәненә ачуы да килә һәм... ул ана бередәге йөгәнсез масса алдында шундый сабыр, мәгънәле вәгазе өчен рәхмәтле дә иде...

Залдан "атомдагы электрон" тизлеге белән искиткеч җыйнак, усак яфрагы кебек җинел гәүдәле, башына кара түбәтәй, өстенә кара өчлек-костюм кигән, мөселманча калдырылган сирәк сакал-мыегы нииндидер ямь, өстәмә затлылык биреп торган зат күтәрелде. Йосыф Сүнчәләй дигәннәре шушы икән.

—Җәмәгать! Сез беләсез, Чечен җөмһүрияте пәйда булу белән, аның мөстәкыйльлеген яклау татар милли хәрәкәте өчен Татарстан мөстәкыйльлеген яклауга тиң итеп кабул ителде. Чөнки безнең тарихлар уртак. Рәсәй тарихында бары тик шушы ике милләт кенә биш йөз еллык геноцид чорында империя белән армый-талмый көрәшүен дәвам итте. Килеп туган яна вәзгыятьтә урыс империясенең үзе басып алган кол милләтләрен деколонизацияләү юлында бары тик безнең республикалар гына халыкара аренага чыга һәм көрәшә алачак иде... Без Чечен республикасын беренче булып таныдык!.. Без бу хакта Рәсәйдә беренче булып генерал Дудаев исеменә телеграмма суктык, махсус делегация дә җибәрдек!.. Азатлыкны буу өчен Рәсәй Чечнягә гаскәр кертә башлагач, кемнәр мона каршы ачлык вахтасына басты? Безнең халык! Безнең язучыбыз Илдар Хафиз!.. Ниһаять, Рәсәй чеченнәргә каршы сугыш ачкач, Чаллы вокзалыннан солдатлар төяп Ичкериягә юнәлгән хәрби эшелон юлына кемнәр аркылы ятты һәм татар улларын кан-коешка җибәрмәде? Без!.. Шул ук язучыларыбыз Фәүзия Бәйрәмова, Илдар Хафиз житәкчелегендәге бер төркем милләтчеләребез... Без татар халкының намусын саклап калдык!.. Алар арасында сез үзегез идегез!..

—Дөрес!.. Үзебез булдык!.. Булачакбыз!..

—Ичкериядә ике йөз илле меңгә якын кеше үтерелде, яраланды, өч йөз мең качак Ингушетиягә куып чыгарылды!..—дип кычкырдылар астан.—Бу Берләшкән Милләтләр Оешмасы мәгълүматлары!..

—Рәсәй Ичкериядә үз халкына каршы унар тонналы тирәнлек бомбалары, химик корал кулланды! Кичә моны "Голос Америки" хәбәр итте... Чечняга интервенция башлангач, бертуган Шиһаповлар Чаллы ижтимагый үзәге, Чаллы хакимияте белән берлектә, халыктан жыеп, ике тапкыр егерме бишәр КамАЗда чечен туганнарыбызга азык-төлек һәм кием-салым илтте. Алар арасында сез үзегез идегез!..

—Дөрес!.. Үзебез идек!..

—Кем дәүләтчелегебезне тануларын таләп итеп, урыс, инглиз, француз телләрендә Берләшкән Милләтләр Оешмасында пресс-релиз таратты? Кем урыс-чечен фронтына үтеп, бу гаделсез сугыш турында тетрәткеч китаплар язды һәм Ичкерия Президенты Масхадовның рәхмәт кәгазенә лаек булды? Шулай ук безнең язучыларыбыз!.. Дудаевның вәхшиләрчә үтерелүенә ел да ике ай вакыт үтте,—дип дәвам итте Сүнчәләй.—Дөньякүләм мәгълүмат чараларын анализлаганда, нәрсә ачыклана соң? Чечен дәүләтенең законлы Президентын кем юк итте? Ельцин администрациясе!.. Мона хәтта урыс

хәрби машинасының гына көче житми иде. Газеталар язуынча, мөселман терроризмына каршы көрәш байрагы астында Рәсәй ФСБсы бу операцияне Американың Өзәк разведкасы, Израильнең "Моссад" разведкасы белән берлектә үткәргән. Гохи-Чу урманында Дудаевны юк итәчәк ракетаны урысларга Америка биргән булып чыкты, җәмәгать!.. Дудаев башына шул ракетаны төшерү белән кем житәкчелек иткән дисез? ГРУ начальнигы генерал-полковник Корабельников үзе! Күптән түгел, Кремль бәдрәфенә качып, Ельцин аңа Рәсәй герое медален тапшырды! Без бу жинаятьләрнең барысын да Ельцинның Аллаһу Тәгалә каршындагы гамәл дәфтәренә теркәп барабыз. Берсе генә дә онытылмаячак!...

—Ләгънәт, ләгънәт!—дип оран салды зал.—Мәскәү чеченнәргә яңа сугыш ачса, барлык Татарстан белән ярдәмгә барачакбыз!..

—Нинди акыллы бу Сүнчәләй дигән затыңыз. Чын мөхәррир!..

—Тумышы белән Әстерханнан. Бертуган апасы—Чаллыда мәктәп директоры. Жизнәсе—КамАЗ директоры Бехнең икътисади мәсьәләләр буенча киңәшчесе. Укымышлы болгари затлар...

—Моннан бер ел элек урыслар хурлыклы Хасавьюрт килешүенә кул куярга мәжбүр булганнан соң, Мәскәү Ичкериягә басымын тагын да көчәйтте,—дип дәвам итте нотыкчы.—Яңа сугыш чыгару өчен, көн саен провокацияләр ясап торалар. Канатларында номерлары булмаган самолетлар белән бомбага тоту дисеңме, икътисади, сәяси блокада дисеңме, чит ил кешеләрен урлап, чеченнәргә япсару дисеңме... Каспий нефтен Новороссийскийга Чечня аша куу өчен Масхадов урыслардан тоннасына 2,2 доллар таләп итсә, Ельцин, Чупа-Чупайслар чеченнәргә нибары 43 цент кына бирә!..

—Черки-кигәвен кебек, урыс безнең канны да бушка суыра!

—Масхадовка басым ясап, номерсыз урыс самолетлары Чечняны кичә тагын бомбага тотты... Ягулык министры Немцов Чечняны читләтеп яңа нефть үткәргеч төзеп, чеченнәрне ач калдыру белән куркыта...

—Позор! Бәддога! Чеченнәргә үзебез азык илтик!..

—Яклау телеграммасы жибәрик!..

—6 сентябрьдә Аллаһы Тәгаләнең изге кинаясе белән ике бәйрәм: черек Мәскәүнең 850 еллыгы, яшь Чечен жөмһүриятенең 8 еллыгы бергә туры килә. Масхадов бу олуг бәйрәмгә дөньяның барлык парламентларына, шул исәптән Татарстан Дәүсоветына да чакыру жибәргән, әмма Мәскәү илчелекләре беркемгә бернинди виза бирмичә, Чечняны бомбага тота. Литва делегациясе Чечняны мөстәкыйль дәүләт итеп таныр өчен Жәүһәр-калага җыенгач, Мәскәү һава юлларын япты...

—Мескеннәр сез!.. Болай булмый!...

Залны ярып, әче тавыш яңгырады. Кемдер сызгырып та жибәрде.

Кечкенә буйлы, жир мае белән майлаган сыман кара чәчле, күзләреннән шундый ук шомырт каралары тәгәрәп торган бер нәфис жегет туп тизлеге белән залдан тәгәрәп үк сәхнәгә менде һәм Сүнчәләйне этәреп үк диярлек жибәреп, сөйли дә башлады:

—Күпме мөмкин чүбек чәйнәргә?! Мескенләнергә?! Кем без—татармы, әллә үзен сатармы?! Урыс фәлән итә, төгән итә, имеш!.. Телеграмма жибәрик, имеш!...Шп-шп... Сөртеп ыргыталар анда синең телеграммаңны!.. Шп-шп...—Бу инсанның һәр жөмләсеннән соң, ашыгып сөйләгәнгә булса кирәк, әллә борын астында, әллә теле очында нindидер шыпылдау авазлары ярала иде.—Бездән гамәл сорыйлар, ә без һаман гамәл кылмыйбыз, пнимаешь, билеңдә сары каеш!.. Кичә генә мин Чечняның вице-премьеры Шамил Басаев белән телефоннан сөйләштем...Шп-шп...

—Шыттырма!—дип кычкырды залдан кемдер.

—Шыттырмыйм!.. Син ул анда куркышыңнан баздагы сукыр бәрәңге

булып шыткансын, пн-нимаешь, билендә сары каеш... Чеченнәргә сугышчан солидарность объявлять итеп, безгә хәзер Грозныйга... шп-шп... яна гуманитар колонна... дәбрәвәлисләр җибәрергә, кирәк!

—Бертуган Шиһаповларнын берсе,—диде Лотфрахман-кардәш.—Кайнар егетләр... Стомат Сибгатуллович әйткән хәлиуллинчы анархо-синдикалистлар шушылар була инде. Ләкин, ни кызгыныч... алар болгар түгел, татар!.. Бик зур патриот, эшлекле егетләр. Болгарда шундый бер биш кенә синдикалист булса да, без бу татар сарыкларыннан әллә кайчан болгари баһадурлар ясаган булыр идек...

—Алар Чаллыныкымы?

—Яшәүләре—Чаллы. Тумышлары—Азнакай. Милли хәрәкәт лидерларынын күбесе читтән килгән татарлар. БТИҮнен беренче Президенты Марат Мөлеков Себердән. Гаяз Салихов Самардан...

—Татарстаннын үзеннән милләт каһарманнары юкмыни?

—Очраштыра. Хәлиуллин, мәсәлән, Чаллыдан. Әмма ин зур патриотларыбыз читтә кыйналганнардан чыга,—диде Лотфрахман.—Җирле татар күбрәк популист—мал өчен дә, дан өчен. Чит татарлар—кан өчен дә җан өчен...

—Новый пачулкасындагы хәрби частьне басып алып...—диде Шиһапов.—Мәскәүгә каршы безнен үзебезнен эчке фрунтны ач-чарга кирәк!..

—Биш йөз елдан безгә бердәнбер котылыр шаныс килде... Карагыз аны, бүтәнчә безгә шаныс булмаячак...—дип кычкырыштылар Шиһапов тарафдарлары.

—Иҗтимагый Үзәк җыены, энекәшләр, провокацион белдерүләр ясау урыны да... һәм дә ки колхозчылар җыелышы да түгел... Рөхсәттән башка көн тәртибен бозган өчен сезләргә шелтә игълан итәм,—диде рәис тагын кырыс итеп.—Сонгы тапкыр!..Төшегез!.. Сүнчәләй, дәвам итегез!..

—Каян килгән интеллигентлар!..—Рәискә таба башын борган Шиһапов теләр-теләмәс кенә итеп залга төшә башлады.—Төшүен төшәрбез, тик болайга китсә, сез дә югарыга менә алмассыз... Болайга китсә, Татарстан суверенитеты—тү-тү!.. пн-нимаешь, билендә сары каеш!..

Иркен агага мөлековчылар белән хәлиуллинчылар арасындагы аерма анлашылгандай булды. Бу борынгы Афина, Римнардагы плебейлар белән патрицийлар, аксөякләр белән коллар арасындагы мәнгелек бәхәснен татарча чагылышыдыр. Әмма, ни кызык, бередә Мөлеков та, Хәлиуллин да үзләре юк иде.

—Килеп туган шартлардан чыгып, мин Ичкерия Президенты Масхадов исеменә менә шушындый эчтәлектәге телеграмма җибәрергә тәкъдим итәм...—Сүнчәләй беренче тапкыр язуына карап укыды.—"Хөрмәтле Президент Галиҗанәпләре! Чаллы шәһәренен бөтентатар халык җыены сезне һәм барлык чечен халкын атаклы Хасавьюрт килешүенен бер еллыгы, Ичкерия республикасынын мөстәкыйльлек яулап алуынын сигез еллыгы белән кайнар котлый, сезнен азатлык өчен көрәшегездә тулы теләктәшлек белдерә. Халык җыены рәисе Гаяз Салихов". Кабул итәбезме?

—Империягә каршы көрәштә татар егетләре сезләрне корал белән якларга да әзер, дип өстәгез!—дип шаулап кычкырыштылар астан.—Болай гына бармый... Төче камыр ашатмагыз!..

—Моны өстәсәк, текстны телеграф үткәрмәячәк, үткәрсә, прокуратура телеграфны да, безне дә хөкемгә тарттырачак!...—диде Салихов.—Әгәр кемнендер Ичкериягә барып тизрәк сугышасы килә икән, аучы мылтыгы булса, кулына алсын да, Казан-Грозный трассасыннан җәяү йөгерсен!..

Зал чайкалып көлеште. Рәис икенче мәсьәләгә күчте. Иркен ага яна нотыкчынын исем-фамилиясен абайламый калды. Мөнбәргә гүя ташбака

адымнары белән шуышып, өлкән яшьләрдәге кеше күтәрелде. Баш түбәсенә чәчкәле түбәтәй чәпәп алган, соргылт ут яктысында йөзе, мөселманча кырылган җирән сакал-мыеклы зат, үзен чакырып китертелгән кунак сыман, бик иркен, хәтта бераз гасаби тотты. Күкрәк кесәсендә шактый озак казынып, аннан күзлеген, кенәгәсен чыгарды, күзлеге өстеннән тагын да нәрсәдер кигезде, аннан бу күзлеген борын очына гына эләктереп алып, кенәгәсендә шулай ук озак кына актарынды да, сөйли башлады:

—Как ви знат, мин үзем молдаванский татарин. Вернулся сюда своим род, вчу нәселствы, как говорится, двадцать рот. Ми зараз двадцать кашик күтәргән. Двадцать кашик из шесть нация!.. Мой нәселствы даже румынский чигән есть с еврейчик вместе взят! Как тульке Тирасполь война пошел, вся гаварит начал—ах, как харруш, ах, как любим Татарстан!.. Вут и Чална пришли!..

—Урысча гына сөйлә, телне рәнҗетмә!..

—Спасибы ТОЦ, недостроенный фатыйр отвоевали в тридцатый комлекс, да и этот фатыйр жилищнә кәмисси мина дал, значит. Как вы знат, Татарстанда беженецләр вопросында эспициальни закон ниту, своим желанием возвращаться иткәннәр учетка алу невозможно...

—Телне җәфалама, алла бәндәсе!..

—Мин на родине татарча сюйляган!..—диде Җирән Мыек елар чиккә житеп.—Чалныда зигерме биш тысяч беженец, из них татар унтукуз тысяч. Квартира булмаган, работ юк, акча юк...

—Молдавиянең чегән табырында яшәп, безгә кайткан болгар бала бу,—диде Лотфрахман.—Чегән булса да, милли горурлыгы татарныкыннан күпкә югары...

—Разве мать так встречать свой татар-бала?! Бүгян Чалны вокзал двадцать семья необъятных уголок наша любимая... родина. Палатка булмаган, ни вода, ни тепло... А ведь мы, татар—бала, после развал Советский Союз, мужны бар дунҗадан акыллы татар профессор, академики собирал под убший крыша, расти как адин единый натция ... двадцать... тридцать... утуз миллион татар собрать одна куча!.. Эх, вы, йуклаган!..

“Татарчасын белми, бу—аңлашыла, менә урысчасының бөтенләй аңлашылмавы—хафа... Үзенә бер керәшен. Илсез булу—телсез булу икән,—дип нәтиҗә ясады Иркен ага. Шуннан үзенә-үзе үк каршы килеп уйланды.—Ничек... илсез? Алар бит бер илдә... туган совет илләрендә яшәделәр. Юк, алар түгел, Иркен ага үзе илсез. Сәер хәл: илсез Иркен—телле, илле Җирән Мыеклар—телсез... Сәбәп нәрсәдә? Әмриканең Фрэнсис Коллинз җитәкләгән “Адәмзат геномы” дигән гыйльми проекты күптән түгел адәмзатның нәсел кодының уртача сиксән мең геномнан торуын ачыклады. Бу геномнарның кайсында саклана икән адәмзатның телгә, илгә, дингә булган тугрылыгы? Төрле дин, төрле раса, төрле милләт балаларында гасырлар буе тупланган бу әхлакый, милли-тәрбияви мирас дөньяның яшерен генетиклары тарафыннан ниндидер агулы альбуминдә үстерелгән бәрәнге, кәбестәдә боздырылмыймы?”

Иркен ага дөпелдәгән тавыштан уянып киткәндәй булды. Берничә ханым сәхнәгә күтәрелеп килә икән. Әмма, сәхнә йөзлегенә җиткәндә генә, араларыннан берсе, бер бөртек чәчен дә тышта калдырмыйча, ак яулык бөркәнгәне, арттагыларны куллары белән ышыклап, туктатты да, үксеп елап җибәрде:

—Өзбәкстаннан кайтканыек... Азнакайга... Йорт сатып алдык... Яшәргә бирмәделәр! Йортыбызга ут төрттеләр!.. Динчеләр, ваххабитлар, сыпырыгыз моннан, дип кудылар! Өз татарларыбыз!..

—Читләрдә төртенеп йөрмәскә иде!—диделәр залдан.—Артыгызга ут капкач кына!..

—Мин сигез бала анасы!..

—Алардан нинди рәхәт күрдең?—дип сорадылар астан.

—Нинди рәхәт, дисеңме?—Хатын залга укталды.—Өзең аңламагач, оят булса да әйтим... Мин... сигез тапкыр бала табу газабын вә ләззәтен кичердем!..

Зал онытылып кул чапты.

—Маладис, җиңгәчи!..

—Татарстанны алай ук хурлама әле! Хәзер һәр авылда "Үзбәк очы" бар!..

—Хурламыйм!.. Без нәкъ шул "Өзбәк очы" тәрикәтеннән... Фирганәдән кайтканыек... Эш вә йорт-җир бирәбез, дип алдагач, Актанышның Түки авылына кайтып егылганыек...—дип дәвам итте икенче мөһаҗирә.—Мондый имансызлыкны күргәнебез юк иде, илаһым!.. Алар татар түгел... Татар мондый булалмый... Мәҗүсидән үтмәгән, керәшенгә җитмәгән фасон бит болар, илаһым!..—Тамагына гарьлек төере тыгылып, ул озак эндәшәлми торды.—Фураж урлап, сәүдә кылалар да, авыллары белән эчәләр, талаша-сугышалар, эшләр адәмләре дә калмаган... Бер елга якын мал арасында яткырып, мал караттылар да... биш йөз сом хезмәт хакыбызны талап эчтеләр!..

—Без ни... эчмәгәч, тартмагач, урлашмагач... мөселман да булгач... яратмадылар!..—дип өстәде өченчеләре.—Утызынчы елларда качып киттегезме, шунда михнәтләнегез, диләр!.. "Сез—ваххабитлар, мөселман-террористлар, таегыз моннан",—дип сәнәк күтәрделәр!.. Кая барыйк?

—Безгә на историческую родину кайткан возвращенец татарларны защищающий ТОЦ төзергә кирәк!—Тәбәнәк буйлы, гәүдәсе ингә дә буйга да бертигез юанлыкта булганы авырлык белән өстерәлеп, сәхнәгә күтәрелде һәм йөзе белән халыкка борылды.—Как это так? Без уйлаган кайтырга, булып чыктык каторгада катарга, что ли? Без, Донбасстан Алькеевский район кайткан земляки, яклау сорап килдек. Обрат китегез, вы "килмешяк" говорят. Мы не килмешяк, нам на родине закрепиться киряк!.. Скажите, тут в зале берәр зур начальник булган?

Сәхнәгә кыска буйлы, сәгать сиртмәсе кебек сыгылмалы бәндә сикереп менде, башындагы беретын сыдырып салып, Ленин рәвешенә керде дә, сүзгә кереште:

—Шиһапов дөрес әйтә! Без болай тешсез булсак, ТОЦның бернинди абруе калмаячак!.. Әйдәгез, кем тели, хәзер үк утызынчы комплекстагы яңа йортларны басып алабыз! Нәрсә җебеп утырабыз!..

—Алабыз!—Зал тәмам тугарылды.—Туганнарыбызны кыерсыттырмаячакбыз!.. Әйдәгез, утызынчы комплекска!... Культпоход!.. Трат-та-та, трат-та-та!..

Шиһапов, "культпоход"ны житәкләү ниятендә булса кирәк, ялт итеп урыныннан күтәрелде. Ул президиум каршына килеп басуга зал умарта кычедәй хәрәкәткә килде, кешеләр этешә-төртешә рәт араларыннан чыга, шау-гөр килеп, ишек катында туплана башладылар.

Иркен аганың күз алдына чынлап та Шәркый Төркестандагы хунвейбин җыеннары килеп куйды. Мизгел кискен иде. Халәт менә хәзер кулдан ычкыначак. Җыенның рәисе җаваплы ялвару белән хакимиятнең милләтләр һәм дини мөнәсәбәтләр бүлеге мөдире Стомат Сибгатулловичка иңәлде. Анысы, үз чиратында, "Җыенның рәисе син бит, үзең хәл ит!",—дигәндәй, карашын читкә күчерде.

Урыннарыннан күтәрелгән халык, төзелеп бетмәгән йортларны басып алу ниятеннән ишекләргә ябырылды гына дигәндә, ниһаять, Стомат Сибгатулловичның диктор Левитанга охшаган ихтыяри аһәңе яңгырады:

—Сүз Казаннан килгән вәкил, Үзәк ТИҮнең качаклар комиссиясе рәисе Юныс әфәнде Заһретдиновка бирелә!..

Һәм ул Заһретдиновның касыгына төртте. Моны көтмәгән Юныс әфәнде, уянып киткәндәй, дерт итте, үзен кулга алып, ашыкмыйча урыныннан күтәрелде, мөнбәргә килде һәм вәкарь белән генә әйтеп салды:

—Утырыштык, туганнар!.. Аяктагы кешегә кинәш керми. Совет Армиясе шулай уйлый...

Үзәктән килгән вәкилдән гадәттән тыш хәбәр көткән гавам ишек катында бераз таптанды да, йортларны басып алуны үз өстенә алучы табылмагач, аптырашып һәм һау-килеп урыннарына таралышты.

Шахмат тактасында дөрес йөреш ясаган Стомат Сибгатуллович үзеннән канәгать иде. Шул ук халыкны Иркен ага да карашыннан үткәзде, ләкин Стомат Сибгатуллович кичергән тойгыны ул аңлаган кебек аңламаганлыгын аңлады. Ул шушы ук мизгелдә каяндыр түбәннән, ерактан килгән нечкә хис белән бередәге җыенның кавем, халык, милләт, мөселман өммәте булудан туктап, чигенеп вә тагын чигенеп, стихияле хис белән җигелә һәм тугарыла торган эш аты—кара гавамга әверелеп беткәнлегенә тагын бер кат инанды. Таң чыгында чыланган башак сыман, керфекләре чыланды. Ул гарьләнде. Мөһаҗир үзе кичергән бу халәтнең тәсдыйкын, әгәр шулай әйтергә яраса, формуласын, һаман таба алмый җәфалана иде.

—СССР таркалып, союздаш республикалар мөстәкыйльлек алганнан соң, Татарстанга "кайнар нокта"лардан йөз меңгә якын кеше кайтты. Монда дөрес әйттеләр. Безнең качакларыбызны яклый торган законыбыз юк. Аны безгә, татарларның җыелып, көчәеп китүенән курыккан Рәсәй кабул иттерми. Шуның аркасында милләтәшләребезнең кайтып, туган Ватанында тамырланып китүе бик авыр бара... Әйе, без форсаттан файдаланып, Татарстанга барлык татарны... татарның Җир Шарындагы бар каймагын... элитасын дим микән, җыя, туплый алган булыр идек... Кайткан милләтәшләребезнең кире киткән очраклары да... оят булса да әйтим, кардәшләребезне талаган, йорт-җирләрен яндырган, эшләреннән куган очраклар да җитәрлек...—Алтмыш яшьләр чамасындагы, ачык йөзле, ярыйсы гына таза гәүдәле, күренүенчә, элеккеге җаваплы хезмәтендә кеше белән ничек сөйләшергә өйрәнеп беткән Заһретдинов мине ничек тыңлыйлар икән дип белергә теләгәндәй, туктап, күзләренә ишелеп төшә торган аксыл чәчләр учмасын бармаклары белән тарап, аларны инде ничәнче тапкыр артка аткарды да, сүзен дәвам итте.—Атом-төш коралы буенча академиклардан алып, баш мие нейроннарын плазма белән ябештерүгә кадәр диссертация яклаган академикларыбыз бар безнең, дөнья буйлап җыйнаган булсак!.. Татар флотын хәтта коры җирдә туплар өчен адмиралларыбыз, татар армияләрен җитәкләр өчен генерал-гофмаршалларыбыз җитәрлек... "Иске торак" программасы нигезендә без җөмһүриятебезгә бөтенләйгә кайтып урнашырга теләк белдергән атаклы галимнәр, бөек авторитетлар өчен Казанда махсус Академкалачык төзүне үтенеп, Татарстан җитәкчелегенә тәкъдим белән кергән идек. Моннан тыш, төрле регионнардан кайткан милләттәшләребез өчен һәр районда, һәр шәһәрдә махсус авыллар, бистәләр төзүне күтәрдек. Ләкин әмма, әмма... Тыңламыйлар!...

Шул чак залдан берәү, кәҗә тавышлары чыгарып, сорады:

—Әбзи, шомартмыйча гына әйт, фатыйрларны кайчан басып алабыз?

Халык тагын җанланып куйды. Кемнәрдер хихылдап та алды.

—Хәзер фатыйрларны басып алуга карата...—диде дә, Казан кунагы уйга калды.

—Отставкадагы полковник, ТИҮ оешкан чорларда безгә Германиядән кайтып төште,—диде Заһретдинов турында Лотфрахман.—Хәрби геодезия

буенча атаклы белгеч. Милләткә нык бирелгән болгар. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә—республикада татарларның нисбәте кырык сигез процентган илле өч процентка житкерелде. Әмма качакларны кабул итү югарыдан туктатылды. Сез аның теленә игътибар итегез, теленә... Сөйләменнән хата таба алырсызмы? Телен саклаган бит, ә? Армиядә бит, ә?

—Төзелеп яткан йортларны басып алу юлы белән милләт кадәр милләтне фатирлы итү чоры үтте, кардәшләр!—дип дәвам итте Заһретдинов.—Теге заманда фатыйр басып алуда катнашкан егетләребезне Президент ярдәме белән хөкемнән саклап кала алдык алуын. Ә хәзер... белмим, белмим. Минем һәркемне фатирлы итәсем килә, ләкин мондый юл белән түгел. Шиһапов кебек кайнар канлы милләтчеләребезне мин мондый экстремаль чаралардан тукталып торырга чакырыр идем. Минем тәкъдимем мондый. Без бу мәсьәлә буенча комиссия төзик һәм иртәгә Чаллы шәһәр хакименә керик, аннан шушы ук комиссияне житәкләп, мин Казанга, Президент аппаратына үзем барам...

—Безнең зыялылар шулай зыянлыйлар инде!

—Шушылар да булды интеллигент!.. Булмый болар белән!

—Әйдәгез, утызынчы күмплекскә!..—диде теге кәжә тавыш.

Президиумда яклаучысы булмаган залның бер өлеше болганып маташса да, икенче өлеше Заһретдинов фикере белән килеште һәм инде ничәнче тапкыр комиссия төзеп тынычланды.

—Өченче мәсьәлә буенча сүзне кыска тотачакбыз, жәмәгать. Ул да булса, латинга күчү.—Салихов сәгатенә карады.—Вакыт кыса. Бу хакта информацияне, сезгә үзем житкерергә булдым. Моннан берничә көн элек кенә үз эшен тәмамлаган Икенче Конгресс, билгеле булуынча, татар дөньясын яңа имляга—латинга күчерә башлау буенча низамнамә кабул итте. Бу хакта сүз ун ел барса да, галим-голәмәбез арасында... әйтик, ягъни мәсәлән... "ж" хәрефенә койрыкны кайсы тирәгәрәк куярга дигән сымаграк буш бәхәсләр куерып китү аркасында, сүздән эшкә күчә алмый торган идек. Мәгълүм булуынча, латин имлясын егерме тугызынчы елда Сталин милләтебездән мең еллык гарәп имлясын тартып алу һәм тиз арада ана славян кириллицасы кертү өчен вакытлы чара итеп кенә кулланган иде. Нәкъ ун елдан соң бу шулай килеп чыкты да. Әмма милләтебез шушы кыска гына вакыт эчендә дә латин имлясының телебезгә бик ятышлы булуын чамалап өлгергән иде... Сезгә шулай ук мәгълүмдер: мондый мәтәлешләрнең бөек татар-мөселман өммәтен гарәп имлясыннан куып чыгару һәм урыс-насрәни булмаган барча милләтләрнең имляларын кириллицага куып кертү өчен генә эшләнгәнлеген алдан аңлап өлгергән сиксән ике зыялыбыз бу хакта Сталин бабайга хат язып, шуның өчен лагерьларга ябылып, башлары белән исәпләштеләр... Гарәптән латинга, латиннан кириллицага күчү мәсьәләсенең сәясәткә әйләндерелүе аркасында меңләгән татар уллары һәм кызларының башлары ГУЛАГ түмәреннән очты. Бу түмәр хәтта ата сталинистка әйләнгән мәшһүр язучыбыз Галимжан Ибраһимовны да кызганмады... Шамил Усманов, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Мәхмүт Галәү кебек дисталәгән титаннарыбызның башлары да тәгәрәп төште бу түмәрдән... Бөтентатар Ижтимагый Үзәге урыннардагы халык жыеннарыннан фикер көтә: латинга күчүне хуплыйбызмы, юкмы? Кем ничек уйлый?

—Хуплыйбыз! Хуплыйбыз!...

—Алай гына түгел, жәмәгать. Исем-фамилияләрегезне әйтеп сөйләгез!.. Протокол алып барыла.

—Алай икән,—диде тагын теге чыелдык тавыш.—Тагын пртакул!.. Син тагын да безнең башларны кистерәсең килә икән!..

Халык тирә-ягына карашып алды. Әмма күпме генә карашмасыннар,

чыелдыкны таба алмыйлар—гүя бу тавыш каяндыр идән астыннан килә иде.

—Уенга бормагыз. Фикерләрне сәхнәгә күтәрелеп тә, урыннардан да әйтергә мөмкин. Рәхим итегез!..

—Мин әйтәм!..

Иң арттагы рәтләрнең берсеннән ифрат та таза гәүдәле кеше күтәрелде.

Сәхнәдән ерак булганлыктан, йөзе ачык күренми иде.

—Рәхим итегез!..

—Минемчә, латин кирәк инде ул. Бик кирәк. Ул ведь безне артка өстерәгән гарәп түгел, так ведь? Латин булса, Всемирный банктан Татарстанга да бераз тамар иде, так ведь? Иначе бер дә таммый бит. Әнә, Төркия латин белән җилдергәч, елына ун процент национальный прирост бирә, так ведь. Безнең базарда да ни өчен барысы төрек чүпрәге?

— Кытай чүпрәге!—диделәр залдан. Нотыкчы моны ишетмәде.

—Чөнки төрекләр чүпрәкне латинча эшли, так ведь. Латинга китсәк, дөнья безнең белән дә исәпләшә башлый. Хәзер бөтен Галәм кәмпутергә күчә, интернет-чинтернет, туда-сюда. Гарәпнең буш соскыдай хәрефләре белән кая барасың да, урысның җан тырный торган кырлы-мырлы мефодийләре белән кая барасын? Латин хәрефенең анын соскысы зур. Анда международпризнание. Әмма безнекеләр ун ел халык башын катырып, латинга күчәргә ашыкмыйлар. Чөнки теләмиләр, так ведь? Теләрләр иде, мәсьәләне Мәскәү алдында үз исемнәреннән күтәрергә куркалар, так ведь? Башта халыкны ике-өч чүплек башы әкәдимигенең буш бәхәсләреннән арыттылар. Бу пар чыгару өчен кирәк иде, так ведь? Хәзер халык чын-чынлап латинны таләп итә башлагач, тегеләрнең артларына су китте—имеш, халык фикере кирәк! Конгресстан раслатылган дуәкәмәт кирәк, так ведь? Халык фикере кирәкми аларга—халык сорый дигән булып, шул ук Мәскәү алдында инде халыкның да фикерен корбан итәргә кирәк, так ведь? Булмаячак ул, күрегез дә торыгыз!.. Мин—соңгы чалбарларымны салып биреп "за", тик бирмәячәкләр!.. Минем—бетте!..

—Әйбәт, абзый кеше. Яхшы сукаладың. Исем-фамилияңне генә әйтсәң...

—Хаим Солтангалиевич Муллагалиев булам. Туганмын Базарлы Матак, кайтканмын Свердлау.

—Нинди Хаим? Нинди Хаин?—Зал көлешә-көлешә шаулашты.—Каюмдыр син!.. Хәкимдер!..

—Каюм да, Хәким дә, Хаин да түгел, Хаим мин!.. Хаим!..—Паспортта ничек язылган, пртакулыгызга шулай кертегез!..

—Мин притоф! Мин категорически притоф!—Сәхнәгә "против" урынына "притоф"лар белән самавыр сыман кайный-кайный парланып-буланган кеше сикереп менде. Анын шома шәрә башы түгәрәк ай кебек яктырган, бу шәрә айны уратып алган чәчләрнең бөдрәләре гүя тере кебек бөтерелеп калтырана иде.—Латин безгә кирәкми!.. Аны безнең җитәкчеләр колагына масоннар пышылдады. Минем абзыкайларым латинда надан калды!.. Ни гарәпчә, ни кирилда, ни латинча укый-яза белмиләр!.. Аннан... икенче ягы да бар бит әле, җәмәгать... Ярый, күчә башладык, ди... Яхшы. Күпме татар бар дибез җир шарында? Жиде миллион? Шулай гынамы? Әйдә, ун, әйдә, унбиш миллион булсын, ди. Шуларның хет ун проценты кирилда булса да татарча укый-яза белсен, ди. Миллион-миллион ярым халык була, әеме? Әгәр без хәзер латинга күчсәк, безнең якындагы ун ел латин телендә басылачак китапларыбыз, гәзит-журналларыбызны шушы миллион ярым татар да укый алмаячак бит? Бу бит хәзергә телле татарны телсез итү,

рухи кыру булачак!.. Яһүдиләрдән үрнәк алырга кирәк, алар иудиш белән иувриттә сөйләшсә дә, бер дә алфавитларын үзгәртми! Бар, үзгәртер сиңа яһүд!.. Кытай үзгәртәме, яппун үзгәртәме? Аннан, шунысын да әйтим, мең ел буе гарәпчә, латинча, кирилда басылган иске мирасны без кайчан латинга күчереп өлгерербез? Ун ел эчендә нигә без аларны бастыра да башламадык? Миннән алдагы Хаим иптәш дөрес әйтте—курыктык, җәмәгать!..

Кайнап суынган кардәшебез, чәч бөдрәләрен җилфердәтеп, төшеп тә китте.

—Исемегез? Фамилиягез?—дип кычкырды аның артыннан Салихов.

—Нигә сиңа безнең исем-фамилияләр? Тозлыйсың мәллә?—Залның караңгы чоңгылыннан аның тавышы гына ишетелде.—Бывший социалистик ярыш алдынгысы Фрезер Зөлкарнәев дип яз!..

—Миңа... сүз!..—Залдан тагын да бөтерчек кебек кеше мөнбәргә күтәрелде һәм ярып та салды.—Татарстанда аракы сатуны тыярга кирәк!

—Тыярга! Чучка үрчетүне тыярга!—Зал гөж килде.—Татарстан сарык ите генә ашарга тиеш!

—Татар сарык, ат үрчетүгә күчәргә тиеш!

—Булма арык, аша сарык!—дип куәтләде зал.

—Сарыкка бүре ияләшә...

—Иптәшләр, алай башбаштак кыланмыйк инде, бу бит бригад җыелышы түгел. Залда педагогия, укытучыларның белемен камилләштерү институтыннан галимнәр юкмы?—дип сорады рәис.—Компетенцияле чыгышлар да кирәк!..

—Компетенция белән әллә кая барып булмый. Укытучыларны наданлаштыру институты бит ул...—диде залдан шул ук чыелдык тавыш.—Алар сарыкны чучкадан аермый!.. Шуңа шашлыклары да чучканыкы, тәүбә-тәүбә!..

Зал шартларга җитеп көлде. Бу иҗтимагый Үзәк җыены дигәннәре әкәмәт тә кызык, әкәмәт акыллы халык парламенты икән.

—Туктагыз әле, "Әти үлеп ята—көлеп эчем ката", дигәндәй, көләсез.. Миңа сүз бирегез...

—Әйдә, Гаскәр әфәнде, рәхим ит!..

Алдагы рәтләрнең берсеннән уртача гәүдәле кеше ут яктысына чыкты һәм күзләрен идәннән алмыйча мөнбәргә күтәрелә башлады. Коңгырт чәчләре кыска итеп кыркылып, керпе кебек тырпайган кин, текә маңгайлы, семит халыкларына хас булган бөркет борынлы инсан, ашыкмыйча, вак-вак адымнар белән атлап, үзенә хас илтифат һәм нәзакатьлелек белән сәхнәгә күтәрелде, мөнбәрнең артына ук керер-кермәс кенә туктап, милләттәшләренә авыр вә сынаулы караш ташлады.

—Барыгызны да игътибар белән тыңладым. Күп фикерләр белән килешәм. Тик бер нәрсә—татар чокыр аша сикереп чыгарга җыенганда гына аны шушы сикерешне ясамаска кодалау белән генә килешмим!—диде ул чак ишетелерлек сабыр аһәң белән.—Баланың табанына шырпы кадалса, аңа арыш ипие чәйнәп бәйлиләр дә, табандагы шырпы пылт итә дә шундук килә дә чыга... Безнең җанга кадалган империя шырпысын без ничек чыгара алабыз? Шул ачы арыш ипие бурысын үтәгән латин имлясы белән генә чыгара алабыз, җәмәгать!.. Әмма безнең иң дөрес... иң гадел фикерләребезгә дә масштаб, офыклар җитешми!.. Бездә, татарда, "Агач юнганда юнычкы оча",—дигән әйтем бар. Сарык та исән, бүреләр дә тук булалмый, җәмәгать. Корбансыз гына азат була алабызмы? Әле миннән алда гына чыгыш ясаган әбзи татарның соңгы миллион укучысын югалту турында яшь түкте. Югалсын! Ул вакытлыча югалту, мәңгегә югалту түгел!.. Укый-яза белмәгән, урыслашкан, үзбәкләшкән, дебильләшкән ун миллион

татарның миңа ни пычагыма кирәге бар? Әгәр минем халкым, чеченнәр кебек, батыр һәм бердәм була ала икән, миңа халыкны саклап калу өчен йөз мең татар да житә!.. Үзебез кылый булсак та, безнең трактор туры барырга тиеш. Явыз Иваннан соң биш йөз елда югалмаган татар латин кертеп кенә югалмаячак!.. Яшәсен латин галәиһәссәлам!..

Зал дәррәү килеп кул чапты. Аяклары белән дөбердәп, зык купты.

—Ур-ра-а!.. Яшәсен үлемсез татар милләте!..

—Гаскәр Кандаров,—дип таныштырды оратор белән Лотфрахман.—Чын милләтче. Сиксәненче еллар азагында Гаяз Салихов белән бергә Чаллыда беренче татар ижтимагый үзәген оештыручыларның берсе...

—Юк, югалмаячак ул, татар! Безгә тимерне кызуында сугып калырга кирәк!.. Дөрес әйттеләр, моннан ун ел элек кирәк иде. Без бу эшкә Ельцин заманында ук керешкән булсак, хәзер, Ельцин чечен сугышыннан айный алмый яткан заманда, без, шартлатып латинча язган-укыган татар, урыс империясен эчтән, коралсыз-нисез, тыныч юл белән жимергән булыр, урысның үзенә дә чын урыс дәүләте төзеп биргән булыр идек...

—Татарга дан!..

—Дөрес әйтә! Нәрсә озак чүбек чәйнәргә!

—Тавышка куйыйк та, бетте-китте!...

—Куймый торыйк! Мине, кәриннәйне дә, тыңлагыз әле!..

Залның уң канатындагы аралыктан, арттан, карангыдан яктыга көчә һәм йөзе белән ачыла, аныклана барып—ышансаң ышан, ышанмасаң ышанма, кем дисез?—күкрәгеннән теге транспарантын алып ташлаган, инде килеп, тәмәке утыннан көйрәп-изрәп беткән пинжәк якаларын яктыртып, анда орден-медальләрен генә калдырган, түшәмнән төшкән яктылык галифесенең күн өлгеләрен, хром итекләрен кояштай балкыткан Кәжә Зөфәретдин килеп чыкмасынмы!

Кулында кечкенә капчык. Ул аны дек итеп идәнгә куйды.

—Мине тыңлагыз!.. Монда сезнең күбегез килмешәк яңа Чаллылар, күмәкләп, чым-чыкыр килеп ятасыз. Ә мин—ялгызак Зөфәретдин Жәүһәретдинов булам. Иске, су астында калган Чаллыдан булам, чурту-матыр, дөбер-шатыр. Бер тапкыр кәриннәй, иске Чаллы кешесен дә тыңлагыз!.. ТОЦ дигән сүзне күп тапкырлар ишеткәнем булды, тик аны тәмләп караганым юк иде... Жыелышларыгызга да йөргәнем булмады. Бу юлы, пәвиске днягезгә латин куела икән дигәч, килдем...—Зөфәретдин-кардәш, мөнбәр артыннан чыгып, кызыл барыс тугърасы белән янәшәдән басты һәм, хәле беткәндәй, уң кулы белән мөнбәргә тотынды.—Чөнки бүген миңа... бөек Ватан сугышына илле ике ел үткәннән соң... бөек Лилин-Ысталин тәрбиясендә үскән денсез бер татар малаена, дәмичәтельни фикер килде... Юк, кирәкми безгә латин!... Аның кара үрмәкүч кебек хәрефләре безне денсез итә икән бит!.. Теге вакытта безне, имеш, вак халыкны, тиз генә алга сикертәбез, дип латинга күчерделәр... Әмма безне тиз алга сикертүчеләр, нишләптер, үзләре латинга сикермәделәр, кирил-мефодийләрендә калдылар, яппуна-мать. Безнең буын бит латинда шәп укыйбыз дип надан... юк, сукыр... юк, денсез калды!.. Менә мин үзем—гарәптән дә, латиннан да, кирил-мефодийдән дә буш калган зашитник Отечества!.. Беләсезме нәрсә? Алданмыек, туганнар!.. Латин безнең малыбызны алга тартса да, жаныбызны артка өстери!.. Безне Көнбатыш анпериалистларына кол итә... Без бит кайчандыр якын Көнчыгыштан, гарәп Ибне Фадланнардан нур алган кешеләр, чурту-матыр, дөбер-шатыр... Татарның иманы гарәптән булып, имласы латиннан булалмый!.. Монда эшне ышпиунар йөртә. Соңгы елларда Төркиягә оялап алган шәйтан менә шушы дин белән имла, жан белән тән аерымлыгыннан килеп чыкмаганмы? Шуннан килеп чыккан!..

Латин безнең милләтнең карахтерына ят нәстәкәй!. Алфавит бит ул, минем аңлавымча, белем алу чарасы гына түгел, денле булу чарасы да... Алфавитта—жанның кылы!.. Латинда бит—сөйләшеп булмый, ул телсез, үлгән тел... Теле булмагач, кысыр алфавиты безгә нәрсәгә кирәк? Ә менә гарәп телендә сөйләшеп була!.. Укып була!.. Ике миллиард халык белән бер намазлыкка басып, намаз укып була!.. Әйдәгез, латинга отлуп бирик тә, мең еллык гарәбебезгә кире кайтыйк!..

Иркен ага әле кичә генә танышкан Зөфәретдин кардәшенең акылына, фикерләвендәге, тел-лөгатендәге үзгәрешләргә таң калды. Бер-ике чүп гыйбарәне санамаганда, бу бөтенләй икенче, нәфис, нечкә әдәби тел—остазлар теле иде.

Һәм, иң мөһиме—ул үзе алыштырып куелгандай, икенче кеше иде.

Залдан "Дөрес! Хакны сөйли бу карт!" дигән сүзләр ишетелде.

—Нигә дөрес булмасын, мин бу хакыйкатьне кырык биш ел элек, миңа керәге булмаган сугышның колы булып, ут эченә кергәч тә аңлаган булганмын... Ысталин мине герман белән сугышканда жинел булсын өчен, гарәптән аерып, алдан ук латинга өйрәткән булып чыкты, явыз!... Мин моны фактически кичә генә аңладым. Бу фикерләргә мине шушында утырган кеше—Америкадан кайткан якташыбыз этәрде.—Зөфәретдин кардәш Иркен агага күрсәтте.—Ул миңа, житмеш ике яшьтәге денсез каткан картка, жан белән тән берлегенә юл ачты... Мин сезнең исемегезне дә белмим, югыйсә... Рәхмәт сезгә, кардәш!..

Зал кул чапты.

Бу Иркен аганың үз гомерендә алган һәм, иң мөһиме, туган жирендә Тере Чаллы Тамырыннан кабул иткән беренче бүләге—ордены иде. Әмма ул алачак икенче, иң зур бүләк әле алда булган икән.

—Әйтеп бетерәм!—Зөфәретдин-кардәш хакими ишарә белән мөнбәргә сукты.—Мине чыгыш ясарга мәжбүр иткән төп сәбәп—анавы качаклар мәсьәләсе булды. Йөрәккә төшкән мәсьәлә, туганнар. Әгәр жанымны тетрәтмәгән булсагыз, мин бәлки монда чыгып сөйләнеп тә маташмас та идем -кардәш.

—Әби белән!..—дип кыстырды кемдер.

Көлешеп алган зал, житди хәбәр көтеп, мәет чыккан йорттай тынып калды.

—Белмисезме? Белмисез шул!.. Чөнки без бары тик үзегезне беләсез. Чөнки сез килмешәк. Сез бирегә фатыйр өчен генә килгәнсез. Сез фатыйр аласыз да качасыз. Ә миңа—Ватан кирәк!.. Минем фатыйрым—Ватан!.. Мин менә унынчы көн инде Ватан сагында... Үзәк Базар мәйданында Иске Чаллының мең еллык тарихын—су астына киткән Аттила бабай каберлекләрен, урамнарын, сирәк йорт-каралтыларын яклап ачлыкта ятам! Сез белмисез дә, килеп тә күренмисез!..

Халык аһ итте.

—Аһ итеп кенә калмагыз, минем янга килеп күренегез. Чаллы урамында әле булса исән-сау үсеп утырган бердәнбер Тирәген-Йөрәген яклап ачлыкта яткан Бөек Ватан сугышы ветераны Зөфәретдин Жәүһәретдинов янына килеп чыгыгыз. Минем Тирәгем-Йөрәгемне тамырлары белән төпләп, аның урынында дошманнар фахишәләр притоны, казино төземәкче итәләр!.. Әйе, ашаудан баш тарттым мин! Ашар ашым тамагыма таш булып торды... Су эчәм дә, тәмәке тартам!... Әле мин сезнең янга киткәндә үземнең урыныма карачкымны калап калдырдым. Чаллыда минем бер карачкым гына да читтән килгән миллион татарга тора!..Врачлар да, брачлар да килми минем янга, карачкымнан да куркалар!.. Ә сез курыкмагыз. Килегез... Юк, кайтыгыз!.. Китмәгез туган жирдән!.. Качаклар, хокукларыгызны яклап,

минем белән бергә ачлыкка басыгыз! Гарәп яклылар, минем белән бергә ачлыкка басыгыз!.. Беләсезме, сез ни өчен көрәшмичә кире илләрегезгә кайтып китәсез? Чөнки сезнең җанда зимагурлык утыра. Имеш, знай наших! Китәләр! Китеп барып, безне харап итәләр!.. Һы, татар аны гына күргән, яппуна-мать... Юк, китмисез!. Бәхет өчен туган җирдә дә көрәшергә кирәк!.. Их-ма!..

Ул капчыгыннан көмеш тальянын чыгарды һәм җырлап җибәрде:

Зимагурның атаманы
Кәркеш[1] буа биленә.
Ашый калжа, сөя маржа,
Ник кайтсын ул иленә?!

—Китмибез! Кайтабыз, чурту-матыр, дөбер-шатыр!..

Ул күзгә кебек ялтырап торган итекләрендә нурлар уйнатып, гармуныннан көмеш моңнар коеп, залга төшеп китте.

Иркен ага аягына басты. Аның белән бергә президиум да, зал да басты. Халык гү килеп кул чапты.

Кәефе килгән рәис тәкъдименең үтәчәгенә тулы ышаныч белән латинга күчүне яклап, тавышка куйды. Шулай да Зөфәретдин кардәшнең чыгышыннан соң, латинчыларның рәте шактый сыегайган булып чыкты. Гарәпчеләр залның яртысын диярлек тәшкил итеп өлгергән иде.

—Юк болай булмый!—диде рәис.—Татарлар бердәм булырга тиеш! Милли гимныбыз—“Татарлар, берләшегез!..” Сәхнәдә милләтебезнең көрәшче җырчысы Асия Әхмәтшина! Баянда—көйнең авторы, милли композиторыбыз Вәсим Әхмәтшин!..

Сәхнә артыннан, кояштай елмаеп, бит алмасындагы уймаклары белән зал тирәнлегенә кадәр ап-ачык күренеп, як-ягына тимерчеләрчә янтаебрак атлап, таза гәүдәле хатын килеп чыкты һәм президиум янынннан диярлек җилләнеп үтеп, сәхнәнең сул канатына барып басты да бар тавышына җырлап та җибәрде:

Җавап тотар заман килде—
Байракка тинләшегез!
Иман нуры булып тамсын
Коръәнгә күз яшебез!
Азатлык өчен жанны да
Кызганмый көрәшегез!
Таңнарда серләшегез,
Татарлар, берләшегез!...

Ниндидер көч Иркен аганы бөтереп-бөтереп күккә алып менеп китте. Ул гүя тын да ала алмый иде. Кояш, исәнме! Ул, Кояш, ялкынланган, тирәсенә алтын тузаннар очырган Кояш, менә-менә якында, эргәдә, инде кул белән тотып карарлык аралыкта иде!

Арабыздагы имансыз
Карагруһ көяләрен,
Милләтен сатып, мал җыйган
Бар “эшемияләрен”
Тамырлары белән йолкып,
Кояшка күрсәтегез!

[1] Кәркеш (диалект.мишәр.)—каеш билбау.

Бер телдә сөйләшегез—
Татарлар, берләшегез!..

Зал идәне-түшәме белән бергә гүли, бергә җырлый, бергә җылый иде.

Иркен ага үзен космик корабтагы беренче галәмкяр итеп тойды. Ул гүя, болгар-татар, Гагаринны галәмгә күтәргән титан иде. Шул ук вакытта ул үзе дә татарның беренче галәмкяры иде. Гагар-ин—болгар-ин. Аның берлән бергә Галәмгә гүя барча милләте менгән, барча милләте очып йөри, алар арасында болгар-татар Гагарин да елмая, һәм гүя тирестән, кара эштән күзе томаланган милләт, карашы-чырайлары ачылып китеп, миллионлаган шәрә куллары белән Кояшның алтын тузанына баткан да, чүпләмле тастымаллар берлә Кояшның күзен каплаган майлы тапларны сөртә, Кояш исә, рәхмәт йөзеннән, барча дөньяны тагын да яктырак, тагын да илһамлырак, тагын да сихәтлерәк нурлар белән яктырта!..

Ул аптырады: татарда мондый композитор-көйче, мондый җырчы, мондый җыр була торып, ничек аларны Бөтендөнья татар Конгрессының Йомгаклау концерты программасына кертмәгәннәр? Хуҗалар мондый монафыйклыкка ничек юл куя алганнар, диген?! Әйе, ул Конгресстан соң күрсәтелгән концертта татарның мәшһүр җыручылары башкаруында гүзәл җырулар тыңлады. Тамаша тәмамланганчы аның җаны яшь дәрьясында йөзде. Ләкин бер генә җыру да аны болай күккә, Кояшның үзенә күтәрмәде. Йә, Ходай, ни кадәр талантлы да соң бу безнең татар! Аның талы вә теле, ихластан да, кискән саен үсә, малы—таланган саен арта, ишәя тора, даны—яланган саен баллана тора!..

Әйе, җырга барча халык кушылган, аны барча халык күтәреп алган иде.

Без—илен сөйгән илдәшләр,
Җегәрле, сәләтлеләр,
Ватаннан ватансызлыкны
Куарга сәбәплеләр.
Кайтып, туган нигезләргә
Ил өчен көрәшегез!
Бер монда гөрләшегез—
Татарлар, берләшегез!..

Иркен ага гүя тын алудан бөтенләй диярлек туктады. Гүя бар дөнья тын алудан туктады. Ул судагы тоз булып эреде. Гүя ул эреп юка чыккан иде. Ул инде судагы су, тоздагы тоз иде.

Йә, Хода, татар-мөселман итеп яратуына рәхмәт!.. Бу халыкнынмы хокукка хаккы юк?! Хаклыбыз туган Ватанда шактый ук!.. Аһ, Тукай, Тукай!.. Зиһенендә нәрсәдер ялт итеп яктырды. Аны кырыс чынбарлыкка кайтарып, зал алкышлар белән шартлады.

—Нинди яхшы җыручы... Халык артистыдыр, гуй?

—Юк,—диде Лотфрахман кардәш.—Бар милләтнеке... Әлегә званиесе генә юк...

Зал аягында иде. Залда өермә, залда давыл, залда хисләр шашып-шашып кайный иде. Җырның иляһи могҗизасын кичергән Иркен ага җырчы берлә басып торган кечкенә, җыйнак буйлы, түгәрәк йөзле, инде башындагы чәчләре сирәкләнә башлаган ир затын—көйчене күрми дә торган икән. Иркәй исә, хатыны кебек үк киң елмаеп, залга караган да , гүя "Мин сезнең өчен барысын да эшләдем, инде тагын да нәрсә эшли алам соң?" дигәндәй ихлас кичерешләрдә басып тора... Афәрин! Һәм болар, милләтнең ике алтыны—ир вә хатын? Һәм алар уртак балалар үстерә? Нинди бәхет,

иляһым! Менә ошбу манзараны күрү өчен генә булса да кайтырга кирәк булган икән...

Титаклап булса да барып, җырчыны һәм көйчене кочасы килеп китте. Тыйнаксызлык булыр дип түзде. Шул чак бер ак шәльяулык ябынган карчык сәхнәгә сикереп менде һәм такмаклап бии башлады:

Ай да бирәү, кояш та бер,
Кояш чыкмый болыттан.
Ельцин түбәтәй кисә дә,
Аерылмадык урыстан.
Ельцин түбәтәй кисә дә,
Күңеле дөрест түгел.
Безнең кулыбызда тәсбих,
Муенда крест түгел!..[2]

Зал туктаусыз кул чаба иде әле.

—Бу җырчы Асия Әхмәтшинаның анасы Фатыйма апа Хамматова була,—диде Лотфрахман.—Кайбер җыеннарга, Бакчасарай авылыннан карчыкларны ияртеп, ул да килгәли...

—Татар Иҗтимагый Үзәгенең чираттагы җыены үзенең эшен тәмамлады. Күтәрелгән мәсьәләләр буенча барыгызга да рәхмәт белдерәм...—дип игълан итте залга рәистәш Гаяз әфәнде.

—Төрлеләр кая? Төрлеләр?

—Без монда "Төрлеләр" өчен киләбез!..

—Вакыт кысты, җәмәгать!..

—Ә нигә американ сөйләми? Американецка сүз бирик!—дип шаулашты зал.

Гаяз әфәнде Иркен ага үтенеч белән карады.

—Әгәр мөхтәрәм кунагыбыз каршы түгел икән, без аңа зур теләк белән сүз бирәбез,—диде ул мөнбәргә күрсәтеп.—Рәхим итегез, Иркен ага!..

Иркен ага мөнбәргә күтәрелеп тормады. Җәмәгатькә ихтирам йөзеннән, берничә кәлимә генә әйтмәк булды.

—Мөхтәрәм кардәшләрем!..

Шул чак гөлт итеп залда ут сүнде.

—Гел генә шулай мәтәштерәләр!..

Америка кадәр Америкадан кайткан татар авызыннан чыгачак хикмәтле сүзне теләсә нинди шартларда да тыңларга әзер булган җыен ут сүнүгә керфеген дә селкетмәде.

Иркен ага әле генә ишеткән җырның ләззәтле шаукымында йөзә иде.

—Һәмма кардәшләрем! Мин сезләрне... гүзәл татар өммәте вәкилләрен... Әмрикә татар җәмгыяте исеменнән кайнар сәлимлимен...—дип башлады ул сүзен.—Конгресс кабул иткән кануннарны, бүген килеп, сезләрнең бердәм тәсдыйкъләвыгыз милләтемезнең көч вә сихәт мәртәбәсен исбатлыйдыр. Бүгенге күркәм халык җыенында милләтемезнең хезмәткә вә җырга әзерлеген күреп илһамландым... Алыс Уйгырстан татарларында "Арбасы ватылгач—елаган, аты үлгәч—көлгән" дигән мәкаль бардыр кү... Безгә атымыз үлгән хәлдә дә көлеп алга барырга кирәктер кү... Сезләр мине гафу итә күрезез... Бүгенгә башкача берни сөйли алмамдыр. Иртәгә иртән иртүк, ерак бабаларым эзләрен эзләп, сәяхәткә чыкмак булып торам. Сәяхәттән кайткач, насыйп итсә, йәнә дә очрашырмыз һәм мин сезләргә ошбу җыенда хисап тотармын... Аллаһы Тәгалә сезләргә солтанатлык бирсен...

—Сәяхәтегез кай якларга?—дип сорадылар астан.

—Мамадыш вилаятенә,—диде Иркен ага.—Соңра, насыйп итсә, Баулы тарафларына...

[2] Фатыйма Хамматова (1919-2003) шигыре.

—Җәмәгать! Тәртип белән чыгыйк!—дип кычкырды рәис.—Этешмичә-төртешмичә, залның ике канатыннан, бер-берегезгә тотынып, фойега!.. Баскыч текә, мәтәлә күрмәгез!

Халык, кулга-кул тотышып, фойега чыгу белән, ялт итеп ут та кабынды.

—Иркен ага!..—Кырык яшьләр чамасындагы, бүгенге очрашу куәте, алсуланып, йөзләренә калыккан хатынкай, йөгереп килеп, беләгенә асылынды.—Сәгыйдә булам... Минем ике кызым Флора белән Фауна, бәхет эзләп, Америкага чыгып киткән иделәр...—Хатын ялт-йолт итеп тирә-якка караштырып алды.—Сездән киңәш сорыйсым бар иде... Флорасы Америкада калса калыр, Фаунасын кайтарып булмасмы, ә? Сезнең белән очрашып булмас микән, ә? Бик теләр идем!..

—Очрашып булыр, ник булмасын...—диде Иркен ага аны-моны уйламастан.

—Кайчангарак?—дип куанды хатын.—Адресыгыз ничек?

—Минем аша, Сәгыйдә ханым,—диде Лотфрахман арага кереп.—Бераздан элемтәгә керербез, ямегез?..

—Ямегез, ямегез!..—Сәгыйдә ачу белән мыгырданып алды.—Шушы иске ыштанлы болгарист Лотфрахман бар җирне сасытып килә дә, тәгәрмәчкә таягын тыга!..

Хатынкай, дулкыннар өстендәге ялгыз көймә сыман талпына-талпына, китеп тә барды.

—Тарих өчен! Тарих өчен!..—Кинәт җил белән очып чыгып, чабуга сарышкан тигәнәк кебек бер кеше—ул киселгән агач төбедәй кыска буйлы, елтыр башлы, ниндидер озын, сүстәй аксыл-сары, агач кайрысы кебек мәңге юылмаган пычрак чәчле, ямшек танаулы, туктаусыз йөгергән күзле иде—аларны шалт та шолт китереп фотога төшерә башлады. Төшерде-төшерде дә, ефәк чалбарлары белән почмаклатып борылды һәм, йөгереп килеп, кулын сузды.—Танышыйк. Тәтәйхан булам. Безгә очрашырга кирәк. Мин сезгә күп нәрсәләр сөйли алам. Илленче елларда Сталин лагерьләрендә утырдым. Хәзер татар ГУЛАГы тарихын язам!..

Иркен ага сул тарафка игътибар итсә, ни күзләре белән күрсен, икенче бер инсан инде аларны күтәрмәдән үк кинокамерага төшереп тора икән. Анысы да "ары лап-лап, бире лап-лап", дигәндәй, баскычтан баскычка сикереп төште дә, йомгак кебек тәгәрәп килеп җитте:

—Милли хәрәкәтнең кинооператоры Тормасов булабыз!—Әллә югары кан басымыннан, әллә куе кызыл шәраптән кысла кебек кызарган оператор ана кулын сузды.—Бездә һәр мизгел тарих өчен. Бездә бер кем дә, бернәрсә дә онытылмаска тиеш...

—Беркемне дә... Беркайчан да!.. Онытмаска...—дип уфырды арадан берәү.—Новгород сазлыкларында әле булса миллион совет солдаты җирләнмичә ята...

Лотфрахман Иркен аганы тегеләрдән аерып алып китте.

—Кирәк кешеләр түгел. Икесе дә орган кәккүкләре. Кайда татар җыела—алар шунда. Фото-киноматериал ташыйлар. Тегесе, пеләше, Канададагы бер татар баеның утарында тамак хакына каравылда тора. ФСБ чакырса, сабантуй. Конгресс көннәрендә кайтып киткәли...

Алар саф һавага чыктылар.

Аларны каршылаган тыгыз җил шундук урында бөтергәләнеп, өермәгә әйләнде, һавада яңгыр исе аңкыгандай итте. Берничә эре һәм ниндидер коры тамчы төшеп, борынга бәрелде дә, яңгыр башланмастан туктады.

Иркен ага, бергә президиумда утырган һәм соңыннан үзләренең ярдәмен тәкъдим иткән ТИҮ җитәкчелегенә рәхмәт әйтеп, җылы саубулашты.

—Сихәт ханым!—дип кычкырды Лотфрахман бер читтәрәк басып торган төркемгә борылып.—Килегез әле монда!..

Алар янына йөгереп диярлек ак яулыклы, уймак кебек җыйнак гәүдәле хатынкай килде.

—Иркен ага, таныш булыгыз. Бу безнең бик тә ышанычлы кешебез Сихәт ханым... ТИҮ оешканнан бирле—милли хәрәкәттә, болгар җәмгыятенә йөрмәсә дә...

—И-и, Лотфрахман абый!.. Мин бит татарны болгардан аера белмим...

Иркен ага, танышкан сыман итеп, баш какты. Аннан танып та алды: бүген иртән милли бүлеккә хатын-кызлар өчен "Рухият-Хиссият" дигән тәрбияви лекторий ачу тәкъдиме белән килгән ханым иде ул.

—Иркен ага, әгәр рөхсәт итсәгез, мин сезне кунакханәгезгә илтеп куйганчы гына шушы ханым кулына тапшырыр идем... Ул шунда... янәшәдә генә яши... Ә мин... биредә, Яңа Шәһәрдә яшим... Машина сезне кунакханәгә кадәр илтеп куяр. Сез каршы түгелме, Сихәт ханым?...

Бераз аптырашка калган Сихәт ханым иңбашларын сикертеп куйды.

—Шушы ук машина, Иркен ага, сезне иртәгә Мамадышка да алып барыр...

—Мамадышка?!—Ханым, сүз дә эндәшмичә, разыйлыгын белгертеп елмайды.

—Әлбәттә, кардәшем, нигә сезгә шул кадәр алыска барып йөрергә?—дип куәтләде кардәшен Иркен ага.—Ә без... кайтырбыз!.. Шулай бит, сылуым?

Иркен ага белән Сихәт ханым янәшәдән күпер астындарак торган автомобильгә таба юнәлделәр. Лотфрахман аларны озатып калырга дип кузгалды.

—Ләхәүлә вә лә куәтә!..—Иркен ага кыйбла тарафыннан, төзелмичә яткан түгәрәк кунакханә бинасы өстеннән, гүя күк йөзенең яртысын диярлек биләп алып күтәрелгән галәмәт тә зур, гаять тә олуг, биниһая өлкән Ай түгәрәген күреп туктап калды һәм дога кыла башлады.—Ай күрдем аман берлән!.. Аузым тулду иман берлән...

Иркен агага ияреп, Сихәт тә дога кылды. Лотфрахман кымшанмады да.

Үз гомерендә сирәктән-сирәк сынаулар, Тәкла-Мәкан мәхшәрләре, Тәңре-Шәм, Һиндыкышлар аша үтеп, хәнҗәр сыман Карлыгаш сыртларының 3521нче биеклегеннән—боз кабыгы эченнән зәңгәр күзләре илә әле булса чекрәеп, әтисен көтеп яткан нәни Гөлфаныйларының газиз гәүдәсе-рухы белән җанында Галәм биләп килгән Иркен аганың, шушы яшькә житеп, мондый галибанә, мондый камил, бу кадәр дә садә алтын Айны күргәне юк иде...

Бу Ай чынлап та Алтай-Алтын Айлардан чыккан үз Алтын Аебыз иде.

Ул, күз читенә типкән яшен сиздермәскә тырышып, Лотфрахманга кул бирде:

—Хуш иттек!.. Рәхмәт, кардәшем! Күрешкәнче изге догада булың!..

Автомобиль Иске Шәһәргә юл алды.

Бераз гына сулдан, Туфан проспектындагы төзелми яткан биек бина янәшәсеннән аларга таба тәгәрәп, галәмәт тә зур алтын шар кебек Галибанә Ай, әнә, үзе килә иде.

Иркен ага әле һаман да җыр бүләк иткән бәхетнең җиденче катыннан төшмәгән иде...

*Беренче китап тәмам.*

*1999—2007.*



Әхсән
Баян

## АК КҮҢЕЛЛЕ, СЕРЛЕ ДӨНЬЯДАН

### Аваз

**Уйлар төнлә китә ераккарак,
Күккә баксаң, дөнья киңәя,
Фикер мескен йөри галәм буйлап,
Җитә алмый тик бер җиргә дә.
Кояш иле кала тараеп,
Тукталырга ләкин ярлар юк.**

**Миллиард күзле чекерәйгән дөнья
Карый җем-җем... алда—зур хәят.
Караңгысы була—яманлыктыр,
Яктылыгы—изге рухият.
Күзләр карый якты галәмгә,
Уйларыбыз шунда әйләнә.**

**Галәм серләренә ара ерак,
Табам димә эзләп һәм уйлап.
Миллиард күзен чекерәйткән күккә
Карый Адәм—мәңге ялгызак.
Син шул күктән хәбәр көтәсең,
Билгесезлек чыңы ишетәсең.**

**Утлы сахраларда Җир адашкан,
Үзенә хас җаннар эзләгән.
Кайдадыр бит бардыр җан иясе,
Барып кына җит син, и Адәм!
Барлык белән юклык арасын
Уза алсаң, юлдаш табарсың...**

**Мин дә—ялгыз, балкый күз алдымда
Тере галәм—чиксез рухият.
Мин бар икән, ул булырга тиеш—
Мине сөяр өчен туган зат.
Аккош юлы төсле киңлектән—
Күңел күкләреннән сүз көтәм.**

---

Әхсән БАЯН (1927) — *Татарстанның халык шагыйре, прозаик, драматург, публицист; күпсанлы китаплар (шул исәптән ике һәм биш томлык "Сайланма әсәрләр") авторы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Көтмим хәбәр төндәш-көндәшләрдән,
Сәяр ярдан көтәм, ышанам.
Хат булмаса, чылтырар телефон,
Компьютерым әнә сер язган...
Ак күңелле, серле дөньядан
Килер аваз, килер бер заман.

## Төнге утлар

Ниләр булды, булды ниләр генә –
Төннәр алып килә йокысызлык.
Тынгысызлык өстәп, сирпелә ут,
Юк яктысы аның, жылысы юк.

Кырмыска да түгел, кандала да,
Суыра канны, кадала да җанга.
Тукталасың килеп тәрәзәгә.
Күз атасың каршы йортка таба.

Тәрәзәләр анда, утлар яна,
Кемнәрнеңдер балкый бәхетләре.
Ике гашыйк тотынышса кулга.
Ак хисләрнең юктыр сан-чикләре.

Озайталар сөю сәгатьләрен,
Уйлап, бәлки, саубуллашу таңын?
Кычкыруы микән бу яктылык
Билгесезлек тулы минутларның?

Тәрәзәләр. Нинди утлар?! Өйдә
Утырмыйлар микән хәмер чөмереп?
Кабызган да утны, сүндерергә
Онытканмы байгыш бер исерек?

Көмеш чәчле әби, йә бабайның
Соң мәртәбә бәлки ае бата.
Калтыранып дару каба, йота,
Ыңгыраша бахыр, тора, ята...

Җиде төндә тәрәзәдә—утлар.
Туйга түгел, чакыралар уйга.
Кем булсаң да, бәндәм, бул сәламәт,
Кылам дога: Кояшыңны җуйма,
Кояшыңны! Җуйма!

*2007*

## Ватан

Син—туган җир, чишмә башы, син—Ватан,
Бер кат китсәм, ун кабат кире кайтам.
Юрый шайтан: тиздән авыл бетә, ди,
Кала фермер, безгә шул бик җитә, ди.

Юл күрсәтә кем ул килер заманга?
Язмышларны Ходай бит үзе яза.

Синдә туа, синнән башлана ал таң,
Син—туган җир, гомер башы, син—Ватан.

Язмыш кушкан: авылдан килә һәр таң,
Кырда халык чәчкән һәм урган чактан,
Уйлы, туйлы ыруглар торган яктан,
Һәр чишмә синнән башлана, и Ватан.

Юл күрсәтә кемнәргәдер урак Ай,
Юл күрсәтә кемнәргәдер тәресе...
Фермер түгел авыл—тик икмәк саткан,
Ул—халыкның булу, яшәү рәвеше.
Ул—туган җир, чишмә башы, ул—Ватан.

## Алдым күпне

"Син тормыштан барысын алдыңмы?"—дип,
Әллә сынап, куйдың сорап кабат.
Алдым аннан ачы хатирәләр,
Һәм шундыйрак булыр, ахры, җавап.

Тормыштан мин алдым, алдым күпне:
Алдым хыял, сөю, Җир һәм Күкне.
Һәм матурлык бераз, һәм яктылык,
Кайгы алгач, яшьлек яшьләр түкте.

Касә тутырып бирде миңа тормыш:
Ачысын да бирде, татлы бал да.
Йөрәгемне торды шомландырып,
Шайтан суы белән сыйлаганда.

Алганымның җуйдым кайберләрен—
Дуслар белән калсам иде озак...
Исәннәрдән күбрәк киткәннәре,
Кайтмас алар, ялварсам да елап.

Алпамышлар чорын күрмәгәнмен,
Сәгать суккан һәм мин бар булганмын.
Күктә йолдыз гүя—атылганмын
Һәм юклыкка китәчәкмен тагын.

Алып калыр ләкин Җир үзенә,
Ул бит—минем мәңгелек торагым.
Олы сабый, йоклый бирәм бугай,
Ә Җир—бәллү, һич тә аерылмадым.

Китсәм, кала миннән утлы байрак,
Яңа буын ары китәр алып.
Тынгы гына табалмады җаным,
Өндә—ил язмышы,
Төштә—халык.

Күпме алсам, барысын калдырамын,
Китсәм, үзем белән китмәм алып.

*2005*

***

Басып торган идек икәү бергә,
Яшьлек белән сердәш бу төштә.
Казансуның шаян дулкыннары
Сөенешеп һаман йөгерешә.

Басып тордык ак суларга карап,—
Аерылмаска куллар тотышкан.
Ике ярны тоташтырган күпер
Безнең дуслык төсле—корычтан.

Акты сулар, акты бер-бер артлы,
Айлар, еллар кушылып актылар.
Сулар безнең яшь өметләр төсле—
Безнең уйлар төсле яктылар...

Таныш ярга килдем. Күпер тынган,
Корыч булып корыч чатнаган.
Аны төзәтерләр... Нәрсә калган
Безнең бергә торган чаклардан?

Казансуда йөгерә яшь дулкыннар,
Элеккечә көләч, яктылар.
Яшь дулкыннар аңга, җанга кага.
Тик сагышлар кала, акмыйлар.

Сулар ага, күктә болыт ага,
Күләгәсе—елга өстендә.
Мин ялгызым гына нидер көтәм
Какшап калган күпер читендә...

*2007*

## Азат арыслан

БАЛЛАДА

Тереләрне ашап өйрәнмәдем,
Китерделәр миңа әзер ит.
Арысланга дигән өлеш—шактый,
һәм булмадым бигүк нәзберек:
Умырдым шул итне, корсак тутырып,
Бүреләрне көнләштерерлек.
Баш миенә тамчы уй кермәде,
Ач йөрергә туры килер дип.

Тар булдылар тик читлекләр генә,
Кысанлыктан гына тилмердем.
Белмәгәнмен читлек тимердер дип.
Тимерләрне ырлап кимердем.
Үземнең мин җәнлек икәнемне
Белә алмаганмын һич элек.
Рәшәткәләр тимерен кимерә торгач,
Ирек кебек көннәр килер дип.

Әйтте кемдер: "Килде киңлек! Ирек!" –
Читлек ишекләре ачылды.

Күрсәт менә хәзер тешләреңне
Әгәр булса, уйлат башыңны.
Күршеләрдән күрмәк, мин дә чыктым,
Аптыраудан озак кашындым.
Аңгы-миңге йөрдем ят урманда:
Кайсы кеше монда, кайсы җен?

Ник берсе дә миңа китерми ит?
Аша диләр кемне булса да.
Терелләтә ашап өйрәнмәгәч,
Тилмерәм мин ачка, бичара.
Эзлим азык, эзлим һәм үземне
Куе урман, кара тайгада.
Кояш чыга, сизәм, кояш бата,
Буш корсакка барыбер кайда да.

Кем кул сузар, кемнәр калыр йолып
Ачлык дигән ачы кайгыдан?
Ырлап түгел, шыңшып, ыңгырашып.
Тимер читлегемне сагынам...
Алда—ярлар, биек, текә ярлар,
Биек тауда торган җиремнән
Ыргыйм кара суга, йә бер браконьерга
Үз тәләгем белән бирелэм.

*2006*

***

Их, сез, июль яшеннәре,
Күкрәүле яңгырлары!
Бәхетнең биек түбәсе,
Шатлыклар яңгыравы!

Яшенле яшьлек еллары
Яңара сезнең аша.
Гөрләвекләр, тар урамга
Сыймыйча, читкә таша.

Күкрәгем ачык яңгырга,
Йөрәк типми ял сорап.
Уза яңгыр... Күшегеп мин
Торам ялгыз калтырап.

Күкрәүләр ерак, ерак...

*2004*

***

Киләчәктән сөю көтмим инде, –
Эзләр чакның белэм узганын.
Яшь көннәргә кайтып, икенче кат
Гашыйк булам бер үк кызга мин.

Гашыйк булам ике, өченче кат,
Вакыт үтмәгәнгә исәплэп.
Карарга да базмый, бүгенгемә
Алып кайтам аны җитәкләп.

*2003*



Әхәт
Сафиуллин

# СЫНАУЛАР АША

ПОВЕСТЬ

1

Ишек шакыдылар. Тирән уйга талып тәрәзә янында басып торган Әлфия сискәнеп киткәндәй булды.

—Керегез!—диде ул, кулы белән тиз генә битләрен сыпырып, һәм өстәленә таба атлады.

Ишектән килеп кергән хуҗалык эшләре мөдире Тәнзилә—юан гына гәүдәле, тәбәнәк буйлы, табак битле илле яшьләр тирәсендәге хатын—борчулы кыяфәтенә караганда, бик мөһим эш белән йөргәнгә охшаган иде: йөзе ачулы, кырыс.

—Хәерле көн, Әлфия Закировна!—диде ул һәм, сәламен алганны да көтмичә, нindидер ярсулык белән тезеп китте:—Йә, нишләргә инде болар белән, Әлфия Закировна, ә?! Теге башкисәр—"Тюремщик" кушаматлы Василийны әйтәм—эчеп, тагын тавыш чыгарган! Анысы да бер хәл—тавышы миңа кагылмый!—әле унбиш көн элек кенә биргән өр-яңа юрганын пычак белән тураклап бетергән! Эчеп алса, пычакка үрелә торган гадәте бүген генә түгел бит инде аның. Хәзер миннән тагын юрган сорый! Бөтен гомерен төрмәдә уздырган шундый адәм актыкларын нишләп аерым тотмыйлар икән, ә?! Гөнаһсыз карт-коры шулардан зыян күрә. Бу юлы акчаны, пычак белән янап, дүртенче бүлмәдәге Галимулла абыйдан алган. Кичә кызы килеп киткән иде, бераз акча калдырган булган, ахрысы…

Картлар йортында күбесенчә кыска гына итеп «завхоз» дип йөртелгән Тәнзилә, үзен директорның бернинди сүзсез, хәтта ничектер битараф кына тыңлап утыруын күргәч, шып туктап калды. Һәм бераз аңа ничектер төбәлеп, сынап диярлек карап торды да, хатын-кыз күңеле белән бүген хуҗаларының кәефе юклыгын шундук аңлап, тавышын әкренәйтә төште һәм:

—Авырмыйсыздыр бит, Әлфия Закировна, ә?—дип сорады.

—Нәрсә?—диде моңа каршы директор, аны тагын да гаҗәпләндереп.—Әйе, әйе… Юк, юк, авырмыйм, Тәнзилә апа…

—Төсегез киткән, шуңа соравым…

—Нишләптер начар йокладым бүген… Син дөрес әйтәсең, Тәнзилә апа, аптыраган ул утырып чыкканнар белән! Зинһар, ала күрегез бездән шуларны, дип беркөн министр урынбасарына тикле барып кердем. «Кая куйыйк соң без аларны?—дип кулларын гына җәйде.—Әлегә андыйлар өчен аерым йортлар

---

Әхәт САФИУЛЛИН (1936)—*язучы; «Онытылган вәгъдә», «Сер бирмәдек», «Тулгана дөнья» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

юк...» Шул явыз өч адәм актыгы йөзгә якын кешене куркытып яши бирә... Милиция дә берни эшли алмый, янәсе, кылган җинаятьләре юк! Шуларны бездән алсалар, мәчеткә хәер бирер идем, валлаһи! Ярар, тагын милициягә барып карармын, үзе белән дә сөйләшермен. Хәер, кеше сүзен аңлый торган бәндә түгел бугай инде ул: әле күптән түгел генә сөйләшкән идем мин аның белән, бүлмәләрендәге урындыкларны йомычкага әйләндереп бетергәч... Ә юрганны бирми тор! Директор бирмәскә кушты, диген.

—Аңладым,—диде завхоз һәм инде чыгарга дип борылыр алдыннан ана тагын бер тапкыр үтәли тишәрдәй булып карап алды.—Бик йончыган шикелле күренәсез бүген, Әлфия Закировна. Житмәсә, мин дә йөрим тагын вакытлы-вакытсыз... Гафу итегез!

—Юк, юк, борчылма, Тәнзилә апа! Әйтәм бит, нигәдер бик начар йокладым бүген. Шунадыр, хәзер башым авыртып тора.

—Мондый башкисәрләр белән йокысыз калмыйсыңмы соң?! Йөзләренә дә күтәрелеп карыйсым килми шул төрмә токымының! Бар гомерләрен төрмәләрдә үткәргәннәр дә, картайган көннәрендә кешечә тәрбия кирәккән аларга!

—Нишлисең бит, Тәнзилә апа, алар да безнең кеше...

Завхоз чыгып китте.

«Бигрәк сизгер хатын!—дип уйлап алды Әлфия, аның артыннан ишек ябылгач.—Бер генә тапкыр күз ташлый, шунда да кәефеннең ничеклеген төшенеп ала! Әллә кешене үтәли күрә торган сәләте бар инде?!»

Әйе, ул, чыннан да, бик йончыган. Чөнки бүген керфек тә какмады диярлек—төне буе күңелсез уйларыннан арына алмыйча аптырап бетте. Йокларга, ял итәргә кирәклеген дә, күзләрен йомган килеш уфылдап ятудан бернинди файда юклыгын да белә, тик нишләтәсең аны! Аның көрсенеп ятуын сизгән ире дә тынычландырып карады. Юк, үч иткәндәй, барыбер күзенә йокы кермәде. Таң алдыннан гына изрәп китте китүен дә, ләкин инде торыр вакыт җиткән иде. Нишләсен, торып басты. Ә башы тубал булган: үзе авырдыр—әйтерсең үзенеке түгел, башка кешенеке, җитмәсә әле, әллә ниткән эчпошыргыч авазлар белән шаулый, чигәләре ярылырдай булып авырта—кемдер чүкеч белән туктаусыз сугып тора диярсең...

Әй, һич кенә дә аңлый торган түгел бу тормышны! Әле генә такыр юлда келтерәп тәгәрәгән тәгәрмәчтәй җайлы, бернинди борчусыз гына бара иде, ә менә уйламаганда гына, бөтенләй көтмәгән ягын күрсәтеп, аны да, ире Вадимны да кайгыга салды да куйды. Бердәнбер балалары шундый хәсрәткә төшерер дип кем уйлаган! Ни җитмәгән ана?! Сынык ипи дип тилмергәне, ни киим дип аптыраганы булмады—теләгәнен ашап, теләгәнен киеп үсте бит югыйсә. Дөрес, баштарак тормышлары әллә ни борын чөярлек булмады анысы—үзенең хезмәт хакы ташка үлчим генә иде, ире дә көрәп алмады. Бары тик моңарчы коммунизм төзеп яткан илнең сәясәте капма-каршы якка—капитализм юлына борылып, тезүче-инженер булып эшләүче ире Вадим тәрәзә һәм ишекләр ясый торган үз фирмасын оештырып җибәргәч кенә тормышлары күз алдында тауга таба тәгәрәде, акча мәсьәләсендә бернинди кыенлык күрмичә, иркен яши башладылар: заманында ире алган ике бүлмәле «хрущевка»ларын сатып, яңа проект буенча салынган кирпеч йорттагы көләп торган өч бүлмәле фатирга кереп утырдылар, җәйләрен яшәр өчен Салмычыда ике катлы коттедж да салдырып куйдылар. Ел саен кая да булса чит илгә барып ял итәләр. Гәрчә Вадимы: «Ташла бу эшеңне, нервыңны бетереп йөрмә шул балалар янында, өйдә генә утыр!»—дип әйтә килсә дә, яраткан эшен ташлыйсы итмәде. Юк, акча өчен түгел, ә җаны шулай теләгәнгә эшләп йөрүе, чөнки эшсез ятуны күз алдына да китерә алмый, бу аның өчен яшәүдән туктау сыман. Сау-сәламәт килеш ничек дүрт стена эчендә бикләнеп ятмак кирәк?! Акылдан язарсың! Дөрес анысы, укытучының эше җиңелдән түгел—хәзерге балалар белән эшләү өчен нервыларың тимердәй булырга тиеш!

Ләкин мәктәптә укыганда ук укытучы булу турында хыялланган, аннары институт тәмамлаган, үз эшенә тәмам гашыйк кеше бит ул.

Әлфия Яшел Үзән мәктәпләренең берсендә унбиш ел физикадан укытты. Менә өч ел инде, балалар укытмый, ә өлкәннәр йорты директоры булып эшли. Бер дә мәктәбен ташлыйсы килмәгән иде дә, хакимияткә чакырып, бу эшнең дә бик җаваплы икәнен һәм аны нәкъ Әлфия шикелле тәҗрибәле педагог, балаларны сөйгән кеше җитәкләргә тиеш, дип аңлаткач, ике атна чамасы уйланып йөрде-йөрде дә, риза булды.

—Өлкәннәр белән эшләр өчен нигә балаларны сөйгән кеше кирәк?!—дип гаҗәпләнде ул.

—Балалардан да болайрак бит алар...—диде хакимият башлыгы.

Дөрес әйткән икән. Ул бу сүзләрнең асылына монда эшли башлагач кына төшенде. Әби-бабаларыбыз тикмәгә генә: «Алтыдагы акыл алтмышта», «Сигез яшьтәге холык сиксән яшькә кадәр», «Җидесендә ни булса, җитмешендә шул булыр»,—димәгән шул. Ләкин ни генә булмасын—өч ел эчендә төрлесе булды!—Әлфия бу эшен дә бөтен барлыгы белән яратты. Иртән эшенә дә очынып бара, кырыкмаса кырык төрле мәшәкатьләр белән көннең үткәнен дә сизми, җәмгыятьтә генә түгел, хәтта якыннарында да аңлау тапмаган, кимсетелгән бу карт-корыга, инвалидларга үзенең бик кирәкле кеше икәнен җаны-тәне белән төшенүе аның күнеленә—канәгатьлек, җанына тынычлык бирә иде.

Әйе, әле моңарчы шушындый кайгы белән күзгә-күз очрашканнары юк иде. Әлбәттә, тормыш дигәннәре борчуларсыз да бармый, ләкин аларны кичә киленнәре алып килгәне белән чагыштырып була идемени?! Ул күнелсез хәбәр мизгел эчендә бөтен тынычлыкларын җуйды да куйды: инде ике ел Чаллыда яшәүче малайлары Рафис эчкечелеккә сабышкан!.. Әти-әнисе түгел, аны күреп белгән күрше-күлән дә ышанмаслык хәбәр иде бу, чөнки ул тәртипле генә үскән, мәктәптә дә яхшы укыган, аннары, әтисе юлыннан китеп, төзүче-инженерлар институтын тәмамлаган, яшьтән үк әтисе кул арасына кереп үскән, эш сөючән, кулыннан җитәкләп йөрткәнне өнәмәгән, һәр эшне үзе белеп һәм үзенчә эшләргә яраткан, киләчәктә дә тормыш сукмагыннан әнә шулай: «Мин үзем! Мин үзем!»—дип мөстәкыйль адымнар белән атларга, һәрчак үзенең кемлеген раслап яшәргә җыенган бердәнбер малайлары иде бит! Институттан соң үзләре янында калдырасылары килгән иде дә, юк: «Мин үз сукмагымны үзем салырга тиеш!»—дип Чаллыга китеп барды. Шунда өйләнеп тә куйды, матур итеп туй үткәрделәр. Бер елдан, шатлыкларын арттырып, балалары туды. Баштарак яннарына еш баргалап йөрделәр, тормышлары—җитешле, тату гына яшәп яталар иде.

—Моңарчы сезгә белгертмичә килдем, ә хәзер... чыдар әмәлем калмады...—дип күз яшьләре белән елады киленнәре Луиза.—Яшәп була торган түгел аның белән—атналар буе эчә! Җитмәсә, өчәр-дүртәр көн юкка чыгып тора! Белмим, кайларда йөри торгандыр ул?! Булмый... аерылышырга гариза бирәм...

Киленнәре авызыннан иңнәренә мең потлы йөк булып ишелә барган чуен сыман авыр бу сүзләр аларга аяз көндә яшен суккандай тәэсир итте: башта ни әйтергә дә белмичә, өнебезме бу, төшебезме, дигәндәй, кымшанырга да базмыйча, бер-берсенә карап телсез калдылар. Аннары, үзара килешкән сыман, икесе дә берьюлы тирән итеп көрсенеп куйдылар. Көрсенү түгел, әллә нишләрсең монда, чөнки моңарчы ул-бу сизелмәгән, андый-мондый кыек юлларда йөргәне дә ишетелмәгән иде ләбаса! Әгәр шешә белән шулай артык мавыгып китсә, шушы көнгә хәтле беленмәс идемени?! Йа Хода, ничек бирелгән соң ул мондый афәткә?!

Ни уйларга да белмичә, тораташтай катып, тәмам аптырашта калдылар. Киленнәре белән бик озак сөйләшеп утырды алар. Аңа бирмәгән сораулары калмады, вакытында чаң сукмавы—үзләренә хәбәр итмәве өчен үзен дә шелтәләп алдылар. Вадим бүген иртән үк киленнәре белән Чаллыга чыгып

китте. Ә ул—эштә. Тик бернигә күнеле ятмый, бернигә кулы күтәрелми, уйлары һаман шушы коточкыч хәбәр тирәсендә бөтерелә: «Ничек шулай килеп чыккан сон бу?! Ул шешә белән дуслашырга тиеш түгел иде ләбаса, чөнки исерекләрне жене сөйми иде бит! Ниләр генә булган бу балага?! Эшендә берәр нәрсә килеп чыкканмы? Әллә никахлары нык булмаганмы? Алай дисән, бер-берсенен күзләренә генә карап торалар иде…»

Әлфия, хәтта күкрәгеннән сызгыруга охшаш нindидер зәгыйфь аваз чыгарып, тирән итеп көрсенеп куйды, кайгысын яшерер урын эзләгәндәй, шомырттай кара, ләкин бүгенге йокысыз төннән сон ничектер тоныкланып, монарчы гел очкынланып торган, хәзер нурлары сүрелеп калган күзләре белән кабинет түшәменә карап алды, аннары, арыган кыяфәт белән ашыкмыйча гына урыныннан торды да, тәрәзә янына килеп, урам ягын күзәтә башлады. Анда, инде көз хакимлек итүгә карамастан, быел кешеләрне июнь-июль айларында да сөендермәгән жылылык хөкем сөрә, күктә ник мендәр хәтле болыт әсәре булсын—ул, рәссам ясап куйган сыман, зәп-зәнгәр һәм чип-чиста, шактый ук югары күтәрелә төшкән кояш үзенен миллионлаган нурлары белән күзләрне чагылдырырлык итеп балкый, әйтерсен, әллә ничә төрле төсләргә кергән яфракларнын, монсуланып калган агачларнын, гомумән, көзнен искиткеч матурлыгын, гүзәллеген бөтен барлыгы белән күрсәтеп калырга тели. Бер сүз белән әйткәндә—әбиләр чуагы, табигатьнен һәрвакыт күркәм икәнлеген раслый торган вакытларнын берсе.

Кинәт анын күзе подъездан бер-бер артлы урам ягына килеп чыккан ике инвалид коляскасына төште. «Чыктылар!—дип куйды ул үзалдына, нindидер күтәренкелек белән.—Менә кайда ул көчле кешеләр! Инвалид булсалар да, аларга бернинди эчүчелек чире, бернинди наркомания афәте йокмаган, чөнки рухлары белән, мәхәббәтләре белән көчле алар! Ике аяклы, сау-сәламәт булып та үзәкләре черек, төрле зәхмәткә каршы тора алмаган, тормышта жилкәләрен гел жил унаена гына тоткан ихтыярсыз, жебегән адәм хәсрәтләренә менә кемнәрдән үрнәк алырга кирәк! Шушы аяксызларга карасан, дөньяда алардан да бәхетле кеше юк сыман! Мондый мәхәббәт сирәк була торгандыр… Ә сөю хакына шундый корбан биргән шушы хатын кебек, белмим, дөньяда тагын берәр хатын-кыз бармы икән?.. Юк, табылмас, мөгаен».

2

Бу йортта олыгайган көннәрендә ялгыз, караучысыз калган, яисә балалары, нindидер сәбәпләр аркасында хәтта якын туганнары янына сыеша алмаган карт-коры белән бергә берничә инвалид та яши иде. Әле генә подъездан килеп чыккан коляскаларда шуларнын икесе—ирле-хатынлы Гөлфирә белән Низаметдин Сәфәргалиевләр утыра.

Юк, мондый йортта яшәргә тиеш түгел иде алар, чөнки иренә—утыз өч, ә хатынына егерме сигез генә яшь әле. Ләкин, чыннан да, язмыштан узмыш юк икән шул. Бәла алар капкасын кыска гына вакыт эчендә хәтта берничә тапкыр килеп какты, аларны аерым-аерым да, икесен бергә дә сынады…

Хәер, алар бу турыда искә алырга яратмыйлар инде—йөрәк яраларын кабат яңартудан куркалар. Чөнки алар хәзер дә, шундый бәхетсезлекләрдән сон да … бәхетле. Әнә алар өлкәннәр йорты янындагы агачлыкка әбиләр чуагы белән өретелгән көзнен саф һавасын суларга чыккан.

—Карале бу яфракка, Гөлфирә! Анын берүзендә ничә төрле төс: күк йөзедәй зәнгәрсу да ул, кояш кебек янып та тора сыман!—диде Низаметдин, хатынына жирдән алган өрәнге яфрагын күрсәтеп.—Буяганнар диярсен!

Бу вакытта башын югары күтәреп өскә, үзенен төз кәүсәсе белән горурланып күккә ашкан мәһабәт нарат очына карап баккан Гөлфирәсе тиз генә ана таба борылды.

—Искиткеч!—диде ул, елмайганда ун бит очына куна торган кечкенә чокыры белән энжедәй ап-ак тешләрен күрсәтеп.—Монысы кичәгесеннән

дә матуррак! Алып керәсеңме?

—Ничек алмыйсың инде моны?!—Низаметдиннең куе кара кашлары, гаҗәпләнүдән дугаланып, маңгаена сикерде, шунлыктан түгәрәк, тик яңак сөякләре чак кына калкуланып торган бернинди тапсыз, чиста каратут йөзе, тарая төшеп, озынаеп калган сыман тоелды.—Ул бөтенесеннән дә матур бит!

—Синең ул яфракларың бер чемодан бугай инде!

—Булсын! Кышын рәхәтләнеп карап утырырбыз әле шуларны!

—Алла боерса, диген! Һаман онытасың шуны әйтергә.

—Алла боерса,—диде Низаметдин, хатыны сүзен тыңлап.—Күз алдыңа китер: тышта күз ачкысыз буран котырына, җил улый, ә синең белән без—кырын яткан килеш, җылыда!—үзләренә җәй, көз ис-төсләрен сеңдергән шушы аллы-гөлле яфракларны карап утырабыз! Безгә рәхәт, гүя тышта кыш та, буран да юк! Гүя синең белән без, менә хәзерге шикелле, яфраклары янып торган шушы агачлыкта йөрибез...

—Хыялый да инде син! Сине тыңлаганда егерме биш градуслы салкында да эссе дип изүеңне чишеп җибәрерсең!

—Егерме биш градус салкын салкынмыни ул?! Ә менә кырыкка якыны салкын дисәң дә салкын, ичмаса!—Низаметдин, шул салкынга хәзер дә туңган сыман, бөтен гәүдәсе белән калтыранып куйгандай булды.—Бер мәртәбә үзәгемә үтте шундый салкын...

—Кайда? Бер дә сөйләгәнең булмады...—Гөлфирә җәһәт кенә коляскасы белән аның янына килеп туктады.

—Нәрсәсен сөйлисең аның?!

—Йә, сөйлә инде, Низаметдин, сөйлә!

—Ярар, ярар... Шулай бер мәртәбә Волгоградка житәрәк—гел ерак рейсларга йөрдем бит мин!—машинам тырт-пырт килде дә ялан кыр уртасында туктады да калды. Алай итеп карыйм, болай итеп, юк, кабынмый гына бит! Инде караңгы да төшеп килә. Ә мин, бәхетсезгә каршы, берүзем—кулдашым бер якын туганының туена дип сорап калган иде. Нишлисең: «Ярар,—дидем,—түй гел булып тормый,—бер юлга гына ничек тә түзәрмен». Анысын тикшереп карыйм, монысын—юк, әле генә гөжләп килгән машина кабынырга уйламый да! Нишләргә? Инде трассада машиналар да сирәгәйде, ара-тирә генә үткәннәре дә, туктамыйча, выжылдап кына узып китә! Берәрсе туктаса, минем жансыз тимер-томыр кисәген шәһәргә таба өстерәтергә исәп. Юлда басып тора-тора туңып беттем—кыш бит, суыклык кырык градуслар чамасы бардыр! Житмәсә, кырда шактый ук себертә дә башлады! Машина кабынса, кабинада җылыныр идең дә... Юк, ул төнге юлда карачкыга охшап тик тора. Туктале, дидем бераздан, минем искерәк тәгәрмәч бар лабаса, шуны ягып җылынырга кирәк! Кузовтан шул баллонны ышыграк якка төшереп аңа бактан солярка алып сиптем дә шырпы сызып җибәрдем. Шул ут янында кайнаша-кайнаша төн чыктым. Ул баллон гына житмәде, әлбәттә, тагын шактый чүпрәк-чапрак, хәтта машина астында ятарга туры килсә кирәге чыгар, дип йөрткән бушлатыма да шунда янарга насыйп булды. Ярый әле, ягар нәрсәләр таптым! Алар булмаса, аяк-куллар шакырдап ката иде. Иртән карыйм, минеке шикелле бер КамАЗ машинасы килеп туктады. Әнә шул мәрхәмәтле бәндә машинамны Волгоград шәһәренең бер гаражына тикле өстерәп алып барды. Рәхмәт төшкере, анда аны төзәтергә дә булыштылар. Менә шулай, Гөлфирәкәй җаныем, ничә еллар буе юллар үлчи-үлчи төрле хәлләргә очрарга туры килде Низаметдин абыеңа!..—Ул сүзен шулай шаярып тәмамлады.

—Бу турыда бер дә сөйләгәнең булмады,—диде хатыны, аның кулларын үзенең йомшак, кайнар кулларына алып.

—Моның нәрсәсен сөйлисең? Шоферлар өчен гадәти нәрсә ич бу!—Низаметдин, иркәләнергә теләгән бала-чага сыман, маңгаен аның чигәсенә төртте.

—Үзе туңып үлә язган, үзе, нәрсәсен сөйлисең, дип торган була!

—Тәнендә җаны булган ир-ат ничек туңып үлсен?! Андый кеше үзен ир-ат дип йөрергә дә тиеш түгелдер, алай бик тиз бирешерлек булгач...—Кинәт Низаметдин хатынының колагына:—Без нишләп соң очраштык икән, ә, Гөлфирә? Иртәрәк очрашасы калган безгә, иртәрәк! Әйеме?—дип пышылдады.—Никадәр вакыт әрәм узган!..

—Язмыштан узмыш юк, диләр. Дөрестер, мөгаен.—Гөлфирә кулы белән иренең вакытсыз кырау төшә башлаган, бераз дулкынланып торган кара чәчен сыйпарга кереште.—Ул кайчан нәрсә буласын, киләчәктә нәрсәләр күрәсен кеше дөньяга тәүге авазын салуга ук язып куя ди. Шул язганны күрми дә калып булмый, аннан качып та котыла алмыйсың ди. Димәк, ул безне дә үз вакытында очраштырган дип уйларга кирәк. Нәкъ без туганда язып куйганча...

—Күрәзәче әбиләр шикелле син!—дип көлде Низаметдин һәм, йөзенә ниндидер моңсулык чыгарып башын күтәрде дә, хатынына карады.—Әйт әле, Гөлфирә, син... тик дөресен-дөресен генә... язмышыңны минем белән бәйләвеңә чыннан да үкенмисеңме?

—Вакыты-вакыты белән әллә ниткән юләр сораулар бирәсең...—Гөлфирә, кинәт кулын кискен генә тартып алды да, үпкәләп, ачулы йөзен читкә борды.—Һаман ышанмыйсың... Һаман ярама тоз сибәсең...

—Туктале, Гөлфирә, туктале! Син нәрсә инде?!—Үзенең соравы белән хатынының авырткан җиренә кагылуын аңлап алган Низаметдин, бу ялгышын ничек төзәтергә белмичә, өзгәләнеп, аны үзенә таба каратырга тырышты.—Минем бары тик: «Юк, һич үкенмим!»—дигән сүзеңне генә ишетәсем килгән иде. Башка нәрсә уемда да булмады, валлаһи! Гафу ит, ачуландырырга уйламаган идем... Йә инде, Гөлфирә, кара инде миңа! Шуны ишеткәч, яңадан туган шикелле булам бит мин...

—Эгоист кеше шикелле гел үзең турында гына уйлама!—диде инде бераз йомшара төшкән хатыны, аңа таба борылып.—Ярамый алай! Сине яңадан тудырырга тиешле ул сүзләрнең мине кабат үтерергә мөмкин икәнлеген дә истән чыгарма. Элеккеге газапларыма кайтарасың ич син мине! Ә минем аларны кабат кичерәсем килми... Килми! Мин дә җансыз агач бүкәне түгел ләбаса! Аңлыйсыңмы син шуны?—Гөлфирәнең күзендә яшь ялтырап китте.—Мин сөюемне расладым түгелме соң инде?!.

—Гафу ит, Гөлфирә, зинһар, гафу ит! Әллә ничек килеп чыкты. Һич тә ачуландырырга теләмәгән идем. Хәзер мин сиңа үземә ышанган кебек ышанам бит! Ярар, тынычлан! Әйе, эгоист бугай шул мин... Тик сине сөйгәннән генә ул...

Икесе дә тынып калды. Әллә ниткән шомлы һәм икесе өчен дә мәңгелек булып тоелган эчпошыргыч тынлык иде бу. Бераздан аны Гөлфирәнең ягымлы тавышы бозды.

—Кирәргә кирәк, төшке аш вакыты җитеп килә бугай...—диде ул, яшьләрен сөртеп.

«Шөкер, кичерде бугай!»—дип уйлап алды Низаметдин, бер үк вакытта күңеленнән сөенеп тә, хатыны алдында үзен әле һаман гаепле дә санап.

Һәм ике коляска бер-бер артлы ашыкмыйча гына подъездга таба тәгәрәде.

3

Алар моннан өч ел элек «Ялгызлар клубы»нда таныштылар. Инде икесе дә яшь-җилкенчәк түгел: Низаметдин—утызынчы, ә Гөлфирә егерме бишенче яше белән бара иде.

Низаметдин малай чагыннан ук бик оялчан табигатьле булып үсте, иптәшләре мәктәптә укыганда ук берничә кыз белән танышып өлгерсәләр, ул исә алар катына барырга да кыймады. Аннан соң нигәдер аны кыз-кымызлар

ягына бик тартмады да. Ул яшьтән үк техникага гашыйк иде. Кулларына өлгергәнлек аттестаты алган иптәшләре төрле институт ишекләренә ябырылганда, мәктәпне яхшы гына тәмамлаган Низаметдин, аларны гаҗәпләндереп, шоферлар курсына барып керде, аннары бер автохуҗалыкка эшкә урнашты. Ярты ел да үтмәде, тәҗрибәле бер шоферның кулдашы булып ерак рейсларга, үзләре әйтмешли, «дальняк»ка йөри башлады. Кая инде монда кызлар кайгысы—кайчак унар-унбишәр көне юлда уза. Җитмәсә, ике ел солдат шулпасын да чөмерде әле! Армиядән дә яраткан шул эшенә әйләнеп кайтты.

Елны еллар алыштыра, ә алар исә аның яшен саный торды. Әтисе белән әнисе олы малайларының әле һаман килен алып кайтырга җыенмавына борчыла ук башлады. Хәтта үзе дә бөтен гомерен машина руле артында уздырып пенсиягә чыккан әтисе Гарәфетдин—әле дә көч-куәте сизелеп торган, чәчләре яртылаш агарган карт—бу турыда үзе сүз кузгатып карарга мәҗбүр булды.

Шулай бер көнне кичке аштан соң балконнарына тәмәке тартырга чыккач, ул, инде төссезләнә төшкән коңгырт күзләре белән аңа сынаулы караш ташлап алды да:

—Йә, сөйләп җибәр, улым, хәлләр ничек?—дип сорап куйды.

—Хәлләр?!—дип гаҗәпләнде Низаметдин, чөнки әтисе аның эше турында гел хәбәрдар иде.—Хәлләр яхшы. Берсекөнгә Ставрополь ягына чыгарга җыенабыз менә... Безнең эшне беләсең ич, әти, нигә соравың?

—Тормыш гел эштән генә тормый бит, улым. Күп төрле ул...

—Аңламыйм, нинди хәл турында сорыйсың соң син, алайса, әти?

—Хәзер сиңа ничә яшь инде?—диде әтисе, малаеның үзенеке шикелле үк коңгырт күзләренә туры карап.

—Монда яшьнең ни катнашы бар?!

—Вакыт үтә, яшең бара... Ә син өйләнү турында уйламыйсың да! Буйдак булып калырга җыенмыйсыңдыр бит?

—Менә син ни турында икә-ә-н,—дип елмайды Низаметдин.—Өлгерербез әле, әти, башка кайгың булмаса, юкка кайгырма!

—"Өлгерербез", имеш...—дип кабатлады әтисе, иренenә мыскыллы елмаю чыгарып.—Һәр нәрсәнең үз вакыты бар аның, улым. Әниең белән без картая барабыз. Оныкларны сөясе килә башлады... Күптән вакыт бит инде! Менә монысы да хәл, монысы да эш аның...

—Шулайдыр да, тик кызлар күзләргә вакыт юк бит әле, әти...

—Бу яшьтә дә кызлар белән йөрмәгәч!.. Ашык-пошык кына өйләнеп куярсың аннары... Ә хатынны йөреп, карап-сынап алырга кирәк. Уен эш түгел!

—Ярар, йөрербез, карарбыз, сынарбыз, әти!—дип елмайды Низаметдин, аның сүзләрен кабатлап.

Дөресен генә әйткәндә, өйләнү турында шушы сөйләшүдән соң гына уйлана башлады ул. Чыннан да, дус-ишләре инде күптән өйләнешеп беттеләр. Хәтта кайберләре икешәр бала атасы инде! Хаклы бит әтисе, хаклы: аңа да күптән вакыт! Ә аның әле сөйгән кызы да юк. Өйләнү өчен бит башта сине ярты сүздән аңлый торган яр табарга кирәк. Ә гел ерак юлларда йөргән кеше андыйны ничек тапсын?! Хәер, теләгәндә вакытын да табарга булыр иде дә... тик кызлар янына бару өчен кыюлык, алар белән сөйләшә белерлек тел дә кирәк бит әле! Ләкин, нишләтәсең, анда боларның берсе дә юк. Менә бит кайсы ягы бар бу мәсьәләнең! Ә алар үзләре килеп сүз катмый. Күпләр өчен чын бәлагә әйләнгән шул кыюсызлыкны, оялчанлыкны җинәрдәй берәр дару да уйлап чыгармыйлар, ичмаса! Дөрес, хәзерге яшьләрнең күбесе монын ише нәрсәне аракы белән җиңәргә тырыша. Тик аның өчен түгел шул бу гамәл—аракысын да, эчкән кешеләрне дә җене сөйми!

Бәлки, берәрсе белән белдерү буенча танышып карарга кирәктер? Аларны

хатын-кызлар да яза бит хәзер! Юк, бармый бу юл, бармый. Беркөн ерак юлларда йөргәндә беренче дустына әйләнгән радиодан, андый белдерүләр аша табышканнарның сирәге генә гаилә кора, гадәттә, аларда гүзәл затлар үзләрен бик арттырып мактыйлар, дип сөйләделәр.

Туктале, хәзер танышу өчен махсус кичәләр дә бар түгелме соң? Анда кыз-кымызны үз күзләрең белән күрергә була. Монда мәхәббәт аңлатып кызарасы, азапланасы да юктыр, чөнки алар үзләре дә пар эзләп килә ич! Булды, мәсьәләгә бераз ачыклык керде: аның өчен иң яхшысы шушы! Шундый кичәләр турында белешергә дә... тәвәккәлләргә! Буйдак исемен йөртергә гарип-гораба түгел лә ул!

Ниһаять, бер ял көнендә, бөтен кыюлыгын бер йодрыкка төйнәп дигәндәй, шундый кичәгә китте.

Юкка шикләнеп йөргән, бер дә куркырлык жир түгел икән! Монда барысы да ачыклар, ягымлылар. Хәтта шундый ачыклар, әйтерсең алар бу кичәгә үзләренә пар эзләп түгел, ә инде табылган ярлары хөрмәтенә ял итәргә килгәннәр: бер-берсе белән чөкердәшеп сөйләшә-сөйләшә бииләр, төрле уеннар уйныйлар. Кичәдәге җылы халәтне килеп керүгә үк сизеп алган Низаметдин, бераздан, үзенең тартынуын тәмам онытып, бөтенләй тынычланып калды һәм юллар игътибарлы булырга өйрәткән коңгырт күзләре белән берсеннән-берсе матур киенгән, берсеннән-берсе чибәр кыз-кымыз халкын күзләргә кереште.

Егетләр кебек үк, аларның да төрлесе бар иде монда: чем-кара, аксыл, сары чәчле чибәрләр дә, хәтта ирексездән: «Бу туташ күп газаплар күрергә өлгергән икән, башына нинди кырау төшкән!»—дияргә мәҗбүр итәрлек көл төсендәге чәчләре дә. Соңыннан белде: шулай буялган гына икән алар!

Низаметдиннең бер күрүдә гашыйк булу хәлләре турында әле монарчы китаплардан гына укыганы бар иде. Ышанмый да, исе дә китми иде мондый хәлләргә: аның өчен гашыйк булсалар ни дә, булмасалар ни. Җаны теләгән елан ите ашаган ди. Бер күрүдә гыйшкы төшү түгел, монарчы аның, гомумән, мәхәббәт хакында уйланганы да булмады, аның нинди җимеш икәнен татып карамаган иде әле ул. Аны аңлар өчен ул хисне үзенә кичерергә кирәк бит...

Кинәт үзеннән ерак түгел генә ни турындадыр елмаешып сөйләшеп торган ике кызның берсе шундук игътибарын җәлеп итте. Алай гына да түгел, хәтта ул аны инде күптәннән белә шикелле тоелды. Шунда Низаметдин ирексездән кулы белән галстугын рәтләп куйды, аннары шул мизгелдә бармаклары белән ни өчендер кинәт кенә муенын кыса башлаган күлмәк якасына кагылып алды һәм төкереген йотып җибәрде. Хәтта аны йотканда тамак төбеннән ниндидер аваз чыккан сыман тоелды, шуна күрә, кеше ишетмәдеме, дигәндәй, тиз генә тирә-ягына каранып алды.

Кыз чибәр иде. Уртача буйлы («Карале, буе да минеке шикелле!»), арттан бәрхет чәчтоткыч белән эләктереп куелган шактый озын кара чәче бик таралмыйча гына җилкәсенә сибелгән, чиста, түгәрәк, алсуланып торган йөзеннән («Исеме дә Алсу түгелме икән әле!») ниндидер нур бөркелә сыман, матур булсын, дип тырыша-тырыша кылкаләм белән сызган кебек күренгән нечкә, кыйгач кашлары битенә, маңгаена ниндидер табигый гүзәллек өстәп тора.

Низаметдин ирексездән күңеленнән: «Мин эзли торган кыз бит бу!—дип сөенеп куйды.—Күр син аның матурлыгын!» Тик шунда үзенең кайда, нинди жирдә икәне исенә төште дә, кинәт күңелен: «Ә нишләп монда килде икән ул?! Бу гүзәллеге белән нигә кияүдә түгел?»—дигән сораулар тырнап узды. Дөрес, аларга артык җәелергә ирек бирмичә, шундук үзен: «Тормышта ни булмас!..»—дип тынычландырырга тырышты. Чыннан да, аның китаплардан, тормышта бик чибәр кызларга яр табуы авыр дип укыганы бар. Егетләр андый чибәрләргә мәхәббәтләрен белдерергә кыймый икән. Янәсе: «Күр,

ул нинди чибәр, ә аның янында мин...» Ә икенче берәүләре исә, мондый чибәр кызның, әлбәттә, сөйгәне бардыр инде, дип уйлый. Шулай итеп, алар янына барып карауЧы да булмый. Нәтиҗәдә ир-атлар: «Бер кашык су белән йотарсың, валлаһи!»—дип сокланып йөргән чибәр-чибәр кызлар, кияүгә чыга алмыйча, утырып кала икән...

Кызның өстендәге зәңгәрсу күлмәге дә, кайберләрнеке кебек, әллә кайдан күзгә бәрелеп тормый: чигелмәгән-чукланмаган дигәндәй, гади генә, ләкин ул әнә шул гадилеге белән үзенә бик тә килешеп тора. Колагындагы кечкенә алкасының ялтырап-ялтырап китүе дә кызга ниндидер серле матурлык өсти сыман. Икенчедән, киенү рәвеше, бизәлмәгән йөзе дә, шушы кечкенә алкасы да аның самими табигыйлеге, гадилеге турында сөйли иде бугай. Болар барысы да Низаметдин күңеленә сары май булып ятты, чөнки артык ясанган-бизәнгән, үзе әйтмешли, «штукатурланган», минем алкам гына да күпме тора, дип мактанырга теләп колакларына йодрык хәтле алтын алкалар таккан хатын-кызларны җене сөйми аның—үзе гади булганлыктан, ул гүзәл җенесләрдә дә гадилекне өстен күрә иде.

Әйтәсе дә юк, кыз Низаметдингә бер күрүдә үк ошады. Тик аңа ничек сүз кушасы да, аның белән ничек сөйләшеп китәсе? Тиктомалдан гына янына килеп: «Миңа бик ошыйсыз, сезнең белән танышырга телим»,—димәссең бит! Шул ук вакытта кулыннан да ычкындырасы килми: кем белә, берәрсе, аның шикелле, читтән генә карап тормыйча, аны биергә чакырса? Шунда сөйләшеп китәрләр дә, калырсың аннары тәп башына утырып! Менә шулай, Низаметдин, монда килергә кыюлыгың җиткән икән, башкасына да әзер бул, җебеп торма! Кем җебегән әле монда?! Хәзер, хәзер... Күрәсең бит, ничек серләшәләр! Сүзләрен генә бүлдерәсем килми... Әйттең сүз! Бәлки, алар кич буе сөйләшер?!

Юк, чыннан да, тәвәккәлрәк булырга кирәк, тәвәккәлрәк! Кинәт шул вакытта талгын гына музыка яңгырый башлады да, ул, күңелендә барган бәхәскә нокта куеп, стенага сөялеп торган җиреннән үз-үзен ирексезләп йолкып алгандай итеп, көлешә-көлешә сөйләшеп торучы шушы ике кыз ягына атлады.

—Гафу итәсез, сезне чакырырга мөмкинме?—диде ул, читтән күзәтеп торган теге кыз янына килеп.

Кыз исә, иптәшенә, нишлисең, чакыргач чыкмыйча булмый инде, гафу ит, дигәндәй, ничектер гаепле кеше сыман елмаеп карап алды да, Низаметдингә кулын сузды.

Алар бөтен кичә буе гел икесе бергә биеделәр. Берничә ир-ат кызны чакырып караган иде дә, ул итагатьле генә итеп гафу үтенде.

Шушы кичәдән соң җитәкләшкән килеш сөйләшә-сөйләшә йөреп, алар таңны Казан урамнарының берсендә каршы алдылар. Тагын өч айдан хатыны булачак Гөлфирә исемле бу кыз белән сөйләшүе җиңел, хәтта аның белән янәшә атлаганда ничектер сулыш алуы да иркен, рәхәт иде. Әйтерсең инде алар моннан берничә ел элек үк таныш булганнар да, бераз гына аерылып торганнан соң менә тагын очрашканнар! Ул кешене тыңлый белә, тиешле-тиешсез җирдә сүзенне бүлдерми, киресенчә, сүз очын югалтырга ирек бирмичә, әңгәмәне тиешле юнәлештә алып барырга булыша, һәр сүзен үлчәп кенә сөйләшә. Аның бөтен халәтеннән, хәтта ашыкмыйча, салмак кына атлавыннан да сабыр холыклы икәнлеге сизелеп тора. Әнә шул сабырлыгы белән дә җәлеп итте ул Низаметдинне.

«Нәкъ минем иш!»—дип җөпләп куйды ул күңеленнән, бүгенге бәхетеннән исерә-исерә. Дөрес, сүз кызның кайда, кем булып эшләве турындагы сорауга җиткәч кенә «минем иш!» дигән ул сөенече кинәт якты, ачык төсмерен югалта төште, чөнки Гөлфирә, институт тәмамлап, бер оешмада икътисадчы булып («Юк, миңа тиң түгел бу чибәркәй!..») эшли икән. Кыз үзенең җавабыннан соң аның кинәт кенә ничектер күңелсезләнеп калуын үзенең нечкә күңеле

белән шул мизгелдә үк сизеп алды. Һәм аның нindидер өметсезлек белән әйткән: «Әй мин гап-гади шофер гына...»—диюенә каршы йомшак кына:

—Эш кешенең кем булуында түгел бит, Низаметдин, нинди булуында!—диде. Һәм дәшмичә берничә адым атлаганнан соң үз-үзе белән сөйләшкәндәй, уйчан гына:—Кеше чын мәгънәсендә кеше булсын ул! Аның беренче шарты исә—эчкерсез, ышанычлы булу,—дип өстәп куйды.

4

«Әйт әле, Гөлфирә, син... тик дөресен генә... язмышынны минем белән бәйләвенә чыннан да үкенмисеңме?»

Низаметдине авызыннан чыккан бу сүзләр Гөлфирәне ирексездән үткәннәренә алып кайтты. Хәер, алай авыз тутырып, үткәннәр дип әйтерлекләре дә юк иде әле аларның, чөнки танышып-кавышып бергә яши башлауларына да өч кенә ел! Тик шушы кыска гына вакыт эчендә дә кайберәүләр гомерләрендә дә күрмәгәнне күрергә, гомерләрендә дә кичермәгәнне кичерергә туры килде инде аларга. Язмыштан узмыш юк, дигәнне шушы кыска тормышлары да раслый: анда аларның бәхетләре фаҗигаләр белән бергә үрелгән...

Кешенең табигате шулай инде, теләсә-теләмәсә дә, ул үткәннәре белән яши, аларга кабат-кабат әйләнеп кайта. Гөлфирә дә бәхетле мизгелләрен еш исенә төшерә, аларны кабат кичергәндәй, ирексездән елмаеп-елмаеп куя. Хәтта кайчак күзләрен йомып, башын кулларына салып, татлы кичерешләргә талырга ярата. Әйе, әйе, күзләрен йомып! Шунда ул рәхәтләнеп искә алырга яраткан мизгелләр аның аяз күнге зәңгәр һава сыман зәп-зәңгәр күзләре алдына тагын да ачыграк, тагын да бәхетлерәк, матуррак булып килеп баса һәм үткәннәренең үзе һич тә хәтерләргә теләмәгән, үзен кара кайгыларга салган, сары сагышлары белән йөрәген әле хәзер дә чәнчеп-чәнчеп ала торган тирән яралар калдырган ямьсез мизгелләренә тиз генә урын бирмичә, күз алдында озаграк тора, озаграк саклана сыман. Мондый вакытларда аннан да бәхетле кеше юк! Күнеленнән кабат-кабат кичерергә яраткан әнә шул матур кичерешләре белән бәхетле иде ул. Ә андый мизгелләр булды бит алар тормышында, булды! Хәтта бергә яши башлаганчы ук, танышкан кичләреннән үк бәхетле иде алар, чөнки бер-берсен беренче күрүдә үк ошатыштылар. Уртача буйлы, коңгырт күзле, янаклары бераз калкулы, каратут чырайлы Низаметдин теләсә нинди чибәр кызлар күңелен дә яулардай егет иде шул!

Тора-бара, юк, беренче көннән үк бугай, аларда күп кенә уртак яклар булуы да ачыкланды. Мәсәлән, бу кичәгә икесенең дә тәүге килүләре генә икән. Тик аерма шунда гына: егет кеше буларак Низаметдин килергә, ниһаять, үзе батырчылык итсә, Гөлфирәне исә иптәш кызы өстерәп диярлек алып килгән—ул да, аның шикелле үк, оялчан, шау-шулы мәҗлес-кичәләрне, буш күңел ачуларны жене сөйми. Бу турыда сөйләшкәндә икесе дә балалар шикелле рәхәтләнеп көлгәннәр иде. Холыклары шул кадәр дә туры килер икән!

Аннары—бер-берсен өзелеп сагынулардан, зарыгып көтүләрдән соң булган очрашу мизгелләре... Дөрес, көткәннәреннән сирәк иде ул очрашулар, чөнки Низаметдин еш кына ерак юлларда була. Аның каруы ничек сагынып кайта иде ул! Машинасын гаражга да куеп тормыйча—кайтышлый ук!—янына очынып килеп керә дә, шатлыгыннан уттай янып торган күзләре белән көйдереп:

—Мин сине шундый сагындым, Гөлфирә! Белсәң икән!..—дип ана чәчәк бәйләме суза. (Ул аның янына бервакытта да чәчәксез килмәде!)

Әлбәттә, мондый чакларда Гөлфирә бергә эшләүче иптәшләреннән уңайсызлана. Ә алар ана җылы караш ташлап (кем белә, бәлки, кайбере көнләшептер дә):

—Бәхетле син, Гөлфирә!—диләр.—Тизрәк чык инде син аңа! Ярата бит ул сине.

—Әле безнең танышканга да…—дип куя бит очлары кызарган Гөлфирә.—Бүген танышып, иртәгә кияүгә чыкмыйлар…

—Соң, заманасы шулай аның хәзер: иртән танышалар, кичкә өйләнешәләр!—дип көлешә кызлар.—Кара аны, мондый егетләр юлда аунап ятмый!

—Аунап ятканнарының кирәге дә шул хәтле генә,—дип елмая Гөлфирә һәм, бетерик бу сүзне, дигәндәй, күзләрен компьютер экранына юнәлтә. Ә үзе эченнән генә дулкынлана-дулкынлана, ләкин моны сиздермәскә тырышып, түземсезлек белән эш сәгатенең тизрәк тәмамлануын тели башлый: кичен аны сөйгәне белән очрашу көтә бит!

Алар барлыгы өч айдан чак кына артык йөрделәр. Бер дә бер көнне—Гөлфирә аны яхшы хәтерли—Мәскәүгә барган жиреннән, гадәттәгечә, кайтышлый ук янына килеп кергән Низаметдине башта, аны менә хәзер беренче генә тапкыр күргәндәй, хәтта кулындагы чәчәген дә сузмыйча, бермәл аңа сүзсез генә карап торды. Гажәп, мондый чакларда үзенә бертөрле жылылык, бар сагынуын аңлата торган: «Мин сине шундый сагындым, Гөлфирә! Белсәң икән!..»—дигән сүзләрен дә әйтмәде. Үзенең күзләре яна! Шулай беравык карап торганнан соң гына телгә килеп, кулындагы чәчәк бәйләмен селки-селки ниндидер ярсулык белән, кискән сыман өзеп-өзеп:

—Житте, Гөлфирә! Мин башка болай түзә алмыйм! Теләмим!—диде.

Гөлфирә хәтта куркып калды: «Ни булган? Нәрсәне теләми?»

—Берәр нәрсә булмагандыр бит, Низаметдин?—дип сорады ул, үзенең бәрхеттәй йомшак, ягымлы тавышы белән һәм, үпкәләгән сыман, иренен турсайтып куйды.—Исәнләшмәдең дә… Нәрсәне теләмисең?

—Әй, гафу ит, Гөлфирә!—диде Низаметдин, исенә килеп, һәм аңа кулындагы чәчәкләрен сузды.—Сагынуга түзә алмыйм мин, Гөлфирә… Башка түзәргә теләмим дә! Авыр газап бу…—Ул, иелә төшеп, калганын аның колагына пышылдады:—Кыскасы, очрашу вакыты да, урыны да элеккечә. Калганын шунда сөйләшербез…

—Ярар, аңладым. Исәнме!—дип кулын сузды Гөлфирә, уңайсызлануыннан нишләргә белмичә.

—Исәнме, Гөлфирә, исәнме!—диде Низаметдин һәм, ничек очынып килеп керсә, шулай очынып чыгып та китте.

Кыз аның артыннан иңнәрен сикертеп, гажәпләнеп карап калды.

—Менә күрерсең, бүген кулыңны сораячак ул!—дип елмаешты иптәшләре.—Ишеттең бит, башка түзә алмыйм, диде! Әй, бәхетле дә инде син, Гөлфирә!

—Әйтерсез тагын!..—дип кулларын селтәде ул.—Фантазер сез!

—Карале, кара, шатлыгыннан безне гаепләргә маташа, ә!—дип иптәшләре дәррәү көлешеп алдылар.

Дөресен генә әйткәндә, Низаметдин сүзләре аны, бер яктан, гажәпләндерсә, икенче яктан, яшертен генә булса да, кайдадыр тирәндә, күңеле түрендә: «Әллә?..»—дигән яшертен сорау туып, башында әле генә кызлар әйткән нәрсә турындагы уй да ялтырап китте.

Ул көнне кичен Низаметдин, күрәсең: «Күп сүз—юк сүз»,—дигән гыйбарәне истә тотып булса кирәк, көндезге сөйләшүен, кемдер әйтмешли, үгезнең мөгезеннән алып, хәтта ниндидер һавалык белән, бернинди кереш тә ясап тормыйча, дәвам итте:

—Әйдә өйләнешәбез, Гөлфирә!—диде ул, аны үзенә таба тарта төшеп.—Күпме йөрергә була болай тилмереп?!

—Әле танышуыбыз кая, син инде кавышу турында… Иртәрәк түгелме, Низаметдин?

—Соң, өч ай йөрибез бит инде!

—Борынгылар: “Кешене белү өчен аның белән бер пот тоз ашарга

кирәк",—дигәннәр. Ә без бер-беребезне белеп бетердекме икән соң әле?

—Мин сине әллә кайчаннан бирле беләм шикелле инде! Кыскасы, ни... киләчәк тормышымны синнән башка күз алдыма да китерә алмыйм мин, Гөлфирә. Тартмыйк, сузмыйк...—Низаметдин, ниндидер ләззәт кичереп, бармаклары белән аның чигәсендә бөдрәләнеп торган чәчләренә кагылды.— Йә, ни әйтерсен?

—Сиңа ни булды соң әле, Низаметдин?!—дип гаҗәпләнде Гөлфирә, кыйгач кашларын маңгаена чөеп.—Нигә ашыгасың шулай? Әйтерсең, артыннан куалар...

—Беркем дә кумый анысы...—диде Низаметдин, ләкин шунда кылт итеп әтисе белән булган беркөнге сөйләшүе исенә төште бугай, ирексездән төртелеп калды. Тик аны әйтеп торуны кирәк тапмады.—Беләсеңме нәрсә, Гөлфирә... Ерак юллардан соң минем зарыгып көткән хатыным янына кайтып керәсем килә башлады...

—Мин сине болай да зарыгып көтеп алам бит, Низаметдин! Ни кирәк инде сиңа тагын?

—Аңламадың син мине, Гөлфирә... Хатыным янына, дидем бит мин!— Низаметдин «хатыным янына» дигәнне басым ясап әйтте.

Кыз уйга калды. Шактый озакка сузылгандай булды аның бу тынлыгы. Тик бераздан гына, Низаметдиннең күзләренә карап, әкрен генә:

—Бер атнадан җавап бирермен...—дип куйды.

—Бер атна бик озак бит ул, Гөлфирә! Нәрсәсен уйлыйсың инде аның?!

—Ашыккан ашка пешкән, диләр. Үзең дә уйла!

—Мин күптән уйлаган инде!

Чыннан да, бер атнадан соң Гөлфирә аңа кияүгә чыгарга ризалыгын бирде. Матур гына итеп туй үткәрделәр дә Низаметдиннең әти-әнисе, энесе белән бер фатирда яши башладылар. Өч бүлмәле фатирның зур бер бүлмәсе аларныкы иде.

Иренең әти-әнисе дә бик ошатты аны, гел «кызым!» дип кенә йөрттеләр. Бәлки, үзләренең кыз балалары булмаганга шулай яратканнардыр. Күп кенә киленнәрнең каенана-каенаталары белән этле-мәчеле яшәүләре турында адым саен ишетеп торган Гөлфирә, аны яраткан, үзенең күңеленә дә, җанына, рухына да бик якын булган ире өстенә, бу яктан да чиксез бәхетле иде. Ул мөлаем кешеләр исенә төшкәндә әле хәзер дә үзәкләре өзелеп китә, күзләреннән яшьләр бәреп чыга...

Әйе, рәхәтләнеп искә төшерердәй, үзен бәхет күгенең җиденче катында итеп сиздергән андый матур-матур мизгел-хатирәләр шактый булды шул ул кыска гына үткәннәрендә. Ләкин...

## 5

Ләкин Гөлфирә беркөн дөньяда үзе өчен иң кадерле, иң якын кешесе булган Низаметдиненә: «Минем аларны кабат кичерәсем килми... Килми! Мин дә жансыз агач бүкәне түгел лабаса!»—дип тә юкка гына әйтмәде бит. Бу сүзләр тикмәгә генә әллә кайдан тирәннән, күңеле төпкеленнән килгән ниндидер әчке сыкрану, хәтта җан ачысы белән ыңгырашу сыман, ачынулы ярсулык белән чыкмады лабаса! Шул кыска гына үткәннәренең кайбер сәхифәләрен кабат искә төшерәсе, кабат кичерәсе килмәгәнгә күрә тышка чыкты ич ул сүзләр...

Үткәннәрнең йөрәкне әле хәзер дә дулкынланып еш-еш тибәргә мәҗбүр иткән бәхетле мизгелләрен хәтерләве күңелен авыр сагышларга ташлый, бәгырьне үтмәс пычак белән сызып җибәргәндәй итә торганнары үзара шундый үрелгән ки, аларны бер-берсеннән һич аерып булмый—тормышта бәхет белән фаҗига, шатлык белән кайгы янәшә, кулга-кул тотышып атлый икән... Алар синең искә төшерергә теләмәвеңне сорап торалармыни?! Кайчандыр күңеленә авыр яра булып сенеп калган ул күңелсез мизгелләр,

киресенчә, күңелләрләренә караганда ешрак искә төшеп, юри тинтерәткән, юри чыгырыннан чыгарырга тырышкан сыман: «Онытмадыңмы? Онытма!»—дип шул йөрәк яраңны әледән-әле яңартып, әледән-әле үзәгенне өзеп тора.

Башта Низаметдинен, соңыннан Гөлфирәнең үзен дә аяксыз калдырган, булачак балаларын ана карыныннан ук тартып алган шундый фаҗигаләрнең берсе—аны күңелсез мизгел дип кенә әйтергә кемнең генә теле әйләнер икән?!—алар гаиләсенә истә-төштә булмаган телеграмма рәвешендә килеп төште...

Шау-гөр килеп сөйләшә-сөйләшә кичке ашны ашап утырулары иде... Низаметдин берничә көн элек кенә Омск шәһәренә китеп барды. Өстәл янында сүзнең очы, гадәттәгечә, олы малаеннан аермалы буларак, сүзгә оста, җор телле каенатасы Гарәфетдин кулында. Бүгенге табын янындагы сүзе телевидение һәм радиодан туктаусыз яңгырап торган мәгънәсез, үзе әйтүенчә, тозсыз җыр сүзләре, татар көеме, әллә урысныкымы икәнен дә аңлап булмаган җырлар турында иде. Бу мәсьәләдә яхшы мәгънәдә «милләтче» иде ул: тел бозуларга, җәмәгать урыннарында татарларның үзебезчә сөйләшергә базмауларына җен ачулары чыга инде!

—Әллә, мин әйтәм, безне телдән генә түгел, моннан да аеру өчен юри әйләндерәләрме икән ул җырларны? Аларда саф татар сүзләре калмый да бугай инде. Көлке бит: «мәхәббәт» «мәхәпәт»кә, «һәм»—хәтта дикторлар телендә дә!—«хам»га, «шәһәр» «шахар»га әйләнде,—дип Гарәфетдин ачуыннан кулын селтәп куйды.—Үз татарыбыз җырлый, үз татарыбыз сөйли бит шулай! Менә шунысы куркыныч. Ә үзебез чит илләрдә яшәп тә әби-бабаларыбыздан калган гореф-гадәтләребезне, туган телебезне бүгенге көндә дә күз алмасыдай саклап килүче милләттәшләребезгә сокланган булабыз... Әйтерсең шуны ук үзебезгә эшләргә кемдер комачаулый!

Шул вакыт аның сүзен ишек кыңгыравы тавышы бүлде. Ирексездән бер-беренә карашып алдылар: «Кем булыр бу?» Гөлфирә, тиз генә урыныннан торып, ишекне барып ачты.

—Телеграмма!—диде килеп керүче яшь кенә кыз, бик ашыккан кыяфәт белән.—Менә монда кулыгызны куегыз!

Гөлфирә ул сузган карандаш белән култамгасын салды да, кыз, бәладән баш-аяк дигәндәй, шундук—әйтерсең могҗиза белән баскан урынында эреде!—юкка чыкты. Бу нинди дер мизгел генә булды. Килен кеше шунда кызыксыну һәм ни сәбәпледер кинәт кенә күңелендә туган шомлану белән кулындагы телеграмманы укып чыкты:

«Сафаргалеев попал аварию тчк лежит второй больнице тчк Омск тчк»

Ул аны ашыга-ашыга берничә кат укып чыкты, тик андагы сүзләр һич кенә дә акылына барып җитмәде, дөресрәге, Гөлфирә анда язылганны аңыша алмый азапланды.

—Йә, нәрсә бар анда, кызым?—дип сорады аның телеграмманы шулай озак укуына түземсезлеген җуя башлаган каенатасы.—Кемнән? Кайдан? Ни бар анда?

—Низаметдин...—диде Гөлфирә үзе дә ишетмәслек акрын тавыш белән. Шулчак телеграммадагы сүзләр, андагы хәрефләр бер зураеп, бер кечерәеп башта биешә башлады, аннары, кулындагы кәгазьдән сикереп төшеп, кухня түшәменә, стеналарына сибелде. Һәм ул, әле генә рәхәтләнеп ашап утырган өстәлләре ягына ничектер сәер караш ташлап алды да, кискән агач сыман идәнгә ауды. Беркем берни аңламый да калды.

—Ни булды, кызым?! Әй, Ходаем, әй Ходаем!—дип каенана белән каената аңа ташланды, ә Низаметдиннең энесе, аның каенесе Шамил, тиз генә килеп, бу минутта беркемгә дә кирәкмәс кәгазь шикелле идәндә яткан телеграмманы алып укыды.

—Абый, авариягә эләгеп, хастаханәдә ята икән...—диде ул, кинәт кенә карлыгып калган тавыш белән.

—Әй, газиз Ходаем! Ниләр генә булды икән ул балага?—дип яшьләрен сөртте каенанасы.

—Кем уйлаган…—дип куйды киленен диванга күтәреп салырга маташкан каенатасы, берни күрмәгән күзләре белән ишек катларының түшәмстеналарын айкап. Аның бу сүзләре белән ни әйтергә теләве аңлашылмый калды. Хәер, аны ишетүче дә булмады бугай.

—Улым, бар, кит әле моннан!—дип кычкырды шунда әнисе, идәндә һәм килененең күлмәгендә кан тапларын күреп.—Әй, атасы, харап иттек бугай баланы… Әй, Ходаем, әй, Аллам!.. Бар, син дә чыгып тор әле, атасы!

Тикмәгә генә: «Бәла ялгыз йөрми, бәхет ишле килми»,—димәгән икән борынгылар. Беренче карашка бер фаҗига турында гади генә кәгазь кисәге алып килгән хәбәр шул ук мизгелдә көтелмәгән, беркемнең дә исе-төшендә булмаган тагын бер коточкыч бәла китереп чыгарды: Гөлфирә шушы кичтә үзе белән Низаметдине дә, каенанасы белән кайнатасы да көтеп йөргән һәм, ниһаять, инде аның булачагы турында белеп барысы да шатланып-сөенеп бетә алмаган баласын югалтты. Карынында ук югалтты. Ул моны, бераздан аңына килеп, үз өстенә иелгән каенанасының яшьле күзләрен күрү белән үк аңлап алды. Шунда йөрәген кешеләрдә инде мәңге төзәтеп булмаслык ялгыш җибәрүен аңлаганнан соң гына, хәтта йөрәген генә түгел, ә бөтен санынгәүдәсен үтмәс пычаклар белән аркылы-торкылы кискәләгән-тураган чакта гына туарга мөмкин булган, чарасызлыгы белән шундый тирән, шундый үкенечле уфтану хисе чорнап-чолгап алды ки, хәтта сулавы да кыен иде аңа.

—Ни булды, әни?—дип ачынып сорады ул.—Баламны югалттыммы?

—Борчылма, кызым, борчылма!—диде каенанасы, яшьле күзләрен читкә борып.—Барысы да яхшы булыр, Алла боерса…

Тик «барысы да яхшы» булып чыкмады шул: кан эчендә яткан Гөлфирәне «Ашыгыч ярдәм» машинасы хастаханәгә алып китте, ә каенатасы Гәрәфетдин, үзе дә ни үле, ни тере килеш, бәлагә тарган олы малае Низаметдин янына барырга җыена башлады…

Ул аның яныннан, Омск шәһәреннән, ике атна чамасыннан әйләнеп кайтты.

—Шунысына сөенергә кирәк: исән калган,—диде ул, күзләрен өйдәгеләрнең үзенә төбәлгән сораулы карашларыннан читкә борырга тырышып.—Ләкин ни…—Ул монысын, ин авырын, якыннарына ничек әйтергә дә белмичә, тирән сулап, көрсенеп куйды. Шуннан соң гына калтыранган тавышы белән:—Ни… нишләтәсең… язмыштыр инде… аягын кискәннәр…—дип өстәде.—Икесен дә… Тагын бер ай-ай ярымнан алып кайтырга мөмкин, диделәр…

Аның шушы сүзләреннән соң өйдә ниндидер авыр, шомлы тынлык урнашты, шактый вакыт беркем бер сүз дә әйтергә кыймады. Мондый үзәк өзгеч тынлык, гадәттә, өйдән мәет чыккан чакларда гына була бугай. Әйтерсең бу минутта һәркем әле генә ишеткәненең асылына төшенергә тырыша, ләкин ничек кенә тырышса да аны һич тә аңлый, мәгънәсенә төшенә алмый азаплана иде. Тик гаилә башлыгы әле генә житкергән явыз, кырыс чынбарлык бераздан аңнарына барыбер барып ирешә бугай, кинәт каенана белән әле кичә генә хастаханәдән кайтып кергән килен, үзара сүз куешкандай, бер-беренә сыенып, икесе дә берьюлы елап җибәрде. Хәтта тормыш юлында инде дөньяның ачысын да, төчесен дә шактый татырга өлгергән Гәрәфетдин өчен дә газаплы, авыр күренеш иде бу. Шуңа күрә ул, моңа тизрәк чик куярга, шул ук вакытта үз йомшаклыгын да җиңәргә теләп бугай, калтыранган тавышына ир-ат кырыслыгы индерергә тырышып:

—Җиттеме сезгә?! Исән бит ул! Шуңа сөенергә кирәк!—дип кычкырды.

## 6

Ул чакта, каршы килүләренә дә карамастан, Низаметдинне алып кайтырга каенатасы белән Гөлфирә дә барган иде. Инде бу ямьсез хәбәрне ишеткәннән соң—житмәсә, үзе дә баласын югалтты бит әле!—күзенә рәтле йокы кермәгән хатын юл буе тирән уйларга чумып барды: ашыйсы да килми, сөйләшәсе дә, күз алдында һаман беренче танышкан, бергә йөргән чаклардагы чибәр егет, аңа һәрвакыт игътибарлы булган, аны өзелеп яраткан, һәрчак шат, мөлаем йөзле, бөтен гәүдәсеннән, бар хәрәкәтеннән дә аны теләсә нинди бәла-казадан, авырлыклардан сакларга әзер булган ышанычлы көч бөркелеп торган Низаметдине басып тора. Өйләреннән әле күптән түгел генә сау килеш чыгып киткән ирен ничек ике аяксыз итеп күз алдына китерә алсын ул?! Билгеле, инде бу явыз чынбарлыктан күз йомып кына котылып булмаслыгын аңлаган, дөресрәге, аңларга маташкан Гөлфирә мондый коточкыч хәлне күз алдына китерергә дә омтылып карады, тик моннан берни дә чыкмады, үз-үзен ышандырырга тырышкандай, ниндидер шифалы дога укыган диндар шикелле, күнеленнән һаман: «Юк, юк, аның аяксыз булуы мөмкин түгел! Мөмкин түгел!»—дип кабатлады. Үз күзләре белән күрмичә, бу хәбәрнең чынлыгына мәңге ышанмаячак ул!

Низаметдине, гадәтенчә, юлга чыгышлый кагылган иде аңа, кагылган иде...

—Ярый, Гөлфирә, ни... китеп барыш минем. Мин кайтканчы, кара аны, сагынып-саргаеп куя күрмә!—дип коңгырт күзләрендә шаян очкыннар уйнатып елмайды ул, аның башын күкрәгенә кысып.—Бу юлы озакка түгел... Алай да бик юксынырмын мин сине, Гөлфирә...

Менә шулай дип чыгып киткән кешенең берничә көннән үк аварияга эләгеп аяксыз калуына ничек ышанмак кирәк?! Әле менә хәзер дә ул шушында, самолетта да елмаеп, аның башын күкрәгенә кысып бертуктаусыз: «Бу юлы озакка түгел... Бик юксынырмын инде мин сине, Гөлфирә...»—дип кабатлый сыман.

«Нигә ул миңа, гадәттәгечә: «Мин сине бик сагынырмын инде, Гөлфирә»,—димәде, ә, бик юксынырмын инде,—диде икән?!»—дип гаҗәпләнде самолет тәрәзәсеннән мамык тауларыдай кабарынып-кабарынып торган ак болытларга карап барган Гөлфирә, авыр көрсенеп. Ул ирексездән хәзерге хәлләтенең шушы мизгелендә Низаметдиненең сау чакта әйтелгән шушы соңгы сүзләре эченнән әйтеп бетерелмәгән ниндидер серле мәгънә, ниндидер күрәзәчелек сизенүе булу-булмау мөмкинлеген эзли иде бугай. (Гадәттә, дөньядан киткән сөекле кешеләрен якыннары да менә шулай, аның кайчан, кайда, ни дип һәм ничек, нинди халәттә әйтүен кат-кат хәтерләп искә алалар.) Менә хәзер Гөлфирә дә шулай: аңа иренең ул сүзләре эчендә дә әлегә үзе аңлап бетерә алмаган ниндидер яшерен мәгънә ятадыр кебек тоела... Аны бигрәк тә Низаметдиненең монарчы бер тапкыр да әйтмәгән «юксынырмын» сүзе борчыды: «Әллә ул моның белән ниндидер башка нәрсәне аңлатырга теләдеме икән?» Ялгыша иде, әлбәттә: яраткан иренең бу сүзендә дә сөюен белдерүдән башка нинди мәгънә ятсын?! Кая барса да, ни генә эшләсә дә үзенә тынычлык таба алмаган, үзен кая куярга, нишләтергә белмәгән ачынулы җанының бәргәләнеп тыпырчынуы гына иде аның бу халәте.

—Бетеренмә, кызым!—диде аның хәлен аңлаган каенатасы йомшак тавыш белән.—Язмыштан узмыш юк... Кайгырып үзеңне генә бетерәсең. Барыбызга да авыр...—Ул бер мәл дәшмичә торды да, төкереген йотып җибәрде, аннары калтыранган тавыш белән өстәп куйды:—Авыр хәл, кызым, бик авыр хәл! Ходай барыбызга да сабырлык бирсен. Аңа да җиңел түгелдер...

—Аңлыйм мин, әти... Тик уйламыйча буламыни?.. Кеше бит без...

—Дөрес, кызым... Шушындый зур сынау алдында да кеше булып калырга язсын...—Соңгы вакытта иннәренә төшкән кайгыдан күзгә күренеп бетәшеп,

ничектер кечерәеп калган каенатасы, син мине тынлыйсыңмы соң, дигәндәй, төссезләнә төшкән коңгырт күзләре белән тиз генә килененә карап алды.— Барыбызга да!..

Ул да көнелсез уйлар дингезендә йөзә иде бугай, шактый вакыт тавышы-тыны чыкмый торды. Тик бераздан гына нигәдер үкенгән, көнелендәгесен дәвам иткән сыман гына:

—Ә бит төшемә кергән иде бу нәрсә,—дип куйды.—Тик мин аны нәрсәгә юрарга гына белмәдем...

—Ничек итеп күрдең, әти?!—дип гаҗәпләнеп сорады Гөлфирә.—Йә, сөйлә әле, әти, сөйлә!

—Шушы соңгы рейсына...—Гарәфетдин калтыранып чыккан тавышына көрлек өстәргә һәм бу юлы «соңгы» сүзеннән качарга теләп бугай, сүзен янадан башлады.—Шушы рейсы алдыннан өч-дүрт көн элек төш күрдем... Нindидер авылда яшибез, имеш. Җыйнак кына авыл өе, аяз, кояшлы көн, күк йөзе зәп-зәңгәр, ник мендәр хәтле болыт кисәге булсын! Шул күкнең матурлыгына сокланып карап торам. Шунда карашым өй түбәсенә төшсә, аны күгәрченнәр сырып алган! Тирә-якны яңгыратып гөлдер-гөлдер киләләр. Шунда кемдер куркыттымы, кинәт дәррәү куптылар да очып китте болар. Тик берсе генә очып китмичә урынында калды... Карасам, ике аягы да...— Каенатасы битен сыпырган булып, күз яшьләрен сөртеп алды.—Карасам, аның ике аягы да бәйле икән. Нindидер юан, тимерчыбык кебек ак җепләр белән, имеш... Шуны бәйләгән кешене каргый-каргый баскыч куеп, түбәгә үрмәләдем. Ул исә, урыныннан да кымшанмыйча, минем менеп җиткәнне көтеп тора. Күзләре кешенеке сыман зур, тик бик тә моңсу, яшьле. Ага да ага яшьләре... Аны кулыма алып аягындагы җебен чиштем дә түбәгә куйдым, ә ул барыбер очып китми, яшьле күзләре белән тик миңа карап тора. Гаҗәпләнәм инде моның очып китмәвенә. Ә аның аякларына басып талпыныр хәле юк... Карасам, мескеннең аякларын җепләр кисеп, коры сөяккә калдырган икән...—Гарәфетдин авыр гына көрсенеп куйды.—Менә шундый төш. Мин аны беркемгә дә сөйләмәдем, нәрсәгә юрарга да белмичә, эчемнән генә тынычсызланып йөрдем. Аннары онытылды. Менә бу хәл килеп чыккач кына исемә төште. Шушы бәлагә булган икән...

—Шулай очраклы гына туры килгән инде ул, әти.

—Кем белгән инде аны, кызым...

## 7

Хастаханә баскычыннан менеп барганда инде аны менә күпме вакыт борчып, тынгысызлап, берсеннән-берсе авыр сагышларга салып килгән көнелсез уйларын шомлы салкынлык белән каршылаган диварлар тагын да көчәйтеп җибәргәндәй булды. Йөрәге, күкрәк читлегеннән чыгарга җыенган шикелле, еш-еш тибәргә тотынды. Моңарчы юл буе үзенә тынгылык бирмәгән, хәтта билгесезлеге белән куркытып килгән: «Ничек каршы алыр?», «Беренче сүзе нинди булыр?», «Үзен ничек тотар?», «Үзем ничек күрешермен, нәрсә диярмен?», «Хәзер аның белән башкачарак сөйләшергә кирәкме икән?», «Ничегрәк?» кебек сораулар, казандагы кайнаган су кебек, көнелендә берсен-берсе этә-төртә янадан, тик бу юлы нindидер катгыйлык белән, тыпырчына башлады. Җитмәсә, аларга каенатасының әле менә хәзер таксидан төшкәч кенә әйткән сүзләре дә кушылып, Гөлфирәнең соңгы вакытларда болай да инкe-минкe булып калган зиһенен тагын да таркатып җибәрде.

—Син, килен, ни... аннары үзең карарсың... ничек теләсәң, шулай эшләрсең... тик ни... анда әлегә андый-мондый нәрсә сиздерә күрмә инде...—диде ул төртелә-төртелә, әйтергә мәҗбүр булган бу сүзләре өчен үзе дә уңайсызланып бугай.—Үтенеп сорыйм...

—Син нәрсә инде, әти?!—дип үпкәләде Гөлфирә, ана усал караш ташлап.— Миндә бернинди андый-мондый уйлар да юк, булырга да мөмкин түгел, әти.

Ул минем өчен һәрвакыт сөекле ирем булачак!

—Мондый сүзләрең өчен рәхмәт, кызым, тик ни... ашыкма син... Син яшь әле... Алдагысын кем белгән...

Менә инде Низаметдин яткан катка да житеп, коридорга керделәр. Очрашу мизгеле якынлаша барган саен Гарәфетдин белән Гөлфирәнең бөтен тән-буыннарына тикле калтырана башлады. Йөрәкләре шулай котырынып тибә идеме, әллә икесен дә бер үк дәрәжәдә билгесезлек пәрдәсенә төрелгән алдагы, менә хәзер, минутлар да түгел, ә санаулы секундлар гына калган күңелсез очрашу мизгеле шулай куркыта идеме, шайтан белсен. Барысы да бергә чәбәләнеп төйнәлгән иде бугай.

Гадәттә кешеләр бер-берсе белән очрашу мизгелләрен зарыгып көтеп ала. Ләкин дөньяда очрашуларның башкасы да була икән: кеше аны шатлана-шатлана көтә дә, шул ук вакытта аннан... курка да. Менә хәзер хастаханә коридорыннан каенатасы артыннан атлаучы Гөлфирә белән дә шул хәл.

—Миңа куркыныч, әти...—диде ул әкрен генә.—Куркам мин...

—Курыкма, кызым, курыкма! Мәет янына бармыйбыз лабаса!

—Мин аннан түгел... Нәрсәдән курыкканымны үзем дә белмим мин, әти...

—Аңлыйм мин сине, кызым, аңлыйм. Булгалый ул шулай... Син ни... миннән соң күрешерсең...

Ниһаять, алар кыяр-кыймас кына Низаметдин ятарга тиешле палата ишеген ачып керделәр. Дүрт кешелек палата. Шуның ике караватында гына ике сырхау ятуы күренеп тора. Аларның берсе китап укып утыра, икенчесе юрганын башыннан ук ябынып йоклый иде бугай—тавыш-тыны да ишетелми, үзе дә күренми.

—Исәннәрмесез!—диде Гарәфетдин, дулкынлануын басарга тырышып.—Сәфәргалиев янына без...

—Әнә ул йокы чүлмәге!—диде китап укып яткан сырхау монык ише жиргә хас булмаган нindidер күтәренке, хәтта шаян тавыш белән, һәм икенче караватка төртеп күрсәтте.—Аңа Казанына кайтып китәргә вакыт, ә ул йокы симертә!

Аның шаяру катыш әйтелгән бу сүзләреннән аларга ничектер жиңел булып китте. Шундук күңелләренә нindidер жылы дулкын бөркеп: «Димәк, эшләр алай ук начар түгел!»—дигән өметле уй йөгереп узды.

Низаметдин караваты янына килделәр. Берни булмагандай—нәкъ өйләрендәгечә бит, валлаһи!—кулларын як-якка ташлап, гырылдап—бар аның андый гадәте!—йоклап ята. Ул шулай таралып, үзе әйтмешли, рәхәтләнеп, ял көннәрендә ятырга ярата иде.

Каената белән килен бары тик үзләре генә аңлаган нindidер эчкерсез елмаю белән бер-беренә карашып алдылар—эчләренә бераз жылы йөгергәндәй булды.

—Улы-ы-м!—диде Гарәфетдин, кулы белән малаеның юрганын сак кына ача төшеп.—Уян әле, улым, уян!

Нindidер бер эчке сиземләү белән балачактан ук таныш булган шушы тавышны ишетепме, әллә үзенә кагылган кулны тоепмы, Низаметдин кисәк кенә—әйтерсең көтмәгәндә тәненә энә белән кадап алдылар!—сискәнеп китте дә күзен ачты. Тик бер мизгелгә генә, ул бу арада гына исенә дә килеп өлгермәде, беркемне күрмәде дә бугай, ничектер мөлаем елмаеп (бәлки, матур төш күреп яткан чагы булгандыр?) күзен кабат йомды да, ике кулын баш очына таба сузып, тәмле итеп киерелеп куйды һәм... тагын йоклап китте.

—Тор әле, улым, тор! Әллә син безне күрергә дә теләмисеңме?—дип, үпкәләгән сыман йомшак тавыш белән бу юлы әти кеше малаен шактый сизелерлек итеп төрткәли башлады.—Күр син аны, ә! Безне сагынмаган, ахры, син, улым?

Шунда әтисенең тавышы, ул әйткән сүзләр аны төшеннән чынбарлыкка

алып кайтты бугай, Низаметдин чәчрәп уянып китте дә, ашыга-ашыга күзен уарга кереште, гүя монарчы шулар гаебе белән генә йокысыннан айный алмаган.

—Әти! Әтием!—дип үзен-үзе белештермичә кычкырып җибәрде ул һәм шунда бераз гына арттарак басып торган хатынын да күреп алды.—Гөлфирә, син дә мондамыни, бәгырем?! Әй, ничек сагындым мин сине... мин сезне! Белсәң... белсәгез икән! Йә, сөйләгез, әни ничек анда? Шамил ничек? Исән-саулармы?

—Шөкер, барыбыз да исән-саулар, улым. Үзең ничек соң, үзең? Кайтабызмы Казанга? Сагынып беттек инде без сине, озакладың син бу юлы!..

Гөлфирә сизеп тора, әтиләре үзләре өстенә ишелеп төшкән коточкыч бәлане исеме белән искә алмаска, алай гына да түгел, ул турыда, гомумән, артык җәелеп китмәскә, шуның белән болай да гел күңелләре түрендә йөргән йөрәк яраларын кабат яңартмаска, бу авыр хәлне бераз гына булса да йомшартырга тырыша.

—Озакладым шул, әти... Бераз көтелмәгәнрәк эш килеп чыкты бит, шайтан алгыры! Ә менә инде хәзер Казанга гына түгел, җәһәннәм астына барырга да әзер мин...—Әлеге сүзләрен елмаерга тырышып әйткән Низаметдиннең тамагы кинәт карлыгып калды һәм күзләреннән чыккан ике бөртек яшь тамчысы, битендә ялтырап торган ике эз калдырып, аска тәгәрәде.—Тик аякны гына ботинка кыса башлады әле менә...

—Башкасын алырбыз, улым!—диде Гарәфетдин, малаеның шаяруын дәвам итеп.—Элеккесеннән дә яхшысын! Тик кайгырма гына! Егет бул!

—Хәзер кайгырып ни файда? Язмыштыр инде...—дип Низаметдин ирексездән бәреп чыккан күз яшьләрен сөртеп алды.—Син бар, әти, кайту ягын кайгырта башла! Киемнәрне, тиешле кәгазьләрне юлла! Табиблар белә минем китәсен...

—Дөрес, улым, юл кешесенең юлда булуы хәерле. Җыена башларга кирәк...—Авыр сөйләшүдән качар өчен әллә нәрсәләр бирер кебек булып утырган Гарәфетдин, аннан азга гына булса да арынып тору җае чыкканга сөенгән шикелле, тиз генә палатадан чыгып китте.

—Утыр әле яныма, Гөлфирә!—диде Низаметдин, әтисе артыннан ишек ябылуга ук. Гөлфирә исә, сиңа уңайсызламаммы соң, дигәндәй, сак кына аның караватына килеп утыргач, көчле куллары белән аның башын күкрәгенә кысты да, әле аның җилкәсеннән кага-кага, әле чәчен сыйпый-сыйпый:— Мин сине шундый сагындым, Гөлфирә! Белсәң икән!—дип пышылдады.— Акылдан язам дип торам! Ничек уйлыйсың, бәлки, язганмындыр да инде, ә? И, бәгырем! Сине дә күрер көннәр бар икән! Беләсеңме, менә шушы минутларда дөньяда миннән дә бәхетле кеше юктыр. Андый кешенең булуы да мөмкин түгелдер!

—Мин дә бик сагындым сине, Низаметдин... Гел синең турыда гына уйладым...—Гөлфирә бармаклары белән кабат аның чәченә кагылып алды. Шунда аларның элеккегә караганда яртылаш диярлек көмешләнеп калуына игътибар итте, тик ирен борчымас өчен бу турыда бер сүз дә әйтмәде.— Барыбыз да бик кайгырыштык. Нишләргә дә белмәдек...

—Нишләтәсең, язмыштыр инде...—диде Низаметдин, хәзерге хәле белән килешергә мәҗбүр булуын раслаган сыман. Ләкин аның менә хәзер үзенең фаҗигасенә кагылышлы сүзләр белән ничәмә-ничә борчулы көннәр, ничәмә-ничә йокысыз төннәр көтеп алган шушы очрашу минутларының тәмен бетерәсе, кадерен җуясы килми иде. Шуңа күрә ул сүзне тиз генә икенчегә борырга тырышты.—Әйдә, юк-бар нәрсә турында сөйләшмик әле, Гөлфирә! Үзеңнең хәлләр ничек: авырмыйсыңмы, эшең барамы?

—Шөкер, авырган юк, хәлем яхшы...—Иренең соравыннан соң кылт итеп баласын югалтуы исенә төшкән Гөлфирә, үз ялганыннан үзе кызарып, тәртелеп

калды. Тик бу югалту хакында гына түгел, әле аның карынында барлыгын да белмәгән ирена бу турыда әйтеп, аның болай да муеныннан ашкан ярасын тагын да тирәнәйтәсе килмәде. Бер җаен туры китереп, соныннан әйтер әле.—Эш тә бара! Күнегелгән бит инде, көннәр буе саннар сугыштырып утырам шунда...—Ул, авыр хәлдән шулай ансат котылуына сөенгән шикелле, елмаеп куйды.—Эшемдә дә гел сорашалар синең турында...

Әйе, хатынының балага узуы хакында Низаметдине бөтенләй белми дә иде әле. Гөлфирә үзе дә моны каенанасы белән сөйләшкәч кенә ачыклагандай булды. Моңарчы үзендә сизелмәгән кайбер үзгәрешләр турында сөйләп биргәч, кинәт каенанасының күзләре ничектер яшьләрчә очкынланып, йөзе балкып китте һәм ул, ябык куллары белән Гөлфирәнең аркасыннан сөеп:

—Болай булгач, безнең кечкенәбез булачак бит, кызым!—дип чын күңеленнән елмайды.—И-и, Ходаем, изге сәгатьләрдә генә була күрсен! Бик сөендердең син мине, кызым! Тизрәк врачка күрен! Әйтте диярсең, ул да раслар сүземне, Алла боерса! Менә шатлык, менә шатлык!—Каенанасы бу хәбәргә шундый куана иде, әйтерсең картаймыш көнендә үзе балага узган!

Чыннан да, табибә, ике айлык йөге барлыгын әйтеп, Гөлфирәне чиксез шатландырды, ул хатын-кызлар консультациясеннән кулына бәхет кошы тоткандай, очынып килеп чыкты, өйләренә дә күбәләктәй очынып кайтып керде. Тик барысы өчен дә сөенечле булган бу хәбәрне житкереп Низаметдинен генә шатландыра алмады—ул ике көн элек кенә Омск шәһәренә чыгып киткән иде...

Ул арада бер табиб белән, култык астына Низаметдиннең киемнәрен кыстырып, палатага Гарәфетдин дә килеп керде.

—Димәк, безне ташлап китәргә җыенасың, Сәфәргалиев?—диде шактый өлкән яшьтәге ир-ат табиб, аның янына килеп.—Йә, кәефләр ничек?

—Рәхмәт, Владимир Степанович, кәеф яхшы. Житәр, сездә болай да озак кунак булдым, Казан бик сагынган ди анда мине,—дип елмайды Низаметдин һәм Гөлфирәгә төртеп күрсәтте.—Таныш булыгыз, Владимир Степанович: бу—хатыным Гөлфирә.

—Исәнмесез! Бик шатмын,—дип кулын сузды табиб.—Бәхете бар икән—исән калгансың. Гадәттә андый аварияләрдән соң бик сирәк кеше генә...—Шунда ул, сүзнең кирәкмәгән юлга кереп китүен аңлап бугай, туктап калды.—Ярар, Сәфәргалиев, Казаның шулай бик сагынган икән, кайтасың инде. Тик син минем сүзләрне беркайчан да онытма!

—Рәхмәт сезгә, Владимир Степанович, онытмам.

—Мин ышанам сиңа, Сәфәргалиев. Нык бул! Мин анда—ул Гарәфетдин кулындагы кәгазьләргә ишарә ясады,—елдан соң бер аягыңа протез кую мөмкинлеген дә күрсәттем. Бу турыда да онытма! Ярар, яхшы гына кайтып житегез! Сезне аэропортка безнең машина илтеп куяр.

Табиб чыгып китте, ә алар юлга җыена, Низаметдинне киендерә башладылар. Ходай мондый хәлне иң явыз дошманыңа да күрсәтмәсен: бот төбеннән диярлек ике аягы да булмаган кешене киендерүдән дә авыр эш (монда, мөгаен, авыр хәл дию урынлырактыр) дөньяда юктыр. Әле моңарчы бу хакта турыдан-туры сүз кузгатудан сакланып килгән булсалар, менә хәзер, инде аякларының юклыгын үз күзләре белән күргәч, Гөлфирә генә түгел, хәтта ир башы белән Гарәфетдин дә иманеп китте. Алай-болай итеп Низаметдингә чалбарын кидерүләре булды, аның озын, буш калган балакларын нишләтергә белмичә аптырап беттеләр. Йөзләренә тир бәреп чыкты, куллары калтырый.

—Аларның берсен, бөкләп, күкрәгенә, икенчесен җилкәсенә бәйләп куегыз сез!—диде аларны күзәтеп утырган сырхау, хәлләрен аңлап.—Шулай тигезрәк була, бик кабарып тормый...

—Әй, баш та инде синдә, Михаил!—диде якыннарының ничек аптырап калуларын күреп уңайсызланган Низаметдин, үзен елмаерга мәҗбүр итеп.—

Ярый, туган, тизрәк терелә күр!

—Болай булгач, тереләбез инде!

Кинәт палата ишегенең ике ягы да ачылып китте дә, аннан башта арба, аның артыннан, аны этеп, яшь кенә шәфкать туташы килеп керде.

—Сез әзерме? Менә арба, аска шуның белән алып төшәрсез,—диде ул эшлекле кыяфәт белән.

—Рәхмәт, кызым, әзер без,—диде Гарәфетдин һәм Низаметдинне арбага күтәреп салды.—Йә, балалар, кузгалдыкмы, Аллага тапшырып?.. Хәерле сәгатьтә!

—Ярый, сау бул, Михаил!—дип, Низаметдин көрәктәй кулын селкеп алды.

—Хуш, Николай! Ярый, яхшы гына кайтып житегез!

—Рәхмәт, улым!—диде Гарәфетдин, калтыранган куллары белән арбага ябышып.—Шулай булсын...

Бераздан үз гомерендә күпне күргән, бихисап үлеләргә дә, тереләргә дә бер үк дәрәҗәдә хезмәт итеп килгән, менә хәзер үзендә агач бүкәне кебек утырып барган Низаметдиннең Омск—Казан маршрутын башлап җибәргән арба, кылтыр-кылтыр килеп, инде хастаханә коридоры буенча тәгәри иде.

Киләчәктә ике аяксыз бу кешене ниләр көтә, аның язмышы ничек булачак? Анысын арба да, анда утырып баручы ике аяксыз гарип үзе дә, арбаны этеп барган кулларының калтыравы бөтен гәүдәсенә күчкән карт та, арба артыннан, исерек кеше сыман, нindидер томан эчендә атлаган хатын да белми иде.

Киләчәкне язмыш кына белә...

8

Низаметдинне Казанга алып кайтканга күпме вакытлар узса да, шул сәфәрләре искә төшкән чакларда инде үзе дә шундый ук хәлгә калган Гөлфирә әле менә хәзер дә, бизгәк тоткан шикелле, бөтен гәүдәсе белән калтыранып куя, хәтта бөтен җирен кешеләр «каз тәне» дип йөрткән вак төерчекләр каплап ала. Әгәр бу мөмкин булса, ул аны беркайчан да исенә төшермәс иде! Ләкин кеше хәтеренең кирәк чакта—искә төшерә, кирәге булмаганда аны шундук юкка чыгара торган кнопкасы юк шул: үткәннәр теләсә кайчан кылт итеп искә төшә дә куя. Утны гына кнопка белән яндырып-сүндереп була...

Шактый азапланды алар юлда. Омск аэропортыннан очып китә алмыйча гына да тәүлектән артык утырдылар. Чираттагы рейска өлгермәделәр, ә аннары очарга тиешле каһәр суккан самолет, репродуктордан хәбәр итеп торуларына караганда, йә нindидер «техник сәбәпләр», йә «метеошартлар» буенча һаман сонара торды. Пассажирлар өчен тиешлесе җиренә житкерелеп түгел, ә иң гади шартлар да тудыра алмаган безнең ил вокзал-аэропортларында поезд, самолет көтеп утыруның нинди газап икәнен белмәгән кеше юктыр. Әле бу сау-таза пассажирлар өчен газап бит! Ә кеше ярдәменнән башка үзе адым да ясый алмаган кешегә ничек?! Мондый хәлләрдә ул нишләргә тиеш?

Дөрес, Низаметдин, якыннарының хәлен аңлап, аларны артык борчымаска тырышты. Ләкин ул тере кеше бит! Аны бер мәртәбә бәдрәфкә алып бару да нинди газаплы эш икәнен әтисе Гарәфетдин генә белә. Әйткәч тә, ул үзе чүлмәккә утыра яисә йомышын үзе башкара ала торган бала-чага түгел, ә авыр гәүдәле, өстәвенә ике аяксыз ир-ат! Тагын менә безнең бәдрәфләрдәге чират белән шапшаклыкны да кушсаң!.. Житмәсә—сизелеп тора!—әле үзенең көче була торып көчсезгә, башкалар ярдәменә мохтаҗ кешегә әйләнеп калуына күнекмәгән Низаметдин әтисеннән ояла, уңайсызлана да. («Мондый хәлне дошманына да күрсәтмәсен Ходай!»)

Әйе, бик истә калырлык булды аларның Казанга кайтулары. Житмәсә, бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, алар самолеты, Мәскәү аэропорты кабул итмәү аркасында (торф яна, күкне төтен каплаган, диделәр), башка шәһәргә

килеп төште! Мәскәү күге ачылганын шактый вакыт шунда көтәргә мәҗбүр булдылар.

Ярар инде, аннары юл газаплары барыбер артта калды, өйләренә кайтып керделәр. Тик анда да шатлык көтми иде аларны. Беренчедән, моңарчы олы малайларын сөлектәй ир-егет итеп күрергә ияләнеп беткән каенанасы Раушания буе белән кечкенә балага охшап калган Низаметдинен шундый халәттә күргәч, үз-үзен тыя алмыйча һәм аны каядыр утырткanны да көтмичә, кычкырып елый-елый аңа ташланды һәм, аяклары тотмыйча бугай, бераздан аны кочаклаган килеш идәнгә сыерылып төште. Малаен болай да көчкә күтәреп алып кергән Гарәфетдин аны чак кына кулыннан төшереп җибәрмәде.

—Әнисе! Әнисе, дим! Нишләвең бу?! Сабыр ит, баланы куйыйм әле мин!—дип кычкырды ул ачу белән, аннан Низаметдинне көчкә аралап.

Хәер, аңа ярдәмгә арттан килүче Гөлфирә ташланды. «Сабыр бул, әни, сабыр бул!»—дип башта ул, кулындагы сумкасын ташлап, ireннән каенанасының кулларын ычкындырды, аннары аңа идәннән торырга булышты.

—Син нәрсә, әнисе?!—дип гаҗәпләнде аннары бераз тынычлана төшкән Гарәфетдин, маңгай тирләрен сөртеп.—Син мине Низаметдин белән икегезне бергә күтәрә ала дип уйлыйсыңмы әллә?! Бала-чага шикелле асылынасың!

—Сагындым бит, әтисе...—диде Раушания, үкси-үкси.

—Сагындым, дип... Кеше шикелле генә буладыр бит? Житте, бетердек!

—Чыннан да, әни... Син елагач, минем дә күңел тула.

—Ярар, улым, ярар... Шатлыктан бит мин...—Әнисе, яшьләрен сөртә-сөртә, аның янына диванга килеп утырды да башын күкрәгенә кысты.—Бик сагындырдың бит, улым...

—Мин дә бик сагындым сезне, әни! Шундый сагындым!..—Кинәт Низаметдин, әнисе күкрәгеннән башын күтәреп, ике кулы белән аны кочаклап алды. Үзенең күзләреннән мөлдер-мөлдер яшьләр тәгәри иде.—Менә язмыш нишләтте мине, әни... Үз аякларым белән чыгып киттем, әти җилкәсендә кайтып кердем...

—Алай димә, улым! Шөкер, исән калгансың. Шуңа шатланабыз. Үзең дә куана бел шуңа... бетеренмә...—диде Раушания, ябык кулы белән малаеның чәчләреннән сыйпап.—Ходай, җан биргәнгә җүн бирермен, дигән, улым...

—Белмим, әни, бер алган аякларымны кире кайтарып бирер микән ул?..

—Көфер сүз сөйләмә, улым! Ул кешеләрдән берни дә алмый, бары тик аларга сынаулар гына җибәрә...

—Бәлки, мондый сынауга караганда, үлем яхшырак булгандыр, әни...

Сүзнең кирәкмәс юнәлешкә керә баруын сизеп алган Гарәфетдин, аны икенчегә борырга теләп, йөзенә елмаюга охшаш яктылык сытып чыгарды да:

—Карале, әнисе, без ни... арып-талып юлдан кайтып төшкән кешеләр бит! Тамакка капкалап алсак та комачауламас иде,—диде.

—И-и, әтисе, шулай шул. Әй, бөтенләй онытылып киткәнмен! Хәзер мин, әтисе, хәзер, балалар...—дия-дия Раушания, тиз генә урыныннан торып, кухняга таба ашыкты.—Ашарга да әзер, чәем дә кайнаган!

—Ярар, сез сөйләшә торыгыз, мин әнигә булышыйм әле,—дип, аның артыннан ук Гөлфирә дә кереп китте.

Бүлмәдә тирән тынлык урнашты: Гарәфетдин әле генә үлем турында малае әйткән сүзне ишетмәгәнгә сабышты, шуңа күрә аны дәвам итәргә теләмәде, ә Низаметдин исә уйламыйчарак ычкынган ул сүзләре өчен кайтканда да күпме авырлыклар кичерергә туры килгән әтисе алдында унайсызланып калды. Үз кайгысының әти-әниләре, Гөлфирәсе өчен икеләтә авыр яра икәнен дә, мондый хәлгә төшүендә аларның берниндi гаепләре юклыгын да аңлый югыйсә! Тик нишләтәсең аны, әллә кайдагы Омск хастаханәсендә

ялгыз, якыннарынны бер күрергә интизар булып, житмәсә, үлем белән яшәү арасындагы упкын эчендә тырмашып ятканда мәңгелек булып тоелган йокысыз төннәр һәм чарасыз көннәрдә беренинди тынгылык бирмичә һаман күңелендә кайнап, бәгырен кискәләп торган, шулай кайный-кайный үзенең өзлексезлеге белән башын юләрлеккә сабыштыра язган уйлар өереннән тиз генә арыну мөмкин түгел шул... Ул уйлар бер генә минутка да башыннан чыкмый, бер генә минутка да күңеленнән китеп тормый: хәзер Низаметдин, ярга чыгарып ташлаган балык сыман, шулар капкынында бәргәләнә...

—Ашагач бераз ятып ял итеп алырсың, улым,—диде шактый сузылган тынлыктан соң Гарәфетдин.—Аргансындыр...

—Синең жилкәдә йөрепме?—дип шаярткан булды Низаметдин.

Тик Гарәфетдин моны ишетмәмешкә салынды.

—Иң беренче эш итеп, безгә коляска булдыру кирәктер... Кайгырма, улым, әкренләп барысы да жайланыр, Алла боерса!

9

Бүлмәләренә «Хужабикә» дип йөртелгән директорлары килеп кергәндә Низаметдин белән Гөлфирә кызып-кызып ни турындадыр бәхәсләшәләр иде. Биредә китапның нинди дер изге нәрсәгә саналуын (аны гадәттә гел хатыны укый, ә ире тынлап тора) белгән Әлфия бәхәснең сәбәбе хәзер дә Гөлфирә кулындагы китап икәнен шундук төшенеп алды, чөнки аларны мондый халәттә беренче генә күрүе түгел—еш кына укыганнары хакында, әнә шулай туктап-туктап, үзара фикер уртаклашып алырга ярата алар.

—Бәхәс ни турында?—дип сорады ул, елмаеп.

—Бармактан суырып алып язган урыннары күп,—диде Низаметдин, кулын селтәп.—Андый нәрсәләр ышандырмый, тормышчан түгел...

Иренең бу сүзләреннән соң Гөлфирә, чак кына кабарып торган матур иреннәре белән елмаеп, аңа жылы караш ташлап алды.

—Берәр нәрсә син уйлаганча булмаса, сиңа гел тормышчан түгел инде!

—Ләкин язучы укучыны, димәк, мине дә, ышандырырга тиеш ич! Ул язганга ианырга тиеш мин...—Низаметдин, үзенә яклау эзләгәндәй, директорга таба борылды.—Менә бу китапта яшь кенә укытучы кыз—гаиләсе, балалары барын белә торып!—үзеннән күпкә олы ирга гашыйк була да, аның белән очрашу эзләп йөри, Әлфия Закировна! Аңлыйсызмы? Белә-күрә торып! Ә ул укытучы бит, үзе балаларга тәрбия бирергә тиешле кеше! Теге ирне дә әйтер идем... «Син, балакай, бар, өлешенә тигән көмешенне үз тиңнәрен арасыннан эзлә инде, безнең тормышны бозып йөрмә!»—диясе урында, шул кыз белән һаман очрашып тора! Ә язучы дигән адәм исә ул очрашу мизгелләрен шундый соклану белән, хәтта нинди дер ләззәт кичереп сурәтли, әйтерсең сүз унжиде-унсигез яшьлек ике гашыйк турында бара! Нинди мәхәббәт булсын бу?! Чеп-чи әхлаксызлык! Аннары, яшьләр юньсезләнә, бозыла бара, дип шаулашкан булабыз...

—Менә гел шулай ул, Әлфия Закировна! Аның укытучыны КЕШЕ итеп күрәсе килми!—дип көлде Гөлфирә «кеше» сүзенә басым ясап.—Аның өчен ул бары тик укытучы гына! Жаны да, хисе дә булырга тиеш түгел аның... Ә ул бит, иң беренче чиратта—кеше, жанлы кеше! Үзенең унай, тискәре яклары белән. Аннан соң гына укытучы! Шулай түгелме, Әлфия Закировна?

—Укытучы да кеше, диюең белән хаклы дип уйлыйм. Нинди китап укыйсыз соң сез?—дип директор Гөлфирә кулындагы китапны алып карады.—Бу автор яшьләрдән булса кирәк, монарчы очратканым булмады. Шуңа күрә андагы хәлләрнең дөреслеккә никадәр якын тору-тормавы турында әйтә алмыйм. Юкка гына, тормыш катлаулы нәрсә, димиләр. Анда кайчак кеше ышанмаслык хәлләр дә булгалый бит. Тик тормышта булган хәл, дип кенә әдәбиятка булыр-булмас—типик булмаган дип әйтикме аны?—хәлләрне өстерәп кертү дә дөрес түгелдер, минемчә. Ә китап турындагы

фикеремне мин аны укып чыкканнан соң әйтермен. Килештекме?

—Килештек, Әлфия Закировна, килештек,—диде Гөлфирә белән Низаметдин беравыздан.

—Кызганыч, урыны ул түгел... Юкса анын буенча менә дигән диспут та оештырырга булыр иде...

—Әйе, мәхәббәт турында сөйләшер кеше юк шул монда, Әлфия Закировна,—дип көрсенеп куйды Низаметдин, ниндидер үкенеч белән.— Кеше картлыкта үткәннәре белән яши, диләр. Ә бу йорттагылар кичерә торган ялгызлык сагышы, кайчандыр якын күреп йөргән кешеләренең хыянәте инде хәзер аларга яшьлек елларының, сау-таза чакларының бәхетле мизгелләрен искә төшерергә дә ирек бирми торгандыр...

—Шулайдыр, мөгаен,—диде директор.—Тик менә нәрсә кызык... Күңелләрендә нинди генә сагышлар кайнамасын, йөрәкләрендә мәңгелек яра булып калган нинди генә рәнҗешләр йөртмәсен, берсенең дә сер бирәсе килми! Ә бит аларның күбесен хәзерге көндә сау-сәламәт килеш менә дигән фатирларда яшәп ятучы балалары китереп ташлаган! «Ташлаган...» Нинди шыксыз сүз! Аның артында кеше ышанмаслык нинди явызлык, кыргыйлык һәм миһербансызлык ята! Шулай да ник берсенең адәм актыгына әйләнгән шундый баласына тел-теш тидертәсе килсен! Сөйләшкәндә аларны гел мактап кына телгә алалар, хәтта акларга маташалар! Ә үзләренең елап чыкмаган төннәре юк! Күзләрендә—сагыш, сагыш, сагыш!.. Киләчәккә бернинди өмете калмаган авыр, кара сагыш. Әгәр аны үлчи торган прибор уйлап чыгарсалар, ул, мөгаен, шушындый йортлардагы кешеләр сагышын сыйдырып бетерә алмыйча, атлаган саен ватылыр иде...

Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Әйтерсең һәрберсе аерым-аерым мондагы кешеләр сагышын үзенчә үлчәргә, күз алдына китерергә тырыша.

—Бер караганда, балаларның әти-әнисе яисә әби бабасыннан баш тартып, еш кына менә шушындый йортларга китереп ташлавы да кеше ышанмаслык хәл бит, Низаметдин,—дип бераздан тынлыкны тагын директор бозды.—Тик мондый кешелексезлекне күрми дә калып булмый. Әгәр бу турыда берәр язучы әсәр яза икән, аңа ышануы кыен, дип кенә без аны кабул итмәскә тиеш түгелдер бит? Андый проблема бар ич! Алай гына да түгел, елдан-ел күбәя бара бит мондый нәрсә!..

—Менә тагын... Әйтегез әле...—Директор, алга таба сүзен ничек дәвам итәргә белмәгәндәй, аларның әле берсенә, әле икенчесенә күз ташлап, ничектер төртелеп калды.—Сезнең белән иркенләп сөйләшеп утырган да юк... Монда яши башлавыгызга икенче ай китте, ә сезнең турыда бөтенләй белмим диярлек...

Низаметдин белән Гөлфирә, сүз куешкандай, тиз генә бер-беренә карашып алдылар.

—Юк, Әлфия Закировна,—диде аннары Низаметдин ашыкмыйча гына.— Безне монда артык кеше дип китереп ташламадылар. Без әти-әниләребезне, дусларны үзебез ташлап килдек...

—Ничек инде ул «үзебез ташлап?!»—дип бүлдерде аның сүзен директор. Гаҗәпләнүе шулкадәр көчле иде бугай, матур соры күзләре, түгәрәкләнеп, мангаена сикерде.—Монысы бик аңлашылып житми...

—Без якыннарыбызның кызганулы карашларын тоеп яши алмадык, Әлфия Закировна,—диде Гөлфирә, сүзгә кушылып.—Бик авыр хәл бу. Аларга нинди йөк булуыбыз турында әйтмим дә инде! Күз алдыгызга китереп карагыз: бер йортта үзләре бер адым да ясый алмый торган ике гарип! Безгә караганда, аларга авыррак иде бугай.

—Кемнәр инде ул якыннарыгыз?—дип сорады Әлфия Закировна пышылдауга охшаш акрын тавыш белән.—Кайда, кемнәр белән яши идегез?

—Минем әти-әни белән яшәдек,—диде Низаметдин, уң кулы белән чәчен

сыпырып.—Без алардан бер генә авыр сүз дә ишетмәдек! Гөлфирә дөрес әйтә, безгә караганда аларга кыенрак иде... Ул чакта коляскасыз да идек бит әле без!

—Ә Гөлфирәнең туганнары?..

—Мин сигез яшьтән—балалар йортында... Әти белән әни аерылышканнар, әни бик иртә дөнья куйды...

—Алай икә-ә-н... Гафу ит, Гөлфирә, ирексездән ярана кагылып алдым.

—Мин Низаметдиннең авариягә эләгеп аяксыз калганын беләм инде. Ә синең белән ни булды?

—Бәхетсезлек очрагы...—Гөлфирә кинәт кенә иренә карап алды.—Поезд астына эләктем...

—Әйе, поезд астында калды...—диде Низаметдин. Бу акыллы хатын хәзер аларның ялганын нәкъ менә аның күзләреннән укып белер кебек иде һәм, шуна күрә күзләрен яшерергә теләгәндәй, ул башын түбән иде.—Бу кыз әле моннан бер ел чамасы элек кенә каршыга килүче һәр ир-ат сокланып карап уза торган һәм йөзен балкытып, төз, матур аяклары белән баскан җирен дә сизмичә очынып йөри иде, Әлфия Закировна! Күбәләктәй очынып йөри иде минем Гөлфирәм...

Кинәт аның тавышы карлыгып калды, тамагына ниндидер авыр төер килеп тыгылды һәм ул, башын читкә борып, ике бөртек күз яшен сөртеп алды. Аннары чак кына ишетелерлек итеп:

—Мин генә гаепле... Минем аркада гына...—дип пышылдады.

Шунда Гөлфирә көлеп җибәрде.

—Тыңламагыз сез аны, Әлфия Закировна!—диде ул, үзенең бәрхеттәй йомшак тавышы белән көлүен дәвам итеп. Шул ук вакытта үзе иренә кискен генә шелтәле караш ташлап алды. Низаметдин исә хатынының бу карашы белән: «Син нигә шулай ачылып киттең?! Без килешкән идек бит...»—диюен шундук төшенеп, ярамас эш кылган бала сыман, уңайсызланып калды.—Хыялый кеше ул! Аның өчен дөньяда бер мин генә сөйкемле дә, дөньяның бар ир-аты миңа гына карый!

—Көнчелек?

—Юк, нинди көнчелек булсын, Әлфия Закировна! Ул беркайчан да көнләшмәде.

—Ә нишләп үзеңне гаепле санийсың соң син, Низаметдин?!—дип гаҗәпләнде Әлфия, аңа таба борылып.

—Нишләп, нишләп...—дип мыгырданды, әле генә әйткән сүзләренә үкенгән ир.—Саклый алмадым... Менә нишләп!..

—Аяк астында йөргән бәладән кемне кем саклап кала алсын инде, юләрем минем!—дип елмайды Гөлфирә, иренә карап.—Язмыш эше...

—Анысы шулай... Юкка гына: «Язмыштан узмыш юк»,—димәгән шул борынгылар...—Директор утырган урыныннан торып басты да караватъ янындагы тумбочка өстендә яткан китапларның өстәгесен кулына алды.—Әллә математика белән дә шөгыльләнәсез инде?!—дип гаҗәпләнде ул, аны актаргалап.

—Низаметдин мин тәмамлаган институтка керергә җыена, Әлфия Закировна,—диде Гөлфирә, бөтен йөзе белән балкып.—Көненә өч сәгать вакытыбыз шуңа китә безнең.

—Шушы килешме?!

—Нигә гаҗәпләнәсез?—диде Низаметдин.—Инде мин, ничек кенә теләсәм дә, машина руле артына утыра алмыйм. Шулай бит? Шулай. Димәк, ниндидер башка һөнәр сайларга кирәк дигән сүз. Шулаймы? Шулай. Миңа хатыным һөнәре кулай булыр дип уйлыйм. Аңлашылдымы, Әлфия Закировна?

—Аңлашылуын аңлашылды... Тик ни бит... ике аяксыз килеш...

—«Ике аяксыз килеш...»—дип әкрен генә, гүя ишеткәненә ышану өчен үзалдына гына кабатлады Низаметдин аның сүзләрен. Ләкин шундук

җанланып, утырган урынында калкынып ук куйды.—Мин сезгә, бездә мондагылар кичерә торган авыр сагыш юк, дидем. Димәк, без бу йорттан кире Казанга кайтып китәчәкбез әле, Алла боерса! Кайчан? Монысын төгәл генә әйтә алмыйм. Тик үз аякларыбыз белән кайтып китәрбез, дип ышанам. Ишетәсезме, Әлфия Закировна? Миңа аягымны кискән табиблар аның берсенә протез куеп була, диделәр. Ә Гөлфирәгә—икесенә дә! Ишетәсезме, Әлфия Закировна? Икесенә дә, Алла боерса! Хәзергә безнең кәгазьләр, түрәләр теле белән әйтсәк, тиешле инстанция кабинетларында йөри. Ә безнең илдә юк кына кәгазьнең дә нинди тизлек белән хәрәкәт итүе, ышанам, сезгә күптән билгеледер. Күреп торасыз, ел саен зур итеп, концертлар куеп, хәтта кайбер бәхетлеләрнең чәчләрен бушлай алдырган, бушлай мунчалар керткән булып инвалидлар, өлкәннәр көнен, аннары аларның үнкөнлеге дигән чаралар үткәрәләр, ә аннары... икенче көнне үк онытылар! Үзегез уйлап карагыз: Казанда—башкалада бит!—инвалид коляскасын кертерлек-чыгарырлык итеп җайлаштырылган ник бер трамвай, ник бер троллейбус, ник бер автобус булсын! Моны совет власте житмеш ел буе башкарып чыга алмады! Әй-й-й... Сөйли китсәң!..—Ул ачынып кулын селтәп алды.—Ләкин мин дә, Гөлфирә дә оптимист кешеләр. Безнең кәгазьләр, тиешле инстанция бүлмә-коридорларында йөри торгач, барыбер безне шатландыра, аннан соң аяклы итә алырдай нәтиҗәләр белән чыгар дип ышанабыз. Бу эшне кайбер дусларыбыз, түрәләр теле белән әйтсәк, күз уңында тотарга вәгъдә бирделәр. Менә шулай, Әлфия Закировна. Беләсездер, очучы Маресьев ике аяксыз килеш самолетта очкан бит!—Низаметдин тумбочкага таба төртеп күрсәтте.—Ул китапны өч мәртәбә укып чыктык без! Дөрес, хәзерге яшьләргә андый китаплар кирәк түгел... Аларның күбесе, шашына-шашына, телевизордан «боевик»лар карый...

—Мин сезнең алдагы көннәрегезгә шундый ышаныч белән каравыгызга чын күнелемнән куанам,—диде беравык дәшми торганнан соң директор.—Сөйләшеп утыра торгач, сезнең ул ышанычыгыз миңа да көчкәндәй булды.

—Сез нәрсә, Әлфия Закировна?!—дип гаҗәпләнде Гөлфирә.—Аякларыгыз, шөкер, үзегез белән ләбаса!

—И-и, Гөлфирә, тормыш дигәнең кайчак тез астына шундый итеп китереп суга, хәтта аяксызлар бәхетлерәк кебек тоела башлый...

—Әллә берәр кайгыгыз бармы, Әлфия Закировна?

—Тормышта җанын ни дә булса борчымаган кеше юктыр ул. Һәр кешенең—үз кайгысы. Тик аны һәркем үзендә генә йөртә...—Директор сәгатенә карап алды.—Әй-й, тәмам онытылдым мин сезнең белән! Күптән менә шушылай иркенләп сөйләшеп утырасым килгән иде. Вакытыгызны алуым өчен ачуланмагыз!

—Булмаганны... Нинди ачулану ди ул, Әлфия Закировна! Якын итеп керүегез өчен рәхмәт сезгә.

## 10

Бүлмәләрендә тынлык. Бары тик Гөлфирәсенең тигез итеп сулавы гына ишетелә дә, аның сулышы җаена беленер-беленмәс кенә бер күтәрелеп, бер төшеп торган юрганнарының шул җансыз хәрәкәте генә сизелә бугай.

Тик Низаметдиннең керфекләренә генә һич тә йокы кунмый. Йоклап китмәмме дип меңгә хәтле санап та караган булды, юк, аның да файдасы тимәде! Аны бүгенге сөйләшү уйлар дингезенә ташлады. Ә анда төшеп йөзә башладыңмы, дулкыннарыннан тиз генә котылырмын димә!..

«Мин генә гаепле... Минем аркада гына...»

Ул бу сүзләрне бары тик үзенә генә, үзе өчен генә әйткән шикелле иде дә, тик директор белән Гөлфирәсе дә ишеттеләр шул, ишеттеләр. Хәер, хатынының да аягын югалтуга китергән вакыйгадагы гаебен (бәлки, җинаятен дию

дөресрәктер дә әле!) Әлфия Закировна алдында: «Саклый алмадым...»—дигән булып шома гына йомып калды калуын. Һәм ул моңа ышанды да, әлбәттә, чөнки аның башкача килеп чыгуын ул да, бүтән кеше дә уена китерә алмас, хәтта дөресен сөйләп бирсәң дә ышанучы булмас иде...

Ә менә шундый коточкыч карарга килергә мәҗбүр булган сөекле хатыны, Гөлфирәсе алдында ничек акланасың?! Әле беркөн генә, күңелендә бернинди начар уй тотмыйча, бары тик җанына дәва бирә торган «һич үкенмим!» дигән җавабын тагын бер мәртәбә ишетергә теләп кенә бирелгән: «Язмышыңны минем белән бәйләвеңә чыннан да үкенмисеңме?»—дип соравыннан соң да ничек кабынып киткән иде бит ул! Туктале, нәрсә диде әле ул аңа? Әһә... әйе, әйе: «Һаман ышанмыйсың... Һаман ярама тоз сибәсең...»—диде. Җитмәсә, бераздан шушы сүзләренә өзелеп, ачыргаланып, күзләрендәге яшьләр аша: «Элеккеге газапларыма кайтарасың ич син мине! Ә минем аларны кабат кичерәсем килми! Мин дә җансыз агач бүкәне түгел ләбаса!»—дип тә өстәде бит.

Ә ул исә бүген тагын Гөлфирәсенең гомерендә дә искә алырга теләмәгән ул ярасын кабат хәтерләтеп куйды. Хәер, нишләп аның йөрәк ярасы гына булсын ди ул фаҗига!? Икесенеке дә бит ул, икесенеке дә! Әйе, уртак фаҗигаләре...

Шул хәл кылт итеп исенә килеп төшкән чакларында Низаметдиннең дә үзәге өзелеп китә бит, аның йөрәге дә инде кайтарып булмаслыгы көн кебек ачык чакта гына туа, шуннан соң җанына гомерен буе тынычлык бирмичә, аны һәр минут, һәр секунд саен кимереп торган үкенеч белән күкрәк читлегеннән чыгардай булып котырынып-котырынып сызлана башлый. Әй, күңелендә инде беркайчан да төзәтеп булмаган ялгышыңны йөртүдән дә авыр нәрсә юк икән бу дөньяда! Вакыт бар яраларны да төзәтә, диләр. Ә менә кеше күңеленә кадалган үкенечне вакыт та йолкып ташлый алмый, ахрысы. Андый үкенеч тә, үткәннәр шикелле үк, кешене соңгы сулышына хәтле озата бара һәм бары тик аның белән бергә генә юкка чыга бугай...

Туктале, кайчан башланды соң әле ул үкенеч? Авариядән соң хастаханәдә аңына килгәч, аяксыз калуын бөтен аяусызлыгы, бөтен чынбарлыгы белән төшенгән көннәнме? Әй, үзе белән шул куркыныч чынбарлыкны алып килгән ул кара көн! Әй, мәңге үтмәс тоелган сары сагышлар, берсеннән-берсе караңгы, берсеннән-берсе өметсез уйлар белән чиятәнеп беткән, һәрбере бер айга торырдай ул ямьсез көннәр! Әй, шул газапларны, өметсезлекне күзеңне йомган саен хәтерләтеп, караватта борылып яткан саен көчәйтеп торган ул шыксыз озын төннәр!.. Сезне онытып буламыни соң?! Сез һаман Низаметдиннең хәтерендә бит... «Омск» дигән исемне ишетсә, бөтен гәүдәсе белән әле дә юкка гына калтыранып куямыни ул! Дөрес, менә хәзер, инде андагы газап-сагышларына бераз вакыт узганнан соң, ул бу шәһәрне кайчак үзенә бертөрле җылылык белән дә искә ала: ни әйтсәң дә, аның табиблары исән калдырды бит аны! Әйе, монысы—хәзер. Ә ул чакта... Ул чакта исән калуына да үкенә иде бит ул...

Алай да кайчан башланды соң ул, кайчан? Мөгаен, Казанга кайткач, аны өйләренә күтәреп алып кергән әтисенең елый-елый аңа ташланган әнисенә: «Сабыр ит, баланы куйыйм әле мин»,—дип кычкыру мизгеленнәндер. «Баланы куйыйм әле мин...» Ул чакта әтисенең бу сүзләрен ишетү иң беренче тапкыр үзенең аяксыз калуы турындагы коточкыч хәбәрне ишетүенә тиң булды. «Баланы куйыйм әле мин...»—дигән бу сүзләр Низаметдинне чын мәгънәсендә тетрәндереп җибәрде.

Йа Хода, нишләттең син бу ир-егетне?! Нигә аны—моңарчы бөтен җире сау-сәламәт булып җир җимертеп йөргән Низаметдинне—әти-әнисе кулындагы сабый бала хәлотенә калдырдың?!.

«Баланы куйыйм әле...» И Алла, и газиз Хода! Көче, дәрт-дәрманы ташып торган бу кешене шушындый хәлгә төшергәнче җанын гына алган булсаң

ни була!! Нәрсә? Якыннарымы? Бер еларлар иде дә... тора-бара әкренләп оныталар... килешерләр иде алар бу югалту белән... Нәрсә, әллә син бу ир-ат «бала» белән аларга җиңел булыр дип белдеңме? Аны исән калдырып ялгышлык эшләмәдеңме син, Ходаем? Аңа гына түгел, якыннарына да нинди газаплар, нинди кыенлыклар китердем, дип уйламыйсыңмы?..

Ни генә булмасын, вакыт үтә торды (аны туктатып буламыни?!), әкренләп Низаметдин дә үзенең бу халәтенә ияләшә төште. (Хәер, аяксыз кеше кайчан да булса аларның юклыгына ияләшә аламы икән?) Аның өчен ин читене үзен бәдрәфкә дә күтәреп йөртүләре, менә шул чакларда үзенең көчсезлеген кабат-кабат тоярга мәҗбүр булуы иде. Әйткәч тә, бала-чага түгел, ир кеше ләбаса ул... Әтисенә рәхмәт, ул, аның бу мәсьәләдә аеруча кыенсынуын аңлап, подшипник-тәгәрмәчләрдә тәгәри торган кечкенә арба әмәлләде, аннары унитазлары янына ниндидер баскыч сыман нәрсә ясап куйды. Шулай итеп, малаен аның өчен бик кыен хәл булган оялу-тартынудан, үзләрен бик күңелле булмаган мәшәкатьтән коткарды. Шул исәптән киленнен дә, чөнки өйдә чакларында Низаметдинне патшалар да җәяү йөри торган җиргә ул алып керә, алып чыга иде.

Кайчан башланды соң ул, кайчан? Шайтан белгән аның кайчан башланганын! Көне-сәгате язып куелмаган ла аның. Бәлки, күңеленә көнчелек корты кереп оялагачтыр? Монысы да дөрес шикелле бугай бит. Булды андый чак алар тормышында, булды. «Чак» дип кенә әйтү хәтта аның бу халәтен бик кыска, тар кысада гына калдыру булыр иде, чөнки ул "корт" шактый озак кимерде бит аның күңелен. Шуңа күрә аны «чаклар» дип әйтү дөресрәк бугай...

Көнчелек дигән нәрсә дөньядагы миллионнарча гаиләләрне җимергән, ничәмә-ничә миллион кешеләрнең чәчәктәй гомерләрен вакытсыз өзеп кара гүрләргә керткән һәм шушы явыз эшләрен шундый ук эзлеклелек, шундый ук түземлелек белән хәзер дә дәвам итә торган куркыныч авыру бит ул. Бер йоктымы, аннан тиз генә, болай гына котылырмын димә: аның кешеләргә кайгы-хәсрәт өләшә торган капчыгы һәрвакыт үзе белән! Күпме фаҗигаләр, күпме күз яшьләре үзләренең булачак хуҗаларын көтеп ята анда!..

Тфү, шул вакытларны исенә дә төшерәсе килми, валлаһи! Исенә төштеме, ирексездән йөрәге сулкылдап куя—әйтерсең аны кемдер пычак белән сызып җибәрә, күз алдына кабат Гөлфирәсе белән булган фаҗига килеп баса. Үкенеч белән бергә, мәңге аерылмас дуслар сыман, кулга-кул тотынышып! Ә аны кабат кичерүе аның өчен аерата авыр, бик авыр. Юкка түгел бит бу, һич тә юкка түгел...

Әй, ул көнчелек корты!.. Шул вакытта ул Низаметдин күңеленә тәмам баш-аягы белән кадалды. Кадалды да, башта җанын өшетте, аннары аның канын, каны белән бергә аның барлык җылылыгын, җылылыгы белән бергә аның барлык хисләрен, хисләре белән бергә аның барлык кешелек сыйфатларын суырырга тотынды. Бер дә туктап тормыйча, көннәр, атналар, айлар буе суырды!

Һәм Низаметдин бераздан көнчелек дигән шул явыз кортның агулы теле булган шик белән йөзгә-йөз торып калды. Аңа һаман төскә-биткә чибәр, саф-таза, гел күбәләктәй очынып кына йөри торган (бәхетеннән шулай очынып йөрүе дип кем уйлаган?!) җиңел сөякле Гөлфирәсе моннан соң инде аның белән тормас, аны ташлап китәр дә башкага чыгар шикелле тоелды. Бу хәл иртәгә, иртәгә булмаса—берсекөнгә, берсекөнгә булмаса—шушы атнада, актыгында, киләсе айда, ләкин, һичшиксез, барыбер шулай, ул уйлаганча килеп чыгар сыман иде. Ул шул кара көннең килүен курка-курка көтеп, үз-үзен шуңа ышандырып яшәде...

Аңа һаман менә хәзер, шушы минутта, Гөлфирәсе башка ир-ат белән күзгә-күз карашып сөйләшеп торадыр, ул ир заты аның хатынын сөядер, иркәлидер, теләгән саен үбәдер, шулай итеп, алар аңа "мөгез" куядыр, аннары,

бергәләшеп, бу вакытта өеннән түгел, баскыч төбенә дә чыга алмый яткан аяксыз Низаметдиннән эчләре катканчы көләләрдер кебек тоела иде.

И-и, ул шик дигән нәрсә! Жанынны, өенне суырып ала, кешелегенне калдырмый икән ул!

Әйе, нәкъ шулай. Иң башта ул кешенең аңын ала, аңлы фикер йөртү сәләтен генә түгел, хәтта нәрсәнең нәрсә икәнен аңлау сәләтен дә бетерә. Низаметдин белән дә шулай эшләде: анда монарчы, сау-сәламәт чагында, сөеп туя алмаган, егет-кыз булып йөргәндә дә, бергә яши башлагач та бер генә кыек сүз дә әйтмәгән хатынына каршы ниндидер нәфрәт уята торды һәм, ни гаҗәп, шуннан соң ул ана каршы әйтергә, хәтта начар, ямьсез сүзләр белән чәнчеп-чәнчеп алырга, аны кимсетергә, хәтта, хаклы икәнен белә торып та, аның аек фикеренә каршы килергә сәбәпләр эзләргә һәм андый сәбәпләрне юктан да табарга жай гына эзли башлады. Гөлфирәсе эшеннән бераз иртәрәк кайтса да (аның өчен сорап кайткалый иде бит югыйсә!), кибеткә-фәләнгә кереп чак кына соңарса да ярамады Низаметдингә: «Нәрсә, бүген иртәрәк жибәрдемени?», «Нәрсә, аерылыша алмый тордыгызмы?» Хәтта бергә табында утырганда да, әгәр Гөлфирәсе бүген ана гадәттәгедән ачыграк йөзле булып күренсә дә, артык караңгы шикелле тоелса да ярамады ана: «Бүген көнең бик күңелле үтте, ахрысы?», «Нигә кара көеп утырасың, безнең табын ошамый башладымы әллә?!»—дип Гөлфирәсенең бәгыренә кадап-кадап алгалады ул.

Омскидан кайтканнан соң иренең бөтенләй икенче кешегә әйләнеп баруын, үзенә карашының да капма-каршы якка үзгәрүен, аны нидер газаплавын күреп, Гөлфирә бу көтелмәгән хәлдән аптырап калды. Әйе, гаҗәпләнеп тә түгел, ә—аптырап. Берничә мәртәбә ачыктан-ачык сөйләшергә дә тырышып карады. Сөйләштеләр дә.

—Син минем белән яшәмәссең инде,—диде ул баштарак, ниндидер ярсулы ачу белән.—Мин сиңа имгәк кенә бит хәзер...

Моңа каршы Гөлфирә, аның чәчләреннән сыйпый-сыйпый:

—Юләрләнмә, Низаметдин, ташла бу юк-бар уйларыңны!—дип юатырга тырышты.—Мин мәңгегә синең белән! Дөньяда иң якын кешем син минем!

—Син моны юатыр өчен генә әйтәсең... Мин күрмим генә... Бәлки, инде башканы тапкансыңдыр син?.. Мине алдап кына йөрисеңдер...

—Ни сөйләвеңне чамалыйсыңмы син, Низаметдин?!—диде Гөлфирә, аның бу сүзләренә гаҗәпләнеп. Хәтта кыйгач кашлары, маңгаена сикереп, турыланып калды.—Син нәрсә?! Син... син... мине кем дип беләсең?!—Кинәт ул, яшьләренә буылып, елап жибәрде.

Моңа охшаш сөйләшүләр булгалады инде алар арасында, булгалады. Гадәттә аларны, инде иренең тупаслыгына (хәер, аннары ул моның көнчелек галәмәте икәненә төшенде) чыдар хәле калмаган хатыны башларга тырыша иде. Тик—бөкрене кабер генә төзәтер, дигәннәрме борынгылар?—Низаметдин тора-тора аның кара-каршы утырып аңлашырга, көнчелегенең бернинди нигезе дә юклыгына ышандырырга тырышуына бармак очы хәтле дә игътибар итми башлады.

—Ышанмыйм мин сиңа... Алдыйсың син...—булды аның җавабы. Хәтта мондый сөйләшүләрдән кача ук башлады.

Әлбәттә, баштарак үзләре арасындагы мондый хәлне өйдәгеләргә белдермәскә тырышсалар да, бер өстәл янында ашаучы кешеләрдән яшереп буламыни андый нәрсәләрне? Тора-бара күнелен көнчелек шиге кимерүен төшенеп алган малайларының үз кызлары кебек күргән киленнәрен кыерсытып яшәве ата-ананы тәмам борчуга салды.

—Син нишләп хатының белән гел кырлы-мырлы сөйләшәсең?—диде шулай беркөнне әтисе, караватта китап укып утырган Низаметдин янына килеп.—Ни булды?

—Берни булмады...

—Күрәбез... Сукыр түгел...

—Нәрсәне күрәсез, эти? Әйтеп сөйлә!

—Нишләп син адым саен хатыныңны рәнҗетергә тырышасың? Нигә аңа бәйләнергә генә торасың?

—Хатын-кызга ышанырга ярамый, эти... Тормас ул минем белән... Китәр ул...

—Юләр сатып үзеңнән-үзең әллә нәрсәләр уйлап чыгарып ятма! Син балачага түгел. Тормаслык кеше ике аяксыз икәнеңне белүнең икенче көнендә үк китеп барыр иде. Ә ул, мескен, синең өчен өзелеп тора! Нишләтергә белми! Хатын-кыз башы белән бәдрәфкә тикле күтәреп йөртә, бала шикелле, ваннада юындыра. Юк, бергә яшәргә теләмәгән хатын-кыз алай итеп йөрми ул, улым, ышан миңа! Сукыр булмасаң, күрәсеңдер, соңгы вакытларда ничек ябыгып калды бит!

—Бәлки, аның сөйгән кешесе бардыр? Шуңа ябыгадыр? Монда минем ни гаебем бар?

—Күрсәтер идем мин сиңа «дыр»ыңны! Кара аны, юньлегә түгел синең бу шашынуың! Мондый хәлгә төшүеңдә аның тырнак очы хәтле дә гаебе юк лабаса! Шулай булгач, нигә җәберлисең аны?! Әллә аңа җинел дип беләсеңме?

Низаметдин шактый вакыт дәшмичә торды.

—Көнләшәм мин, эти... Нигәдер гел Гөлфирә ташлап китәр, бүтән кешегә чыгар шикелле тоела миңа...—диде ул аннары теләр-теләмәс кенә һәм авыр гына көрсенеп куйды.

Әтисе башта, беренче мәртәбә генә күргәндәй, малаена озак кына карап торды, аннары бер дә ашыкмыйча гына, иркенләп көлеп җибәрде.

—«Нигәдер...»—дип кабатлап куйды ул аның сүзен.—Нигә икәнен белмисеңме шуның?! Ә мин беләм: юләрләнеп төрле юк-барны уйлап ятканга күрә. Тыңла мине: ташла шул саташуыңны! Өйгә бәла чакырма!

—Нинди бәла чакырыйм ди мин, эти?!—дип көлеп сорады Низаметдин.

—Көлмә син, көлмә! Әтиең ни әйткәнен белә ул! Бәла аяк астында гына йөри, диләр. Безнең капканы кага күрмәсен...

—Вакыты-вакыты белән әллә ниләр әйтеп куясың син, эти! Әллә картаясың инде?..

—Картаерсың да сезнең белән...—диде әтисе.—Әниең дә бик борчыла башлады бу хәлгә. Ул да сукыр түгел—күрә, чукрак та түгел—ничек сөйләшкәнеңне ишетә... Соңгы сүзем шул: әгәр дә киленнең китүен теләмисең икән, туктат аның җанын ашавыңны! Башка берәү булса, бу хәлгә түзә алмыйча, күптән китеп барыр иде... Алтын ул безнең килен!

«Алтын ул безнең килен!»

Кем белә—кешенең эчен ярып карап булмый!—бәлки, шулайдыр да. Һәрхәлдә бу хәлгә тарганчы аның шулай икәнен Низаметдин үзе дә белә иде. Ләкин менә хәзер дә, ул аяксыз халәткә төшкәч тә, шулай булып калдымы икән соң ул? Болай үзе нәкъ шул, элеккеге Гөлфирәсе шикелле, бернинди аерма да юк шикелле. Ә тора-бара да шулай булырмы? Тормышның, юк, тормышларының бөтен авырлыкларын аның белән янәшә атлап, аның белән бергә җигелеп тартырга көче житәрме? Чөнки аяксыз кешенең яшәгән һәр сәгате авырлык лабаса! Аның белән бер төрле сөйләшеп, күңеле белән бөтенләй башканы уйлап йөрмиме ул? Алдагы тормышта, башкалар белән чуалып, аның үзен, гаиләләрен адәм мәсхәрәсенә калдырмасмы? Хыянәт итеп йөрмәсме?

Күңеленә менә нинди сораулар тынгылык бирми, шик артыннан шик уятып кына тора! Нишләргә дә белми. Ичмаса, галимнәр кешенең эчендәге уйларын белә торган берәр прибор уйлап тапмыйлар! Әгәр шундый нәрсә булса: «Туктале, Гөлфирә, миңа, иң якын кешем бит син минем, димә, әйдә без ниләр уйлагыныңны менә шушы прибор белән тикшереп кенә

карыйк!»—дияр иден дә—шагыйрь әйтмешли, шалт, Мөхәммәтҗан!—шундук белер иден...

Ә болай әллә кала ул синең белән, әллә юк... Калса да, кем белә, әллә якын итеп кала, әллә вакытлыча, үзенең күнеленә ошаган башка берәүне очратканчы гына... Калса да, бу—дөньяда кеше ышанмаслык хәл. «Нишләвең, юләр?!»—дип дуслары ук гаҗәпләнәчәк, ә аннан соң, котыртып, юлдан яздырырга да күп алмаслар.

Кыскасы, ямьсез уйлар белән Низаметдиннең башы каткан инде. Әнә шулай уйланып-уйланып утырганнан соң—йөри-йөри уйланса да җиңелрәк булыр иде, ичмаса!—хатынын урынсызга рәнҗетүен аңлап, кайчак үкенеп тә куя. Әйткәч тә, ул да аның шикелле үк кеше, җансыз түгел бит.

Шундый чакларның берсендә аның башына куркыныч бер уй килде. Гомерлеккә үзенә бәйләп Гөлфирәне бәхетсез иткәнче, әгәр аны Низаметдин үзе белгән кешегә кияүгә чыгарга күндерсә? Ул вакытта кайчандыр өзелеп сөйгән кешесе башка ире белән, аның үзен шикләрдән арындырып, матур гына яшәп китәр иде. Ә үзе? Нәрсә үзе? Баштарак авыр булыр, билгеле, ләкин аннары онытылыр, төзәлер ул йөрәк ярасы. Вакыт барлык яраларны да төзәтә, дип юкка гына әйтмиләр ич. Аның каруы аның йөзенә дә, әти-әнисе, туган-тумачалары йөзенә дә берниндн кара йокмый калыр, кеше арасында да хурлыгы булмас, шәхсән үзе, "мөгезле Низаметдин" дигән исем алудан, кеше көлкесе булудан да котылып калыр! Андый исем бер тагылса, аның карасын гомер буе юып бетерә алмассың, валлаһи!

Хәтта ул аны кемгә димләргә икәнлеге турында да уйлады. Алар гаражында яше утыз икегә җитеп тә һаман өйләнмичә йөрүче Габдулла исемле бер якын дусты бар. Бик акыллы, бик тә сабыр егет, төскә-биткә дә башкалар алдында бер дә ким-хур түгел. Ул Низаметдин янына хәзер дә еш керә. Бу егет аның Гөлфирәсенә менә дигән пар булыр иде. Ләкин бу турыда башта хатыны белән сөйләшергә кирәк бит әле!.. Монысы да җиңел эш түгел: җаен, вакытын табарга, әти-әниләре өйдә булмаган чакны туры китерергә кирәк...

Бер ял көнне, чыннан да, андый җай чыкты—өйләрендә икесе генә калдылар. Гөлфирәсе аны ваннада юындырганнан соң, күтәреп алып чыгып, караватларына утыртты, алдына поднос белән чәй, бал китереп куйды. (Низаметдин ванна кергәннән соң өрә-өрә кайнар чәй эчәргә ярата.)

—Сиңа сүзем бар, Гөлфирә...—диде Низаметдин, чәе белән мавыккан булып, башын күтәрмичә генә.—Тик ни... син мине бүлдермә, ярыймы?

—Ярар. Тыңлыйм сине, Низаметдин.

—Менә нәрсә. Ни... хәлемне күреп торасың, Гөлфирә, гомерлек инвалид бит инде мин хәзер. Сине бәхетле итәргә теләгән идем дә, барып чыкмады...—Низаметдин тирән итеп көрсенеп куйды да, көч җыйгандай, бер мәл туктап торды. Аннары сүзен кинәт кенә калтыранып һәм карлыгып калган тавышы белән дәвам итте.—Кешегә гомер бер генә бирелә... Дөрес аңла мине... Киләчәктә минем белән азапланып яшәргә кирәкми сиңа... Кирәк түгел сиңа мондый тормыш! Син яшь әле... Кыскасы, яңа тормыш корып җибәрергә кирәк сиңа, Гөлфирә... Аңла, бу сүзләрне әйтүе минем өчен дә мең газап! Тик сине дә бәхетсез итәсем килми. Минемчә, син Габдуллага яисә теләгән башка кешегә кияүгә чыгарга тиеш... Миңа бик авыр булыр... ләкин мин ни... синең бәхетең хакына бу югалтуны ирләрчә кичерергә тырышырмын... ничек тә түзәрмен...—Ул күзләрен читкә борды.—Менә шул, Гөлфирә...

—Беттеме сүзең? Әйтеп бетердеңме?—дип айнып киткәндәй өздереп-өздереп, үзенең һәр сүзенә ниндидер ачулы басым ясап сорады Гөлфирә.—Димәк, син миңа ышанмыйсың? Әйтәм аны, инде күпме вакыт җанымны ашыйсың! Сизенәм, көнчелек корты кимерә күңелеңне. Ярар, туры сүзең өчен рәхмәт. Тик мин синнән мондый сүзләрне гомердә дә көтмәгән идем! Ипи белән ант итеп әйтә алам: беркайчан да көтмәгән идем! Димәк, сине—аяклы килешме, аяксызмы, монысы минем өчен барыбер!—элеккечә үк

сөюемне кабат расларга тиеш булам?!. Ярар, башкача ышанмыйсың икән, мин монысына да барам!—Аның күзләрендә яшьләр күренде һәм ул, аларны сөртеп тә тормыйча, бүлмәләреннән чыгып китте.

—Мин сине сөюем хакына гына бит, Гөлфирә...—дип калды аның артыннан Низаметдин.

...Ул Гөлфирәсенең нәрсә эшләргә җыенуын да, үзенең сүзләре белән хатынын нинди коточкыч бәлагә салуын да, киресенчә, ул бәлане тизләтүен белми дә, хәтта күз алдына да китерә алмый иде әле...

11

Низаметдиненең сүзләре Гөлфирәнең соңгы вакытларда күңеле түрендә торган саен тирәнрәк үтеп керә барган тынгысыз бер уен кабат кузгатып, тагын да җанландырып җибәрде. Алай гына да түгел, хәтта әле монарчы күңелендә йөргән: «Эшләргәме моны, әллә кирәкмиме?»—дигән икеле-микеле соравына да: «Кирәк!»—дип ап-ачык итеп җавап та бирде. Ул ниндидер бер эчке сиземләве белән бу эшне хәтта тизләтергә кирәклегенә төшенгәндәй булды...

Ә аның ул уе үзенең асылы белән акланырлык, ләкин кеше ышанмаслык, үзенең мәгънәсе белән зур мәгънәсезлек, ләкин ире ышанырлык иде: «Мәхәббәтләрен саклап калу өчен үзенә дә Низаметдине хәленә төшәргә кирәк!»

Кеше ышанмаслык түгелмени бу уй?! Әйе. Һәрхәлдә хәзерге көннәрдә сөюләре хакына мондый корбанга баручылар күптер дип әйтеп булмыйдыр. Ләкин булган бит андыйлар элек, булган! Кешеләр мәхәббәтләре өчен суга да, утка да кергәннәр, әллә ниткән газаплар кичергәннәр, хәтта үлемгә дә барганнар бит! Хәер, Гөлфирә өчен бу кадәресе барыбер, ул, бу уен тормышка ашырып, үзен сөюе бәрабәренә корбан итә дип уйларга җыенмый да, аның бары тик ире халәтендә буласы, хәле-торышы, бәхетсезлеге буенча аның белән тигезләшә-тиңләшәсе генә килә. Һәм ул моны эшләячәк! Һичшиксез, эшләячәк!

Юк, юк, бүген генә туган уй түгел иде бу. Иренең аңа булган элеккеге карашы (сөюе дисәң, артык төче яңгырый бугай) үзгәрә башлагач, аннан соң моның көнчелек, шуннан килеп чыккан шик аркасында иканенең тәмам төшенеп алгач шыта башлаган, ләкин яраткан кешең хакына барырга мөмкин булган, хәтта барырга кирәк булган авыр да, шул ук вакытта куркыныч та уй иде ул...

Һәм Гөлфирә шушы көннән соң аны ничек итеп тизрәк тормышка ашыру турында чынлап уйлана, шуңа әзерләнә башлады. Гәрчә икенче Анна Каренина исеменә дәгъва кылырга җыенмаса да, бераздан үзләреннән ерак булмаган тимер юлда поездларның кайсы вакытларда үтүен минутына хәтле белә иде инде ул...

Һәм, ниһаять, күңелендә йөреп хәзер исә тәмам «өлгереп» җиткән шушы уен башкарыр өчен үзе билгеләп куйган вакыт килеп тә җитте.

Ул, минутына хәтле уйлап,—болар соңыннан, инде эш узгач кына билгеле булды,—бер көн алдан дус кызына шылтыратты:

—Гүзәл, син миңа бик-бик кирәк идең, иртәгә көндезге унике сәгать егерме минутта Әмәт станциясенә кил әле, ярыймы?

—Кая, кая?!—дип гаҗәпләнеп сорады Гүзәл.

—Син нәрсә, ишетми башладыңмы әллә? Әмәт станциясенә, дим.

—Ни булды? Нигә?—дип кызыксынды дусты.

—Сиңа әйтәсе сүзем бар...

—Ә нигә аны Әмәт станциясендә әйтмәкче буласың?! Дүшәмбе көнне эшкә килгәч әйтерсең. Янмый торгандыр бит?!

—Эштә әйтә торган сүз түгел ул... Йә, киләсеңме, юкмы?

Телефон трубкасы чак кына тынып торды да аннан Гүзәлнең

—Ярар, алайса, килермен,—дигән тавышы ишетелде.

—Тик монда синең нәкъ беренче егерме минутта килеп житүең кирәк, Гүзәл! Монда вакыт бик мөһим нәрсә... Аңладыңмы?

—Ярар, аңладым. Бик кызыксындырып җибәрдең әле. Синең кешечә генә булмас инде!..—дип көлде Гүзәл.

—Көтәм. Анда чак кына астарак бер эскәмия тора. Шуның янына килерсең.

Икенче көнне нәкъ сөйләшенгән вакытка Әмәт станциясенә килеп житкән Гүзәл күзләре белән Гөлфирәне эзләп маташканда станция аша поезд үтеп бара иде.

—Гүзәл!—дип кычкырды аңа Гөлфирә, кулын болгап һәм, Гүзәлнең дә аны күреп алуын сизде дә, тиз генә беренче рельс янына утырып... ике аягын үтеп баручы вагон тәгәрмәче астына тыкты...

Бер-ике секундлык мизгел иде бу.

—Гөлфирә! Гөлфирә-ә-ә!—дип шашынып акырды Гүзәл һәм аңа таба ташланды.

Гөлфирәнең аны ни өчен чакырганын шунда гына аңлап алды ул...

12

Бу фаҗига турында кичкә табан аларга килгән Гүзәл хәбәр итте. Барысы да тораташтай катып калдылар. Шулай булмый соң! Шушы тыныч кына өйнең килене, шушы өй хуҗасы малаеның хатыны тора-торышка, уйламаганда поезд астына барып керсен әле! Үзе бит, үзе!

Өйдән мәет чыктымыни, ник берсе бер сүз әйтсен! Чын мәгънәсендә коелып төштеләр. Шулай дәшмичә, нишләргә дә белмичә күзләрен идәнгә төбәп утыра торгач, Гарәфетдин, олы малайлары Низаметдинне усал карашы белән өтеп алды да, үзалдына:

—Барып килим мин,—дип куйды.—И-и, бала, бала... Ниләр генә булды соң сиңа?! Нишләдең син, нишләдең?

—Аның янына кертмиләр, Гарәфетдин абый!—диде аңа Гүзәл.—Операционныйга алып кереп киттеләр аны. Аннары берничә көн реанимация бүлегендә ятачак. Барысы да әйбәт булса...

Ул чыгып китүгә, Гарәфетдин очынып Низаметдин янына килде дә, аны күзләре белән ашардай булып, ачу белән:

—Ишеттеңме? Нишләп көлмисең?—дип сорады.—Әйттемме мин сиңа, өйгә бәла чакырма, дип.

—Кем белгән аны... мондый хәл буласын... Кем уйлаган...—диде Низаметдин, күзләрен күтәреп әтисенә карарга кыймыйча.

—«Кем белгән, кем уйлаган...»—дип үчекләп кабатлады әтисе.—Аны мин белергә тиешме? Синең хатын бит ул! Мондый адымга син этәрдең аны, син! Ә хәзер, кем белгән дә, кем уйлаган, имеш! Шундый киленне, шундый баланы бит, ә! Күзеңә генә карап тора иде бит ул синең! Шуны да аңлый алмадың син! Әй, Аллам, исән генә кала күрсен инде!.. И-и, бала, бала!..

—Үз кызыбыз шикелле иде бит, балакаем,—дип монарчы дәшми утырган Раушания елап ук җибәрде.—Менә нәрсәгә котырынган икән син, улым... Шундый баланы бит, шундый баланы!..

—Сез нәрсә? Мин аны үз кулларым белән поезд астына төртеп кертмәдем ләбаса!..—дип куйды Низаметдин, кыяр-кыймас кына.

—Беренчедән, «аны» түгел, ә Гөлфирәне дип сөйләш!—Гарәфетдин хәтта ачуыннан йодрыгын йомды, әйтерсең лә менә хәзер малаена ташланырга җыена иде!—Икенчедән, дәшмә... тының да чыкмасын! Кабартма минем ташыган ачуымны!

... Тездән түбән җирдән ике аягын да өздергән Гөлфирә хастаханәдә ике айга якын ятты.

—Менә без хәзер икебез дә бер халәттә,—диде ул Низаметдингә, кайтып кергәннең беренче минутында ук.—Хәзер көнләшмәссең инде... Мин сине сөюемне расладым шикелле...—Шунда ул башын иренең күкрәгенә төртте, аннары күтәрелеп аның йөзенә карады.—Сагындым да соң мин сине, Низаметдин!..

Низаметдин яшьле күзләрен читкә борды да калтыранган куллары белән аны берничә мәртәбә кысып-кысып кочаклап алды, аннары чәчләреннән сыйпарга кереште. Берсүзсез генә! Әйтерсең бу мизгелдә ул үзенең телле, сөйләшә ала торган кеше икәнен бөтенләй онытткан иде. Тик хатынын шактый вакыт шулай иркәләгәннән соң гына телгә килде:

—Гафу итә күр мине, бәгърем... зинһар, кичер мин юләрне!—диде ул, яшь аралаш.—Кем уйлаган бит... Шундый адымга барырсын дип кем күз алдына китерә алган!.. Мин дә...

—Сөрт әле күзләреңне, Низаметдин! Ир-атлар күз яшен күрә алмыйм мин! Минем сине гел көчле ир итеп күрәсем килә. Элеккеге кебек...

—Яшь... Нәрсә ул яшь? Аны сөртергә була, ә менә минем аркада шундый эшкә баруың... Мондагы гаебемне сөртеп кенә түгел, юып та бетереп булмас. Соңгы сулышыма хәтле сулкылдап торачак ярам ул...

—Ярар, битәрләмә үзеңне! Язмыш эше бу ...

—Шулай буласын кемнәр белгән!...

Алар ул көнне, менә шушылай бер-беренә сыенышып, бик озак сөйләшеп утырдылар.

13

Әйе, кешенең үткәннәре, ул кая гына барса да, нәрсә генә эшләсә дә, гел үзенә ияреп йөри. Вакытында әйтелмичә калган, кайчак бөтенләй урынсыз әйтелгән сүзләре, кылынган кирәкле, кайчак бөтенләй кирәге булмаган эш-гамәлләре, шул кирәкмәс сүз вә эш-гамәлләре тудырган, һаман җанына тынгылык бирмичә сызланган йөрәк яралары, инде гомергә дә кайтарып, төзәтеп булмый торган үкенечләре белән бергә ияреп йөри алар кешегә. Ул үткәннәрнең яралары, үкенечләре кешенең соңгы сулышына кадәр озата бара һәм тәмам шул мизгелгә җиткәнче аның җанын ашый-кимерә, күнеленә тынгылык бирми. Үткәннәрдән качып котылган кеше юк әле. Дөньяда яшәмәгән андый кеше. Булмаган андый кеше!

Үткәндәге шул яраларын, шул үкенечле эш-гамәлләрен искә алмас өчен, кайчак аларны беразга гына булса да онытып торыр өчен кешеләр үзләренең зур-зур байлыкларын да кызганмаслар иде. Тик... Тик мөмкин эш түгел шул бу!

Бергә нибары өч ел да җиде ай гына яшәгән Низаметдин белән Гөлфирәгә карата язмыш дигән карачкы бигрәк аяусыз булды.

Үзләренә килгән кайгыларны, үзләре сызланып үткәргән яраларны, үз йөрәкләре аша кичергән үкенечләрне, аларны тудырган мизгелләрне, сәбәпләрне алар да бик теләп, рәхәтләнеп онытып торырлар иде югыйсә. Тик алар да кеше бит. Димәк, кешелек дөньясына хас һәр нәрсә аларга да кагыла: аларның кыска, ләкин бик гыйбрәтле, фаҗигале үткәннәре дә үзләре белән мәңге барачак... Гомер-гомергә шулай булган, шулай дәвам итә, телиләрме, теләмиләрме, киләчәктә дә шулай булачак!

14

Низаметдин белән Гөлфирә иртәнге ашларын ашап бүлмәләренә чыкканнар гына иде, атылып диярлек директорлары килеп керде.

—Сөенечле хәбәр алып килдем мин сезгә!—диде ул, кулындагы кәгазен селтәп.—Низаметдин, сине дә, Гөлфирә ханым, сине дә протез мәсьәләсендә Казанга чакыралар! Инстанция бусагаларын таптый торгач, гозерләрегез,

ниһаять, унай җавап белән кайтты!

—Шулаймы? Яхшы хәбәрегез өчен рәхмәт, Әлфия Закировна,—диде Гөлфирә, тыныч, сабыр булырга тырышып, ә үзенең күзләреннән ике бөртек яшь бәреп чыкты да, бераз тулышып, мөлдерәшеп торганнан соң алсу бите буйлап аска, иягенә таба тәгәрәде. Аннары ул ире ягына борылып:—Ишеттеңме, Низаметдин?—дип сорады.—Килде бит без көткән сәгать!

—Ишетмичә!—дип елмайды ире, аның иңенә кулын салып.—Кайчанга чакыралар, Әлфия Закировна?

—Берсекөнгә. Менә кәгазе, менә чакырулары! Аларны үзегез белән алырсыз.

—Алай булгач, Габдуллага шалтыратырга кирәк, килсен безне алырга,—диде Низаметдин.

—Кем ул?—дип сорады директор.

Низаметдин белән Гөлфирә сүзсез генә бер-беренә карашып алдылар.

—Яхшы дустыбыз,—диде Низаметдин.—Аны күргәнегез бар сезнең, безнең янга килгәләп йөри.

—Теге түгәрәк кенә йөзле чибәр егетме?

—Әйе, әйе, нәкъ үзе. Аның чибәр икәнен кайчан абайлап алдыгыз әле, Әлфия Закировна?—дип шаяртып куйды Низаметдин.

—Моның өчен ир-атка бер күз төшереп алу да җитә,—диде директор, елмаеп.—Бүген минем дә бер шатлыгым бар бит әле, дуслар!

—Әйтегез, без дә уртаклашырбыз, Әлфия Закировна!—диде Гөлфирә, җанланып.

—Минем сезгә, күңелендә борчу йөртмәгән кеше юк дөньяда, дигәнем бар. Безнең дә улыбызга кагылышлы зур борчуыбыз бар иде. Шөкер, җайланды ул эш! Кайчак ир-ат заты авырлыкка тиз бирелүчән бит ул: җебеп төшә, юк кына сәбәптән эчә башлый...

Директор чыгып китүгә Низаметдин белән Гөлфирә әкренләп юлга җыена башладылар.

—Без монда кайтабыздыр бит әле?—дип сорады Низаметдин.

—Әлбәттә! Әллә син бардың да, шундук протез кидереп кайтаралар дип беләсеңме?! Аны кат-кат үлчи-үлчи аякка яратып эшләве, аннан соң житешсез җирләрен җайлавы-көйләве алай тиз генә ерып чыга торган эш түгелдер дип уйлыйм. Хәер, анысын анда әйтерләр. Озакка сузылса да, безнең яшәр урыныбыз бар ла! Мин әти-әнине дә бик сагындым инде.

—Мин дә!—диде Низаметдин.—Алар да сагынгандыр... Тик ни... алар алдында да гаепле сизәм бит мин үземне...

Кичен телефоннан Габдуллага шалтыраттылар. Унай җавап киләсен ул да белеп тора икән—теге атнада гына министрлыкта булган. Шушы көннәрдә протез кую мәсьәләсендә Казанга чакырачакбыз, дигәннәр. Инде андый кәгазьнең килүенә ул да бик шатланды.

Өлкәннәр йортында берәрсенең кечкенә генә шатлыгы да минуты белән барлык бүлмә ишекләрен кагып өлгерә. Ә монда аның ниндие бит әле: «Ике аяксыз шушы парның икесен дә, протезлар куяр өчен, иртәгә Казанга алып китәчәкләр икән!» Бу хәбәрне ишетмәгән кеше калмагандыр. Берәүләре бу хәбәргә бик шатланды—яшь килеш аяксыз калган бу икәүне кызганалар иде, кайберсе көнләшкәндер дә, билгеле—дөньяда төрле кеше бар бит. Ләкин алар өчен чын күңелдән сөенүчеләре күбрәк булгандыр. Бәлки, бу яхшы хәбәргә әле барысы да шатлангандыр...

Шушысы дөрестер, мөгаен. Юкса аларны озатырга бердәм булып барлык аксагы-туксагы да, хәллесе дә, хәлсезе дә, хәтта урын өстендә ятканнары да чыкмас иде. Һәрберсе Низаметдин белән Гөлфирәгә үзенең җылы сүзен әйтеп калырга тырышты, тизрәк аяклы булып, «җир җимертеп» йөрүләрен теләде.

Чү! Үзенең зур гәүдәсе белән аларны әйләндереп алган кеше төркемен

ера-ера "Тюремщик" Василий килә түгелме?!

—Пардон, дайте пройти! Пардон, дайте пройти, говорят!—шуның тавышы бит бу.

Ниһаять, ул әлегә коляскаларында утырып торучы Низаметдин белән Гөлфирә янына килеп житте.

—Ну, Низам, пока! Я буду рад видеть вас на ногах! Ты уж извини, пожалуйста, меня за прошлое... Не хотел я обидеть, ей-богу... Вышло както не так...

—Ладно тебе, Василий. Как говорится, кто старое помянет...—Низаметдин, аның әле моннан бер атна чамасы элек кенә аларга килеп керүен исенә төшереп, җинелчә генә елмаеп куйды.

—Дай, Низам, денег на поллитровку!—диде ул, кереп тә өлгермәс борын. Үзенекен таләп итәмени! Низаметдиннең ачуы чыкты, чөнки, куркытыпянап, аның башкалардан да акча алуы турында ишеткәне бар иде.

—Не дам!—диде ул аңа, катгый итеп.

—Дашь, еще как дашь!—дип, бармакларын сөнгедәй тырпайтып, "Тюремщик" аңа таба иелә төште. Янәсе, күзләреңне төртеп тишәм хәзер. Куркытуы иде, әлбәттә.

Шунда Низаметдин—ничек шулай килеп чыккандыр, аннары ул моңа үзе дә гаҗәпләнде—юлбарыстай сикереп аның бер кулын эләктереп алды да бар булган көче белән (ә көч мәсьәләсендә ул төшеп калганнардан түгел иде!) артына каерып та куйды! Нишләсен, авыртуга түзә алмаган "Тюремщик" ирексездән аңа арты белән борылырга мәҗбүр булды.

—Ты чего делаешь, а? Ты чего это?! Пусти! Пусти, говорят! Больно же, Низам! Озверел, что ли?!

—А денег надо?

—Не надо мне твои деньги! Пошутил я... Честное слово, пошутил!..

—Обещай, что больше ни у кого не будешь отбирать денег! Они же и так обиженные! А ты, бессовестный, у них последние деньги отбираешь... Знаешь, что хочется мне сейчас делать?

—Что?—дип сорады "Тюремщик", кызыксына төшеп.

—Сломать твою поганую руку!

—Ты что, Низам, бог с тобой... Пусти, я обещаю тебе, ей-богу, обещаю...

Җибәрде Низам тегенең кулын. Дөрес, ул хәзер үк үзенә ташланыр дип көткән иде көтүен. Ләкин, ни гаҗәп, ташланмады, бары тик кулын селкиселки бераз басып торды да:

—Ну и рука у тебя, татарин! Не рука, а железо, ей-богу!—дип борылып чыгып китте.

Менә хәзер аның каршында әнә шул Василий елмаеп басып тора! Вакытывакыты белән кызык та инде бу дөнья...

—Люблю я таких не унывающих людей!—дип, "Тюремщик" җинелчә генә Низаметдиннең җилкәсенә сугып куйды.—Ей-богу, нравятся мне такие люди! Ну, бывайте!

—Мы, видимо, вернемся еще, Василий. Вещи остаются...

—Вернитесь только на своих ногах! Иначе не пустим. Ей-богу, не пустим!

Бераздан Габдулла, берәм-берәм күтәреп, Низаметдин белән Гөлфирәне утыртты да, машина, аларны озатырга җыелган карт-корыны, аксак-туксакны зәңгәр төтенгә күмеп, урыныннан кузгалып китте.

—Хәерле сәгатьтә!

—Хәерле сәгатьтә!

Бер-беренә сыенышып арткы утыргычта утырган Низаметдин белән Гөлфирә сүзсез калдылар. Икесе дә шатлыклы мизгел кичерәләр иде бугай.

—Хәерле сәгатьтә, Низаметдин!—диде бераздан үзенең уйларыннан арынган Гөлфирә, аңа күзләрендәге барлык шатлыгы, йөзендәге барлык нурлары белән елмаеп.

—Шулай булсын, бәгырем, шулай була күрсен!—Низаметдин, хатынының кечкенә, кайнар кулларын учларына алып, күкрәгенә кысты.—Мин сине ник шул кадәр яратам икән, Гөлфирә?

—Шуны да белмисеңме?! Юләр булганга!—Гөлфирә шундый рәхәтләнеп, иркенләп кычкырып көлеп җибәрде, руль артында утырган Габдулла ирексездән борылып карап куйды.

—Карале, Габдулла, әйдә быел синең туеңны үткәрик әле, ә?! Чынлап әйтәм мин, дус! Без сине Гүзәл исемле бер гүзәл кыз белән таныштырырга җыенабыз, Алла боерса. Менә дигән кыз, мин сиңа әйтим! Дөресме, Гөлфирә?

—Дөрес, дөрес. Бик әйбәт кыз!

—Карарбыз әле анда...

Машина минут саен, чакрым саен Казанга якынлаша барды. Анда аларны үткәннәрен онытырга, үзләрен янадан Кеше итеп тоярга мөмкинлек бирер дип хыялланган... протезлар көтә иде...

Бераздан Габдулла радионы борып җибәрде. Анда берәү шигырь укый иде:

Кешеләрне җил-давыллар сыный,
Кайгы-хәсрәт сыный кешеләрне;
Аягыннан ега йомшакларны,
Көчле итә бары көчлеләрне.

Кешеләрне зур байлыклар сыный,
Зур урыннар сыный кешеләрне.
Азы гына кеше булып кала,
Кеше булып кала көчлеләре.

Кешеләрне аерылышулар сыный,
Кавышулар сыный кешеләрне;
Мәхәббәтнең ялкыннары яман,
Көл итми ул бары көчлеләрне.

Кешеләрне кешеләр дә сыный,
Хайваннар да сыный кешеләрне;
...Бик күпләрне хәзер аңлап булмый:
Хайваннармы, әллә кешеләрме?

Шигырь сөйләнеп беткәч, Низаметдин белән Гөлфирә бер мәлгә тынып калды.

—Кешене Ходай сынау өчен генә яраткан бугай бу дөньяга...—дип куйды ул аннары, тынлыкны бозып, ничектер уйга талган сыман.—Шуннан соң үзеңнең чын мәгънәсендә Кеше булып калуыңны тою шул сынауның иң ләззәтле, иң шатлыклы мизгеледер, минемчә...

Низаметдин дәшмәде. Ул да уйлар диңгезенә чумган иде бугай.

*2005—2006 ел.*



Эльмира
Шәрифуллина

# ҮЗ ҖИРЕМНЕҢ ҖИЛӘГЕ МИН

## Киңәш

**Нигез ташы салган чакта
Очраса егет, кыз—
Егетен өмәгә чакыр
Кыз балага чәчәк суз!**

## Бүләк

**Яхшылык кылсам кешегә
Горур сизәм үземне;
"Рәхмәт!" белән бүләкләнсәм,
Фәрештәмнең канатлары
Сыйпый кебек иңемне.**

## Әткәм сурәте

**Яшәү өчен һәркем көрәшә.
"Сугыш" дисәң—үлем янәшә...
Кан эченнән кайткан әткәмнең
Һәрбер сүзе җырга тиңләшә!**

## Яктылык

**Гәрәбә нурыдай хәтер
Яктырта күңелемне:
Гәрәбә муенса таккан
Әнкәм ачты телемне!**

---

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА—*шагыйрә, прозаик, публицист; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. "Яңгыр җиле", "Сөюемнән мин бер чибәр идем" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Йөрәктә кала

"Бер булдыксыз шунда..." дисең,
Син тапкан бала бит ул.
Ана әйткән авыр сүзләр
Йөрәктә кала бит ул.

## Элек һәм хәзер

Әхлаклы, динле замана:
Җан азыгы—китапта.
Гонаһлы талымсыз дәвер:
Һәммә азык—ятакта...

## Имгәккә әйләнү

Имгәнгән мәчетләр белән
Ил тулган заманнарда
Туып, имгәккә әйләнгән
Яшәргә калганнар да...

***

*Айвазовскийның "Тугызынчы дулкын" картинасын караганда*

Шашкан дулкынын куптарып
Ярга ыргыта диңгез...
...Бу болганчык дәверләрдә
Шул дулкыннарга тиң без.

## Шәхестә җир кодрәте

Шәхесләренең йөзендә
Милләтенең сурәте.
Талантлылар белән арта
Туган Җир кодрәте!

## Ләбибә Ихсановага

Балалар сафлыгы сездә,
Изгеләр җылылыгы!
Эшсөярләр тырышлыгы,
Егетләр кыюлыгы.

## Зөлфәткә

Дөл-дөл тамырыннан синең
Исемең, газиз дустым:
Дөлфәтне биргән туфракны –
Мөслимне җанга кыстым!

## Мөслимгә

Туган ягым—түр ягым,
Тирә-юньдә—бер ягым!

Бәлзәмдәй мәрхәмәт эчеп.
Яшәреп йөргән чагым!..

## Үз кадереңне белмәү

Кайберәүләр тау күчерә,
Кем менәлми үргә дә...
Адәм булып туганлыгын
Белми иңә гүргә дә...

## Корама дус

Юлдашлар юлда сынала,
Дуслар—кайгы килгәндә.
Төрттерергә маһирлар бар
Йомшак жиреңң сизгәндә.

## Беркатлылык

Кәбестә кебек "беркатлы"
Кайчак бездә дус-ишләр!
Катлы-катлы әләкләре
Үзенә төшсә, нишләр?

## Гомер

Учларымда язу-сызу—
Гамәл дәфтәремени?
Көн—таңым белән туа да
Шәфагым белән эри...

## Кырыктан кырык төрле

Кырык ата баласыннан
Кырык төрле уй ага:
Берсе капканы кага,
Калганы жанны чага.

## Гадәт китми

Балалыгым бетмәс инде
Соңгы сулышка кадәр.
Ящькә манчый һәр шырпы-сүз,
Өшетә шымчы-хәбәр.

## Татлы тәгам

Сүз-хәрефне сайлап алып,
Йөрәгем моңга төрә.
Шигырьләрем татлы тәгам—
Күрәсе килгән күрә!

## Ал җилкәнем

Түбән агым тарта кайчак,
Көчсезләнә күңел.
Юк, бирешмим! Борыл, җилем,
Ал җилкәнем, терел!

## Тимә!

Тол хатыннар—ялгыз җаннар
Җилкәнсез калган көймә.
Әдәпсез уйларың белән
Толлар янына тимә!

## Шундый заман

Иңнәремдә авыр кайгы. Көч-хәл белән
Атлап барам, кан-яшь белән юлны "сыйлап".
Гөжләп тора карурмандай кеше алда,
Ник берәүсе күз сирпесен хәлне сорап...

## Чуен кебек елтырый

Тәти егет, әти-егет үзләрегез,
Сызлануны күрми үтә күзләрегез.
Майлы коймак сузган кебек сүзләрегез,
Чуен нурлы битлек кигән йөзләрегез...

## Хамелеон

Кеше башыннан йөргәннәр
Ничек аклый дисәм, үзен?
Мулла песиедәй тыйнак—
Намазлыкка бөккән тезен...

## Кешегә чокыр казыма

Теш кайрап йөрмә кешегә,
Телеңне тешләтерләр.
"Дус"ка корган капкыныңны
Үзеңә эшләтерләр.

## Әрәм итмә

Караны ак төскә буяу
Мәшәкатьле.
Көч-куәтең әрәм итмә
Шул сәбәпле!

## Чагыштыру

Тиреңнән чыгарга җитеп
Кешегә яраклашу—
Чагыштырып караганда,
Ком чүленә су ташу.

## Намуссызга

Үз җиремнең җиләге мин,
Үз илемнең тургае.
Җиләк кебек гомеремә
Теш батыра бурзае...

## Бозык дөнья

Кәкре күзге, бөкре дөнья,
Бозык адәм баласы...
Кәкре-бөкре дөньясында
Ничек туры каласы?

## Кабатлану

"Дөнья матур, дөнья киң"
Могҗизага еллар тиң.
Бүген пешкән тәгам-аш
Кичәгегә авандаш...

## Чагылыш

Шәрекъ дусның яратканы
Парча кием, алтын-көмеш.
Бизәкләрен баетадыр
Сусыз дала, сусыл җимеш.

## Чит милләтне сайлаучыга

Яралгысын туар баланың
Татыса да ана карыны,
Ятлар белән корган тормышның
Нәтиҗәсе ике сарылы.

## Иш итмәү

Парлыларга парсыз кирәкми:
Түләү ни дә бездән терәү ни?..

## Алтыдагы алтмышка

Бизәсә дә йөзен кершән,
Холык шул ук, һаман үшән...

## Таяк һәм маяк

Аунап яткан моңсу таяк—
Урынын тапса, мәшһүр маяк!..

## Асыл мәхәббәт

Мәхәббәтнең чын асылы—
Туар көннең мең фасылы.

## Киңгә тиң

Күңеле киңнең дөньясы киң,
Дус-ише үзенә тиң.

## Картлык—хаклык

Шатлык түгел дөрестән дә, әйе, картлык,
Әмма ләкин тәҗрибә ул һәм дә хаклык!

## Шундый вакыт җиткән

Мемуарлар язар вакыт җиткән икән,
Арабыздан иң шәп дуслар киткән икән.

## Кем кайгысы кемгә кирәк?

Лычма су булдым кайгыдан,
Аңлап, текәлде ай гына...

## Наз җитмәү

Ялындырып кына шытып чыкты
Тәрәз төбендәге үсенте.
Кояш назы җитеп җитми әле,
Яз һавасы әзрәк кысынкы.

## Бал көне

Яңгырлы көн—ял көне.
Мунчадан соң тәмен табып,
Чәйләп эчкән бал көне.

## Беркатлылык

"Йөзек кашым" дигәннәргә ышанмамын,
Дип әйттем бит үз-үземә күптән инде.
...Мең дә бер кат ихласланып ышанганмын.
Юха елан боргаланып башын чөйде...

## Сүнмәс хәтер

Хәтер сүнсә—муллыкта да халык бөлә,
Хәтер сүнсә—көпә-көндез тарих үлә...
Сүнмәсен дә, үлмәсен дә безнең хәтер,
"Үлә" дигән коткы үзе "китсен кәтер"!



Юныс
Сафиуллин

# АКМУЛЛА

**Катнашалар:**
**"Дала" күренешендә**

Акмулла. 40 яшьтә
Динмөхәммәт. 45 тә, кәрван тотучы бай
Бәдретдин. 43 тә, аның энесе
Госман. Динмөхәммәтнең төпчек улы, 14 тә
Дәүләтша. Акмуллага дошман бай, 59 да
Мөхәммәтсәлим. 22дә, олы яшьтәге башкорт шәкерте
Исәнгилде. 40 яшьтә
Һәсәнзадә. Әзәрбәйҗанлы

**"Хибесханә (төрмә)" күренешендә**

Акмулла. 45 яшьтә
Идрисби. 48 дә, ата карак
Исукаев. 45 тә, Акмулла аркасында надзирательлектән алынып тоткын ителгән надзиратель вазифасын башкаручы стражник
Тылмачев. Конторщик
Дусмаил Качкынбаев. Казакъ, Акмулла шәкерте
Якуп. Шәкерт
Арысланбай. Шәкерт
Торгунбай. Шәкерт

**"Зыяфәт" күренешендә**

Акмулла. 63 яшьтә
Риза казый Фәхреддин. 36 яшьтә

Юныс САФИУЛЛИН (1947) – *драматург; күпсанлы пьесалар, сценарийлар авторы. Казанда яши.*

Әмирхан Туктамышев. 65 тә
Кәрим морза. 55 тә
Мөхәммәтсәлим Өметбаев. Башкортның олы мәгърифәтчесе, акыны, 45тә
Закир Рәмиев (Дәрдмәнд).
Исмәгыйль. Өлкән казый
Дусмаил Качкынбаев

**"Хушлашу" күренешендә**

Акмулла. 63 яшьтә
Габдегомәр. 14 яшьтә
Чегән кызы

## Дала

*Ялга туктаган кәрванчылар чатыры. Тын дала өстендә кәрванчы чатырыннан саз авазы ишетелә. Ана котлаган тавышлар кушыла:—Бәрәкалла!. Күңелеңдә моң бар икән, олан! Динмөхәммәт, мондый улың булу зур куаныч!*

*Далада ат пошкырып куя. Якында гына арба килеп туктаганы ишетелә. Дала караңгылыгын әчтән төшкән яктылык белән кискәләп, чатыр япмасы ачыла:—Улым, Госман!—Чатыр яктысында торган әлеге тавышның иясе—олы гәүдәле ир янәшәсендә яшүсмер малай да күренә.*

Госман. Әйе, әти!

Динмөхәммәт *(малайдан сазны алып).* Шыпырт кына күз-колак булып килче. Начар ниятлеләр йөрмиме икән?! *(Чатырга кереп югала.)*

*Кабат караңгыланып киткән чатыр мәйданына атлы арба туктаган тарафтан бер юлчы керә. Госман аны күреп туктап кала.*

Госман. Кем син, агай, ниятең ни?

Акмулла. Мин мосафир, ә үзең кем?

Госман. Мин Госман, кәрванбашның улымын.

Акмулла. Кәрванбашның аты ничек?

Госман. Динмөхәммәт.

Акмулла. Белгән кешем түгел икән. Кәрваныгыз кай якка юл тота?

Госман. Хива белән Үргәнечкә. Ә син үзең каян килеп кая барасың, абзый?.

Акмулла. Мин казакъ далаларыннан кайтып киләм, чырагым...

Госман. Син кайсы милләт кешесе соң, агай? Киемең казакъныкы, ә үзең безнеңчә сөйләшәсең...

Акмулла. Казакъларны читкә аерма, чырагым. Алар да безнеке дию лазим. Без төркидән туган... Кашкарый төркиләр турында ни дигән...

*Чатырдан шаулашып Дәүләтша белән Динмөхәммәт чыга.*

Дәүләтша. Энең Бәдретдин тилекәй икән. Акынымны хурлай. Исәнгилде үлән бәйгеһендә Акмулладан да өстен сыкты.

Динмөхәммәт. Дәүләтша, кударланма. Әнә далага күз сал. Нинди мәһабәт, нинди тыныч ул! Ишетәсеңме, ял итүче кәрвандагы дөяләрнең акрын гына сулыш алуларына хәтле ишетелә. Даласының һавасын кымыз белән кушып эчәрлек, валлаһи. *(Чатыр ягына)* Бәдретдин энем! Бәдретдин *(чатырдан чыга).* Мин монда, абый!

*Дәүләтша Бәдретдингә үпкәсен сиздереп, чатырның бер кеше дә булмаган ягына китә. Кесәсеннән алып тел астына насбай сала, тагы нидер алып исни. Төчкерә.*

Динмөхәммәт. Улым, син дә мондамы?

Госман *(яктыгарак чыга).* Монда, әткәй!

Д и н м ө х ә м м ә т. Турсык белән чынаякларны шушында куегыз әле!

Чатырдагылар да һава иснәргә чыксын!

Г о с м а н. Әти, монда бер мосафир да бар иде...

А к м у л л а *(яктыгарак чыгып)*. Әссәламегаләйкем!

Д и н м ө х ә м м ә т. Вәгаләйкем әссәлам!

А к м у л л а. Мин бер фәкыйрь хәлфә буламын. Озын юл килеп үзем дә, атларым да йончыды. Аларны кәрваныгыз янәшәсенә тугарып хәл алсам ничек булыр икән?..

Д и н м ө х ә м м ә т. Бик хуп, бөрадәр, тугар.

А к м у л л а. Рәхмәт, бай. *(Китә башлый)*

Д и н м ө х ә м м ә т. Аннары табыныбызны уртак кыл. *(Акмулла киткәч)*. Улым, Госман! Мосафирга комган белән тастымал китерерсең. Юынып алыр!

*Госман йөгереп кенә бик зур турсык алып кереп атасы күрсәткән җиргә куя. Чатыр япмаларын Бәдретдин белән икәүләшеп як-якка күтәреп кыстыралар. Чатыр алды яктырып китә. Озын киезне шул якты төшкән җиргә җәеп, чынаяклар тезәләр. Чынаякларга кымыз коелып, Бәдретдин чатырдагыларны табынга чакырырга кереп киткәч, Госман чатырның кеше йөрми торган ягында торган комганга су сала.*

Д ә ү л ә т ш а *(тагын бер тапкыр нидер иснәп, рәхәтләнеп төчкергәч, бик кәефе килеп)*. Исәнгилде! Кил бире, акыным! Нимә тип һаман талашаһыгыз?

*Чатырдан Исәнгилде, Бәдретдин, кырпу бүрекле әзәрбәйҗанлы Һәсәнзадә һәм Мөхәммәтсәлим исемле бик мәһабәт гәүдәле горур 22 яшьләрендәге башкорт шәкерте чыга.*

И с ә н г и л д е. Акмулла шигыре түгел дим, ә Бәдретдин әнә, һаман шуны Акмулланыкы ди...

Д ә ү л ә т ш а. Акмулла да Акмулла. Уны башкорт далаһыннан эт ектереп кыудырган инем.

Д и н м ө х ә м м ә т. Ни өчен кудырттың, Дәүләтша дустым?.

Д ә ү л ә т ш а. Балакайдарымны укытканда котыра башлады. Казаннан Бохарага, Бохарадан тагы да ары һөрелгән Курсавины үрәтә башлады. Иманһыз Маржанины, һукыр Каюмды остазым тия ине.

И с ә н г и л д е. Казан кешеләре аңа ничек остаз булсын. Аның Казанда булганы да юк.

Д ә ү л ә т ш а. Нә килһә Казан ягыннан килә. Казандыкылар дөнья болгатуыһыдар.

Д и н м ө х ә м м ә т. Әйдә, бу турыда сөйләшмик. Әнә кымыз көтә.

*Акмулла кергәнне Госманнан башкалар сизми. Госман Акмулланы чатырның ар ягында торган комган белән ләгән янына алып барып юындыра башлый. Акмулла бәхәсләшүчеләрне дә тынлый.*

Д и н м ө х ә м м ә т. Кардәшләрем, кымыздан житешенез!

Б ә д р е т д и н. Акмулланың башка шигырен укыйк алайса!

Д и н м ө х ә м м ә т. Талаш чыкмаслыкларын гына...

Б ә д р е т д и н *(кесәсеннән куен дәфтәрләре чыгарып, ак тышлысын ача)*.

Дөньяда кайда барсаң гыйлем эстә,
Һәр заман әһле гыйлем чыкар өскә.
Наданлар жарамыйдыр һич бер эшкә,
Ушбу сүзне һәр даим төшер искә.

Галимнәр бу дөньяга баш булмакда,
Халыкның күз өстендә каш булмакда,
Йөрмәгән табиг улып вәхшилеккә,
Наданнар ни эшләсә фаш булмакда.

Акмулла табынына күз салыныз,
Ни теләсә шуны табар жаныныз.
Авыз иткәч берсе мактар, берсе сүгәр,
Кемгә им, кемгә агу туры сүзләр!

*Мәжлестәгеләр соклану тавышлары белдерәләр.*

М ө х ә м м ә т с ә л и м. Әй, сөбхан. Ошбу Акмулланың үден күрһән ине. Аягына баш орып, һин дала котбы тейһәң ине. Авыз иткәс берһе мактар, берһе һүгәр *(көлә)*. Ысыннан да һүгәләр бит! Машалла, йөрәккә һары май булып ята.

Һ ә с ә н з а д ә (әзәрбәйҗанлы). Яшасын Акмулла акын!

*Акмулла юынып бетереп, кулларын сөртә-сөртә, арбасы ягына чыгып китә.*

*Госман аңа иярә һәм кулына ак чикмән тотып кергән Акмуллага киенергә булыша.*

Исәнгилде. Һед башка Акмулланы һөйләйһегез, ысын Акмулланы беркем белмәй, уны Дәүләтша бай белән мин генә беләм!. Ул минең кустым, авылдашым. *(Шигырь укый)* Менә уның шигыре, тынлагыз: "Башкортларым, укыгыз һед, укыгыд..."

Мөхәммәтсәлим. Тукта, тукта, Исәнгилде агай, һин бит ысын башкорт түгел, һин бит мал алыр өсен генә башкорт булып йөреүһе адәм. Нәмәгә тип башкортларга, укыгыд дип лыгырдайһың. Һин башкортны надан тимәксе булаһыңмы?

Исәнгилде. Акмулла шулай дигән. Башкортларым, укыгыз тигән.

Сәлим. Тимәс. Башкорт ул бөек халык. Урал тауларыдый гайрәтле халык. Ул һинең кебек ер һыуалсаны түгел!

Исәнгилде. Шәкерт, тик тор. Һиңә әле укырга да укырга. Бохарага барып кеше күлдерә кұрмә.

Динмөхәммәт. Туктап торыгызчы, бөрадәрләрем. Мосафир, син дә табынга утыр. Әйдәгез, кымыздан да житешенез!

Бәдретдин. Акмулла ага барлык төркиләр өчен дә тырыша. Шуңа төркинең тулы йорты аңа мөкиббән!

Һәсәнзадә. Чох разыймын! Бөйек шагыйрь. Сәйат-Новадай шагыйрь.

*Госман Акмулланы табынга утыртып кулына чынаяк белән кымыз бирә.*

Сәлим. Бына Бәдретдин һүзе акыллы исмаһам. Рәхмәт, кардәш.

Барсы бергә. Шулай.

Дәүләтша. Жамагать, Мифтахетдин Камалетдин улы Акмулла Маржани белән Курсавидан күрмәксе, түрәләргә, муллаларга, менә һезнең кебек олыларга тел озайта! Аны да беләһезме?

Һәсәнзадә. Дәүләтша, Исәнкилде газизләрем, Акмулланың нә күнаһы вар? Бәдретдин. Дөрес, Һәсәнзадә бай. Менәни ди Акмулла. *(Куенынннан дәфтәр алып укый).*

Жаманды түрә кылсаң—йортың бозар,
Гакылсызны үстерсәң—ботың сузар!
Түрә димә, кара димә—фигылен кара—
Кәй жаман аргамактан мәстәк узар.

Менә Акмуллада сүз яман адәмнәр турында гына бара ласа!. Мәстәк дигәне гади эш аты, әнә шул гади эш аты да начар аргамактан өстен чыгар дигән.

Дәүләтша. Һәсәнзадә бай. Акмулла үзен ак дисә дә, жырулары ак, нәфис түгел. Һез менә минем акынны тыңлап карагыз әүвәл! Ыру шундай була ул!

Исәнгилде.

Их, алтыным, бәян әйлә, сүзем кабул итәрмүһән,
Шулай тилмертеп үк аллә Өфеләргә китәрмүһән.
Арткаеннан китәем лә, Өфеләргә житәем лә
Аһ, магышукәм кыса-кыса туйганча пәп итәем лә.

Дәүләтша. Йә, жәмагать, алкыш ишетмәем! Акыным Исәнгилде аңа лаек! Исәнгилденең йыруы Акмулланыкыннан нык нәфис ул.

Динмөхәммәт. Акмулла үзе монда булмагач, бу хакта сөйләү кирәкмәс!. Бетерик.

Исәнгилде. Акмулла моннан бик күп еллар элек Дәүләтша байга балалар укытырга яллаңган. Шунда Акмулла дип аңа мөхтәрәмебез Дәүләтша бай үзе кушкан!

Бәдретдин. Булмас. Менә бу яшел дәфтәрдәге шигырендә Акмулланың, мине ак жилән киеп йөргәнгә Акмулла дип атадылар дигән сүзләре бар.

Дәүләтша. Әнә шул жиләнне аңа мин бүләк иткән инем!

Госман. Акмулла дигән исемне аңа казакъ халкы биргән диләр!

Дәүләтша. Өлкәннәр һүденә кысылма, көсек! Акмулла дигән исемгә минем аркада ия булды Мифтахетдин, әмма аклай алманы. Бик үзһүзле кеше. Дуамал, Тукһанбайга кайтып үги атаеннан мәрхүмә әсәенең мирасын дәгъвалап талашып йөргән. Шул хәерсене кызганып балаларымды укытырга сакырдым. Аңа газиз кызымды катынлыкка бирмә келәнем. Дим буенын атакты бае итмәк булдым. Менләгән куе булыр ие. Ә ул—Акмулладан көтөүсе ясама, көтөүсе менән бөтен дала тулган, ә мин бер генә тип, казак далаһына сыгып касты. Эстәрледә үрәнгән өнәре буенча тәрәзәләр яһап көн күрде. Ә бай булса һүзе нык үтәр иде. Ахмак!

Госман *(яттан сөйли).*

Яхшыны сүккән белән аты китмәс,
Яман сүзнең күнелдән табы китмәс.
Саф алтынны нәжескә буяу белән
Нәжес китәр, алтынның заты китмәс.

Сәлим. Машалла! Әллә буһы да Акмулла агаебызныкымы?

Исәнгилде. Түгел!. Мәдрәсәдә күпме укып берни белә алмагансың! Тәсдикъ ит, Дәүләтша бай.

Дәүләтша. Такмак кына бу.

Бәдретдин. Бәлкем монысы ошар? *(Дәфтәрдән шигырь укый)*

Аткан уктан файда аз—җонсыз булса,
Юлдашыңнан файда аз—җүнсез булса.
Мөнәҗәт, шигырь белән эше булмас—
Күңеле каткан бер дәрдсез, моңсыз булса!

Дәүләтша. Исәнгилде кияү, Акмулла дип синә генә кушасым калган.

Бәдретдин *(өченче дәфтәрне ачып укый)*:

Адәм камил булмас кайнап пешмәй,
Мәхәббәт касәсеннән шәраб эчмәй.
Дошманнар тозакларны салып карай—
Тургайның тозагына лачын төшмәй.

Исәнгилде, нигә җыру әйтеп җавап кайтармыйсың?. Әгәр син Акмулладан өстен икән, укы шигырь...

Исәнгилде. Башта шуны сорыйм, кайсыгызның Акмулланы күргәне бар?

Акмулла. Йә, йә, ниндиерәк соң ул, Акмулла?

Исәнгилде. Менә минем кебек пәһлеван бер адәм ул, Акмулла.

Акмулла. Ялган.

Динмөхәммәт. Мөсафир, бүлдермә, бер башлагач әйтеп бетерсен.

Бәдретдин. Чыннан да ниндиерәк соң ул Акмулла?

Акмулла. Бик әйтер иде дә, бичараның Акмулланы күргәне юк.

Дәүләтша. Йитде. Тагы да мыскыл итһән, башың кисеп этләргә ташлаем. Акмулла менән ул күп әйтеште, әйт әле, Исәнгилде!

Исәнгилде. Без Акмулла белән ике акын кара-каршы йыру әйтеп күп ярыштык. Бер-беребезне еңә алмагас, безгә инде көрәшеп тә карагыд диделәр. Әнә шул көрәштә—мин өстен сыктым.

Акмулла. Син Акмулладан өстен чыктыңмы? Булмас. Мине сыртыма әйләндереп салган Акмулланымы җинден? Кит, чын сүзне дөрес булса да сөйләмә!

Дәүләтша. Был ниткән кире каткан адәм. Таныш та кебек үде? Исәнгилде, йәле күрһәт? Уны Акмулла йиңгән, һин Акмулланы еңгәнһең, димәк һин монау адәмне дә һыртына һала алаһын! Әнә нисек шыр ебәрде. *(Тел астына нидер салып сикереп тора, гайрәтләнеп).*

Көтәм! Көрәшенез!

Динмөхәммәт. Кирәкмәс. Яшь кешеләр түгел бит инде алар. Кырык яшьтә акыллырак булган яхшы.

Акмулла. Кымызыгыз өчен рәхмәт, бай. *(Торып китә башлый).*

Дәүләтша. Минә менә тиздән алтмыш. Исәнгилде курыкһа, үзем көрәшәем. Тукта, йолкыш адәм, касма!

Исәнгилде. Башлагач яфрак астына качма инде! *(Затлы бишмәтен салып ташлап, Акмулланың билен кәмәре белән уратырга итә).*

Акмулла. Нишләмәк кирәк... язмыштан узмыш юк. *(Җиләнен салып Госманга бирә)*

Исәнгилде. Их син, камыш сыйрак!

Дәүләтша. Берүк үтерә күрмә үзен!

*Акмулла белән Исәнгилде тарткалашалар.*

Исәнгилде. Тукта, хәрамлашма. Казанча көрәшәсен, монда Казан түгел.

Дәүләтша. Әйе! Көрәш безнеңсә!

*Акмулла Исәнгилдене еккач, барчасы «Аh» итәләр.*

Акмулла. Акмулланы ектым дип нигә ялган сөйләп йөрисең, Исәнгилде? Һин дә Дәүләтша бай, кеше танымаслык хәлгә килгәнһең икән. Һинең яшьтә бакый дөнья турында уйларга вакыт!

Исәнгилде *(җирдән торалмый утыра).* Кем син?

Акмулла (шигырь әйтә).

Батырны «батыр» диләр—көчен күргәч,
Останы оста диләр—эшен күргәч!

«Ишарәт—гакыллыга» дигән сүз бар—
Артык сүз әдәбсезлек асыл затка.

Арбасы ягына китеп бара. Барсы беравык тынып торалар.

Динмөхәммәт. Акмулла үзе ахры бу! *(Барысы да шаулашып алалар.)*

Улым, Госман чакыр үзен, табын түренә утыртыйк!

Барсы бергә. Хәлфә Акмулла! Мифтахетдин Мөхәммәдьяр улы Акмулла!

Чакырабыз! Арабызга килче!

Акмулла *(ике яклап уртадан ара калдырган хәлдә тезелеп баскан кәрванчылар арасыннан тамаша залына таба килә башлый).*

Саескан хәким булып тутый булмас,
Мескен илнең баласына һич сан булмас.
Бозавы үлгән сыерның сөте булмас,
Җүкәне майлау белән каеш булмас.

Башка илне без күрәбез: тауга чыккан,
Һичкайчан ил уналмас түбән баккан.
Мәгърифәт дәрьясы күпкә уртак,
Онытылып хур калмыйдыр кулын тыккан.

Тормышы башка илләрнең көн шикелле,
Тормышы надан илнең төн шикелле.
Үзенез уйлап караныз, мигә салып,
Күренә шушы җире мин шикелле.

Динмөхәммәт. Госман, сазынны алып кил әле, улым. Җырлап бирик әле, Акмуллага, Мифтахетдин абыена.

*Госман сазын алып килә. Динмөхәммәт җыр суза.*

## Труйский хибесханәсе, ягьни Троицк шәһәре төрмәсе

*Кайдадыр бер шпананың чая да моңлы да булган нindидер караклар көен сызгыруы ишетелә. Төрмә камерасында ике катлы сәке. Икенче каты төрмә камерасының тәрәзәсе турысында. Тәрәзә тимер рәшәткә белән тотып алынган. Сәкенең икенче каты хәзергә буш.*

Акмулла *(Идрисбинең бишмәтенә карап).* Булды шикелле, Идрисби. Шулай да сал әле, җөе тигез чыкмады.

Идрисби. Мине кулга алучы казак нагайкасы белән ертып төшерде. Издем дә соң үзен, атыннан сөйрәп алып. Их, атына атланып качарга өлгермәдем—дуслары килеп җитеп башымны тиштеләр. *(Бишмәтен салып Акмуллага суза).* Акмулла хәзрәт, кайчан котыласың инде бу парашалы төрмәдән?

Акмулла. Ә син үзең?! Котылсаң да, кабат шушындагы кандала, борчалардан талатырга, стражниклардан кыйналырга кайтасың.

Идрисби. Төрмә—дом родной. Но син шагыйрь булсаң да, арттырма, миңа сугарлык стражник юк бу таш капчыкта. Әнә, син ябылып асралган дүрт елда, мин моннан өч тапкыр котылып чыктым. Ә сиңа 4 ел буена суд та юк, черт та юк. Бик хәтәр җинаятьчесең ахрысы, бырат? *(Көлә.)*

Акмулла *(көлә).* Рас әйтәсең, бырат, ат карагы гына түгел мин.

Идрисби. Шулаен шулай диден дә, дүрт елга, нибары, мең баш атны урнаштырдым да, урыс байларының дистә ярым кибетеннән ярлыларга мул гына өлеш чыгарттырдым.

Акмулла. Төрмә түрәләрен баетам дисәң, дөресерәк булмасмы? *(Җепне тешләп өзә һәм бишмәтне Идрисбигә суза.)*

Идрисби. Чичән шул син, чичән. Ак атыңнан җиргә төшеп караганың юк, күрәм. Ә миңа *(Акмулланың колагына гына нидер пышылдап, муенын ышкып күрсәтә. Тегесе ышанмый күтәрелеп карагач).* Туры килә. Шунсыз булмый!

Акмулла *(кулын күтәреп дога кыла).* Иннә иләйһи вә иннә лилләһи рәжигун! Шелтә кылмыйм, мәгәр кеше җанын кыю...

Идрисби. Тамчы үкенмим. Алар надзиратель Исукаевтан да кабәхәтрәк адәмнәр иде. Ну, бырат, төрмәне шыр җибәрткәнсең бит. Бөтен төрмә малын читкә шуыткан крыса Исукаевны тәки капкынга керткәнсең.

Акмулла. Яманны дошман күрмәк—дин сөннәте! Исукаев—кулы белән эшләгәнне муены белән күтәрергә тиешле ерткыч адәм!

Идрисби. Бая күрдем ул крысаны, исправникка кертеләр. Тикшерүчеләре Петербурдан ук килгән, ә! Әгәр каурый каләмең шундый көчкә ия икән, бырат, нигә син үзеңне дә якламыйсың?. Кемнәр бар бит инде синең анда?

Акмулла. Бар да, җук та. Бишмәтенне киеп карале.

Идрисби *(киеп)*. Шәп инде, шәп синең белән бер генә тегүче дә ярышалмый, брат. Рәхмәт! Хакын сора!.

Акмулла. Син шушы сәяхәтләрдә йөргән арада, кәгазьгә интегәм мин.

Идрисби. Кәгазь—тфү! Хет капчыклап. Судны булдырабыз, вчү!. Әгәр сине Себер җәһәннәменә озата башласалар, порукага алырбыз! Син хәзер үк Петербургтагы танышыңа хат әзерлә. Амнистиягә җибәртерлек итеп!.

Акмулла. Хатка гына калса зары да гаризасы да күптән әзер! Менә порукага алырлык акчаны кайдан табарга?

Идрисби. Идрисбигә ышан!. Әйттем бетте! Мең тәңкәләп кенә торса, бүген үк табам. Әмма синең өчен күбрәк сорарга да намуслары житәр. Ул кадәр акчаны төрмә белән генә күтәреп тә булмас, мөгаен, бөтен ил белән жыярга туры килмәгәе.

*Кинәт кыңгырау кагыла. Зур йозакның куркыныч тавыш белән шалтырап ачылуы ишетелә. Кулларына надзирательнең ачкычлар бәйләмен тоткан стражник белән конторщик Тылмачев пәйда була. Алар Исукаевны камерага төртеп үк кертәләр. Ул Акмулланы күрүгә чигенә башлый. Конторщик аны аркасыннан тотып туктата.*

Исукаев. Бик прошу, мине башка камерага илтегез.

Надзиратель. Монда тиеш.

Тылмачев. Син беләсең, иң шәп камера шушы!

Исукаев *(надзирательгә)*. Стражник, помоги ради бога! Петя, забери меня отсюда!

Надзиратель. Карцерга утыртуларын көтәсеңме?!

Тылмачев. Господин Мифтахетдин Камалетдинович! Әйдәгез конторага!

Акмулла. Нигә?

Тылмачев. Безнең дә самоварыбыз ага башлады. Ямарсын.

Акмулла. Туйдырды әле бу, господин Тылмачев!

Тылмачев. Кунакларым бар. Ярый, синең дә хәлеңне аңлыйм—жинаятеңне тикшерү шактыйга сузылды. *(Акмуллага гына.)* Борчылма, тиздән суд була.

Акмулла. Аста мине күрергә килгәннәр. Атнадан артык көтәләр Нигә безне очраштырмыйлар, господин Тылмачев?

Тылмачев. Төзәт башта самоварны.

Акмулла. Өегездән китерткәннәрен дә рәтләп торам түгелме! Очраштырсагызчы. Алар бит казакъ далалары буенча йөзләгән чакрымнарны үтеп килгәннәр...

Тылмачев. Ярый көт, рөхсәт сорап киләм.

*Кабат тимер ишекнең дөбер-шатыр ябылуы, зур йозакның шалтырап куркыныч тавышлар чыгарып бикләнгәне ишетелә. Акмулла борылып карау белән Исукаев чигенеп ике катлы сәкегә бәреләһәм житез генә икенче катка үрмәләп менә.*

Идрисби. Ну-ка, төш, минем урыннан, кандала!

Исукаев. Төшмим, Акмулла мине тоткын иттерде, хәзер әнә башымны да ашарга жыена!

Акмулла. Урыс түрә ташлаган сөякләр хакына дүрт ел буе күңелемә таш ччтен, Исукаев. Әнә шул ташларың бугазыңа утырды.

Идрисби. Төш, иблис, ботыңнан тартып төшергәнче!. Синең урының параша янында, таракашка.

Исукаев. Кемне яклыйсың, Идрисби. Мине якла син. Күпме ярдәм күрдең миннән! Смотри, б-б-б буду мин камерада *(шомлы итеп)* временно. Тиздән чыгам. Ә бу Акмулла государственный преступник. Затлы карак исемеңне пычратма!

Идрисби. Аһ, әле син миңа да яныйсыңмы? *(Сәкенең беренче катына сикереп менеп икенче каттагы Исукаевны йолкып алып параша чиләге янына китереп сала.)* Ботарлап тыгыйммы сине шушы параша чиләгенә?!.

Исукаев. А-а, жибәр, тимә, кирәкле сүзне беләм! Төрмә начальнигы Петр Иванович башкорт старшиналарына, казакъ түрәләренә Акмулланы далага кайтартмаска вәгъдә бирде.

Идрисби. Шул гынамы?.

Исукаев. Казакъ түрәләре аны далада каңгырып йөрүче бичара нугай хәерчесе, диделәр. Начальниктан «Төрмәдә черет» дип ялындылар. Әнә зур түрә Исәнгилде дә «башы бедһен» диде.

Акмулла. Исәнгилде? Ул да булып киттеме. Ни житми ансына?

Исукаев. Син анын: «Үләнле жирдә куй, үлекле жирдә мулла Акмулла симерә» дип шаяртуына: «Даулы жирдә түрә симерә, сахрада безнен кебек муллалар булмаса, сезнен кебек жаһилләрнен башын эт кимерә» дигән булгансын.

Идрисби. Судны кайчанга куйганнар? Шуны әйт!

Исукаев. Тәгаен белмим. *(Идрисбинен ачулы карашыннан куырылып).* Суд булуга Акмулланы ике елга арестантлар ротасына жибәртәм диде төрмә начальнигы Петр Иванович. Әле теге ни «Акмулла хамелеон» дип тә өстәде! Чыннан да, казакъча син үзенне казакъ дисен, башкортка син үзенне башкорт дисен, татарга татар дисен! Ниятен ни?

Акмулла. Ә синен ниятен ни, Исукаев? Казакъ, башкорт, татарны талаштырып далага хужа булып алган урыс патшанын малын саклаумы? Атана нәләт. Бирән йөрәгән күпме тоткыннын күз яшен йотты, эт жан!

Исукаев. Мине яптырдым дип куанасынмы?!. Мин иртәгә үк моннан чыгып, тәрәзә каршында артымны күрсәтеп тәрәт итәм. Ә син үз башынны үзен ашадын!

Идрисби. Ә синен башынны мин ашыйм, Исукаев! *(Исукаевны ләктереп муенын бора башлый.)*

Исукаев *(Идрисби кулында чәбәләнеп).* Каравыл, үтерәләр!

*Ишек кабат ачыла. Стражник-надзиратель, Тылмачев керәләр.*

Стражник. Что за шум?

Исукаев. Меня убивают! *(Дүртъаяклап барып кун итеген коча).* Петя, куда угодно... только не оставь меня с ними!

Стражник. Ну ладно, пошли... *(Исукаевны иярт)*

Тылмачев. Мифтахетдин Камалетдинович. Рөхсәт алдым. Тик озакка түгел.

*Исукаев белән Акмулла бусагадан атлауга кабат авыр ишек шыгырдап ябыла. Йозак эленә. Тылмачев Акмулланы сәхнә алдындагы озынча урындык янына алып килә. Ә үзе читкәрәк барып күзәтә башлый. Каршы якта казакъ шәкертләре күренә. Ин алдан Акмулланын ин яраткан, сонырак остазы турында язачак шәкерте Дусмаил Качкынбаев атлый.*

Дусмаил. Молдакәм! Сине дә күрер көн бар икән! *(Күрешергә кул бирә.)* Акмулла *(күрешеп).* Досмаил, чырагым, Аман келдегезме?!

Дусмаил *(казакъ шәкертләргә).* Жулдастар, бире келен! Менә бу шәкертләр казакъ далаларыннан жыелып сине күрергә келделәр, молдакәм. *(Таныштыра.)* Тургайбай—Тургай суы жарларыннан, Жакуп—Кече Жөздән, Арысланбай минем шәкерт—Тингезкүлдән...

Акмулла. Айда, бүз жегетләрем! Таныс булыйк! *(Күрешеп чыга).*

Дусмаил. Жулдастар, менә ол енде, безнен бүтүн төрки дөньясына хаклык даулаучы акын, ялкынлы чәчән!

Акмулла. Синен дә шәкертен бар диген, ә, Дусмаил, чырагым!

Дусмаил. Әйе, молдакәм. Арысланбай зур укыган булыр!

Арысланбай. Тоткынлыкта да үлән әйтеп жәүһәр таратучы сандугач Акмулла шушы булып икән!

Торгунбай. Тургайсудагы айтыста да усы Акмулла акын жинде! Акын, син белеп тор, безнен Тургайнын Урускул бай сине төрмәдә черетәм, мәнге чыгармыйм дигән!

Якуп. Безнен Кече жөзнеке Батуч ол! Шол Батуч иблисләрчә мактана гуй. Ә син төкер, Акмулла чичән! Акмулла дошманы—дала дошманы. Безнен дә дошман булып торур!

Акмулла. Сабыр етенез, бүз жегетләрем! Сез тансык казак сахрасы исен алып келдегез! Кымыз исе, казылык исе.

Дусмаил. Молдакәмнен борыны ис тоя гуй. Сине сахрада онытмадылар. Тол хатын Алтынчәч «чакча баш нугаема бирен» дип бүләк тә жибәрде. Кайчан тагы кайтып «мене жанына сал» дип шаяртыр икән диде. Арсланбай тапшырын.

Арысланбай. Бүләкте рәхәтләнеп тапшырамыз гуй! *(Кечкенә генә турсык белән кымыз, тастымалга төрүле казылык чыгара).*

Дусмаил *(кымыз салып).* Бер аяк кымыз эчеп куй, молдакәм!

Акмулла. Жаксы. *(Эчә. Кәефләнеп.)* Кымызнын куәте тамырларга та-

ралды гуй! Ничек сагындым мен даланы! *(Дусмаил салып биргән кымызны кабат күтәрә.)* Әнә дала тудырган кымыздан тамырларымдагы кан кайнап тау елгасыдай агар булды. Менәзе гүзәл Алтынчәчкәгә күп рәхмәт тапшырыңыз! Хәзер үк сезнең белән казакъ арасына кайтып китәр ием гуй. *(Татарча сөйләп китә).* Ул далалар гел күз алдымнан китми. Әле бүген генә төш күрдем. Башларына кечкенә кызыл түбәтәйләр кигән кызлар жырлый-жырлый киез басалар. Иксезчиксез даланың бер башыннан икенче башынача жәелеп йөз менләгән куйлар үтә. Дөяләр кәрваны узып бара. Елкылар көтүе уйнаклап чаба. Сагынам да соң яшел даланың ак таңнарда көмеш дулкынлы дингез кебек кайнавын. Нә сөйлим, ау. Кымыздан әбдән мас булдым ахры. Зиндан мене чарчагата алмады, бөрадәрләрем!.

Дусмаил. Ә без зинданнан кайткан: «Басыңнан гакыл китәр—бәла килсә», дигән сүзләрең укып, жөда кайгыга төшкән идек.

Акмулла. Төрле чак була. Мондыйны да язабыз. *(Шигырь сөйли).*

Әсәре асыл сүзнең, балдай татыр,
Кол жирдә күңел куркак—телем батыр
Ак жаны нахак көйгән бичараңыз
Акырын кыйсса жазып сулкылдатыр.
Бәндәне ризык дигән кыймылдатыр,
Сачелгән ризкы булса, жөреп татыр;
Һәр бәндә күрәсене күрмәй калмас—
Кирәк солтан булсын, кирәк император!

Дусмаил. Ой-бай! Менә бу энде чын Акмулла акын!

Арысланбай. Дахи шул: Алтынчәч апаем да Акмулла молдакә мөнәжәтләр яза дип хәйран булгай. Сорап кайт дип әйтепләр калды.

Тылмачев. Вакытыгыз чыкты! Акмулла, саубуллаш.

Акмулла. Господин Тылмачев, әйдә казакның күчтәнәч кымызыннан да авыз ит! *(Тылмачев килә башлауга).* Монда чиста савыт юк икән, алып кына чыкчы! *(Тылмачевны алдап кертеп жибәрүгә, шәкертләргә куенынннан алып кечерәк дәфтәрләр өләшә)* Менә жазган шигырьләрем, мөнәжәтләрем. Жугалтмагыз! Дусмаил, чырагым, Югары таш мәдрәсәдә хәлфәлек итүче Хафиз меллага хатымны житкерсәнче. Тиз арада Петербургка озатсын! *(Хат бирә).*

Дусмаил *(тышын укып).* Кем ул, Гобәйдулла солтан Бүкәев?.

Акмулла. Үз казагыбыз. Менә Якуп шәкертнең якташы.

Якуп. Безнең ханыбыз Жиһангирның улы. Патша сараенда, полковник.

Акмулла. Генерал ол хәзер. Хафиз мелланың колагына гына: «Тиздән суд була, Акмулланы порукага алу кирәк, төрмәдәге дусларым акчаның күп өлешен үзебез жыярбыз диделәр» дип әйтергә дә онытма.

Дусмаил. Без дә жыярбыз, молдакә. Сенең хакка бөтен дала кубар!

Акмулла. Казак түрәләре менән башкорт старшиналары төрмә юлын таптый икән. Акмулла зинданда чересен дип.

Тылмачев *(күренә, савытны сузып).* Сал, әйдә, тамаклар тәмам кипте.

Акмулла *(аның савытына тутырып кымыз сала, үзенә дә коя).* Кымыз дигәндә Акмулла үлеп китәде.

Тылмачев *(эчеп).* Шәп нәрсә, болай, шәп!. Якташларың белән саубуллаш, Мифтахетдин Камалетдинович! Вакыт чыкты!

Акмулла *(шәкертләренә якынлаша, Алар остазларын аягүрә басып каршылыйлар. Шуннан барсы бергә кочаклашкан хәлдә торалар. (Акмулла үзенең яраткан жырын башлый, шәкертләре аңа кушыла.)*

Хатлар гына языйм, бир кау(ы)рый,
Бибкәй, Бибкәй...
Сагынмакта укып багырсаң.
Сагынганың шуннан, һай, беленсен,
Бибкәй, Бибкәй...
Хатка каршы хатлар салырсаң.

Акмулла. Дусмаил, бүз жегетләрем: Гече Жөзднең Жагупы, Тингезгүлнең Арысланбае! Тургай елга буеның Тургунбае, күрешкәнчегә кадәр!

Шәкертләр. Саубулыңыз, мулдакә. Безне тиз арада көтенез!

Акмулла. Әйдә, господин Тылмачев, самовырны күрсәт! *(Китә.)*

Дусмаил *(як-ягына каранып куеныннан шигырьләр дәфтәрен ала, ача, укый).*

Айтамын үгет кылып казакъ халкын,
Күңлегез дин жагына сунчә салкын;
Иң әүвәл пакълау кирәк эчнең керен,
Эчтә тулып жатмасын сасык эрен;
Аh, дәрига! Эч тазарсын, эч тазарсын,—
Булмаса, файда бирмәс коры белем!
Белмәгән казакъ та бар, нугай да бар,

Ин әүвәл иман гыйльмен унайлап ал!
Мулла булсын дин өчен жанын кыйган;
Өйрәтсен шәкердләргә әүвәл иман,
Дин мәгънәсен үз теленчә төшендерсен,—
Югыйсә ике яклап булыр Ибан.
Инсафдан бер мыскал юк эшемездә,
Кинә, хәсәд, фәсәд тулган эчемезгә,—
Гавамга бер ак сәлләң өлкән булсын,
Атын-арбаң, киемең күркәм булсын,
Хосусән жаһил халыклардагыча
Үзең симез, корсагын таудай булсын!
Бол көндә тышымыз хуб, эчемез буш -
Илаһыбыз риза булмас эшебездән.
Тыш таһарәт алу белән эш бетмәйде,
Булмаса чын таһарәт әүвәл эчдән.

Я к у п *(үз кәгазьләрен чыгарып укый).* Сез монусын тыңланыз!.

Аркам минем күп сөйкәнеп кутырлаган,
Хаклыкка Акмулла тик утырмаган;
Симерсә, берен-бере эттәй талап,
Дәүләткә адәм бармы котырмаган.
Саргаеп, төн йокламый, таң ашабыз,
Гакылдан кайгы белән адашабыз.
Ау корып чебен тоткан үрмәкүчтәй,
Кандала, борча белән талашабыз.
Урыным минем яткан—аты зиндан.
Һәр төрле адәми бар жәфа кылган.
Эчендә төрле гыйбрәт—хисабы юк,
Хаиннар ничә төрле—бар жыелган.
Тимердән кадакланган тәрәзәсе,
Кара таш урап алган кирәгәсе,
Урысның тулып ятар кенәгәсе,—
Ходадан дошманына теләмәче!

Арысланбай *(куен кесәсеннән үзенә бирелгән дәфтәрне алып күз ташлый).* Бу дәфтәрдә үләннәр гел нугайча.

Д у с м а и л. Нугайча аңлыймыз, укы!

А р ы с л а н б а й *(укый).*
Тугърылык бу заманда корып калган,
Туры әйтүче арт якта торып калган.
Кай муллалар казакъка ялгандылар,
Сыер үгезсез калам дип курыккандай.
Дәүләтле мирзаларга яраклашып,
Шәригатьне теләгәнчә борып салган.
Нәфсе аркасында азган телебез бар,—
Жылкычылар муйныбызга корык салган;
Эшебез нәтижәсе шушы булды—
Ничә жиргә шайтан тозак корып алган.
Бөркетләр Каф тауына күчеп киткән,
Урнына—козгын, байгыш куныл калган.
Котырган бу заманда бүз балалар
Хәрамлык ягына тиз кузгалалар;
Тыюсыз үз алдына йөреп үскән,—
Аман торсалар иде кыз балалар!

Бозыклар берен-бере саклашалар,
Хыянәтен белеп тә яклашалар.
Бакый дөньяда аларга тәмуг бар,
Фание да булса иде залимгә тар!

Т о р г у н б а й *(икенче дәфтәрне карап).* Монда да нугай үләннәре күп. Мөнәжәтләр дә бихисап.

А р с л а н б а й. Мөнәжәтләрне Алтынчәчтән көйләтермез.

Т о р г у н б а й. Дусмаил молдакә, Арысланбай! Карагыз бу Петербургтагы солтанга! Жакупның жакташына!

Д у с м а и л. Патша яныралы Гобәйдуллаә ибне Жиһангиркай жанәбләренә-мени?!

А р ы с л а н б а й. Укы!

Т о р г у н б а й. *(укый)*

Әссәламегаләйкем асыл затка,
Мәйданда узып килгән аргамакка.
Дәрәжәңә тиң итеп язып булмас,
Охшап торам мин бүген жабалакка.
Тышауланган тулпар ерак китә алмас,
Читлектәге сандугач сайрый алмас.
Ләүхелмәүхүздәгеләр булмый калмас,
Беркем тәгъдиреннән уза алмас.
Кайда гына күрсәләр дә зур байны,
Башкортмы ул, казакмы, йә нугаймы,
Һәммәсе шуна каршы һайлап чабар,
Битен-кулын вә чабуын да ялар.
Фәкыйрь бәндә булгач—дәшмә, читкә кит,
Кемгә кирәк алтын сүзен, гыйбрәт ит.
Әйтер булсаң туры сүзен чәйнәрләр,
Аяк-кулың тышау белән бәйләрләр.
Түз, шулай да, тәкъдир үзе кушкандыр,
Ходай үзе яратканны сынардыр.
Ислам дөньясы да бүген сынала,
Бөркет тә гел оча алмый—тын ала.
Һәрбер зат үз аслына кайтмый калмас,
Тутыклы булат кылыч та чапмый калмас.

Я к у п. Акмулла бусын жаза гына башлаган икән гуй. Монда мына Шиһабетдин Мәржани хәзрәткә мәдхиясе дә бар.

Д у с м а и л. Ол анысын да күптән жазып ие. Бик кө тәмез. Жазып бетергәнме? *(Алып карый.)* Күп өстәгән, күп баеткан, әмма ахыры аман жук икән. Әйдәгез тизрәк мәдрәсәгә, калганын анда укырбыз...

## Зыяфәт

*Уфа. 1894 елның көзе. Мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов йортында Акмулла хөрмәтенә оештырылган зыяфәт, ягъни махсус кунак ашы мәжлесе.*

*Таш диварда Мәккә, Мәдинә, Истамбул рәсемнәре. Түрдә озынчарак өстәл тора. Шул өстәл алдындагы тамашачыларга таба борып куелган өч урындыкта Казан*

*кунаклары—мөлаем йөзле шактый олы яшьләрдәге Әмирхан Туктамышев белән европача киенгән морза Кәрим Баруди һәм дә ак җилән киеп, ак чалма ураган, ягъни казый киемнәреннән булган Риза Фәхретдин утыралар. Мөфти йортының террасасы дип фаразланган ягындагы сәхнә кырыеннан тамашачыларга таба башкорт шагыйре һәм мәгърифәтчесе Мөхәммәтсәлим Өметбаев белән 63 яшьлек кырыс кыяфәтле өлкән казый Исмәгыйль Дәүләтбаев йөреп тора. Ни турындадыр үзара күңелсез генә сөйләшәләр.*

Өметбаев *(тамашачылар каршына килеп житкәч, туктала, сәгатен алып карый да, өстәл янындагыларга борылып).* Бу Акмулла дигән бәндәгез килмәскә булды микәнни һуң?

Ризаэтдин. Үзем дә аптырап торам, галиҗәнабләре. Озакламам дигән иде.

Исмәгыйль *(мыскыллы төрттереп).* Аты чыгымлагандыр, йә арбасы ватылгандыр.

Ризаэтдин. Ватылмас. Ул бит бик оста балта остасы. Арбасын үзе ясаган. Өч бүлекле. Урта бүлемдә үзе утырып йөри. Алдагы бүлемендә балта, ышкы, өтергe, бораy кебек эш кораллары вә атларына солы тота, ә иң арттагы бүлеге китаплар белән тул-тулы.

Исмәгыйль. Үзе казакъ, үзе балта остасы, гаҗәп.

Туктамышев. Татарча беләме соң ул?

Кәрим морза. Мәрҗанигә мәрсиясе татарча лабаса.

Ризаэтдин. Әйе, Акмулла белән мәхкәмә бүлмәбездә озын вакытлар бары үземезчә сөйләштек. Шунсы бар, казакъ арасында йөреп шактый гына казакълашкан. Бөрҗән якларыннан килгән саф башкорт белән очрашкач та халис башкортларча сөйләшә алды.

Өметбаев. Телләр белүе ярай, балта остаһы да булһын әйдә. Мина шул караңгы ни өсөн мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов хәзрәтләре уның хакына зыяфәт үткәрергә булды?

Ризаэтдин. Мин мөфти Мөхәммәдьяр хәзрәткә: «Шәһәргә Акмулла дигән шагыйремез килгән, сезгә күрсәтәсем килә» дидем. Ул риза булды. Безнең бәхеткә мәркәзебез Казаннан Әмирхан Туктамышев белән Кәрим морза Барудилар да килеп чыккан иде. Аларны да чакырдык.

*Әмирхан белән Кәрим мирза хуплап баш кагалар.*

Өметбаев. Уныһы ярар, мәгәр мөфти хәзрәтләрен көтмәгәндә губернаторга сакыртып алулары гына отры гаҗәп? Уйлашаек! Фу, ниндәй эссе! Күзгә көндә йәйдән дә тегеләй кыздыра. Террасага гына сыгып һава һулап керәемсе! *(Битен яулык белән сөртә-сөртә чыга).*

Исмәгыйль. Риза әфәнде, мөмкинме? *(Терраса янына ук барырга мәҗбүр итә)* Мине тыңлаган булсаң, мондый хәлгә калмый идек. Тәҗрибәсезлегең харап итә.

Риза казый. Теләгеңне ачыклап әйт, Исмәгыйль казый?

Исмәгыйль. Сәлим әфәндедән гафу сора да, зыяфәтне тарат. Юкса Мәскәү, Петербургның олуг дәрәҗәле чинауниклары белән даими аралаша торган Өметбаев әфәнденең каһәренә юлыгуың бар. Кабат әйтәм, ниндидер даладан килгән йолкыш шагыйрь аркасында мәхкамәи шәргыябезгә бәла китермә!. Әнә, Өметбаев җанәбләре дөрес чамалый. Губернаторның мөфти хәзрәтне һич көтмәгәндә чакыртып алуы шушы эшкә бәйләнгән булса кирәк. Яна күрмә. Әйдә, мин Сәлим әфәндене бире чакырам. *(Терраса ягына юнәлә).* Сәлим әфәнде, сезне чакыралар ине. Күрененезче!

Өметбаев. *(Террасадан килеп чыгуга, ана каршы яктагы тыш ишек ягыннан Риза Фәхретдин яшьләрендәге Дусмаил Качкынбаев пәйда була. Ризаэтдин ишетерлек кенә итеп).* Акмулла шушымыни?

Ризаэтдин. Таныш булыгыз, казакъның мәгълүм акыны Дусмаил Качкынбаев. Акмулланың шәкерте. Акмулланың ни сәбәптән тоткарлануын, бәлки, ул белгәндер?!.

Дусмаил *(башын иеп).* Әссаләмәгаләйкем!

Бүлмәдәгеләр *(ишетелер-ишетелмәслек итеп).* Вәгаләйкем әссаләм.

Исмәгыйль. Хуп! Акмулла дигәнәре кайда йөри инде?

Дусмаил. Галим Каюм Насыйриның Казаннан Ырынбурга узып барышы.

Мифтахетдин әфәнденең шуны озатып йөрүе.

Исмәгыйль *(бот чабып)*. Гажәп, бик гажәп!

Дусмаил. Каюм Насыйрины озату белән килеп житәм дигән иде гуй. Бик түбәнчелек белән гафу сора, үзем килүгә һәммәсен аңлатам дигән ие.

Исмәгыйль. Нәрсәсен аңлатырга, кемлеге болай да аңлашылды. Казакъ даласында дип беләме әллә ул үзен, бичара.

Дусмаил. Безнең казакъларны сөйләргә оста диләр гуй, мәгәр без тынларга да оста. Сөйләгез, әфәндем, аксакалларга бездә хөрмәт зур.

Исмәгыйль. Китик, Сәлим кустым! Болай мыскыл иттермик!

Ризаэтдин. Газизләрем, безнен теләгебез һич тә кемнедер кимсетү, мыскыл итү түгел. Казанда Акмулланың «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» нәшер ителеп, ике ел эчендә бөтен төрки галәмендә зур кызыксыну уятты. Бәс шулай икән, мәшһүр Акмулланың шушы яшендә кайдадыр ком далаларында бәдәви булып каңгырып йөрүе зур ялгыш түгелме? Уфага тупланергә чакырту мәслихәт булмасмы үзен? Бу зыяфәтнең максаты да шушы хакта фикер алышу ниятеннән иде.

Туктамышев. Шигырьләре тагы да бардыр бит?

Ризаэтдин. Бар дип әйтү аз, күтәреп булмаслык буаз мәжмәгъ.

Кәрим морза. Ул кульязмасы белән танышырга да өлгерденме?!

Ризаэтдин. Үзе белән бергәлектә ике көн тоташ укыдык.

Туктамышев. Аны төрле телдә яза диләр. Болары да шулай төрле телләрдәме?

Ризаэтдин. Мәжмәгътагы шигырьләренең яртысы Казан төркиләречә, ягъни үземезчә. Берникадәресе халис башкорт та аңларлык, шуннан калган зур өлеше гел казакъ теле белән Казан төркие катнашында.

Кәрим мирза. Бу аңлашыла. Ул бит казакъ арасында яши. Казакълар да аңласын дип яза. Дусмаил әфәнде, Акмулла казакъка охшаганмы соң?

Өметбаев. Нишләп казакъка охшаһын, атаһы бар булмышы менән башкорт булгас, башкортка охшарга тиеш.

Исмәгыйль. Хак бу, үги атасы башкорт булгач, ул үзен башкорт дип тә таныта.

Дусмаил. Ә мина «башкортны бик үк сөймим» дигәне дә бар. Бәгъзы вакытларда атам казакъ, анам нугай кызы дисә дә, без казакларга да охшамаган ул.

Ризаэтдин. Газизләрем, без тагын читкә киттек. Кем булса да барыбер түгелмени. Сон, әйдә, Сәлим әфәнде теләгәнчә бары башкорт кына булсын. Анардан ни зыян. Без барыбыз да туганнар—төрки балалары!

Туктамышев. Туктап тор, казый, мәрсияне тынла син! *(Мәрсиядән өзек укый.)*

Казанда бер фазыйл чыкты алмаз булып,
Көнчеләре күбәйде гам-хас булып *(онытып тора)*.
Ничек әле, морза?

Кәрим мирза *(күтәреп ала)*.

Хәмде лиллаһ, бу дәвердә бездән чыкты
Мәржани Шиһабетдин ахунд хәзрәт.

Бәс, «бездән» дип әйтә икән, монда инде аңларга теләгән кешегә би-ик аңларлык. *(Торып терраса ягындагы тәрәзәгә бара).*

Өметбаев. Тормышындагы сыуарлыгы шигырьләренә дә күскән. Шигъри куәте бар, белеме етмәй. Мәрсияне әйтәм, мәрсия дип куйһа да, мәдхия бит ул *(тора)*. Мәдхия!

Дусмаил. Дөрес, Сәлим әфәнде, Акмулла аны унбиш еллар элек мәдхия итеп башлаган иде. Теләге Казанга барып Мәржани хәзрәткә үз кулы белән тапшыру иде.

Өметбаев. Нимә дип тапшыралмай калган һун?.

Дусмаил. Мәржани хәзрәтләрен мәдрәсәдә чактук остазы итеп таныса да, үзен ана лаек итеп санамады. Барып танышырга ояллы. Аннары ана шул төрмәдә утырулары да бик комачаулады гуй.

Исмәгыйль. Тукта-тукта! Зинданда утырган кеше белән минем һич тә уртак эшем булмас. *(Китапны атып бәрә дә китәргә кузгала).* Кәрим мирза. Жәмәгать! Риза казый! Күзләремә ышаныргамы-юкмы белмим. Әле генә килеп туктаган хәерче арбасыннан миллионер Закир Рәмиев төште.

*Риза казый кабат террасага ашыга, аның артыннан башкалар да шул якка*

*баралар. «Ни һөйләйһең? Алтын прискалары хуҗасымы? Ялгыш күрмәдеңме һуң? Валлаһи газыйм менә» дигән сүзләр китә. Ул арада каршы яктагы тыш ишек ягыннан башта Акмулла, аның артыннан Закир Рәмиев (Дәрдмәнд) килеп керә. Балкон ягындагылар чыгып баскан хәлдә тәмам сүзсез торалар.*

Акмулла. Әссаләмәгаләйкем! *(Аның сәламен ишетмиләр).*

Рәмиев. Әссаләмәгаләйкем, кардәшләр!.

Һәммәсе *(уянып киткәндәй, ду китереп).* Вәгаләйкем әссәләм!!!.

*Риза казый Рәмиевның каршысына ике кулын сузып килә, Рәмиев та аңа якынлаша. Бер-берен бик хөрмәтләп күрешәләр. Башкалар да миллионерны уратып алалар. Хөрмәтләү сүзләре әйтелә. Бу мәлне бусага янында очрашкан Исмәгыйль белән Акмулла бер-беренә сынагандай карашып торалар.*

Исмәгыйль *(кинаяле көлеп).* Үзеңне дөньяның тоткасы дип уйлаган идеңме?

Акмулла *(шулай ук көлеп).* Юк, кендеге дип уйлаган идем!.

Исмәгыйль *(Рәмиевкә ымлап).* Кендеге дә тоткасы да шул—алтын капчыгы!

Акмулла. Дөньяда тулып яткан газизләр бар,

Телләрен сандугачтай—акча кискән!

Рәмиев *(шундук аңлап).* Бу киная минем тарафка очырылды ахры, Мифтахетдин бәй?!

Акмулла. Ул барыбызга да кагыла, Закир әфәнде.

Ризаэтдин. Сез танышлармыни, Закир бәй?!

Рәмиев. Прискаларыбызның «Восток» дип йөртелгәне шагыйрь Акмулла яшәгән авылга терәлеп тора. Еш очрашамыз. Аның шигырьләрен тыңлау ләззәт. Олуг галимебез Каюм Насыйриның ул әле генә Оренбург ягына баручы кәрванына озата төшкән иде. Шунда бер очтан арбасына утыртып мине дә зыяфәт кичәгезгә алып менде. Рөхсәт итсәгез, мин шушы диванга посып, осталар алдында телем тыеп кына шигырь тыңлар идем.

Өметбаев. Әгәр Закир Рәмиев кебек һәр минуты алтын бәяһе торган морза безнең мәҗлесебезне олыларга уйлай икән, без бик тә шат.

*Исмәгыйльдән башкалар хуплау белдереп тавышланып ала. Рәмиевләр белән килгән саз уйнаучы, Рәмиевнең ишарәсенә буйсынып, уйный башлый.*

Исмәгыйль *(сазны барып туктата).* Зыяфәтне Закир морза Рәмиевның килеп олылавы бик күркәм, мәгәр Мөфтинең үзеннән башка гына үткәрүебез ярый торган эш түгел. Өлкән казый буларак мин моңа мотлака каршы. Алай һич ярамый.

Рәмиев. Нишләп ярамасын. Нәрсә югалтабыз?! Шигъри бәйгегә эшлексез бер карт катнашты ни дә, катнашмады ни аңардан ни зыян.

Исмәгыйль. Сез мөфти турында эшлексез карт дисезме, хөрмәтле мирза?

Рәмиев. Мин әйткән сүз түгел, миссионер Ильминский сүзе.

Туктамышев. Мөселманнарны урыс диненә алдап кертүче Ильминскийны әйтәсезме?

Исмәгыйль. Бәлкем безгә бу сүзләрегезне ачыклап бирерсез! Икеле-микеле уйларга урын калмасын иде.

Рәмиев. Сезгә дә ачыклап бирә алам. Моннан ун ел элек мөфти морза Тәфкилев үлгәч, күпчелек мөфтилеккә князь полковник Әхмәтсолтан Чыңгызовны тәгъдим итә. Ильминский шундук Изге Синодка: «Чыңгызывны мөфти итү ярамый, ул мәгърифәтле кеше, мөселманнарның күзен ачтырыр, Солтановны кую кирәк, Солтанов эшлексез, тик ятуны яратучы бояр баласы, мөселманчадан бертөрле белеме юк, хатыны да яшь, үз хозурыннан башканы белми» дип хат яза. Һәм, күрәсез, полковник Чыңгызыв урынына поручик Солтанов куелып ун ел инде мөфтилек итә.

Ризаэтдин. Утырышыйк, җәмәгать! *(Өстәлне ача).* Җиләк-җимешләрдән авыз итегез.

Рәмиев. "Җиләк-җимештән дә асылырак җимеш күңел җимеше", дигән Сәгъди. Сыйланыйк әле шул күңел җимешләренең иң асылы—шигъри тәлгәшләр белән! *(Саз уйнаучыга кабат ишарә кыла. Тегесе кабат уйнарга керешә).*

Туктамышев. Афәрин!

Кәрим морза. Күтәбез!

Исмәгыйль. Кем башлый?

Өметбаев. Был зыяфәттең ияhе Акмулла. Игътибарзы уга бирәек!

Акмулла.
Бөрадәр, баштан бәла без кичергән,
Күп кайгы тарта-тарта без исергән;
Башым хәйран, эчем вәйран—диванамын,
Ни мәгънә чыгар дисез бер исәрдән?

Туктамышев. Туктамагыз, Мифтахетдин әфәнде, дәвам итегез!.

Акмулла.
Кимчелегем билгеле каләмемнән,
Жүнсезлегем билгеле каләмемнән
Бар микән бу дөньяда миндәй яман?
Һичбер эшем бармады алга табан.
Ялварам, бик алай карамагыз—
Тулпар түгел без бүген—алашабыз.
Кечерәйтсәнез, кечерәергә мин ярыймын,
Үзегезгә зураерга ярасаңыз!

Өметбаев *(үзе дә сизмәстән).*
Гомерден язы үтте, көзе килде,
Бәхеттен назы китде, сазы килде.
Тыныслан hин, сык юлдан, hаклан зурдан
Байгыш hакланганлай hаклан, көсле нурдан!

Акмулла.
Бәлки син ул тарафта дамелладыр,
Хакыйкатьтә мулла, йә галимдер?
Әмма чын галимнәрдән булам дисәң,
Сабыр кылу кирәк иде бу юлда бер.

Өметбаев *(татарчалап җавап бирә).*
Сабый чагымдай көләлмим, көлкедән кача күнел,
Бозып ятса шигъри сүзне наданнар, шаша күнел.
Йортын да юк, нигезен дә, балтаң да суга төшкән
Үзен кучеп йөргән кебек, телең дә булган кучмән.

Акмулла *(башкортча).*
Кая гына барhаң да унда аh-зар,
Шомлы ил базарында сәүдә насар!
Алтын кадрен оста белер тейгән hүз бар,
Гәүhәрде эт муйнына такhаң касар!

Өметбаев *(әсәрләнеп аягына баса).* Исемә төште. Бынан 21 ел элек без кәрвансылар туктала торган кое янбшда осрашкан инек. Мин Бохараи шәрифкә укырга бара инем, ә hин Исәнгилде менән көрәшеп уны hыртына hалдың. Шуннан бирле шигырзәренде укыем. Бер генә үпкәм бар: hин Урал Агиздел буйларында, башкорт йирләрендә туып үсhән дә, ялгыш бер шигырендә дә башкорт атамаларын кулланмайhың! Ә менә казакъ атамаларын да, Казан, Идел яки Маржани кебек татар галимнәрен дә hәр шигырендә телгә алаhың!

Акмулла *(елмаеп).*
Хаклык сөйгән Мәрҗәнигә аузын ачкан,
Еландай зәhәрен чәчкән мулла сезмә?
Борыныңны ая, бәрадәрем,—
Котырсан да, Уралдай тауны сөзмә!

Мона, Мөхәммәтсәлим кустым! Үз авызымнан ишеттен, миндә башкорт атамаhы да бар. Инде тагы тынла *(кинәт яна шигырь чыгара)*:

Һәр халыкта була икән мөхәкъкыйк—
караңгыда учак кабызган тәүге галим.
Башкорттың да бар бит үндәй Маржание
Был hин кустым Өметбаев Мөхәммәтсалим!!

Менә башкорт галиме дә үләнгә кереп китте.

*Кочаклашалар. Башкалар да бу дуслык күренешеннән канәгать калып шаулаша.*

Ризаэтдин. Газиз кардәшләр, безгә менә шушылай еш очрашып, танышлыкны яңартып тору кирәк. Сөбханалла, менә ерак далалардан үз итеп килгән кадерле Дусмаил әфәнде, мәшһүр Акмулла, Казанлы Әмирхан әфәнде, Кәрим мирза. Уфаның үз баласына әверелгән шанлы Өметбаев, мәжлесебезнең йөзек кашы Закир Рәмиев...

Рәмиев. Риза казый, мәжлесебезнең йөзек кашы Акмулла... *(Әсәрләнеп китеп Акмулла шигырен укый башлый).*

Мәгънәви дуслар булырга бергәлек төп шарт түгел,
Тыштан төрле булсак булыйк, чуар булмасын күнел,
Һәр өметле бәндәсенең Ходайдан үз өлеше,
Син бер тиен кызганганга—алтыны йә көмеше.
Киеме иске диеп тә, начар уйда булма син,
Карга диеп уйлаганың, асыл шонкар булмасын.
Тәнребез тигез яраткан Бәгъдадын вә даласын,
Йорты Болгар булса булсын, йортны болгар улмасын!

*Һәммәсе тан калып кул чаба.*

Туктамышев. Закир әфәнде Рәмиев, сезне дә шигырь яза дип беләбез.

Кәрим морза. Әйе-әйе, бу шигырь үзегезнеке ахры?!

Рәмиев. Язгалыйм вакыт тигәндә.

Ә бу шигырь Акмуллабызныкы! Котлагыз аны! Мактаганны ул бик яратмый, мәгәр мактауга лаек!

*Һәммәсе чын күңелдән Акмулланы котлыйлар.*

Рәмиев *(Акмулланың ике кулын кыскан хәлдә).* Риза казый дөрес әйтә, Мифтахетдин бәй, синең кебек мәшһүребезнең Уфада, Казанда, йә булмаса Ырынбурда тупланүе һәммәбез өчен дә кирәк. Без абыем Шакир белән берничә ел инде татар гәзитләре, журналлар чыгару өчен тарткалашабыз. Матбагалы халык булу өмете тиз арада тормышка ашар кебек.

Акмулла. Ансы хак, безнең төркиләрне патша чиновниклары көчләпкөчләп аяк астындагы үлән хәлендә тота. Шулай бит, Исмәгыйль әфәнде!

Исмәгыйль *(үпкә аша).* Тирән гыйлем, төзек әхлак кирәк дисең, ә үзеңнең төрмәләрдән башың чыкмый. Хатын өстенә хатын аласың! Безнең күз өстендәге кашыбыз шулай итә икән, башкалар нишләмәс.

Акмулла.

Күтәрмәс туры сүзне кара надан,
Дошманга пәйгамбәр дә ярамаган.
Күк тимер кайрау белән алмаз булмас,
Күк ишәк кордаш булыр, мондаш булмас.

*(Дусмаилдән «Асәрь»не ала)* Риза казый, менә «Асәрь»ыңызны, ягъни үзебезчә итеп әйтсәк, «Эзләр» дигән әсәрегезне укып чыктым. Сез анда гарәп, фарсы шагыйрьләрен, Һималай тауларыдай зур мираслы ислам дөньясы галимнәрен күтәрәсез! Ә менә төрки дөньясының терәкләре булырлык дала мәдәниятен тудыручы бөекләрне телгә алмыйсыз. Барлык төркиләр бергә берләшкәндә генә, уртак мирасыбызны бергә үстереп кенә тарих мәйданында яшәп кала алырбыз. Киресенчә булса, югалырбыз.

Риза казый. Әйдә, бәрадәр, үзең яз әле шул дала бөекләребез турында. Без ике куллап нәшер итәр идек.

Акмулла. Менә, ниһаять, үзегез үк, хәтта хөрмәтлеләребез каршында минем далада кирәгерәк булуымны исбатладыгыз!. Миңа вакыттыр, далама китим. Болай да күп эшенезне калдырдым.

Рәмиев. Мифтахетдин әфәнде. Әйдәгез, барлык шигырьләрегезне туплап китап итеп чыгарабыз.

Акмулла. Барсын үк булмас. Алар дала буйлап чәчелгән, җыеп аласы, эзгә саласы бар. Әнә Дусмаил кулында да шигырьләрем байтак. Аңардан ала аласыз. Хуш, Дусмаил чырагым!

Дусмаил. Хуш, молдакә!

Риза казый. Ә сон, миңа күрсәткән кульязманы калдырмыйсыңмыни?

Акмулла. Алар әле эшләнеп бетмәгән икән.

Риза казый. Алайса кал, башта шуны эшләп бетер. Уфабызда ышыкка зар булмассың.

Акмулла *(кульязмасын култык астына кысып).* Болар далада туган лачыннар, шуңа канатларын дала җилләрендә генә чыныктырып була. *(Ул алга таба чыгуга мәҗлестәгеләрне аңардан нәфис пәрдә бүлеп ала).* Әйе, минем күп шигырьләремә канат куйган кадерле урын бар. Ул Златоуст белән Миасс каласы арасындагы Сарыслан авылыннан ерак түгел аккан Җәмеш елгасы буе. Шунда гына тегермәне дә бар. Бөдрә тирәк янында атларымны тугарып башларына солы салынган капчыклар эләм дә, текә ярга ут ягам. Ут янына үзем ясаган җыелма урындыкны рәтләп куеп шигырьләрем белән сөйләшә башлыйм.

## Саубуллашу

*Габдегомәр атлы малай күренә. Кулында Акмулла чыбыркысы.*

Габдегомәр. Әйдә, шагыйрь абый, сине әтием көтә. Кунаклар янына чакырды.

Акмулла. Атларымны яхшы сакладыңмы? Мә, шуның өчен сиңа әргән. *(Кесәсеннән бик кечкенә генә әргән чыгара.)*

Габдегомәр. Ни-нәрсә соң ул, әргән?

Акмулла. Бик яшь чакта алган идем. Моны мин казакъ өйләренә килгәндә, көен җибәреп кесәгә салып куяр идем. Шул вакытта кесәмдә уйный торган иде. Аларны казакъ хатын-кызлары, бала-чагалары, ир-атлары гына түгел, зур укыганнар да, хәтта хан үзе дә тынлап кызык таба иде.

Габдегомәр. Без дә тынлап карыйк!

**Акмулла.** Ашыкма, мин күздән югалгач тыңларсың, Габдегомәр.

**Габдегомәр.** Син безгә кунакка бармыйсыңмыни соң?

**Акмулла.** Юк, чырагым! Юлчының юлда булуы яхшы.

**Габдегомәр.** Әтигә ни диям инде мин хәзер? Сез бит далада очрашкан булгансыз.

**Акмулла.** У-у, дала бик зур.

**Габдегомәр.** Оренбург даласы. Әтинең исеме Госман. Бабайныкы Динмөхәммәт. Карвән йөртүче сәүдәгәр. Сез дуслашкан булгансыз!.

**Акмулла.** Далада дуслашкан дусларым һәр шәһәрдә дә йөзләгән. Дус саен кунак булып йөри башласаң әбде мас булырсың?

**Габдегомәр.** Ансы ни тагын? Әбде мас.

**Акмулла.** Исерек.

**Габдегомәр.** Ә-ә, алкашмыни? Андыйлар шактый шул. Тагы кайчан киләсең.

**Акмулла.** Бар да алла кулында.

**Габдегомәр.** Әнә чегән кызы, фал ачтырыйкмы? Әй, цыганка, погадай ка!

**Чегән кызы.** Дай ка руку, сейчас погадаю. Учыңны ач, князь.

**Акмулла.** Син башта танцуй, цыганочка *(Чыбыркысын чегәннәр кебек шартлатып берничә бию хәрәкәте ясый).*

**Габдегомәр** *(кесәсеннән кәгазь акча чыгара).* Башта бие, чегән кызы! Потом погадаешь!

*Чегән кызы бөтерелә башлый, һәм ике куллап-алга сузылган чыбыркы белән Акмулла арасына килеп кера. Акмулла көлә, кинәт чыбыркысы белән кызны тарта-тарта артка чигенә башлый һәм житез генә күкрәгенә кыскандай шаяртып ала да, чегән кызын иреккә җибәрә. Габдегомәр кызга акча бирә. Акчаны тиз үк яшергән кыз Акмулланың кулына үрелә.*

**Акмулла** *(монсу гына итеп, шигыреннән бер юл әйтә).* "Дөньяда сүзебез бар—үзебез юк!" Тик бер шарт сиңа, чегән кызы, язмышымны укы, әмма үземә әйтмә. Мин моннан еракка киткәч кенә Габдегомәргә әйтерсең! *(Чегән кызы, укып, куркудан кинәт артка чигүгә, ым белән генә «дәшмә» дигән хәрәкәт ясый һәм чыбыркысын Габдегомәргә суза).* Әргәнле генә түгел, чыбыркылы да бул, чырагым. *(Каушап калган кызга акча суза).* Дөньяда сүзебез бар—үзебез юк! До свидания, чибәркәй!

*Атлары ягына китеп барган Акмулла артыннан чегән кызы да барып карый. Әмма таш юлдагы дага тавышлары ерагая. Габдегомәр юлга утырып әргәнне борып җибәрә. Бик каушаган чегән кызы аның янына килеп утыра. Борынгы бер көй жир-күкне берләштерә. Аңа бәет кушыла.*

Бәет:

Бисмиллаһи вә биллаһи житте корбан гаете,
Без язамыз, сез укыгыз—Акмулланың бәете.
Дәүләтшаның кулында, Акмулланың куйнында,
Акмулланы үтертү кемнең булган уенда?
Акмулланың арбасын ике күк ат тартадыр,
Акмулланың газиз башы юл буенда ятадыр.
Акмулла намаз укый ак намазлыгын жәеп,
Акмулланы үтереп, Дәүләтша йөри баеп.

*Пәрдә.*



Алинә
Бикмуллина

# БӘХЕТ УЛ ИШЕК ШАКЫМЫЙ

* * *

**"Бәхет ул җиңел аяклы—**
**Килгәне сизелми дә!.."**
**Йокласаң, йоклап каласың—**
**Уятып интекми лә...**

**Бәхет ул җитез йөрәкле—**
**Килә дә китә тизрәк...**
**Артыннан йөгереп тотсаң да,**
**Кайтмас ул сиңа теләп...**

**Бәхет ул күзгә күренми—**
**Күңелең генә тоя.**
**Күңел күзең сукыр икән –**
**Кояш та яңгыр коя...**

**Бәхет ул ишек шакымый—**
**Ачык тот күңелеңне...**
**Меңнәр арасыннан, бәлки,**
**Сайлар ул ... бүгенгеңне...**

* * *

**Күзләрнең язларга,**
**Язларның күзләргә**
**Керергә хакы юк...**

**Кавышыр мизгелләр,**
**Тагын шул мизгелләр...—**
**Вакытның саны юк...**

**Көннәрнең төннәргә**
**Һичкайчан сарылып**
**Сыенган чагы юк...**

**Елларның юлларда,**
**Юлларның елларда**
**Еларга хакы юк...**

**Син миндә адаштың.**
**Мин синдә адаштым...—**
**Хакың юк, хакым юк...**

**Мәңгелек—танылган...**
**Кануннар—язылган...**
**Чикләрдән узарга**
**Беркемнең хакы юк...**
**Хакы юк.**

Алинә БИКМУЛЛИНА—*яшь шагыйрә; шигырьләре көндәлек матбугатта еш басыла. Казан дәүләт университетының татар әдәбияты һәм тарихы факультеты студенты.*

* * *

Мин сине хыялга чакырам...
Юлларга ак теләк җәелгән...
Уйларым чуалды Офыкта...
Мин синдә яшимен бүгеннән...

Бүгеннән мин синдә яшимен...
Эримен мин синең караштан...
Киләчәк, үткәнем томанда...—
Мин синдә мәңгегә адашкан..

* * *

Офыклар да бәхет көтә сыман,
Чиксез күкләр алсуланып кинәт тынган.
Хыял күкрәгенә бик сак кына
Чыңга ашмас ак теләкләр кунган...
Йолдызлардан без түшәгән күпер—
Килеп җитәр-җитмәс никтер сынган...
Офыклар да бәхет көтә сыман...
Араларда гына хыял-томан...

* * *

Вакытның ватылган мәле бу—
Дәвернең дивары алдында...
Сагышның саргайган асылы—
Арада адашып калдым ла...

Әллә соң мизгелдән мизгелгә
Ялгышып атлаган адым ла... –
Ялкынсыз-ялкынлы хисләрем,
Сөюем тамыздым алдыңа...

* * *

Юк, кирәкми артык адымнар!
Еллар кушса, юллар барырлар...
Фанилыкта әгәр язмаса –
Мәңгелектә, бәлки, таныирлар...

Юк, кирәкми артык сүзләр дә...
Мин адаштым, бугай, күзләрдә..
Сине эзләү гадәтемә керде
Үтеп барган һәрбер йөздән дә...

Юк, кирәкми хәтта син үзең!
Тыелып була, булыйк без түзем.
Ялгыз офыкларда мин калам,
Синсез калам, калам берүзем...

Юк, кирәкми артык адымнар...

* * *

*Э. Һадига*

Җәйге томан арасыннан
Бергә әле күп үтәсе...—
Безгә әле бу тормышны
Мең җыеп, мең сүтәсе...

Айсыз төндә сукмак эзләп
Адашып югаласы...
Мең сыналып, мең соңарып
Максатларга барасы...

Ялгышларга мең абынып,
Мең тапкыр төзәләсе...

Елларның юлларын айкап,
Киләчәкне үрәсе...

Олы юлда кайчак туктап,
Үткәнгә сарыласы...
Кара төндә йолдыз булып,
Мең тапкыр кабынасы...

Җилләрдә ачы сыналып,
Хыялда югаласы...
Иңгә-иң салып, бик ерак
Барасы да барасы...



Рүзәл
Мөхәммәтшин

# ӨМЕТ—ИҢ ЯКТЫ УТ

## Ярымай

**Минем өмет. Минем сагыш. Каргыш...—**
**Югалтылган хакның бер ташы.**
**Җилдә уйнап өзгәләнгән байрак,**
**Һәм кемнеңдер үчле карашы.**

**Меңнәр-меңнәр башын күтәрәчәк...**
**Тик әлегә бары кош кебек,**
**Күкрәгемне ертып чыгар өчен,**
**Йөрәк кенә тибә интегеп.**

**Безнең күктә ак ярымай яна:**
**Татар буылганда төтендә,**
**ул—соң өмет**
**безнең бу төндә...**

**Хәтере юк милләт—киләчәксез...**
**Әмма хәтер белән күз килде,**
**Меңләп-меңләп башын күтәргәннәр**
**Меңләп-меңләп янә баш иде.**
**Һәм югалды кыйбла, ятим милләт**
**Мәңгегә ваз кичте барсыннан.**
**Йөрәк кенә тибә хакыйкатьнең**
**Югалтылган ташы астыннан.**

**Безнең күктә ак ярымай яна:**
**Татар буылганда төтендә,**
**Ул—соң өмет безнең бу төндә...**

## Бүгенге хәлләр

**Әнкәй, моңаеп карама һәм түкмә син яшеңне,**
**Син язмышка, бирәр кайчан, ярдәм сорап дәштеңме?**
**Ярдәм иттеме сиңа ул, коткардымы упкыннан?**

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН (1988) — *яшь шагыйрь; шигырьләре көндәлек матбугатта басылып килә. Татар Дәүләт гуманитар педагогия университеты студенты.*

Ә миңа әйтәләр бары: "Ычкын моннан,кит моннан."
Һәм һәрвакыт үзем генә сүндерәмен ялкынны,
Сагыш, җанны кимерергә, минем йөрәккә кунды...
Мин күз яшемне яшерәм күрмәсен дип беркем дә,
Нинди каргыш синең өчен газиз булган кешедә?
Күптәннән хыялсыз яшим: җанымда минем богау,
Әйт, әнкәй, гаепмени ул башкалар кебек булмау?..
Хәзер барсы үзгәрде шул, кем хиссез,шуңа кулай,
Ә без инде һәммәбез дә акылдан яздык бугай...

## Көзге моң

Ак каенның яфраклары очып,
Әкрен генә куна иңемә.
Димәк, кабат сары көзләр җиткән,
Һәм кояш юк кабат күгемдә...

Кичәге көн инде үттемени—
Ник алайса бу көн җитмәде?
Кабат көзләр килде, ә күңелдә...
Ә күңелем моны көтмәде.

Нинди сагыш!.. Болыт арасыннан
Ник бер нуры җанны җылытсын.
Мин барысын оныта алмамындыр,
Әмма барысы мине онытсын...

Күңелдә—көз... һәм шул ук көз атлый
Мин тын атлап үткән урамнан...
Һәм сау калган чәчәк сыкрап сула
Иртән җиргә төшкән кыраудан...

Җир кичерә барсын, йә, Ходаем,
Син дә кичер туфрак улларын!
Син каргама безне: "Тормышлары—
Тормыш түгел,—диеп боларның.»

Без онытсак, каушап, иман сүзен,
Һәм онытсак Сиңа барасын,
Барсы сүнер,әмма өмет булып,
Зинһар өчен, якты ут янсын...

Тормыш безнең бәйләм түгел лә шул,
Без тоябыз моны һәр көзен.
Ярасын бит елап төзәтә көз,
Без ертабыз аның гел йөзен...

Без яшибез—Синең тарафыңнан
Яратылган башка меңнәр күк.
Син беләсең, мин бит әзер идем
Калдырырга барсын бүген үк...—

Тик үләсем килми икән минем...
Һәм Син кисмә минем гомремне...
Ә мин Сиңа соңрак, вакыт җиткәч,
Үз җанымны үзем бирермен.

**Тик онытсам һәм күрмәсәм Сине,**
**Һәм онытсам хөкем буласын,**
**Барсы сүнәр, әмма өмет булып,**
**Зинһар өчен якты ут калсын...**

## Казан

**Аллалар онытты яшьнәгән халыкны...**
**Шартлаган дивардан мәетләр калыкты,**
**Һәм йотты томанда шәфәкъне тын Идел.**
**Ахыргы каһарман кем иде? Син идең!..**
**Өзелде мәңгегә яңраган хәр азан,**
**Калыккан туң кояш эреде бераздан—**
**Казан!..**

**Батырып ал канга кыйналган милләтне,**
**Яңалар яңадан һәммәсен өйрәтте,**
**Күтәреп өскәрәк күгәргән тәресен...**
**Син күрдең! Күрмәгән, гомумән, күрмәсен.**
**Әрнетә йөрәкне тотмаган уразаң,**
**Туктады көн язда, башлансаң да яздан—**
**И Казан!..**

**Шаһ Гали кебекне тудырган бу халык**
**Иелде—мәңгегә "толерант" кол калып,**
**Һәм җанны череткән канлы хач урнына,**
**Бүген ул үз канын үземе суыра?..—**
**Ханбикәң күк горур манараң бераздан**
**Ишелер микәнни өстеңә, чал Казан,**
**Әйт, Казан?!.**

---

## Авторларыбыз игътибарына

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.



Альберт
Кашаев

## САГЫШЛАРНЫ ҖИЛЛӘР ТАРАТА

ЛИРИК ДӘФТӘРДӘН

***

**Еллар оча, аргамактай чаба,**
**Һәркөн шулай алсу таң ата.**
**Онытмадым сине, онытмадым,—**
**Сагышларны җилләр тарата...**

**Елга ташый, ярларына сыймый,**
**Болыннарга иртән чык ята.**
**Йөрәгемдә мәңгелек ут дөрли,—**
**Сагышларны җилләр тарата.**

**Вакыт мине әсир итә алмый,**
**Күңел бары сине ярата.**
**Күктә йолдыз беркайчан да сүнми,—**
**Сагышларны җилләр тарата...**

### Уйна, тальян!

**Уйна тальян, уйна әйдә**
**Йөрәкләрне җилкетеп!**
**Яшь кызларның күңеленә**
**Сөю хисе бөркетеп.**

**Әй, таралсын моңлы көйләр,**
**Кушылып таң җиленә.**
**Алып китсен алар безне**
**Татлы сөю иленә.**

**Уйный гармун, җырлый гармун**
**Хисләргә ялкын биреп;**
**Гашыйкларның учагына**
**Кайнар очкыннар сибеп...**

---

Альберт КАШАЕВ (1946)*—Татарстанның атказанган юристы. Юстиция өлкән киңәшчесе. Журналыбызда шигырьләре беренче тапкыр басыла. Казанда яши.*

## Синең күзләр

**Өй каршында сирень үсә,**
**Чәчәкләре хуш исле.**
**Тамчы-тамчы кыңгыраулар,—**
**Синең күзләрең төсле.**

**Күзләр, күзләр, зәңгәр күзләр—**
**Диңгездәй тирән алар.**
**Дулкыныңа кереп баттым,**
**Мине аннан кем табар?..**

**Йөзәм, чумам, чыга алмыйм,**
**Дулкының әсир итте.**
**Зәңгәр күзләр йөрәгемә**
**Сөю ялкыны сипте!..**

## Синең гөлләр исән

**Күзләреңнән көмеш яшең тама,**
**Сагыш баскан нурлы йөзеңне.**
**Әйтче миңа, иркәм, газаплама,**
**Юатырга ничек үзеңне?**

**Син ишеткән хәбәр дөрес түгел!**
**Хыянәтем сиңа булмады.**
**Йөрәгемдә син утырткан гөлләр**
**Чәчәк ата, алар сулмады.**

**Яшең кипсен, иркәм, күзләреңдә,**
**Кире кайтсын сөю чаткысы.**
**Йөзләреңә кунган сагыш төсен**
**Сөртеп алсын күңел яктысы.**




## "КАЗАН УТЛАРЫ" ЕЛЪЯЗМАСЫ

**журналыбызда дөнья күргән:**

60 ел элек (1948)—**Кави Нәҗминең "Язгы җилләр"** романы;
55 ел элек (1953)—**Мирсәй Әмирнең "Ялантау кешеләре"** романы;
50 ел элек (1958)—**Әмирхан Еникинең "Йөрәк сере"** повесте;
45 ел элек (1963)—**Чыңгыз Айтматовның "Беренче мөгаллим"** повесте;
25 ел элек (1983)—**Фатих Хөснинең "Бирәү килә, бирәү китә"** *повесте;* **Фәүзия Бәйрәмованың "Болын"** повесте;
20 ел элек (1988)—**Рафаэль Мостафинның "Кабан күле серләре"** исемле тарихи-документаль повесте; **Нурихан Фәттахның "Кол Гали"** трагедиясе.



Вакыйф
Нуриев

# КАРА БИШМӘТ

ХИКӘЯ

Биш яшьлек Касыймга яна бишмәт тектерделәр. Эче мамык белән сырылган, иңбашлары чак кына күпертмәле, гәүдәсенә ятышлы кара бишмәт. Малай аны бер киде, бер салды, шуны кигән килеш йоклап та алды. Их, әтисе генә күрә алмады бу көннәрне. Күрсә, сөенер иде. Сугыштан гарипләнеп кайтты ул. Шулай да йорт-хуҗалык тирәсендә кыштыр-кыштыр йөреп торды әле. Тик яралардан мантый алмады, кышның карлы-буранлы бер көнендә китеп барды. Сугышка кадәр үк Казаннан бер туганы үзенә тектергән җиләненнән калган постау биреп кайтарган иде. Касыймга әтисе: "Шуннан сиңа бишмәт тектерербез, улым",—дип гел әйтә килде.

Тик тектерергә өлгерә алмады.

Әнисе Оркыя ханым көрәнсу төстәге бу постауны Чор Иле урысларыннан карага мандырып алып төште. Тектерергә исә Күкчәдән Габдулла бабайны белештеләр. Габдулла ага—ак тегүче. Кышларын өязгә чыгып, Казанда да, башкорт якларында да байларны киендереп йөргән кеше. Һимматле җан.

Беркөнне, йомышы төшеп, Солыга килгәч, үзе сугылды ул. Касыймның инен-буен үлчәде. Аннары постауны култык астына кыстырып кайтып китте. Бишмәтнең эченә мамыкны үзеннән вәгъдә итте.

Бер-ике атнадан Касыйм әнисенә ияреп Күкчәгә "примерка"га китте.

Дөньяда көз яшәп яткан, әбиләр чуагы яшәп яткан көн иде ул. Мәрхәмәтле Җир кояшның нурлар ташкынына кызыл-сары ялкын эчендә утырган көяз каен-юкә, өрәңгеләрнең яктысы белән җавап бирә. Кояш яна, җир яна. Шуңа тагын сабыйның томрап карап торган зур, чиста, самими күзләреннән, сөенеч тулы гөнаһсыз карашыннан агылган нурлар яктысын да өстәсәң... Гаҗәеп балкыш!

Касыйм ак-көмеш тоҗымнарны өзеп алга чаба һәм ни арада күздән югала. Ул да булмый, үзән буена утыртылган яшь каеннар арасыннан "Һәй!"—дип әнисенең каршысына атылып чыккан була. Аннары тагын йөгереп китә. Пәрәвез җепләре анын битенә, күлмәгенә сарыла. Әнә ул койма артына качып торган була. Әнисен шуннан "куркыта".

---

Вакыйф НУРИЕВ (1958)—*прозаик; «Бүре кадәр бүрек», «Ана догасы», «Җиденче палата» китаплары авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

—Зират бу,—диде әнисе төксе генә.—Монда кычкырып сөйләшергә ярамый. Әтиен дә монда ята.

—Нишләп монда ята?

—Үлгәч, монда күмделәр.

—Нишләп күмделәл аны?

—Үлгән кешене күмәләр.

—Ничек күмәләл?

—Җирне казыйлар да күмәләр. Менә әтиеннең кабере.

—Жалкы бит.

—Бөтен кешене дә үлгәч күмәләр.

—Калале, әни, мин үлмим.

—Үләсең, син дә үләсең. Бөтен кеше үлә.

—Юк, мин үлмим! Мин белкайчан да үлмим.

—Үләсен...

—Үлмим!!!

Сары сагышка чумып утырган шомлы зиратның тынычлыгын алып, агач башында ямьсез итеп карт козгын кычкырып куйды. Сәер, шөбһәле тавыштан Касыймның коты алынды. Әнисе кояшта каралган, җилдә яргаланып беткән каты кулы белән аның җилкәсенә төртте:

—Нәрсәгә терәлдең?

—Кем кычкылды, әни?

—Козгын ул. Кош. Әйдә атлавыңны бел!

Бераз баргач, күңелгә шом, йөрәккә хәвеф өстәп, җанбиздергеч тавыш белән, козгын тагын кычкырып куйды.

Ике авыл арасы ерак түгел. Бер чакрым тирәсе. Күкчәгә тиз килеп җиттеләр. Бәхеткә, Габдулла бабай өйдә иде.

—Дәү кунаклар килә икән. Әйдүк, өйгә! Мактап йөрисез. Кәкерәс карчык пәрәмәч (Казан артында камыр өстенә бәрәңге боламыгы ягып әзерләгән ризыкны шулай атыйлар) пешерде,—дип болдырда үзе каршы алды. Аннары киндер алъяпкычын салып, койма башына элде дә җиз комганга су сала башлады.—Әйдәгез, кулларыгызны юыгыз.

Өйдә май исе, таба исе, пәрәмәч исе. Хөрлек, иминлек, бәрәкәт тантанасы.

Табын янына утырдылар. Касыймны да утырттылар. Аның янында—хуҗаның оныгы. Касыймнан ярты башка озынрак, җәлпәк борынлы, зур авызлы бер малай. Үзе бертуктаусыз аягын селки.

—Өстәл янында аяк селкелгә яламый,—диде аңа кунак малай.

Хуҗабикәнең майлы пәрәмәчләрне табынга китереп куюы булды, җәлпәк борын иң зур кисәкне эләктерде һәм томырып ашый башлады. Касыйм, карыны бик ачса да, ризыкка кагылмады.

—Әйдә, кунак малай, ал, җитеш,—диде хуҗа.

—Юк, башта әни алсын.

—Менә нинди акыллы, әдәпле малай!—дип мактады аны тегүче бабай.—Мондый малайга бишмәтнең иң шәбен текмичә булмас.

Чәйдән соң ак өйгә чыктылар. Әнә почмакта хуҗаның тегү машинасы. Шунда ук үтүк, аршын, кайчы, тегәрҗеп киләбе, балавыз, акбур.

Бәй, бишмәт пачти әзер икән бит инде. Һәрхәлдә калыбы бар. Җин очларын, итәген бөреп чыгасы гына калган түгелме соң. Менә аны Касыймга киертеп тә куйдылар.

—Тәк, тәк,—диде Габдулла бабай резинка белән бәйләп башына тарттырган, күпне күргән күзлеген бер күтәреп, бер борын очына төшереп.—Өстенә ипсез түгелме? Кулларыңны күтәреп кара әле. Инбашлары таман. Озынлыгы шулай ярый. Һи, кәкерәс булган бу.

...Бүген бишмәтне алып кайттылар. Касыймның аны киеп урамга чыгасы килә. Кешеләргә күрсәтәсе килә. Тышта янгыр. Бер ява, бер туктый. Менә тагын яварга кыжрап тора. Аягасты быкырдык.

—Беркая бармыйсың,—диде әнисе кистереп.—Өеңдә генә утыр. Өр-яңа бишмәтне пычратып кайтыргамы?! Мондый көндә юньле хужа этен дә чыгармый.

—Күлсе Кәлимә әбигә генә күлсәтеп чыгыйм инде, әни.

—Өстенә пычрак тидерсән...

—Юк, әни, тиделмим. Валлаһи.

—Кәримә әбиең бишмәтеңне күрми калыр дип куркасың мәллә?

—Котлатып кына чыгам.

—Көн аязгач, жир кипкәч котлатырсың.

—И әни, бүген котлатасым килә.

Оркыя ханым улының ихлас, самими күзләрен, үтенүле, ялварулы карашын күргәч ризалашты. “Ярар инде. Кәримә әбисенә генә кереп чыксын инде. Сабый бит...”

—Бар алайса, Кәримә әбиеңә кереп чык. Түлке кара аны, бишмәтеңнең берәр жиренә пычрак тидерсәң—үтерәм!

Касыйм капкадан чыгуга, икенче яктагы күршесе, конюх Тимерхан абыйсы очрады. Дворга ат тугарырга менеп барышыдыр. Сабый аның бишмәтне күреп, шаккатып калуын жылы күзләрен текәп көтте. Тик Тимерхан абыйсы шаккатмады. Күзен чайпалдырып карап куйды да атына чөнгерде.

Икенче күршесе, тавыкларга бодай сибәргә чыккан Кәримә әби Касыймны капкадан керүгә каршы алды:

—О-о-о... Күршем кереп килә икән. Әбәү! Ни күрәм? Бишмәт! Өр-яңа бишмәт!! Кил әле монда, кил әле. О-о-о... күрше, бик килешле, бик фасунлы булган бу. Каян алдыгыз?

—Алмадык, тектелдек.

—Кем текте?

—Күксәнең Габдулла бабае.

—О-о-о... Габдулла бабаң тексә, тегә инде ул.

—Менә монна, каптылмасы да бал.

—Бәрәкалла! Каптырмасы да бар. И-и-и... әйдәле, күрше, өйгә керик әле. Синең бишмәтеңне котларга кирәктер ич инде, име.

Кәримә әби самавырын янартып жибәрде. Өстәлгә шикәр куйды. Бер шакмагын яңа бишмәтне котлап, Касыймның кесәсенә салды. Аннары әби белән малай—ике дус, ике күрше тирләп-пешеп чәй эчтеләр.

Кәримә әбисеннән Касыйм, һөмәй кошы тоткандай, сөенеп чыкты. Тик менә Тимерхан абыйсына гына күңеле китек калды аның. Күрше малае өр-яңа бишмәт киеп басып торсын. Шуны күрмичә узып китәргә мөмкинме инде, җә. Бишмәтне көн саен тегеп тормыйлар бит. Юк, сабый күңеле мондый битарафлык белән килешергә теләмәде. Үз капкаларын узып Тимерханнар капкасына килде ул. Бишмәтенә берәр кәнфит-мазар өмет итеп тә килүе иде. Аларның малае гел кәнфит суырып йөри.

Малай капкага килде. Әмма ачып керергә кыймады. Үзләре чыкмасмы әле. Ул песи-песи генә койма ярыгыннан ишегалдын күзәтә башлады.

Тимерхан исә бу вакытта үзе Касыймнарда иде. Байталын тугарып төшкәндә, кулына канюшнида атларга су ташый торган зур, иләмсез чиләген тотып, бастырып килеп керде ул:

—Һе-һе... Малаеңа бишмәт тектергәнсең икән. Безнең кыз да бер кияү күрсен, дигән, ди, берәү.

—Тектердем шул. Без дә юкадән тегелмәгән. Бишмәте үзенә бик килешеп тора.

—Һе-һе... Киендерсән, киндер таягы да кияү була, ди. Тектерүен тектергәнсен дә, кәҗәнә расчут ясамадың бит әле син.

Тимерханның акылга таман бер малае бар. Быел сарык көтүен көтте. Әтисе шуның өчен кәҗә башына—бер пот, сарык башына ярты чиләк исәбеннән бәрәңге җыйды. Оркыяның кәҗәсе җәй уртасында көтүдә аягын сындырды. Аны Артель тавыннан җәймәгә салып алып кайттылар. Көтүгә чыга алмыйча абзарда ятарга мәҗбүр булды бичаракай. Тилмереп, җылап ятты. Кайчан кермә, күзендә яшь. Аптырагач, чалдырдылар. Менә шул кәҗә өчен бу комсыз, йөзен дә чытмый, бәрәңге сорап кергән бит.

Әстәгъфирулла!

Ул кәҗәне Тимерханның үз малае харап итте югыйсә. Тау башыннан көтү өстенә таш тәгәрәткән бит.

Юк, бәрәңгесеннән бигрәк, кеп-кечкенә малайның кеп-кечкенә бишмәтен күпсенеп кергән бу хөсетле тәре.

Тимерханның чигә тамырларының зәңгәрләнеп бүртеп чыгуын, күзләренең кызарганнан-кызара баруын күреп торган Оркыя чирканып куйды. Теләсә, ул аның иманын киеп, буш чиләкне башына каплап чыгара ала. Тик бу адәм актыгы белән әчелешле буласы килми. Бу үчле нәгъләтнең йортка зыян-зәүрәт салуы да мөмкин. Күрше-күләннең тавык-чебешен шул гына кырыштырып тора. Кулыннан тоткан кеше булмагач, әйбер әйтүче юк. Сугышка да бармады ул. Башын юләргә салып котылды. Военкоматка каралырга баргач, комиссия утырган бүлмәне бәдрәф белән бутаган, дип сөйләделәр. Булыр-булыр ул оятсыздан. Бәрәңгене бирергә дә котылырга бөрмәсеннән бет чәйнәгән ул кабахәттән. Аның белән каберең янәшә булмасын. Оркыя чоланда утырган, базга салмыйча хәзер ашарга дип калдырган ярты капчык бәрәңгене Тимерхан алдына утыртты:

—Мә ал шуннан... Тамагыңнан үтәрлек булса...

Тимерхан капчыкны күтәреп чиләккә бушата башлады. Чиләк чөмәкәй тулды. Бер бәрәңге сыймады, җиргә тәгәрәп төште. Сирәк очрый торган эре, шәмәхә бәрәңге. Нишләтергә аны? Чиләктә урын юк. Калсын инде... Күзе кызган Тимерханмы соң аны калдыручы. Ул кесәсеннән сөяк саплы пәке чыгарды һәм әлеге бәрәңгене урталай ярды. Ярты бәрәңгене чиләгенә ничек тә сыйдыру җаен тапты ул. Көтүдә ике генә ай йөргән кәҗә өчен ярты чиләктән дә күп алмас, дип уйлаган Оркыя аның бу кыланмышын җирәнеп карап торды.

Башын күршесенең койма ярыгына терәгән Касыймны күргәндә Тимерханның чиләк белән бәрәңге күтәреп алардан чыгып килеше иде.

—Ах, син, башың беткере, нәрсә тикшерәсең безнең койма ярыгыннан?!—диде ул һәм, карасына коелып, сабыйны якасыннан эләктереп алды. Эләктереп алды да, тешләрен кысып, этеп җибәрде. Бичара малай пычракка капланды.

Һай, бишмәт!

Һай, бала!!

Касыйм өйгә керергә курыкты. Әнисе аны караңгы төшкәч кәҗә яткан ятим абзардан эзләп тапты. Җилтерәтеп өйгә алып керде.

Керүгә пычрак бишмәтне салдырып алды да шуның белән җан көченә малайның башына кундырды. Касыйм җан ачысы белән кычкырды:

—Әнием, тимә минә, тия күлмә. Авылттыла бит, әнием.

—Мин, азапланып, көн күреп яшәүче тол хатын, тырышып-тырмашып сиңа бишмәт тектереп йөргән булам. Ә син, паразит, дуңгыз кебек җирдә

аунагансын. Пычракта аунарга дип тектердемме мин аны?! Быкырдарга дип тектердемме?!

—Әнием, сукма!

—Кидерермен мин сиңа моннан соң ул бишмәтне. Кырыен да күрмәссең.

—Әнием, мин аны бүтән кимим. Мин аны өйдә генә саклап тотам.

—Ник баттың?—ана кеше Касыймга тагын берне сылады.

—М-м-м-м-мине Тимелхан абый э-э-этеп җибәлде.

—Тимерхан! Ыштыр битнең монда кереп йөрәк бозуы җитмәгән...

Ул арада хатын ташый башлаган камырын күреп, почмакъякка ыргылды. Ипи саласы иде бит ул. Тик мичнең бер кисәве янып бетми. Ул стенага сөяп куелган кисәү таягын алды да күмерләнеп беткән ярканы төяргә тотынды. Юк, ул яркага сукмый. Ул, гүя, Тимерханны дөмбәсли. Ул, гүя, Тимерханны тукмый. "Мә, сволочь! Мә, кабахәт!"

Тимерханга булган бөтен ачуын Оркыя ханым янып бетмәгән чи усак яркасыннан ала. Шулай итеп, үзенең парын чыгара. Ул үҗәт кисәүне җәт кенә кече учакка эшермәкче булды. Җан көченә, кискен селтәнү. Кисәү таягы нәрсәгәдер бик каты килеп төртелде.

—Ай!—үзәк өзгеч тавыш.

Оркыя ханым кулындагы таякның очлы башы (нигә очларга кирәк инде?), әнисенең артыннан шыпан-шыпан гына узып баручы Касыймның чигәсенә кадалган иде.

Малай идәнгә ауды.

Чигәдән кан тибеп чыкты.

Өнсез хәлендәге ана башта ни булганын аңлый алмыйча торды.

Аннары күзләрен акайтып түшәмгә текәлгән улының өстенә капланды.

—Һай, улым, ни булды? Улым! Улым!.. Ник дәшмисең?

Оркыя ханым аны селкетергә-җилтерәтергә тотынды. Йөрәге жу итте. Үзе дә хәлсезләнде.

—Улым бәгърем!

Касыйм дәшмәде.

—Улым, җаным!

Малай күзләрен тагын да зуррак итеп ачты да тынып калды.

Нишләп йөрде икән соң ул мич каршында? Хәер, тамагы ач бит, ипи кайчан пешеп чыгар икән, дип көтеп йөрүе булгандыр инде...

...Кара көзнең җепшек кары тын зиратның тын почмагындагы суынырга да өлгермәгән вак кәсләр арасына тула, әле беркөнне генә "Һәй" дип әнисе каршына атылып чыккан малайны хәтерләүче сагышлы каеннарга сарыла.

...Атна-ун көннән Тимерханны паралич сукты.

...Өйдә, дивардагы кәтүкле чөйдә балчык-пычрагы кагылган, өр-яңа, чип-чиста бишмәт эленеп тора.

Анага улының истәлеге булып эленеп торамы ул, әллә... йөрәк ярасы булыпмы?

Улының төсе булып эленеп торамы ул, әллә... гыйбрәт булыпмы?!

**Редакциядән:** ***Бу көннәрдә каләмдәшебез Вакыйф Нуриев үзенең 50 яшьлек юбилеен бәйрәм итә. Без аны чын күңелдән котлыйбыз, иҗади сәенечләр һәм гаилә бәхете теләп калабыз.***

*Татарстаннан читтә яшәүче каләмдәшләребез*

## УЛЬЯНОВ (СЕМБЕР) ӨЛКӘСЕ



Иделбикә

### Яшә, Казан!

**Шанлы Казан! Бөек Казан!**
**Аң-гамәлнең Син кыйбласы.**
**Тантанаңа баглый зур ДАН**
**Дөнья татарлары барсы!**

**Идел-Чулман дәүләт чагы**
**МЕҢ елыңның тәүге таңы.**
**Болгар бабаларның ташы...**
**Барсы—тарихыңның башы.**

**Син канкардәш. Син—чын туган!**
**Чит татарның Синдә җаны.**
**Җирең изге—күпме сеңгән**
**Дошман койган болгар каны...**

**Биналарың—тарих эзе,**
**Җимерелсә дә афәттән,**
**Алып сәнгать оеткысын,**
**Калыккансың мәгърифәттән.**

**Талантларны туплаучы Син!**
**Сембер данын яклаучы—СИН!**
**Без—иңдәге соса җебе,**
**Тукымада нигез җеп—Син!**

**Без—ут күрше,**
**Уй-гамәл бер:**
**Аралаша Казан-Сембер.**
**Рәхмәтле без: ярдәм кулың**
**Игелекләр белән тулы!**

**Һич түгелсең җир даулаучы,**
**Син—милләт җанын саклаучы,**
**Айсбергны үткән кораб,**
**Тынычлыкка юл яручы.**

**Яшә, Казан, иминлектә!**
**Халкың булсын мул хөрлектә.**
**Безне тарта изге кыйблаң,**
**Мәңге, мәңге нур сип, КАЗАН!**

### Мәхәббәт

**Һай, көчле нур! Терелтә дә җанны,**
**Үтерә дә уксыз-агусыз.**
**Мәгърур имән сыман тамыры тирән.**
**Нинди аура! Яктырта да таңны,**
**Йолдызга да илтә очкычсыз,**
**Актык хәлендә дә түгел сүрән...**

---

Иделбикә (Лена САБИТОВА–САДЫЙКОВА)—*шагыйрә; татар һәм рус телләрендә дөнья күргән берничә китап ("Мәхәббәтнең мең фасылы", "Бәхеткә үс, Кеше", "Дөнья авазлары") авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Ульяновскида яши.*

Бер карашы кайчак—көткән чорың,
Йә яндырып алган бер мизгел,
Йәки вулкан булып килгән тәэсир:
Туа уйда җырланмаган җырың,
Ата тансык чәчәкләрен гөл,
Ташкынланып гөрли-дөрли гомер!

Сөю-сөелү күмсә бар якларың,
Җан күзләре түбән карамый—
Көнең мәхәббәткә тик буйсына...
Яисә шып туктата уй чаптарың,
Бер сүз угы җаның яралый,
Фикер канатларың бердән сына...

Тик мәхәббәт шулай яралый,
Һәм мәхәббәт үзе дәвалый.

## Кандалыйга мәдхия

И, Ходаем! Гозерем зур: бир фикернең олысын!
Сүздән ярат күккә ашкан олы сын.
Тел-дин югалткан адәмгә бир, Тәңрем, ярдәм-мәдәт,
Олы рухны аңлау өчен кирәк лаеклы сәләт.

...Нәселеннән рухани ул. Гомере узган шул юлдан.
Габделҗаббар—муллалыкның җиденче буыныннан.
Тумышына ике йөз ел, ике гасыр эчендә
Халыкка таралган наме—көч кодрәте төсендә.

Авыллардан, күңелләрдән йөз ел буена җыеп,
Әсәрләрен эзли аның ничә галим ил булып.
Сембер ягының шагыйре, туган авылы Ертуган.
Күп әсәрләре югалган эзсез—вакыт йотудан.

...И, белем юлларын таптау, табан, "сыйрак талдырып",
Мәдрәсәдән мәдрәсәгә, туган якны калдырып;
И, гаделсезлек кичерү—нахак сүздән кыйналып,
Наданнар күрә алмаудан йөзгә бәреп сүз салып.

И, илерү, бәгыре янып, Ходайдан сабыр сорау:
"Бу җирдә юк кадерем",- дип, йөрәге еламсырау;
Дошманнары гаеп табып, төрмәгә дә озату,
Хәбәргә, туган күрергә зар-мохтаҗ булып яту.

Анда да ике ел буе иҗат-утта януы,
"Сөбәтел-гаҗизин" дигән поэмасын язуы.
Егетлек вакытындагы нәсыйхәтләр, вәгазьләр...
Кай җирдә күмелгән сүзләр? Кемдә алар, кем табар?

"Рисаләи-л-иршады" иҗтимагый кыйммәтле,
Әдәби дәрәҗәсе дә югары—мөрәүәтле.
"Кыйссаи Ибраһим Әдһәм"—дин, әхлак легендасы—
Шатлыктан ваз кичеп гизгән дәрвиш юлы-дөньясы...

Дәрес: гаделлек, аң-белем ике дөньяга ярар,
Ә наданлык, ачкүзлелек—бу дөньяда да зарар.

**Кыргыйлыктан узган адәм сөюдә бәхет тапкан:**
**"Шашкын мәхәббәт җырчысы" Кандалый шундый заттан!**

**Хатын-кыз гүзәллеген дә шагыйрь үзенчә күргән;**
**Гашыйк хисләрен олылап, йөз-йөз җыр язып биргән.**
**Бар инәлү-шигырьдән—иң хислесе "Сәхибҗамал",**
**(Шагыйрь мәһәре дә шулдыр—хаклыдан хаклырак мал!)**

**Ходайдан булмаса каләм, шигърияте—иделе,**
**Кышкы боз "таш эретерлек" җырлар язар идеме?**
**Тынгысыз шагыйрь күп күргән, гомере юлда булгач,**
**Дошманга—"пәкедәй үткер, сөйгәненә—сандугач".**

**Наданлыкны кӯралмаудан җисемең-җаның белән,**
**Мужигын да, мулласын да каләмең "күрә белгән"... -**
**Калын китаплар язарлык Кандалыйга—мәдхия,**
**Дини дөнья һәм шигърият шуңа аңа баш ия!**

---



Рифкать
Хисмәт

## Шагыйрьгә

**Шигырь язсаң, яз син аны**
**Көннең сугып кадагына.**
**Кушылсын ул, аваз булсын**
**Үз чорыңа,**
**заманыңа!**

**Заман-чордан артка калган**
**Зәгыйфь шигырь—кирәк түгел.**
**Укучысын тапмый бит ул,**
**Кабул итми аны күңел.**

**Базарда гел ихтыяҗ зур,**
**Булсын әйбәт товар гына.**
**Язма шигырь, ышанмасаң**
**Укучысын табарына.**

---

Рифкать ХИСМӘТ (1939)—*шагыйрь; "Күңелем көзгесе" исемле китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Ульяновскида яши.*

Яхшы шигырь лаек була
Әһәмияткә, әлбәттә,
Яратылып укылсын,
Хезмәт итеп җәмгыятькә!

## Җырыма

Сөенергә иртә әле сиңа, җырым,
Матбугаттан алдым, диеп, мин дә урын.
Күңелләрнең түрен яулый алсаң, сөен,
Гомерең һәм яшәү көчең—шунда синең.

## Рәхмәт тәкъдиребезгә

Чын мәхәббәт ул кабынып
Йөрәк, җанда дөрләсә,
Аны сүндерә алырлык
Җиһанда юк бернәрсә.

Моның шулай булуына
Шик-шөбһәсез ышанам.
Чөнки үзем дә шул утта
Гомерем буе янам.

Картлыгым якынлашса да,
Сүрелдермим, сүндермим.
Яндыручым син булганга,
Пыскып янмыйм, гел дөрлим.

Син үзең дә нәкъ минем күк
Яшисең янып, дөрләп.
Уртак бер утта янып, без
Гомер итәбез гөрләп...

Мәхәббәт нык бәйләгән бит
Безне бер-беребезгә.
Зур бәхет иярәре без,
Рәхмәт тәкъдиребезгә!



Равил
Шәфигуллин

## Язасы иде былбыл бәетен

Күзгә болын, гүя, сүнгән дөнья.
Карга чукый былбыл мәетен.
Китми калган былбыл. Үлгән юлда.
...Язасы иде былбыл бәетен.

Әйе шулай. Гомер бер өзелә.
Барган җирдән кинәт авасың.
Чикләп биргән гомер чикләренә
Кем дә белми күпме каласын.

---

Равил ШӘФИГУЛЛИН (1941)—*шагыйрь; шигырьләре матбугатта, шул исәптән безнең журналда да дөнья күрде. Димитровград (Мәләкәс) шәһәрендә яши.*

Гомер чикле, үзе—барын җыйган,
Кайгы да бар анда, шатлык та.
Кайгылар бер уза, уздыралсаң,
Бәхет, кайчак, куя чатнап та.

Гомер юлы төрле юнәлешле:
Чапрыш та ул, туры, кыек та.
Кара карга юлда сагалый күк,
Менеп кунып биек кыекка.

Гомер үтәр, вакыт үз канатын
Өстебезгә ябар бер заман.
Фәрештәләр төшеп бәя бирер:
—Монысы әйбәт иде, бу—яман.

...Миңа да шул гомер юлларында,
Ходай бирә белде кирәген.
Бер өзелер юлым, белмим, нишләр
Шигъри юлдан барган йөрәгем?!

## Ак мәчет

Мәхәлләләр йоклый, уянмаган,
Бөтен нәрсә әле тынлыкта.
Мәшрикъ нурын ертып, зәңгәр күккә
Ак мәчетнең ае калыккан.

Күпме гомер үткән шушы айсыз,
Еллар аккан, тормыш чайкалган.
Яшел урам буйлап ак мәчеткә
Бабам килә сыман чапаннан.

Бабам ашыга кебек намазына –
Ак чалмадан, яшел чапаннан...
Еллар шавы аша, аның тавышын
Ишетәм күк... изге Азаннан.

## Сынатмыйм

Татар булгач, әллә соң мин көйсезме.
Җырларымны тыңламаслар, дисезме?
Моңсыз җырлар җырламыймын, тыңлатмыйм,
«Кара урман»ымны сузам,
сынатмыйм.

Татар булгач, әллә соң мин телсезме.
Сүз әйтергә базынмас ул, дисезме?
Башым имим, горурлыкны югалтмыйм.
Тукай, Кандалыйча сөйлим,
сынатмыйм.

Татар булгач, әллә соң мин динсезме.
Татар барда хәтәр була, дисезме?
Нахак сүздән күңелемне җылатмыйм,
Ислам юлларыннан чыкмыйм,
сынатмыйм.

Күңелем киң, әллә соң ул диңгезме,
Нигә әле дулкынланмый, дисезме?
Күпне күргән халкым кебек тыйнак мин.
Татар бит мин! Мена шуңа
сынатмыйм!

## Гозер

Кисәм кискен дулкыннарны,
Җилне бастырам.
Көймәмне этеп җибәрәм,
Ишкәк батырам.

Күз яшьләремне тамызмыйм
Дәрья ярына.
Текә ярда йөзем борам
Кояш ягына.

Артта—сизрәп калган гомер,
Алда да гомер.
Йөрәктә—чиксез батырлык.
Җан боек никтер.

Йөрәктә—Ходай чаткысы,
(Нигә ул кирәк?)
Юлсыз, юньсез бу дөньяда
Кабынса кинәт.

Эзләмим качарга урын,
(Кемнәрдән качыйм?)
Упкынга түгел, күкләргә,
Очыйм ла ... Очыйм!

...Артта—томан сарган гомер,
Алда да гомер.
Йөрәкне, Ходай, суытма!
Бу—минем гозер.



# Абдулла Марат

## Каенсарда

Әйлән-бәйлән уйнарга дип
Тезелгәннәр каеннар.
Бик матур концерт залына
Әйләнгән бу каенсар.

Бөдрә-бөдрә толымнарын
Сыйпый-назлый яз җиле.
Зифа буйлы каен кызның
Иллә дә нечкә биле.

Урман кызлары янында
Аз гына ял итәсе.
Җырларыннан илһам алып
Кабат юлга китәсе.

Юлларыбыз уза безнең
Шушы каенсар аша.
Аз гына ял итиек тә,
Карыйк әле тамаша.

## Ау

Кудылар...
Тоттылар...
Яптылар,
Аттылар—
Учакны эссе итеп яктылар...
Ботакка
Мылтыклар тактылар.
Чөмереп эчтеләр,
Сөякләр аттылар,
Аннары
Сүгенеп яттылар.
Күз иде...

Учакның төтене
Һаваны каплады.
Йолдыз да һавада
Һич урын тапмады...
Тирә-як караңгы,
Күңелләр караңгы,
Ул көнне, нигәдер,
Таңнар да атмады.
Еракта, кайдадыр,
Иптәшен сагынып
Ялгыз пошиның
Авазы яңгырады...

## Яңа гасыр шигырьләре

* * *

Йолдызлар күзгегә карый,
ә күзге ага бара...

* * *

Өчпочмак:
мәхәббәт,
акча һәм
пычак.

* * *

Оясыннан беренче тапкыр
очарга чыккан кош баласы
үзен бәхетле саный,
ә аңа кайгы-хәсрәт яный.

Абдулла МАРАТ (1953) — *шагыйрь; "Ләйсән яңгыр" исемле китап авторы. Иске Кулаткада яши.*

* * *

Беркемгә дә тиң түгел дә
Патшалар...
Ләкин
Аларны да тотып асалар.
Димәк, алардан да өстен
Көч бар—
Халык... Һәм заманнар!

## Күз җитте

Офыкларның алсулыгы
Миләшләргә күчте.
Төн гөлләрен салкын җилләр
Кочып-назлап үтте—
Димәк, көзләр җитте.


Каз канатлары ныгыды,
Бәбкәләре үсте.
Аерылышкан яфраклар
Чык тамчысы эчте—
Димәк, көзләр җитте.

Алтын төскә керде дөнья,
Һава яшьләр түкте.
Җиңү белән кайтып төште
Батыр кыр егете—
Димәк, көзләр җитте.

Кыңгыраулы җырлар белән
Урамнан туй үтте.
Ак күлләрдә балаларның
Тавышлары бетте—
Димәк, көзләр җитте.

Болыннарны матурайтып
Ап-ак мамык калды.
Пешкән алма кебек һаваларда
Алтын кояш янды—
Җәйләр артта калды.

Тик һаман да күңелләрдә
Яшьлек хисе.
Урманнардан исә һаман
Умырзая исе—
И, мәхәббәт көче!



Абдулла Алиш гаиләсе: хатыны Рокия, уллары Алмаз һәм Айваз. 1941 ел.



Мостай Кәрим хатыны Рауза ханым белән. 1970 ел.



*1989 елда Оренбургта Дәрдемәнд яшәгән йорт диварына истәлек тактасы куела. Рәсемдә – шагыйрьнең нәсел дәвамчылары.*



*Гата Камский әтисе Рөстәм белән Казанда очрашу вакытында. 1988 ел.*

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XVI КОРЫЛТАЕ

Инде хәбәр иткәнебезчә, 23 майда Татарстан язучыларының XVI корылтае булды. Аны кереш сүз белән Татарстанның халык язучысы **Т. Миңнуллин** ачты. Ике корылтай арасындагы эшләнгән эшләр турында Татарстан Язучылар берлеге рәисе **И. Ибраһимов** хисап тотты. Шулай ук ревизия комиссиясе рәисе **Ф. Зыятдинов** доклады тыңланды.



Жанрлар буенча докладларны ясадылар: **З. Хәснияр**—проза, **З. Мансуров**—шигърият, **Ә. Закирҗанов**—драматургия, **А. Хәлим**—публицистика, **Р. Корбанов**—балалар әдәбияты, **Мансур Вәлиев**—әдәби тәнкыйть, **Л. Газизова**—рус әдәбияты.

Докладлар буенча фикер алышуда катнаштылар: Р. Фәйзуллин, Т. Галиуллин, Ф. Садриев, Р. Батулла, Н. Гыйматдинова, Л. Шагыйрьҗан, И. Сабиров, Р. Зәйдулла, Н. Сафина, Г. Морат, Р. Сәгъди.

Корылтай эшендә Татарстан Президенты **М. Ш. Шәймиев** катнашты һәм тәфсилле чыгыш ясады, күпсанлы сорауларга җавап бирде. Корылтайда шулай ук премьер-министр урынбасары, мәдәният министры З. Р. Вәлиева катнашты һәм бер төркем язучыларга бүләкләр тапшырды.

Корылтайда альтернатив нигездә зур күпчелек тавыш белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе итеп кабат И. Ибраһимов сайланды.

Яңа идарәгә түбәндәге язучылар үтте: Р. Аймәт, Н. Алешков, Мөдәррис Вәлиев, Разил Вәлиев, Л. Газизова, Н. Гыйматдинова, И. Гыйләҗев, Р. Зәйдулла, Р. Зәкуанов, В. Имамов, И. Иксанова, К. Кәримов, Р. Корбанов, Л. Лерон, З. Мансуров, Р. Миңнуллин, Т. Миңнуллин, Г. Моратов, В. Нуриев, Г. Рәхим, Р. Рахмани, Д. Салихов, Р. Фәйзуллин, З. Хәснияр.

Корылтайда шулай ук Язучылар берлегенең Уставы яңа редакциядә кабул ителде.

Фикер алышу барышында әйтелгән эшлекле тәкъдимнәр нигезендә корылтай резолюция кабул итте.

Бу санда без бераз кыскартып корылтайда ясалган докладларны бирәбез.



Туфан
Миңнуллин,
Татарстанның халык язучысы

# БЕЗНЕ ОЛЫ СЫНАУЛАР КӨТӘ

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XVI КОРЫЛТАЕН АЧКАНДА ӘЙТЕЛГӘН КЕРЕШ СҮЗ

Хөрмәтле Президент!

Хөрмәтле каләмдәшләр, берлек әгъзалары, кунаклар!

Чираттагы корылтаебызга без заманның киеренке вакытында, Россиянең милли сәясәте безгә янадан сырты белән борылган чакта җыйналдык. Милли мәгарифебезгә, милли матбугатыбызга чираттагы куркыныч яный. Безне житди сынаулар көтә. Хәер, без инде сыналган, әмма югалтуларыбыз булса да сынмаган халык. Дәүләтчелегебезне югалтканнан соң дүрт йөз илле ел буе империя басымы астында кысылып яшәсәк тә, рухыбызның потенциаль көчен саклап кала алдык. 1905 ел революциясеннән соң бирелгән аз гына ирекtән файдаланып дәррәү күтәрелдек. Иҗтимагый тормышның бөтен тармакларында даһиларыбыз дөньяга килде. Бөек Тукаебыз үзе генә дә ни тора. Россияне янадан реакция сөреме каплагач иҗат ялкыны сүрелә төшсә дә сүнмәдек.

1917 елда яңадан кабындык. Большевиклар режимы безне янә дә коммунистик империя кысаларына куып кертеп, милләтне буш сүзләр белән алдап, аның сизгерлеген киметте. Шәһәрләребездә, Татарстаннан читт өлкәләрдә мәктәпләребез ябылып бетте, зыялыларыбыз кимегәннән кимеде. Ләкин безнең рухыбыз исән иде. 90нчы еллар башында мәйданнарга чыгып ирек дауларлык көчебез бар иде. Без киләчәккә зур өметләр баглап, дәртләнеп иҗтиһад итәргә керештек. Инде менә тагын милли күгебездә империя күсәгенең күләгәсе пәйда булды. Безне телебездән яздыру өчен мәктәпләребездә үз телебездә укыту мөмкинлеген юкка чыгара торган кыргый законнар кабул ителде. Үз графикабызда язу тыелды. Болар барысы да беренче чиратта әдәбиятыбыз мәйданын тарайтуга китерәчәк. Ләкин төшенкелеккә бирелмик. Шовинистик даирәләр бездән шуны көтәләр. Чөнки өметсезнең киләчәге юк. Без әле исән. Безнең язмыш гел көрәштән генә тора. Без төрле холыкта булсак та, иҗат мөмкинлекләребез төрле булса да, ара-тирә кирәкмәгән ваклыкларга кереп китеп бәхәс корсак та, без бер мәсьәләдә бердәм: барлык татар язучыларының уенда милләт кайгысы, күңелләребездә милләткә хезмәт итү теләге. Аңардан да изге ниятебез, максатыбыз юк һәм булмаска да тиеш. Әйдәгез, шушы рухта корылтайда фикерләшик, бердәм көч булып көрәшкә сәләтле икәнебезне күрсәтик. Көрәшер өчен безнең кулда көчле корал бар. Каләмнән дә затлырак һәм көчлерәк коралны кешелек дөньясының әле уйлап таба алганы юк. Хәерле юлга, хөрмәтле каләмдәшләр!



Илфак
Ибраһимов,
идарә рәисе

# УЕБЫЗДА—МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ ИКЕ КОРЫЛТАЙ АРАСЫНДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА ХИСАП ДОКЛАДЫ

Хөрмәтле каләмдәшләр!

Татарстан Язучылар берлегенең XV корылтаеннан соң нәкъ 3 ел узып китте. Ике корылтай арасында башкарган һәм башкара алмаган эшләребез хакында хисап тотар вакыт житте...

Язучылар берлегенең XV корылтаенда сайланган идарә корылтай кабул иткән резолюцияне тормышка ашыру буенча үзенең төп эш юнәлешләрен билгеләде һәм аларны эзлекле рәвештә тормышка ашыруның планнарын төзеде. Бу планнарның үтәлеше идарәнең һәр утырышында да, 2006нчы, 2007нче Әдәби ел йомгакларына багышланган жыелышларда да яктыртылып барылды. Язучылар берлеге, аның Әлмәт, Чаллы бүлекчәләренең, ижат остаханәләренең эшчәнлеге һәм үткәрелгән чаралар турында "Ике съезд арасында" дигән жыентыкта һәм съезд өчен язучылар берлеге рәисенең отчеты, аерым жанрлар буенча каләмдәшләребезнең докладлары аерым туплама булып сезнең кулларыгызга тапшырылды.

Күз ачып йомган арада узып киткән бу 3 ел республикабыз һәм бөтен халкыбыз тормышында әһәмиятле вакыйгаларга бик бай булды. Башкалабыз Казанга, Алабуга каласына нигез салынуга 1000 ел тулуга әзерлек һәм аны билгеләп үтү, Әдәбият-сәнгать елы, Хәйрия елы кысаларында Габдулла Тукай, Мәжит Гафури, Акмулла, Муса Жәлил, Галимжан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин һәм башка бик күп күренекле шәхесләребезнең юбилейларына мөнәсәбәтле дистәләрчә-йөзләрчә әдәби-мәдәни чараларның бөтен Евразия киңлекләрендә үткәрелүе халкыбызны берләштерү, аның милли үзаңын үстерүгә әйтеп бетергесез тәэсирле йогынты ясады...

Милли идея—бер халыкның төп максатына—үз-үзен милләт буларак саклап калу һәм гомумкешелек дәрәжәсенә лаек рәвештә үз-үзен туплау икәне бик тә аңлашыла. Гап-гади бу максатка ирешү генә бик авыр һәм катлаулы. Ул—бик биектә кебек—нечекләр күтәрелергә соң шул биеклеккә? Ул—янәшәдә генә, әмма авыр таш белән бастырып куелган, нечекләр алырга ул асылташны авыр таш астыннан?

Шушы иң мөһим сорауга жавап эзләү һәм табу бүгенге көн сәясәтчеләренең дә, зыялыларының да жаваплылыгындадыр... 2006 нчы елның март аенда "Казан утлары" журналының баш мөхәррире, халык шагыйре Р.Фәйзуллинның сорауларына биргән жавабында Республикабыз Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев бу стратегик бурычны тормышка ашыру юлларын, ысулларын бик төгәл билгеләде кебек...

Язучылар берлеге идарәсе Республикабыз Президентының тәкъдимнәренә бик игътибарлы һәм рәхмәтле булып, якындагы елларда аларны тормышка ашыру буенча дәүләт һәм ижат жәмәгатьчелеге хезмәттәшлеге булырдай беренче чаралар проектын да эшләде. Ул планны үз вакытында Президент аппараты һәм Мәдәният министрлыгына тәкъдим иттек, 2007 елның 15 гыйнварында Президентыбыз Кремльдә мәдәният һәм сәнгать әһелләре катнашында үткәргән киңәшмәдә без иң өлгергән мәсьәләләрне тагын да күтәрдек һәм аларның күбесе киңәшмәнең

беркетмәсенә кертелеп, бүгенге көндә унай хәл ителеп килә...

Әдәбият тәэсирле бер сүздән, фәһемле, гыйбрәтле бер җөмләдән башлана. Әдәбиятның да башында үз бисмилласы һәм фатиха сүрәсе булырдай газиз Ана телебез тора... Төп сурәтләү чарасы буларак әдәби телебез, Ана телебезнең матурлыгы, тәэсирле көче ике юллык бәетләрдән башлап—поэмаларга кадәр. Нәни парча, хикәяләрдән алып—бәян, романнарга, киң колачлы эпик әсәрләргә кадәр һәрчак үз югарылыгында булырга тиеш.

Соңгы өч елда иҗат ителгән әдәби әсәрләребезгә бәяне галиҗәнап вакыт үзе бирер, 10 елдан соңмы, 20, 30 елдан соңмы? Без бүген исә милли әдәби хәрәкәтнең табигый агышында әдәби эстетик кыйммәтләрнең сакланышы, чагылышы, тенденцияләре хакында гына әйтә алабыз.

Әдәбиятның әнкәсе булган милли шигъриятебез Илдар Юзеев, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗанов, Наис Гамбәр, Рифкать Закировлар арабыздан китү белән ни-нәрсәгә дучар булуын әлегә анык кына әйтү мөмкин түгелдер. Әмма шигъриятебездә образлы сүзнең, кинаяле сүзнең эстетик егәре, тәэсир көче, шөкер, бүген дә үз югарылыгында сакланып килә. Дөньякүләм шигъриятнең иң күркәм форма үрнәкләрен дә таба алабыз бүген татар шигырендә. Бигрәк тә шәрык шигъриятенең онытылган формалары янарыш алды. Бик борынгы шигырь калыбына яңа эчтәлек һәм мәңгелек милли моң салынган төрледән-төрле шигъри әсәрләр дөнья күрде...

Бу урында ике корылтай арасында шигърият остаханәсенең (җитәкчесе Зиннур Мансуров) бик тә нәтиҗәле эшләвен билгеләп үтәр идем мин... Остаханә тарафыннан түгәрәк өстәлләрдә аерым шагыйрьләрнең иҗатын анализлау, яшь язучыларыбызның иҗатын тикшерү даими оештырылды...

Шул ук вакытта шигъриятебезне зәвыксыз һәм тапталган шаблонга әверелгән сүзләр тезмәсенә әйләндереп калдыру омтылышлары да күп. Бу бигрәк тә җыр тексты язучыларга... һәм үзе шигырь язып, үзе көен язып, үзе җырлап шоу оештыручы шигырьчеләргә кагыла... Аларның Язучылар берлегенә кагылышы булмауга карамастан, олы сәхнәгә һәм радио-телевидениегә аларның вирусы үтеп кергәнлектән, күпчелек гавәм бүгенге шигъриятне аларга карап бәяли... Шунардан чыгып та, тулаем иҗат берлегенә һәм аерым шагыйрьләребезгә киләчәктә үз иҗатларын пропагандалауда шул шоуменнардан үрнәк алырга, йоклап йөрмәскә кирәк булачак. Бу уңайдан без бик тә белемле, инде үзләрен чын әдәби сүз, шигъри сүз ияләре итеп танытып килүче яшь шагыйрьләребез һәм шагыйрәләребезгә зур өметләр баглыйбыз.

Соңгы өч елдагы прозаның йөзен хикәяләр һәм әдәби-публицистик мәкаләләр билгели дисәк һич тә арттыру йә киметү булмас. Моның асылында, беренчедән, халкыбыз тормышындагы истәлекле, тарихи вакыйгалар ятса, икенчедән, әдәби басмаларның хикәя жанрына аерым игътибар бирүе, төрле конкурслар үткәрүләре дә ята... Бу күренеш бары хуплауны гына сорый... Әлбәттә, повесть, романнарга да кытлык булмады. Жанрлар буенча махсус докладлар әзерләнгәнлектән, аерым повесть, романнар, публицистик әсәрләргә һәм аларның авторларына тукталып тормастан, шуны ассызыклап әйтәсе килә: милли прозабыз үз мәслəген табу юлында, әмма аңа әлегәчә колачлылык, эпиклык җитми. Моның үз сәбәпләре бар. Съезд дәвамында бу турыда сүз булыр әле.

Милли идея һәм милли каһарманнар турында да сүз алып барабыз икән, алар эпик әсәрләрдә генә туарга мөмкин икәнен һәркайсыбыз белә. Әйтик, Фәүзия Бәйрәмова "Кучем хан" романын язды... Бу әсәр үзенең документальлеге белән дә, вакыт үлчәме һәм вакыйгаларны колачлавы белән дә, әдәби каһарманнарның образ буларак гәүдәләнеше белән дә—чын эпик сыйфатларга җавап бирә торган иҗади хезмәт...

Рабит Батулланың "Мур кырылышы" драматик әсәре кинороман буларак иҗат ителгән. Анда да Алтын Урданың иң кодрәтле һәм таркалу чорлары сурәтләнә, Вахит Имамовның "Казан каласы" романы, Фоат Садриевнең "Бәхетсезләр бәхете", Камил Кәримовның "Ком сәгате" романы да күләме һәм билгеле бер дәвер-чорларны колачлый алулары белән эпик әсәрләр кимәлендә бәяләнергә

хаклыдыр. Әмма сүз бер яки берничә автор турында түгел, ә йөзгә якын прозаикны берләштергән иҗат берлегенең хезмәте турында бара...

Прозабызга гарипләндерелгән заманның әдәпсез детективы үтеп керүе бик сагайта. Бозыклыкны, көчләү, әхлаксызлыкны фаш итәм дип аны пропагандалауга кайтып кала түгелме бу әсәрләр?

Татар прозасы үзенең беренче үрнәкләреннән үк психологик кичерешләргә һәм әдәпле мәгърифәтчелеккә, гыйбрәт алуга корылышы белән аерылып торды... Үз юлыбызны югалтмау бик мөһимдер!

Прозадагы тема талымсызлыгы драматургиябезгә дә әрсезләнеп керергә бик тели. Ел саен үткәрелгән Яңа татар пьесасында без шуның ачык мисаллары белән очрашабыз, ә бит бүген татар драматургиясендә дә шул ук колачлылык, эпиклылык җитми... "Зәңгәр шәл" спектаклендә качкыннар күренешендә генә дә 26 ир-ат катнаша. Персонажларның һәрберсенең үз милләте, үз теле, үз холкы, үз портреты бар... Татар драматургиясе үзенең беренче үрнәкләрендә үк мелодрама һәм социаль драма буларак туды. Шул ук вакытта сатирик комедияләр, лирик комедияләр дә безнең өчен ят түгел...

Милли драматургиябезне милли театрыбыздан аерып карау һич кенә дә мөмкин түгел. Чөнки театр бер үк вакытта гыйбрәтле тамаша да, күмәкләп "китап уку" да, күмәкләп аңа карата мөнәсәбәт белдерү һәм дә күмәкләп рухи чистарыну урыны да, ә иң беренче чиратта, татар театры Казанда, Әлмәттә, Чаллыда, Минзәләдә, Уфада, Оренбургта, Туймазыда—кайда гына булмасын, ул милли сәнгатебезне саклап торучы үзәк тә... Гомумән, театр сәнгатенә язучыларыбыз беркайчан да битараф булмады... Киләчәктә аларның репертуарлары безнең язучыларыбыз әсәрләре белән тагын да тулыланыр, ә язучыларыбыз заманга лаеклы әсәрләр язар диган өметтә калыйк...

Әдәбиятыбызның киләчәге бүгенге балалар әдәбиятының торышына турыдан-туры бәйле. Китапка мәхәббәт бишек җырыннан, балалар бакчасыннан башлана, мәктәптә мәхәббәт инде өлгереп җитмәсә, Тукайның сабые Маэмайны зурайгач арт аякларында басып торырга өйрәтеп булмасын кисәткән кебек, кешене үскәч китап укырга да өйрәтеп булмаячак...

Балалар әдәбияты дигән бик зур өлкә, бик зур тармак бар әдәби иҗатта...

Гасырлар алышынганда, меңьеллыклар алышынганда, иҗтимагый стройлар алышынганда, фәнни-техник алгарышлар көне-сәгате белән үзгәреп торганда без сабый балага, яшүсмергә нинди әдәбият тәкъдим итәбез? Кемгә нинди әсәр кирәген белеп язабызмы?

Бу сорауларга җавап бирү өчен тирәнтен анализлау сорала. Ә күзгә бәрелеп торганы шуннан гыйбарәт:

—кечкенә яшьтәге мәктәп балалары өчен шигырьләр һәм берникадәр әкият жанрында эш бара кебек,

—ә урта һәм зур сыйныф укучылары өчен дөньяны танып белергә ярдәм итәрдәй мавыктыргыч маҗаралы проза, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр психологиясенә корылган чын сәхнә әсәрләре иҗат ителдеме соң соңгы елларда?

Балалар һәм яшүсмерләр өчен җыр текстларын да инде балалар үзләре генә язалар бугай...

Язучылар берлегенең XV съездында мәктәпләрдәге әдәбият дәреслекләренең заман таләпләренә туры килмәве хакында аһ-зарлар күп булган иде. Бу мәсьәләдә без идарәдә дә үзебезгә җаваплылык алып, галимнәребез белән бергә, дәреслекләрнең торышын анализларга алынырга бер-беребезне өндәп карадык. Һәркем бу эшнең әһәмиятен әйтте, әмма бер генә идарә әгъзасының да үзе турыдан-туры бу эшкә алынасы килмәде... Шулай да безнең сорау буенча "Мәгариф" нәшрияты бүгенге дәреслекләрдә кайсы язучыларның әсәрләре ни дәрәҗәдә өйрәнелүен, кайсы авторларның нинди әсәрләрен дәреслекләргә кертү зарурлыгы буенча үз тәкъдимнәрен эшләде һәм, әдәбиятны өйрәнү буенча өстәмә ярдәмлек буларак, ул китап булып та басылып чыкты... Әмма дәреслекләрне әзерләү ул Мәгариф министрлыгы вәкаләте һәм ул дәүләт заказы тәртибендә генә конкурслар аша эшләнгәнлектән, безнең элеккеге Мәгариф министрына берничә мәртәбә мөрәҗәгать итеп тә ул безнең мөрәҗәгатьләргә күрсәткән игътибарсызлык белән

килешеп, ризалашып, тынычланып калдык.

Хәзерге министрыбыз үзе тел белгече, әдәбиятчы, без бүген ана үзебезнең әдәбият дәреслекләрен камилләштерү буенча хезмәттәшлеккә әзер булуыбызны житкерәбез һәм алдагы ике елда, 2010 елга кадәр, бу өлкәдә чын-чынлап янарышлар булыр дип өметләнәбез.

Определенной активностью и плодотворностью отличалась работа секции русской литературы и художественного перевода. Десятки книг, вышедших в Татарском книжном издательстве, имели положительные отклики в республиканской прессе и пользуются читательским спросом. Проведено множество литературных вечеров и творческих встреч.

Выделяя основные тенденции литературного процесса, хочется отметить следующее. В поэзии—следование, в основном, классическим канонам стихосложения, гуманистическая традиция, и почти у каждого автора присутствует тема двуязычия, тема двух народов, проживающих на одной земле. В прозе и драматургии преобладают произведения на историческую тему, популярен жанр остросюжетного и детективного романа. Прослеживается явная тенденция к крупным формам.

Пишущая молодежь концентрируется в основном вокруг литературных объединений, с которыми Союз писателей тесно работает. Надо бы активнее привлекать молодых писателей для участия в мероприятиях Союза писателей Татарстана, проводить мастер-классы с участием известных литераторов. Им есть что передать молодым.

Не вдаваясь сейчас в анализ причин, которые в конце XX века привели к практически полному исчезновению с литературной арены художественного перевода, хотел бы между тем заметить, что на XV съезде писателей была поставлена задача возродить и развить этот род литературной деятельности. Сегодня можно констатировать, что эта задача успешно решается.

В этом, разумеется, решающую роль сыграло то, что в республике не были потеряны необходимые предпосылки для этого. Речь идет, во-первых, о том, что, в составе нашего Союза есть писатели, хорошо знающие два литературных языка, также у нас есть литературные журналы, выходящие на двух языках—в первую очередь, я имею в виду журнал «Идель».

Во-вторых, чтобы снова запустить механизм этого сложного литературного процесса, правительство республики выделило Союзу писателей целевое финансирование.

Группу переводчиков возглавил известный поэт Сергей Малышев. Для оказания группе непосредственной практической помощи для них был организован недельный семинар при участии ректора Российской академии поэзии Валентина Устинова и заместителя главного редактора журнала «Дом Ростовых» Дениса Устинова, которые очень высоко оценили первые плоды творчества секции. Все это позволило в 2007 году при поддержке Татарского книжного издательства издать первый сборник прозы 30 татарских писателей в переводах на русский язык, а совсем недавно вышел сборник татарской поэзии в переводе на русский язык, куда вошли произведения 65 татарских поэтов. Сегодня наши переводчики заняты переводами пьес 8 татарских драматургов на русский язык и подготовкой очередных сборников татарской прозы и поэзии в русских переводах.

Разумеется, литературный перевод должен осуществляться не только на русский язык, но и на другие национальные языки. В апреле прошлого года Союз Писателей РТ и Министерство культуры Татарстана совместно с журналом «Дружба народов» организовали в Казани форум, посвященный проблемам перевода. В его работе приняли участие писатели и переводчики из 5 национальных республик. Перевод на национальные языки был назван главным направлением в сфере литературных начинаний.

Думаем, что в будущем в республиканских издательствах появятся штатные

переводчики, которые будут выполнять государственные заказы на переводную литературу. В свою очередь, Союз писателей должен думать о том, чтобы раскрыть новые потенциальные возможности литературного перевода.

Әдәбиятыбызда сан һәм сыйфат тәнгәллеген булдыру, милли әдәби телебезнең үсеше эволюциясенә үтә дә җаваплы күзәтчелек итү, әдәби телебезгә карата һичнинди талымсызлыкка юл куймау—әдәби тәнкыйтьнең бик тә җаваплы һәм мактаулы бурычы... Бу хакта тәнкыйтьчеләребез бүген һәрвакыттагыча үз эшчәнлекләренә үзтәнкыйть аша бәя бирерләр, ә язучыларыбыз алар эшенә бәя биргәндә чамаңы югалтмаслар дигән теләктә калам.

Отчет чорында талантлы яшьләрне барлау, аларны әдәби иҗатка тарту һәм һөнәри яктан үстерү Язучылар берлеге идарәсенең төп эш юнәлешләреннән булды һәм киләчәктә дә бу шулай булырга тиеш.

Яшь алмашны тәрбияләүнең котылгысыз рәвештә зарурлыгы безнең берлекнең социаль паспортында бик ачык күренә. Без Россиядә сан ягыннан гына түгел, ә яшь буенча да иң өлкән берлекләрнең берсе. Бүгенге көндә безнең уртача яшебез 59 яшьтән артып китә. 323 язучының 172се пенсия яшендә, шуларның 82 сенең яшьләре 70 тән өлкәнрәк булуы, ә яшьләре 35 кә кадәрге язучыларның саны 25 кенә булуы безнең шактый аянычлы хәлдә калуыбыз хакында сөйли. Әлеге яшь каләмдәшләребез арасында 1973—1979 еллар аралыгында туган бер генә кеше дә юк. Моның белән, 1993—2000 елларда Республикабызның югары уку йортларында татар теле һәм әдәбияты факультетлары әллә ябылып тордымы икән дигән шик тә туып куя. Әдәби иҗатка тулы бер буын килми калуының җәмгыятьтәге социаль тетрәнүләргә, рухи кыйммәтләргә карашның җинаятьчел рәвештә начарлануына бәйле булуын без кемгә караганда да яхшырак аңлыйбыз.

Яшь талантларны барлау һәм үстерү элек-электән әдәби-иҗат берләшмәләре аша алып барылды. Бүгенге көндә республикабызда әдәби берләшмәләр саны 26 исәпләнсә дә, аларның исеменә җисеме туры килгәне бер дистәгә җитәр-җитмәс кенә. 2005, 2006 елларда Мәдәният министрлыгының ярдәме белән әдәби берләшмә җитәкчеләренең Казанда укуларын оештырганда ул әдәби берләшмәләрдә яшь иҗатчылардан бигрәк өлкән яшьтәге әби-бабайларыбызның булуына төшендек. Чагыштырмача яшь иҗатчыларны туплаган берләшмәләр Актанышта, Әлмәттә, Мөслимдә һәм югары уку йортларында гына тупланган.... Әдәби берләшмәләрнең эшен фәкать яшь талантлар белән эшләүгә юнәлтүне, алар белән ел дәвамында һөнәри осталык күнекмәләре һәм аерым остазлык итүне Әлмәт, Чаллы оешмаларында өр-яңадан оештырасыбыз бар.

Язучылар берлегендә без өч дистәдән артык иң өметле талантлы яшьләрне туплап үзләренең клубларын төзедек. Алар белән даими эшләүне яшь галимә һәм талантлы шагыйрә Луиза Янсуарга йөкләдек...

Әмма яшь алмашны әзерләүнең фәнни-методологик һәм практик базасы булып махсус югары әдәбият уку йортлары тора... Ни кызганыч, әлегәчә бездә бер генә ВУЗда да профессиональ әдәбиятчылар әзерләү бүлекләре ачылмады... Безнең карашка шундый бүлекчәне Казан дәүләт университетының тарих һәм татар теле һәм әдәбияты факультеты кысаларында алдагы уку елыннан ук ачу бик тә зарур. Әлеге факультетта дистәгә якын язучы-галимебез хезмәт куя... Бер сүз белән әйткәндә, бөтен мөмкинлекләр дә бар. Сәяси ихтыяр, теләк һәм җаваплылык кына кирәк.

Отчет чорында, ниһаять, 15 ел тәнәфестән соң, Мәскәүнең Әдәбият институтында эшләп килүче югары әдәби курсларга талантлы бер тәрҗемәче шагыйрәбез Алена Кәримованы җибәрә алдык... Алдагы уку елында да хөкүмәтебезнең ярдәме белән талантлы яшь драматург Илгиз Зәйниев, яшь шагыйрәбез Йолдыз Миннуллинаның да шушы мәртәбәле уку йортында белемнәрен һәм профессиональ осталыкларын арттырырга дигән олы теләкләре тормышка ашсын иде дип телибез.

Әдәби басмаларның яшьләр иҗатына чын-чынлап йөз белән борылуы—Язучылар берлеге һәм бу басма мөхәррирләренең уртак бер гамәле дип бәяләнергә хаклы.

"Идел" яшьләр журналында ниһаять яшь иҗатчылар белән максатчан эш алып барыла башлады... Шунысы игътибарга лаек, "Идел"нең ике телле булуы яшь авторның иҗат үрнәген бер үк санда ике телдә күрү мөмкинлеген дә тудыра. Шулай итеп, "Идел", беренчедән, яшьләргә киң мәйдан бирсә, икенчедән, Язучылар берлегендә инде иҗади мөмкинлекләре һаман саен киңәя барган әдәби тәрҗемә секциясенә дә мәйдан ача... "Идел"нең бу үзенчәлеге киләчәктә журналның чын-чынлап өстенлеге булып әверелер әле...

Әмма "Идел" журналының чын мәгънәсендә яшьләр журналы булып танылуы өчен әле күп эшлисе бар... Соңгы ике елда журналның тиражы 2 мәртәбә диярлек артуына карамастан, әле урыс телендәге "Идел"нең үз укучыларын тапканы юк. Моның өчен урыс телендәге "Идел"нең урыс телендәге үз авторлары, яшь авторлары булуы зарур...

В последнее время, особенно из Челнов, к нам участились обращения по поводу учреждения нового литературного журнала или газеты на русском языке.

Учреждение любого издания—дело очень сложное. Но уместно будет спросить: а как мы используем возможности журнала «Идель»? Скажу мягко—очень слабо. Русскоязычный вариант должен быть в первую очередь трибуной для молодых русскоязычных авторов и переводной литературы. Совершенно необязательно зеркальное отражение содержания журналов... Мы бы хотели, чтобы в ближайшие 2-3 года общий тираж журнала «Идель» перешагнул 10-тысячный рубеж. Это означало бы нашу конкретную деятельность и в плане работы с молодыми авторами, и в плане работы по воспитанию молодежи—писателей, любителей литературы.

Гомуми әдәби процесста, әлбәттә, атналык әдәби-мәдәни газетабыз—"Мәдәни җомга" газетасы да зур роль уйный. Газетаның үз зыялы укучысы бар... Республикабызның район, авыл мәктәпләрендә "Мәдәни җомга" газетасын алдыруларын күреп, аны мәктәп яшендәгеләр укуын да белеп куандым.

24 битле атналык газетаның һәр санында бер шагыйрьгә, бер проза язучыга һәм тәнкыйтьчегә аерым сәхифә бирелүе, яңа чыккан китаплар турында мәкаләләрнең даими басылып баруы—әдәби тормышыбызның оператив елъязмасын булдыруда, әдәби процессның пульсын үлчәп баруда мөмкинлек тудыруы белән бик әһәмиятле. Шулай ук газета яшь иҗатчыларга да игътибарын сизелерлек арттырды, шул ук вакытта газета академизм сырхавы белән дә авырый кебек. Яңа рубрикалар, дәвамлы бәхәс-дискуссияләргә урын аз бирелә...

Атналык басма буларак, "Мәдәни җомга"—әдәби иҗат берләшмәләренә аена ике мәртәбә булса да үзләренең иҗат үрнәкләрен күрсәтерлек мәйдан бирә алыр иде. Бу исә үз чиратында аның укучылары санын бермә-бер арттырыр иде. Газетаның баш мөхәррире һәм аның урынбасары, Язучылар берлеге идарәсе әгъзалары буларак, Язучылар берлеге эшчәнлегендә бик актив катнашалар. Киләчәктә әйтелгән һәм әйтелмәгән теләкләрне алар искә алырлар, дигән ышанычта калабыз.

Республикабызда татар телендә нәшер ителүче "Мәйдан" журналы үзенең мәйданын елдан-ел киңәйтә бара. Журналның аерым әдипләребез һәм шагыйрьләребезнең иҗатына бер санны багышлаулары да бары хуплауга гына лаек... Журнал редакциясе, баш мөхәррире Вахит Имамов, аерым саннарны Кама аръягы районнары һәм аерым кешеләренә багышлап чыгарып, шул төбәкнең җитәкчеләре һәм киң җәмәгатьчелекнең журналга игътибарын арттырды һәм шуның белән журналның тиражы да үсте... Әмма, шул төбәктә яшәп иҗат итүче каләмдәшләребез бүген ачыктан-ачык "Мәйдан"ның үзләренә мәйдан бирмәвенә аһ-зарларын белдерәләр. Минем карашымча, әлеге журнал иң беренче нәүбәттә шул төбәктәге язучыларны туплап торучы һәм аларның иҗатына мәйдан бирүче басма булырга тиеш. "Мәйдан" журналы шулай ук яшь иҗатчыларга игътибарын да бермә-бер арттырырга бурычлы. Бу тәкъдимнәрне журналның баш мөхәррире һәм Язучылар берлегенең Чаллы бүлекчәсе җитәкчесе, каләмдәшебез Вахит Имамов үзенә кабул итәр дип ышанабыз.

2000нче сан биеклегенә юнәлеш тоткан "Казан утлары" журналын милли әдәбиятыбызның көзгесе дип тә, иҗат бакчасы, иҗат кыры дип тә атап була. Журналның, гомумән, халкыбызның рухи тормышында тоткан урыны елдан-ел әһәмиятлерәк була бара... Язучыларыбызның анда басылып чыккан һәрбер әсәре нәшер ителгән китап дәрәҗәсендә генә түгел, ә аның иҗади үсешенең бер этабы буларак кабул ителә... Хисап чорында журнал редакциясе кылган күп игелекле гамәлләренә өстәп шуны гына әйтәсе килә—журнал әдәбиятыбызга килүче яңа яшь буынны үз вакытында күреп алды, аларга мәйдан биреп:—"Афәрин, яшьләр!"—диде... Алдарак "Казан утлары" һәм башка әдәби басмаларыбызның язмышы хакында җитди сүз булыр. Әлеге исемнәре аталган төп әдәби басмаларга һәм әдәбиятыбызны пропагандалауга үзләреннән лаеклы өлеш керткән "Ватаным Татарстан", "Шәһри Казан", "Мирас", "Сөембикә", "Татарстан", "Ялкын", "Салават күпере" газета-журналларына, "Татарстан—Яңа гасыр", Татарстан дәүләт радио-телевидение коллективларына рәхмәтебезне җиткерәбез.

Ике корылтай арасында үткәрелгән барлык чаралар турыдан-туры Мәдәният министрлыгы һәм аңа караган дәүләт учреждениеләре белән берлектә, ә 2007 нче елдан башлап Мәдәният министрлыгы аша алынган дәүләт финанславына нигезләп алып барылды... Билгеле булганча, отчет чорында безнең төп эшләребезнең берсе булган әдәбиятны пропагандалауга зур көч, вакыт һәм чыгымнар тотылды. 2005-2007 нче елларда барлык 243 язучыбызның төрледән-төрле юбилейларын республикабыз башкаласында, чит төбәкләрдә, район-шәһәрләрдә үткәргәндә яки билгеләп үткәндә дә иң беренче максат итеп әдәбиятны пропагандалау, әдәби иҗатка яшьләрне тарту максаты алгы планга куелды.

Әмма әдәбиятны телевидение аша пропагандалау буенча безнең мөмкинлекләребез тулысынча файдаланылды дип әйтә алмыйбыз. Хәтта "Казан утлары" журналындагы әңгәмәдә Президентыбызның телевидение аша шигърияте пропагандалау буенча әйткән конкрет тәкъдимен җиткереп һәм Яңа гасыр телевидениесендә даими әдәби рубрикалар ачарга тәкъдим итүебез дә әлегә җавапсыз калды... Дөресрәге, телевидение әдәбиятны, сәнгатьне пропагандалауда да үз монополиясен саклап калды, бу эшнең мәгънәви эчтәлеген билгеләүдә язучыларыбыз, әдәбият галимнәре бөтенләй катнаша алмады... "Яңа гасыр" телевидениесенең колачлау киңлекләре һәм географиясе киңәйгән хәзерге чорда аның халкыбызга зыялылар сүзен җиткерә торган даими тапшырулары һичшиксез булырга тиеш. Язучылар берлеге идарәсе ул даими рубрикаларны бер ел элек тәкъдим итте, безнең тәкъдимнәребез бүген дә үз көчендә кала... Алай гына түгел, алдагы бишьеллыкны без яшь иҗатчылар тәрбияләү чоры дип билгелибез икән, бу изге максатыбызга ирешүдә милли телевидениебез безгә йөз белән борылырга бурычлы!...

Татарстан Язучылар берлеге һәм дәүләт китап нәшрияты дистәләрчә еллар дәвамында бер коллектив булып халкыбызны милли китапларыбызга кинәндереп торды... Әмма соңгы 5-6 елда басылган китаплар халыкка барып җитми һәм язучыларыбызга хезмәт хакы—гонорарлар гына—вакытында түләнми башлады... Болай да Рәсәйдә иң түбән гонорарлы төбәк булуга карамастан, 2006-2007 елларда бездә нәшер ителгән китапларның авторларына 4 млн. сумга якын акча әлегәчә түләнмәгән... 2007 елдан исә Татарстан китап нәшрияты авторларга гонорарларны 50 процент китаплата түли башлады... Бу хәл пенсионер язучыларыбызда хаклы ризасызлык тудырды.

Шулай ук "Татмедиа" карамагына күчкән әдәби журналларда да язучылар хезмәтенә түләү мәсьәләсенә җитди үзгәрешләр таләп ителә.

Язучылар берлегенең киләчәк язмышы яшь иҗатчылар кулында дип әйтсәк тә... эстафетаны алар кулына нинди дәрәҗәдә тапшырылуы өчен без—өлкәннәр һәм урта буын—җаваплы. Бу турыдан-туры Язучылар берлеге бинасына да кагыла. Моннан 24 ел элек бу гүзәл тарихи бинаны язучыларыбыз карамагына биреп Республикабыз җитәкчеләре бер игелек эшләсәләр, бинаны тулысынча реконструкцияләү һәм реставрацияләү турында күрсәтмә биреп, Президентыбыз иҗат кешеләренә булган ихтирамны тагын бер кат күрсәтте. Иҗат кешеләре дигәндә, бу бинада язучыларның Г. Тукай исемендәге клубын, "Идел", "Салават күпере", "Сәхнә" журналлары

редакцияләре һәм интеллектуаль милекне, авторларның хокукларын яклау агентлыгы да урнашуын һәм барлыгы 50гә якын кешенең бирерә эш урыны булуын да күздә тотам...

Отчет чорында бинаны тәзекләндереп бетерүгә ирешә алмадык... Монда мин иң беренче сәбәп итеп үземнең булдыксызлыгымны танырга мәҗбүр. Әмма башка "олырак сәбәпчеләр" дә бар шул. Проектлаштыру һәм төзекләндерү эшләрен параллель рәвештә алып барырга килешсәк тә, төп заказчы булган "Татглавинвестрой" дигән оешма безгә бер дә унай тормады... Минем аларның үзләре белән күп тапкырлар очрашып сөйләшүем тиешле нәтиҗә бирмәде, хөкүмәт житәкчесенә, Төзелеш министрлыгына ярдәм сорап язган хатларымны алар жалоба дип кабул итеп, киресенчә, бу эшкә аяк чалдылар кебек... Инде, ниһаять, хөкүмәтебез житәкчесе Рөстәм Нургали улы Миннехановка кереп хәлне сөйләп биргәч, бу эш жайга салынып дигән өмет уянды. Ул 10 млн. сум акча бүлеп бирде, тагын да вәгъдә итте... Зур рәхмәт аңа.

Базар шартларында бина мәйданнарын һәм жир мәйданнарын нәтижәле файдалану кирәклеген, финансистлар булмасак та аңлыйбыз...

Язучылар берлеге ихатасындагы жимерек агач биналар урынына Татарстан китап нәшриятының яңа бинасын төзү турындагы мөрәжәгатьне Илбашыбыз тулысынча хуплады һәм аның хөкүмәт органнарына күрсәтмәсе нигезендә бу булачак төзелешнең документларын "Татгражданпроект" оешмасы әзерли башлады. Ишетүебезчә, бу төзелешне барыбыз да хөрмәт иткән "Таттрансгаз" һәм "Татэнерго" оешмалары үз химаясенә алачаклар. Бу эшләр безнең барыбызда да киләчәккә ышаныч белән карарга өмет уята. Тик бу эшләрне: төзекләндерү һәм яңа бинаны төзүне озакка сузмыйча, алдагы 1-2 ел эчендә Г. Тукайның 125 еллык юбилеена хәл итү өчен яхшы мәгънәдә ужәтлек кирәк булачак.

Ил күләмендә базар мөнәсәбәтләренең тирәнтен урнашып бетүе һәм бөтен яшәешнең милек һәм финанс катнашында табыш алуга корылуы иҗат берлекләренә карата булган традицион карашларны үзгәртте... Бер милексез калган җәмәгать оешмасы йә яшәүдән туктарга, йә үзләренә түбә булырдай спонсорлар табарга, йә ниндидер юллар табып элеккечә дәүләтнең ярдәменә өмет итәргә дучар булып калды...

Үзәктән бердәнбер чыганак булган СССР-Россия Литфондының талануы һәм таралуы аркасында менә 4 ел инде без тулысынча язмыш иркендә калдык...

Безгә яшәүдән туктарга ярамый!

Шуның өчен без үзебезгә түбә булырдай спонсорлар да һәм элеккечә дәүләт финанславы юлларын да эзләдек һәм эзлибез... Дәүләт финанславы, шөкер, тукталмады... Мәдәният министрлыгы аша субсидияләр тәртибендә безнең чыгымнарыбыз финанслана. Отчет чорында "Татнефть", "Татэнерго", "Нижнекамскшина", "Татспиртпром", "Татптицпром" оешмаларының саллы гына ярдәмнәрен алдык... Әмма киләчәктә Россия күләмендә Язучылар берлеге һәм язучының социаль статусы анык билгеләнгән, иң беренче чиратта аның иҗади хезмәтенең дәүләт ихтыяжы һәм дәүләтнең иҗатчыны кайгыртуы гарантияләнгән, бердәм хокукый акты-законы булуы мөһим. Шундый законны кичекмәстән кабул итүне сорап, Россиянең күренекле зыялылары дәүләт житәкчеләренә, Дәүләт Думасына инде берничә кабат мөрәҗәгать итүенә карамастан, әлеге закон һаман кабул ителми... Әйткәнемчә, бернинди милке һәм табыш чыганаклары булмаган җәмәгать оешмасы статусындагы Россия субъектларының иҗат берлекләренә ни эшләргә кала?.. Әлегә бердәнбер юл булып, Язучылар берлеге бинасы каршында Республика Язучылар Йорты дәүләт учреждениесе булдырып, аның дәүләт тарафыннан финанслануын хокукый яктан ныгытып кую сорала.

2006 елда, Президентыбыз белән киңәшкәннән соң, бу мәсьәлә буенча тиешле документлар да әзерли башлаган идек... Ул вакытта Милек һәм жир мәсьәләләре министрлыгының җәмәгать оешмаларына дәүләт милкен тапшыру законга туры килми дигән фикере белән бу эш вакытлыча туктатылып торды. Инде дәүләтебез безне Мәдәният министрлыгы аша субсидияләр тәртибендә финанслый ала икән, димәк безнең иҗат берлегебез—Иҗат йорты исеме белән дәүләт учреждениесе яисә

автономияле дәүләт учреждение статусына ия була ала.

Иҗат берлегебезне саклап калыйк, яшәтик дисәк, безгә үзебезнең Республикабызда өр-яңадан үзебезнең Әдәби фондыбызны төзү турында да уйларга кирәк. Әдәби фондны төп оештыручылар булып Язучылар берлеге белән бергә барлык нәшриятлар һәм типографияләр һәм матбугат, китап сәүдәсе челтәрләре дә, республикабыздагы предприятие, оешмалар да алына алыр иде... Бу мәсьәлә дә бүгенге съездда фикер алышуны һәм билгеле бер карарга килүне сорый.

Уважаемые коллеги!

Не наша вина, что в связи с распадом союзного государства распался и его Союз писателей. К сожалению, международное содружество писательских союзов бывшей страны не смогло стать полноценным преемником бывшего Союза писателей. Началась эпоха деления творческих союзов. При этом у каждого появились сугубо личные интересы и сфера деятельности. Процесс разделения творческих союзов продолжался и в регионах и субъектах России. В этой ситуации наш Союз при поддержке нашего правительства, принял все необходимые меры, чтобы сохраниться.

В последние годы, впрочем, как и прежде, мы поддерживали сотрудничество с писательскими организациями регионов и, прежде всего, с Союзом писателей РФ. Наше взаимное стремление к сотрудничеству было реализовано при подготовке и проведении юбилейных мероприятий в Москве, С.-Петербурге и Оренбургской области, посвященных 100-летию М. Джалиля и 120-летию Г. Тукая. А также в работе Форума писателей и переводчиков Поволжья в Казани в апреле 2007 года. Руководители Союза писателей Российской Федерации также принимали участие в мероприятиях в Казани, организованных Союзом писателей Татарстана.

В настоящее время ведется подготовительная работа по учреждению общероссийской литературной премии имени М. Джалиля, ее учредителями будут выступать Союз писателей РФ, Министерство культуры и Союз писателей РТ.

За отчетный период я в качестве гостя принимал участие в мероприятиях Союза писателей РФ. А народный поэт Татарстана Ренат Харис даже является секретарем правления Союза писателей РФ.

Словом, время и общие цели сближают нас, и в дальнейшем мы должны будем находить еще более плодотворные и интересные формы сотрудничества. Причем, речь не идет о вертикали взаимоотношений. Мы готовы войти более тесно в единое литературное пространство, принимать более активное участие во всех государственных проектах. И тем самым заложить прочную основу для нашего дальнейшего сотрудничества. Я благодарен нашим гостям из Москвы—за участие в работе нашего съезда, желаю им благополучия, здоровья и счастья.

Хөрмәтле каләмдәшләр!

Иҗат берлегебезне саклап калу турында сүз алып барганда без һич кенә дә аның оештыру эшчәнлегендә хәзерге ил күләмендәге вәзгыятькә карап үзгәрешләр булырга мөмкинлеген инкарь итмибез... Галиҗәнап вакыт инде күп кенә функцияләреннән азат итте аны... Әмма милли әдәбиятыбызны үстерүдә иҗтимагый вазифаларны үтәү өчен барыбер дә безнең иҗат берлегебез алыштыргысыз булып кала...

Отчёт чорында иҗат берлегебезнең гамәлләр кыры географиясе киңәйде... Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты белән бергә башкарган бик күп эшләребезнең берсе буларак, без республикабыздан читтә яшәп иҗат итүче, иҗтимагый-милли хәрәкәттә аеруча актив катнашкан милләттәшләребезне Язучылар берлегенә әгъзалыкка да кабул иттек... Аларны үзләре яшәгән төбәктә әдәбиятыбызны пропагандалау, әдәби хәрәкәтне үстерүдә максатлы эшләргә юнәлттек. Иҗау каласындагы шундый хезмәттәшлегебез нәтиҗәсе буларак, Удмуртия Язучылар берлеге каршында татар язучылары секциясе төзүгә ирештек. Себердә, Казакъстанда, Ульянов өлкәсе, Мордовия республикаларында яшәүче язучыларыбызны үз сафларыбызга алдык. Бу нәтиҗәле эшне һичшиксез киләчәктә дә дәвам итәргә кирәк.

Әйе, узып киткән өч ел безнен әдәби берлегебез өчен чын мәгънәсендә сынау еллары булды. Түземлеккә, иҗади житлеккәнлеккә! Ирешкән унышлар һәм хәл итәсе эшләр турында бирелгән вакыт эчендә барысын да әйтеп бетереп булмый һәм андый максат куелмады да.

Инде сынауны үтә алдыкмы, юкмы, аны съезд билгеләр... Эшләгән барлык эшләребезне сайлап куелган идарәнен теләге, тырышлыгы, конкрет гамәлләренен чагылышы дип, ә эшләнеп бетмәгәннәрен идарә рәисенең гаебе дип кабул итәрсез...



Зиннур Хөснияр

# БУЛГАН, БАР ҺӘМ БУЛАЧАК!

ПРОЗА

Сүзне Илбашыбыз мөхтәрәм Минтимер Шәймиевнен түбәндәге фикере белән башлап китсәк, ул ошбу чыгыш-язмада күтәреләчәк көнкадак мәсьәләләргә дә шактый ачыклык кертер һәм аларның чишелешенә ачкыч булып торыр иде: "Теге яки бу милләт турында җир астыннан чыгарган нефтьләре, иккән игеннәре яки җитештергән башка продукцияләренен күләменә карап түгел, анын мәдәниятенә, фән һәм техника тармакларындагы унышларына, мәшһүр шәхесләренә, язучыларына, шагыйрьләренә, галимнәренә карап фикер йөртелә. Бу җәһәттән без бәхетле милләт".

Әлеге фикерләр Татарстаннын мәдәни сәясәтендә нигез ташын тәшкил итә һәм итәргә тиеш дисәк, һич тә хаталанмабыз. Мин үземнең язмамны Президентыбызнын шушы фикер-тезислары яссылыгында әзерләргә булдым: язучы-прозаикларыбыз милләт данын күтәрерлек әсәрләр иҗат итә алганмы? Аларнын әсәрләре үз укучысына ни дәрәҗәдә барып житә?

Димәк, бүген безнен алда ике максат тора: беренчесе, ике съезд арасында милләт данына тап төшермәслек хикәя, повесть һәм романнар иҗат итә алганбызмы, икенчесе, укучы,—Рәсәй һәм Татарстан хөкүмәтләренә салым түләп торучы укучыларыбыз,—әлеге әсәрләрне укый аламы, дөресрәге, ул аларга барып ирешәме икән?

Нинди дә булса әсәрне тәнкыйть утына тоту бик жинел, ә менә ана бәя бирү—ин кыены. Мин бу очракта шундый бер хакыйкатьтән чыгып эш итәргә булдым. "Ин усал тәнкыйтьчеләр—алар үз гомерендә бер җөмлә дә язып карамаган кешеләр яки язып та уңышка ирешә алмаган каләм ияләре булыр",—дигән бер акыл иясе.

Укыйм... Ике корылтай арасында тылсымлы каләмнәрдән тамган әсәрләрне укыйм. Күңел дулкыннары искән җил тәэсиреннән түгел, журнал-китап битләренә тамган фикер-хис, кайгы-хәсрәт, шатлык-куаныч һәм башка шундый тәэссоратлардан тирбәлә, кичерешләрдән дулкынлана. Бөтен бәхетебез шунда ки: татар укый—шигырь, проза китаплары кулына эләкмәсә, йотылып, дөньясын онытып драма әсәрләрен, пьесаларны укый. Укыган... укый... бәлки әле тагын да укыр...

Җүнле әсәр язган һәм язарга сәләтле прозаикларыбызның исемнәрен атап чыгарга ике кулдагы бармаклар да җитә. Шуннан хәлне күз алдына китерик

инде. Өлгергән, рухи азык-ризык булырлык орлыклы башакларыбыз күп түгел. Хәер, арыш басуында билчәне дә, эт эчәгесе кебек чүп үләне дә була инде аның... Ләкин "әдәбият басуыннан" аларны да йолкып атарга ашыкмыйм мин. Алар да, тегермәннән тартырга ярамасалар да, үсемлек буларак, һавадагы зарарлы углекислый газларны йотып, күпмедер микъдарда кислород бүлеп утыралар...

Ни генә әйтсәң дә, бүгенге прозабыз хакында рәхәтләнеп сөйләшеп була. Бигрәк тә, соңгы вакытларда хикәя жанрының активлашуы куандыра. Айның уты сүнмәгән әле! Хәзинәбездә байлык бар, иншалла! "Айның уты..." дигәннән, күренекле хикәячебез Мәгъсүм Хужин хикәяләре, ике съезд арасында "Айның уты сүнгән" дип аталган җыентыкта басылып чыгып, һичшиксез, укучыбызны сөендерде. М. Хужин, үзенең остазы Фатих Хөсни кебек, шөкер, хикәя жанрына хыянәт итмәде: аның югары кимәлдә язылган хикәяләре инде "М. Хужинның хикәя мәктәбе"ен булдырды. Мәктәбе булгач, димәк, анда шәкертләр дә бар дигән сүз.

Ике корылтай арасында әдәбиятыбызда искитмәле талантлы әсәрләр иҗат ителгән, хикәя жанрының "тегермәне" шактый җилле әйләнгән. "Казан утлары" журналы "Хикәяләр конкурсы" игълан итеп, ошбу жанрны алга җибәрүдә гаять зур эш башкарды. Шушы вакыт эчендә редакциягә 100гә якын хикәя килүе нәкъ менә шул хакта сөйли. Иң актив "тегермәнчеләр"—безнең сөекле хатын-кызларыбыз. Бу нисбәттән уннан артык авторның казанышларын искә алып китәргә мөмкин. Активлар арасында да иң активлары була, болар: Нәбирә Гыйматдинова, Рифә Рахман, Рәмзия Габделхакова, Роза Мулланурова, Ләлә Гыймадиева, Эльмира Шәрифуллина, Асия Юнысова, Халисә Ширмән, Дания Гайнетдинова, Гөлзадә Бәйрәмова, Айгөл Әхмәтгалиева, Динә Әхмәтова һәм, әлбәттә, Фирүзә Жамалетдинова. Бу автор аерым игътибарга лаек. Әлеге язучыларыбыз ике корылтай арасында "алтын йомыркаларны" коеп кына торган. Рифә Рахманның Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән "Айлы күлдәвекләр" китабы шул хакта сөйли. Зәвык белән бизәлгән хикәяләр җыентыгы. Рифәнең теле йөгерек: йә язгы шарлавык кебек, йә челтерәп аккан чишмә тавышын хәтерләтә. Һәр әсәр үз көенә генә укучының күңел кылларын чиртә. Аларны матур көй тыңлаган кебек рәхәтләнеп укыйсың.

Фирүзә Жамалетдинованың шулай ук нәшриятта басылып чыккан "Догалы корт" китабында да аерым хикәяләр бүлеге урын алган. Гыйбрәтле, зур мәгънәви эчтәлеккә ия булган хикәяләр! Аларның темалары да бәгырьгә үтеп керерлек, берсе генә дә укучыны битараф калдырырлык түгел. Дания Гайнетдинова, Роза Мулланурова китаплары да шулай ук әдәбият хәзинәсендә матур энҗеләр кебек. Икесенең дә китаплары бары хикәяләрдән генә тора.

Янә шундый бер гүзәл китап Рәмзия Габделхакованың"Көмеш тун" җыентыгы. Шулай ук хикәя-нәсерләрдән генә тора. Рәмзия ханымга үзенең үзенчәлекле каләме бу юлы да хыянәт итмәгән.

"Идел" журналында дөнья күргән хикәяләргә карата да нәкъ шундый ук бәя биреп булыр иде. Халисә Ширмән, Флера Тарханова кебек авторлар анда еш басыла. Гомумән, "Идел"нең зәвыгы бик көчле аның—ул юк-бар әйбер бастырмас. Тарихи әсәрләр булсынмы, мәхәббәт хикәяләре булсынмы, һәммәсе, яшьләр матбагасының нечкә иләге аша узып, укучыга зур сыйфат белән килеп ирешә. Май чүлмәге тышыннан билгеле ди, "Идел"нең бигрәк тә соңгы вакытлардагы эзләнүләре, яңалыклары, әлбәттә, аның битләрендә чиле-пешле хикәяләр бастырырга мөмкинлек калдырмый. Һәм, гомумән, безнең әдәби журналларыбызга "аяк белән язылган" әсәрләр үтеп керә алмый!.. "Сөембикә"нең холкы исә бу нисбәттән тагын да үзенчәлеклерәк, нәкъ кыз-хатыннар кебек үзе усал, үзе гүзәл. Күренекле шагыйрьләребез житәкләгән "Мәдәни җомга" хакында әйтеп тә тормыйм, аларның таләпләре шулай ук югары. Өстәвенә әдәби газетабыз хикәяләргә бик зур урын биреп бара. Соңгы вакытларда укучыларыбызның зур мәхәббәтен яулап алып, өстәл матбагаларына әйләнгән "Шәһри Казан", "Ватаным Татарстан" битләре аша да без хикәя жанрының әдәбиятыбызда төп жанрларның берсе булуы хакында мөһерле алабыз. Атаклы "Ялкын" һәм яшүсмерләр арасында популярлык казанган "Сабантуй" басмалары аша татар прозасының энҗеләре белән яшүсмерләребез тәрбияләнә. Боларның барысына да исә укучыны "Салават күпере" журналы әзерли. Тагын ун елдан "Казан утлары", "Идел" һәм башка басмаларның укучылар саны күпме булачагы нәкъ менә "Салават күпере" журналына бәйләнгән. Уку культурасы,

әдәбиятка мәхәббәт татар баласында нәкъ менә шушы бердәнбер сабыйлар журналы ярдәме белән тәрбияләнми дип кем әйтә ала?..

Кыскасы, хикәяләр хакында сөйләгәндә ошбу басмаларны телгә алырга ашыгуым анлашылсын иде: прозабызның кыска жанры нәкъ менә шуларда урын ала, шулар аша укучыбызга барып ирешә.

Нәзифә Кәримованың "Культурный кодагый" хикәясенең темасы минем күнелгә аеруча нык тәэсир итте. Бердәнбер академик басмабыз булган һәм, әйтергә кирәк, олуг татар әдәбиятын үз җилкәсендә күтәреп торган, бер гасыр тарихлы "Казан утлары" журналында нәшер ителгән әлеге хикәя көнкадак мәсьәләне—дини әхлак мәсьәләсен күтәрә. Минем бу хикәягә юкка гына тукталуым түгел, Ислам дине безнең милләтебезне саклап калды! Ислам дине үрнәге энҗеләре белән бүген газиз балаларыбыз тәрбияләнергә тиешле! Кыйбласы булмаган бүгенге җәмгыятьтә Ислам диненең гүзәл үрнәкләре безнең идеалыбызны баетырга тиешле, ахыр чиктә, ул идеологиябезнең нигез ташы булырга тиеш. Татар өчен элеккеге "коммунизм идеологиясен" Ислам диненең гыйбрәтле, гүзәл үрнәкләре идеологиясе алыштырды. Шуна күрә без аны пычранудан сакларга, аның белән сату итүдән тукталырга тиешбез. Хикәя әнә шул хакта.

Мин "хатын-кызлар прозасы, ир-ат прозасы" дип әдәбиятны икегә аеру ягында түгел. Бары тик гүзәл затларга хөрмәт йөзеннән аларның исемнәрен беренче итеп атап китәсем килде. Һәм, әлбәттә, алда әйтелгәнчә, хатын-кыз авторларыбыз хикәя жанрында иң активлардан.

Шул ук вакытта кайбер әсәрләр кимчелектән дә хали түгел. Мәсәлән, каткан кысалардан чыга алмыйбыз. Авылда элек кем кабахәт булган—колхоз рәисе, бүгенге көннең житешсезлекләренә кем гаепле—түрә гаепле. Мондый аклы-каралы караш һаман да яшәп килә әле. Алай гына түгел бит: дөнья ике генә төстән тормый, тормыш мең төрле төсләр гаммасыннан гыйбарәт!.. Аннан соң кайбер төгәлсезлекләр дә күзгә ташлана. Болында дөнья бетереп чикерткәләр сайраша, күл буенда бакалар сикерешә һәм шул ук вакытта авыл өенең моржасыннан төтен чыкканы күренә. Өстәвенә, хәзер Татарстан авыллары газ яга, аның төтене кыш көне дә күзгә шәйләнми.

Прозада хикәя жанрындагы яңалык Туфан Миңнуллинның "Утырып уйлар уйладым" китабына тупланган әсәрләр булгандыр. Мин алдан ук, кемнәрнеңдер минем белән бәхәскә керәселәре киләсен белеп, аларны "публицистик хикәяләр", дөресрәге, "хикәятләр" дип атар идем. Бу әсәрләрнең форма-алымы гаять үтемле һәм иң мөһиме—әлеге китапның укучыга тәэсир көченең микъдарын бернинди бизмәнгә салып та үлчәп булмастыр. Юк аны күтәрерлек бизмән, уйлап тапмаганнар әле... Мин әлеге китап алдында, аның авторы Туфан абый каршында, әлеге җыентык өчен рәхмәтемне житкереп, башымны иям.

Прозада хикәя жанры алып килгән икенче яңалык Марсель Галиевнын "Рух" әсәре булгандыр. Хикәяләрдән торган роман бу. Тургеневча, "проза в стихах" дияргә дә мөмкин. Тарихыбыз хакында, Ватан, туган тел хакында шундый затлы тел белән укучыбыз каршына килү авторның уңышлы адымы дип бәяләр идем мин. М. Гали укучысына татар теленең музыкасын тыңлата, аның чикләнмәгән затлы мөмкинлекләрен, байлыгының бетмәс-төкәнмәс икәнен исбатлый. «Артык зиннәтле, купшы тел әсәрнең фикерен томалый», дигән бер акыл иясе. М. Гали хикәяләре үзенең мәгънәви җегәре белән әлеге акыл иясенең дә авызын капларлык дәрәҗәгә ирешкән!.. Аның күптән түгел "Рухият" нәшриятында дөнья күргән сатирик әсәрләр җыентыгы да әдәби хәзинә буларак бәяләнерлек.

Тел ул үзе бер гаҗәп дөнья икәнлеге әдипләргә мәгълүм нәрсә. Җыр сәнгатендә баритон, бас һәм башка тавышлар булган кебек телгә дә андый үзенчәлекләр хас икәнлеген бүгенге прозада Марсель Галиев раслап күрсәтте.

Ике съезд арасында Камил Кәримовның басылып чыккан ике хикәясен укырга туры килде: "Сунар вакыты" һәм "Мин әнигә кирәк" әсәрләре. Бу авторның иң "пешеп житкән" чагы, аның язган әсәрләре дә шуңа күрә өлгереп житкән булалар. К.Кәрим вак-төяк темага алынмас, көнкадак мәсьәләләр кызыксындыра әлеге талантлы авторны. Аннан укучы тагын да саллырак әсәрләр көтүе белән ялгышмый торгандыр дип уйлыйм мин. Теле йөгерек, матур, аккош муены кебек сыгылмалы, яшь кызлар биле сыман гүзәл. Камил Кәримов күбрәк бүгенге заман хәлләрен бәяләсә, ә менә аның коллегасы Айдар Хәлим үзе яшь чакта кичергән

вакыйгаларга,—заманга дисәк, дөресрәк булыр,—мөрәҗәгать итә. Темалары кыю бу авторның, бәгырьгә үтеп керерлек итеп тасвирлый белә. "Әкчин" һәм "Миһранның үлеме" хикәяләре шуның ачык мисалы.

Геройларның характерын югары сәнгать дәрәҗәсендә бирү ягыннан мин мисалга Ркаил Зәйдулланың "Кыз-хатын" хикәясен китерер идем. Хатын-кызларыбызга хас булган уртак, типик холыкны ачкан да салган әлеге хикәя. Тагын мине гаҗәпләндергәне шул булды: бәйгегә килгән хикәяләр арасыннан нишләптер икесе генә истә калган. Шуларның берсе, әлбәттә, "Кыз-хатын" әсәре.

Бу юлы мине Әнәс Хәсәнов хикәясе бик сөендерде. "Ефәк пәрәвез" дип аталган хикәясен мин искиткеч уңыш дип бәяләр идем. Бер караганда әллә нәрсә юк та кебек анда. Ләкин, уйлап карасаң, безнең көндәлек тормыш та "әллә нәрсә" түгел инде ул, ыгы-зыгы килеп йөргән булабыз гына. Әнәс Хәсәнов шул ыгы-зыгыдан матур детальләр таба алган. Сүз башлагач, алга китеп булса да әйтим: "Әнис алмалар" повестен дә мин бер тында укып чыктым. Һәм әлеге әсәр бүгенге яшьләр арасында популяр әсәрләрнең берсе булырга тиеш. Безнең тормышта сугыш чоры әхлагы бар, алтмышынчы-житмешенче еллар әхлагы бар һәм бүгенге көннең әхлаксыз "әхлагы" бар. Болар бер-берсеннән асыллары белән бик нык аерыла, элек әхлак тазарак, сәламәтрәк иде. Ә. Хәсәновның әсәрләре әнә шул хакта сөйли.

Юбилее уңаеннан Альбер Хәсәновның бик матур китабы дөнья күрде. "Җәнбәт дәвере" дип аталган әлеге мәҗмуганы йотлыгып укыйсың. Нәкъ Альберт абыйча инде, Садри Максуди, Хәй Вахит якташы икәнлеге күренеп тора: тирәнлек тә бар, укучыны кызыксындыра да белә.

Хикәяләрне бергә туплап укыганда алар хакында фикер йөртү объектив була ала. Вакыйф Нуриевнең "Жиденче палата" китабы һәм Галимҗан Гыйльмановның "Китек ай" белән "Оча торган кешеләр" китаплары бу язма авторына әнә шундый мөмкинлек бирде. "Мөссәлим карт догалары", "Гөлләр дә елый", "Йорт иясе" һәм, әлбәттә, башка хикәяләре Галимҗан Гыйльмановның зур уңышы дип саналырга хаклы. Аның "Ана сүзе" кебек хикәяләрен тыныч кына укып булмый. Вакыйф Нуриевның исә М. Мәһдиев якташы булуы сизелә. "Судан килә" диюләре дөрес икән: В. Нуриев талантлы якташы каләмен үзенә алып калган, ахрысы. Шунысы кызык һәм әһәмиятле дә: Вакыйф юк-бар турында да матур хикәя яза ала, бер караганда гади генә булып тоелган нәрсәләр, аның каләменә юлыгып, һәйкәл сурәтен алалар.

Фәрит Яхинның "Бакыр бозау артыннан" хикәясе авторның янә бер баскычка күтәрелүе хакында сөйли. Иң әһәмиятлесе: Фәрит матур, күркәм вакыйгалар аша тормыш хакыйкатьләренең күктән инмәгәнлеген ачып бирә алган:татар халкының яшәеше, бигрәк тә авыл тормышы, үзе үк хәятнең югары ноктасы ул: сатира да бар анда, моңсулык та һәм җиһанның кырыс чынбарлыгы. Автор кеше күңеленең иң нечкә кылларын чиртә алган. Бу нисбәттән минем шуны да әйтәсем килә: нечкә кыллы скрипкага орынган очракта аңа кагылучы бармаклар да тупас булырга тиеш түгел. Авыл хатынын бозык итеп күрсәтү чак кына күңелгә тиде, әлбәттә.

"Казан утлары" һәм "Идел" журналлары ике съезд арасында актив каләмдәшебез Искәндәр Сиражи хикәяләренә киң урын бирде. Бу хикәяләрдә тормыш бар, геройлары "бу—мин!" дип ялтырап торалар. Мәсәлән, китап нәшрияты Әхәт Сафиуллинның "Кешене өмет яшәтә", Әхмәт Гаделнең "Еракта томаннар артында", Әхәт Гаффарның "Энә күзе", Нурислам Хәсәновның "Хакыйкать хакы", Әсгать Сәлахның "Каеннар юлы", Мәрди Рәфыйковның "Урманчы малае" китапларын нәшер итеп шулай ук укучыга зур бүләк ясады. Әхмәт Гадел үзенчәлекле каләм иясе, хикәяләре шушы хакыйкатьне тагын бер кат раслый. Марат Закир хикәяләре дә югары яссылыкта дип бәяләр идем мин. Әхәт Гаффарның исә үзенең Ходай биргән талантына хилафлык китерергә һич кенә дә хаккы юк, бу юлы да ул аңа хыянәт итмәгән. Әхәт Гаффар—чын хикәя остасы. Нурислам Хәсәновны да без хикәяче буларак кабул итәбез. Халыкчан теле, гади һәм гадәти геройлары һәркемнең исендә калырлык. Әхәт Сафиуллин да нәкъ шундый стильгә ия каләмдәшебез, аның юмор-сатирасы да рәхәтләнеп укырлык. Активлыгы исә сокланып, тел шартлатырлык.

Факил Әмәкнең "Курайчылар" хикәясен шулай ук битараф кына укырга мөмкин түгел. Автор үзе язган теманың бик килешле стилен тапкан, матур характерлар тудырган. Фәнзаман Батталлның сатирик хикәяләрен мин үзем аеруча яратып кабул

итттем. Бер караганда, вак кына булган нәрсәләрдән дә Ф. Баттал ачы итеп көлә белә, ләкин шунысы кыйммәтле: ул геройларын мыскыл итми, ә яратып кына чеметә кебек тоела миңа."Идел" журналында Рөстәм Мингалимнең "Сап-сары күзләр" дип аталган чук гүзәл хикәясе басылды. Моңсу хикәя, мәгънәле хикәя. Бу талантлы шәхес каләменнән шундый әдәби әсәрнең төшүен ешрак күрәсе иде, әлбәттә.

"Идел" журналының ике санында Фәнис Яруллинның "Кыйбласызлар" дип аталган повесте дөнья күрде. Бик тыгыз язылган, гыйбрәтле вакыйгалар белән тулы әлеге әсәргә тәнкыйтьчеләребез үзләренең бәясен бирер әле дип өметләнеп калыйк.

Күптән түгел Нәбирә Гыйматдинованың "Мәхәббәттә гөнаһ бар" дигән китабы "табадан төште". Повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы. Геройлары—мәхәббәт корбаннары, кырыс тормыш корбаннары. Китап авторның "Җәза" дип исемләнгән повесте белән башланып китә. Детектив әсәр укыган кебек кызыксынып, бер сулыштан укыла. Аклар да юк анда, кызыллар да, ягъни гел тискәре һәм унай гына булган образлар түгел—анда тормыш үзе, анда Табигатьтәге, хәяттәге бар төсләр дә бар. Бу язучы—диалоглар остасы. Геройларның һәр әйткән сүзе, һәр җөмләсе һәм хәтта ымлыклары аларның характерын ачуга ярдәм итә. Сюжет сызыгы туры юлдан гына бармый, үзенең фикере ягыннан ул калын урман кебек: шул урмандагы һәр агач бар анда, һәр яфрак искән җилдән салмак кына тирбәлеп утыра, шул урмандагы һәр кошның үз тавышы ишетелә. Ошбу повестька ничаклы хис-эмоция салынган, шулар арасына күпме яшерен фәлсәфи фикер—тормыш фәлсәфәсе салынган. Китапка тупланган җиде бәяннең җидесендә дә җитмеш төрле язмыш, бер-берсен кабатламаган геройлар, укучының исендә калырлык, димәк, бәгыренә кереп калырлык якты образлар.

Зәки Зәйнуллинның "Мәүлет гусар" повесте "Казан утлары" журналында дөнья күрде һәм язучы, минем уемча, әлеге образы белән әдәбиятка чын характер, бабаларыбызның гасырдан гасырга бер-берсеннән күчеп килгән корыч характерын алып килеп: "Менә безнең токым нинди булган һәм нинди ул!" дигән хакыйкатьне раслады. Әлеге әсәр авторның бик уңышлы әсәре, корыч рухлы, тимер бәдәнле татар егетенең якты образы буларак кабул ителде ул. Гомумән алганда, бу әсәр миндә милләтемнең киләчәгенә зур ышаныч уятты.

Фоат Садриевның "Бәхетсезләр бәхете" романының беренче өлешләре укучыга күптән таныш иде инде, ул Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып та басылып чыкты. Аксакал прозаигыбыз үзе алынган теманы дәвам итеп, укучының ялкынлы сүнәргә һаман ирек бирми әле.

Нурихан ага Фәттахның "Аклан" дип исемләнгән хыялый романы тәмамланмаган әсәр булса да, шулай ук тарих сөючеләрдә зур кызыксыну уяткандыр дип уйлыйм. Тарих ул—тарих кына түгел, тарих кабатланып тора. Сөекле язучыбыз Нурихан Фәттах әнә шул хакыйкатьне ассызыклый сыман.

Фәкил Әмәкнең "Шәүлә", Рәфкать Кәраминең "Олы юл да сикәлтәле", Гөлнур Якупованың "Күпер", Заһид Мәхмүдинең "Һәркемнең үз юлы", Марат Әмирханның "Үрбәт ханәкә гыйшкы" дип аталган тарихи романы ике корылтай арасында роман жанрының чәчәк атуы хакында сөйли.

Камил Кәримовның "Уен" һәм "Сакау куке" роман-дилогиясе роман жанрын баетып кына калмыйча, әдәбиятта шактый бәхәсләр дә кузгатты. Бәхәс туган икән, димәк, кызыксыну бар. К.Кәрим үзенең үткен каләме белән гаҗәеп матур образлар тудырган. Тагын бер актив романчыбыз—ул Рауль Мирхәйдәров. "Иманыңнан бер язсаң" һәм "Үзем хөкем итәм" романнары шуның ачык мисалы.

Рәдиф Сәгъдинең роман жанрында беренче тәҗрибәсе. Ләкин шулай булуга карамастан, автор бик кызыклы алымнар белән шактый үзенчәлекле "Ирдәүкәләр" дигән әсәр иҗат итүгә ирешкән. "Ике кояшлы дөнья" дип аталган әсәре дә классик стильдән аерыла. Авторның сурәтләгән дөньясы нәкъ геройлары кебек каршылыклы, анда кискен бәрелешләр тулып ята .Әсәрләрнең икесе дә матур тәэсирләр калдырды. Болар дә татар милләте өчен "эшли" торган күркәм әсәрләр.

Равил Вәли "Канатлы татар" дигән роман иҗат итеп, татар укучысына үзенең атаклы баласы хакында тәфсилләп сөйләп бирә.

Тарихи романчыбыз Мөсәгыйть Хәбибуллинны укучы инде күптән үз итте. Миргазыян Юнысның исә һәр язганын без үзебез дә һәрвакыт көтеп алабыз,

үзенчәлекле темага язучы әдип бүгенге әдәбиятыбызда берәү генә ул.

Мин үзем бүгенге көнгә чаклы Вахит Имамовның "Татар япуны" повесте белән тәэсирләнеп йөрим. Ни кызганыч, тәнкыйтьчеләребез бу әсәрне күрмәде шикелле. Автор Казанның меңьеллыгына тагын бер тарихи роман бүләк итте. "Казан дастаны" Казаныбыз тарихы хакында сөйли, аның тарихи чорын сурәтли.

Ике корылтай арасында "Казан утлары" журналында Мәдинә Маликованың "Тылсым" романы дөнья күрде. Әлеге авторның әсәрләрендә монарчы төп урынны әхлак темасы алып тора иде. Ул моннан бернчә ел элек дөнья күргән повестенда гына тайпылыш ясап, "милли тема басуына" кереп чыкты. Һәм бу "керү" бик уңышлы булган иде. Әдибә инде коргаксый барган "басу"га җан өреп, андагы кибә башлаган "үләннәргә" саф су бөркеп, укычысына кадерле бүләк ясады. Күз тимәсен: әлеге автор үз хисабына китап чыгарып, аны үз көче белән тарата да .

"Тылсым"да гаилә мәсьәләләре күтәрелә. Шул ук рухи дөнья, әхлак мәсьәләсе күтәрелә әсәрдә һәм аны бер сулышта укып чыгасың. "Тылсым" М.Маликованың чираттагы уңышы дип бәяләнергә хаклы.

Бу нисбәттән минем һәммәбезгә дә кагылган (прозаикларга) бер четерекле мәсьәләгә бармак очы белән генә чиртеп узасы килә. Соңгы елларда, социалистик җәмгыять юкка чыккач, без иркенәеп китеп, әсәрләребезнең жанрларын үзебез теләгәнчә билгели башладык. Хикәялек материалның мангаена "повесть", "бәян", "кыйсса" дип чәпибез, повестька "роман" дигән кушамат тагабыз. Бу очракта да "Тылсым" романга ук тарта микән? Сюжет сызыгы берәү генә бит!—Мидхәтнең тормыш юлы. Калганнар төп геройның аяк астында буталучы персонажлар гына миңа калса.

"Тылсым"да мине сөендергән тагын бер нәрсә, ул да булса, геройларның чыгышлары. Мидхәт—Пермь ягыннан, Әнисә—Молдавиядән, калганнар—Себердән. Болар дөнья буйлап сибелгән татарның газиз балалары.

М. Маликованың әсәре бигрәк тә яшь укучы өчен кыйммәтле. Язучының иратны кызганып әйтелгән фәлсәфи фикерләре кызыклы гына.

Фәүзия Бәйрәмова романнары хакында сөйләшүне мин махсус ахыргарак калдырдым. Иркенләбрәк сөйләшү максаты белән, әлбәттә. "Караболак" романы белән укучы "Казан утлары" журналында танышкан иде инде. "Кырык сырт" китабы исә берьюлы өч романны эченә алган: "Кырык сырт", "Караболак", "Соңгы намаз" романнары. Шунысы игътибарга лаек: Чернобыль шартлавы бөтен дөньяга билгеле булганлыктан, анда зыян күрүчеләрне кайгырткан булып кыланган абзый-түрәләр санына да җитми китапның тиражы. "Караболак" китапта икенче булып урын алган. Әгәр мин, Фәүзия ханымга өстәп, аны куәтләп:"Татар булганнары өчен ул кешеләрнең фаҗигасен үз вакытында яшерен сер итеп сакладыгыз! Татар халкы кырылганны читтән көлеп карап тордыгыз!" дип әйтәм икән, бу гаепләвемә каршы берәүнең дә: "Юк, алай түгел!"—дип каршы килә алмасына иманым камил...

"Кырык сырт" романы. Шәхес культы вакытында, немецлар белән булган сугышта халык чебен кебек кырылды дигән хакыйкатьне, шөкер, күптән беләбез. Бу саннарны, фактларны халыктан яшерә алмадылар. Ә монарчы татарның Урал заводларын салганда, Чиләбедә "Маяк" авариясе вакытында, Донбасс шахталарында, Мурманскида балык тоту корабларында меңнәрчә, йөз меңнәрчә кырылганын, юкка чыкканын белә идекме соң без?!

Ахыр чиктә, Чаллыны төзегәндә Советлар иленнән җыелган бандит, шпана арасына саф татар авылларыннан шәмдәй егетләрнең, сылу кызларыбызның барып кереп, милли шәхес буларак тузанга әйләнгәнен беләбезме соң? Монысы бит ерак тарих та түгел бит әле! Монысы—бүгенге язмышыбыз... Хәер, заманында үзенең "Мирас" романында Разил Вәлиев бу хакта чаң каккан иде инде.

"Мәгариф" нәшрияты нәшер иткән проза китапларына күз салыгыз! Андый югары китап культурасы хәтта Мәскәүнең үзендә дә юк!...

"Җыен" һәм "Рухият" фондларының китаплары хакында бу съездда зур сүз булып, алар бик югары бәһа алырга тиешләр! Мин әлеге фондлар алдында башымны иям!..

Шулай ук Идел-пресс каршындагы "Сүз" нәшрияты, "Салават күпере" журналы каршындагы "АК БАРС" нәшриятлары да халыкка искиткеч файдалы китаплар нәшер итәләр.

...Ике корылтай арасында Марсель Галиевнен "Рух" дип аталган шигъри романы дөнья күрде. Менә шуннан бер өзек: "Халыкның холык-табигате, тарихы, гореф-гадәте, омтылышы, уй-гаме сүзләргә сыйган. ...Тел тәмен җуйган—моның да җуя. Кешенен тәнен, җанын туган тел сугарып килә, ул аның холкын билгели, аң-зиһененә чиксез үсеш мөмкинлеге бирә, шул телнен эчке хасиятеннән яралган җыр-моң исә кешенен халәт рухиясенә дәва, омтылыш дәрте өсти...

...Шумердан башлап Фарсистанга, Һиндстаннан алып Төньяк Кытайга, Ерак Көнчыгыштан Урта Азиягә, Уралдан алып Карпатка кадәрге төрле заманнарда төрки тел хакимлек иткән ил-җирләрдәге экзотик үсемлекләргә иелсән....алар һәммәсе:

—Минем исемем—синең җисемен!—дип эндәшер шикелле. Сүз—пирамидаларга кадәр туган, Сүз—пирамидалардан соң да калачак..."

Ошбу китап дөнья күргәннән соң менә бу хакта ничә татар кешесе белде, үз-үзенә ачыш ясаган дип уйлыйсыз? Ике мен, бары тик ике мен!!! Чөнки китапның тиражы ике генә мең данә!

Ике корылтай арасында дөнья күргән янә бер романнан берничә җөмлә: "...Урал татар кулыннан киткән, андагы байлыкка кызыгып, бу якларга кыргый һәм явыз кавемнәр килеп тулган. Урал белән бергә Себер киткән, Тургай далалары, Идел-Җаек киткән. Чит кавем саранча кебек, барысын басып алган. Алар горур тау ирләренен ил-җирләрен тартып алганнар, телләрен, тарихларын, диннәрен җимергәннәр, кол булып үзләренә эшләргә мәҗбүр иткәннәр. Татарлар бу явыз юәҗүҗ-мәәҗүҗ кавеме өчен тау актарганнар, тимер чыгарганнар, корал ясаганнар, шәһәрләр төзегәннәр, җир сөргеннәр, икмәк үстергәннәр.

Аларга янадан, үз җирләренә кире кайту өчен, телләрен һәм диннәрен, хакыйкатьне торгызу өчен, тарихның кырык сыртын үтәргә кирәк була. Әмма бу кырык сыртны кичү серләрен инде бик азлар гына белә булып чыга..." Күпме соң ул язучының "азлар" дигәне? Мин Фәүзия Бәйрәмованың "Кырык сырт" романын эченә алган китапның артына күз салам: нибары өч мең тираж; китапка шулай ук "Соңгы намаз"дип исемләнгән әсәр дә кергән. Чечня сугышында башын салган татар егетенең язмышы... Китапның тиражы Әфганнан, Чечнядан татар егетләрен салып алып кайткан цинк табутлар санына да җитми хәтта! Шул пәһлеван егетләрнең елаудан, кайгыдан сукырайган аналары санына җитәр дип уйлыйсызмы?! Хәсрәтләрен таш итеп бәгырьләренә йоткан аталар, тол хатыннар санына тиңләшә алыр ул тираж, бәлки!.. Юк, өч мен тираж бу саннарга да тиңләшә алмый. Шул табутлар саны чаклы да китап нәшер итеп сата, тарата алмыйбыз бит без халыкка. Ояты безгә булсын!...

Бу "Таткниготорг" хезмәткәрләре җыелышы түгел. Шулай ук тиражлар хакында, аларны халыкка сату проблемасы хакында сүз кузгатуым бик урынлы дип исәплим. Чөнки без язган китаплар җиде миллионлы татар халкының чирегенә булса да барып ирешергә тиеш. Безнең әлек үз дәүләте, үз тәхете булган тарихлы халык шундый шартларга куелган ки, ул бары тик эчке энергиясе хисабына гына үз-үзен саклап кала ала. Үз-үзен саклау инстикты шул чаклы зур ки бу халыкта! Уйласаң, шаклар катасың...

Минем уемча, "китапны компьютерлар, интернет алыштыра" дигән кешеләрдән дә ахмагырак адәмнәр юк. Дөнья галимнәре, төгәлрәк итеп әйткәндә: психологлар, социологлар озак еллар күзәтү-өйрәнүләр нәтиҗәсендә шундый кызыклы ачышка тап булганнар: (9 яшьтән алып 19 яшькәчә балалар, яшүсмерләр өйрәнелгән) көненә 1 сәгать әхлакый, матур әдәбият укудан бала алган рухи байлыкның кыйммәте, 30 сәгать тәрбия дәресен, югары уку йортларында 15 сәгатьлек гуманитар лекцияне алыштыра ала икән! Ачыклык кертик: сүз яшь укучы баланың дөньяга карашын киңәйтү, рухи, күңел байлыгын арттыру һәм баш миен эшләтү, уйлау сәләтен арттыру, ягъни логика-мантыйгын шомарту турында сүз бара. Менә шуннан соң татар китабының халыкка таралу системасын көйләргә, эзгә салырга тиешле кешеләр генә түгел, без, язучылар, кулга каләм алыр алдыннан нинди дәрәҗәдәге әсәр язарга тиешлегебез хакында уйланырга тиешбез. Бер каптырмалы хикәя, повесть, романнар укучыбызның вакытын гына үтерәчәк!.. Соңгы вакытларда компьютерлар аркасында яшьләр арасында килеп чыккан киеренке хәлләрдән барыбыз да хәбәрдар. Интернет белән артык мавыгу бигрәк тә яшьләребезнең психикасына тискәре йогынты ясый, шул сәбәпле төрле җинаятьләр кылына. Күптән түгел шул Интернет аркасында

Рәсәйдә бер татар малаен үтереп ташладылар. Димәк, рухи яктан гына бетү бармый икән, милләтебез Интернет аркасында физик яктан да кырыла. Тизрәк китапка кайтарыйк балаларыбызны, яшьләребезне! Шәп, талантлы каләм белән язылган китапка кайтарыйк!.. Мин компьютер-интернетларга каршы кеше түгел, ләкин һәр нәрсәнең чамасы бар.

Әйткәнемчә, хәерче прозаик беркайчан да үзе яшәгән җәмгыятьтәге түрәләрне халык хөкеменнән яклап, аклап роман язмаячак. Ул аны сүгәчәк кенә, чөнки ул—үзе хәерче, аның нәрсә икәнлеген яхшы белә. Еллар буе каләмен канына мана-мана язган романына прозаик бүген 30-40 мең акча ала. ТАССР вакытында язучының хәле яхшырак иде. Әллә кире шул чорларга кайтып яшәргә инде?...

Ничек итеп татар прозасын яшәтергә, аны халыкка хезмәт итүгә җигәргә соң? Мин алга конкрет сорау куям һәм шул нисбәттән төгәл тәкъдимнәремне дә житкерәсем килә.

1. Бер китап нәшер иткән гонорар язучыга тагын ике ел буе кайгысыз, Илһамланып, рухланып яна әсәр язарга житәргә тиеш. Шул нисбәттә Китап нәшриятларының бюджетын арттыру мәслихәт.

2. Татарстанның бар кибетләрендә (шул исәптән шәхси кибетләрдә дә, чөнки алар Татарстан жирендә урнашкан) китап бүлекләре булырга тиеш. Моның өчен Респуплика житәкчесенең, түрәләрне жыеп, бер сүз әйтүе дә житә.

3. Татар халкы дөнья буйлап сибелгән. Димәк, безнең романнардагы вакыйгалар Татарстан чикләре белән генә чикләнергә тиеш түгел. Прозаикларны озак срокларга Рәсәй буйлап түләүле командировкаларга жибәрергә тиешбез. Безнең "кулга тотып" карарлык унлап прозаигыбыз бар, аларга киткән чыгымнар артык күп булмаячак.

4. Хөкүмәт, прозаиклар белән алдан ике-өч елга договор төзеп, зур әсәр язарга ирек , аларга мөмкинлек бирергә тиеш. Ләкин язучыга "шул темага яз" дип, күрсәтмә ясап түгел; прозаик темасын, язарга алынырга теләгән чорын, проблемасын үзе тәкъдим итәргә тиеш.



Зиннур
Мансуров

# ШИГЪРИЯТ УРТАЛЫКНЫ ӨНӘМИ

ПОЭЗИЯ

Икеләнмичә әйтергә мөмкин: бүгенге хәл-әхвәле ничек кенә бәяләнмәсен, шөкер, шигъриятебезнең илаһи рухы һәрвакыттагыча исән-аман! Мәдәниятле тормышның янар чәчәге буларак, гамь-борчулы кальбебезне хушландырудан туктамый. Юк, безнең шигърият талчыктыргыч ыгы-зыгылы чынбарлыктан качып тору урыны түгел, ул халыкның рухи үсешендә үзен һәрдаим җаваплы итеп тоя. Кайчак уенчакка әйләнүчән гавамның күңелен ачып яшәү аның өчен бик бәләкәй максат булыр иде. Сентименталь җаннарда ләззәтле матурлык хисен генә уяту татар шигъриятендә элек-электән беренче бурыч рәвешендә куелмаган. Безнең күпчелек әсәрләребез кешенең рухын формалаштыруга, җәмгыятьнең әхлак табигатен яхшыртуга турыдан-туры хезмәт итә. Ә моның өчен каләм әһелләренең югары профессиональлеккә ия булуы зарур.

Шапырынмыйча гына әйткәндә, шагыйрьләребез соңгы елларда да шушы олуг максатларны тирәнтен сиземләп, халкыбызның үткәне белән бүгенгесенә киләчәк югарылыгыннан карап иҗат итте. Барлык шигъри жанрларның әдәби барышта үзләрен үсештәге организм итеп тоюы да, газит-журнал битләрендә тезмә әсәрләрнең тулы яңгыраштa мәйдан тотуы да, китап нәшриятларында төрледән-төрле җыентыкларыбызның күпләп чыгуы да шуны раслап торадыр. Әйтик, язучыларның ике корылтае арасында Татарстан китап нәшрияты гына да төрле буын шагыйрьләрнең йөзгә якын җыентыгын укучылар хөкеменә тапшырды. Алар арасында Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиевнең күптомлыклары да бар. Дөрес, әле генә санап үтелгән шагыйрьләр иҗаты төрле чорларга карый, кайберләренең язганнарын соңгы еллар казанышы итеп санап та булмыйдыр. Әмма алар китап продукциясе буларак тулаем бүгенге гамәлләребез исәбенә керә. Гомумән, һәртөрле күптомлыклар әдәбият сөючеләрнең гомерендә тулы бер эраны тәшкил итә, һәм алар киләчәккә барырга үзенчә булышучы шигърияткнең зурлыгын да күрсәтеп тора. Бу җәһәттән Рөстәм Мингалим, Зөлфәт, Клара Булатова, Марсель Галиев, Айдар Хәлим, Флера Гыйззәтуллина, Лена Шагыйрьҗан, Әхмәт Рәшит, Салисә Гәрәева, Харрас Әюп, Мөхәммәт Мирза, Газинур Морат, Илдус Гыйләҗев, Фирая Зыятдинова,Шамил Маннапов, Шәмсия Җиһангирова, Рөстәм Акъегет, Гарифҗан Мөхәммәтшин, Рим Идиятуллин, Ләбиб Лерон, Шәүкәт Гаделша, Хәмит Латыйп һ.б. ларның нәшриятта дөнья күргән аерым җыентыкларын да шигъриятебезнең соңгы еллардагы казанышларын үзенчә кристаллаштырган басмалар рәтенә икеләнмичә куярга мөмкин. Алар турында матбугатта чыккан бәяләмәләр дә шулай кистереп әйтергә нигез бирә.

Гадәттә, әдәби иҗат өлкәсендәге уңышларыбызны барлаган чакта без хаклы рәвештә башка нәшриятларны да телгә алабыз. Әйтик, "Мәгариф" нәшрияты чыгарган китапларны күздән кичермәсәк, язучылык эшчәнлегебезнең хисабы тулы булмас иде. Монда басылып чыккан егермеләп китап та шигъриятебезнең биеклектә калуы хакында сөйли. "Рухият"тә Рәдиф Гаташ, Эльмира Шәрифуллина, Наис Гамбәр кебек шагыйрьләребезнең саллы җыентыклары нәшер ителү дә Пегасатыбызның әдәбият арбасын төпкә җигелеп тартуын дәлилләүче гамәл булып тора. Соңгы вакытта "Сүз" һәм "Чаллы" нәшриятлары да шагыйрьләребез иҗатына зур игътибар күрсәтеп килә. Шунысы да сөендерә: рәхмәт хисләре белән санап үтелгән наширләребез талантлы яшьләребезне дә даими кайгыртучанлык үзәгендә тоталар. Югарыда телгә алынган нәшриятларда Габделнур Сәлим, Марат Закир, Мансур Сафин, Гөлзадә Бәйрәмова, Луиза Янсуар, Ленар Шәех, Гөлназ Вәлиева, Гөлнур Корбанова, Рифат Сәлах, Ләйсән Юнысованың мөстәкыйль җыентыклары дөнья күрү аерым елларда хаклы-хаксыз рәвештә "шигъри бушлык" яки башка яманатлы мөһерләр сугылган шигъриятебезнең дәвамчанлыгына барыбер дә ышаныч уята.

Һәммәбез дә яхшы белә, хәзерге "прозаик заман"да шигырь арты шигырь язып, күпшы метафора тапканга куанып кына яшәргә ярамый. Лирик дөньяны беркадәр артка чигендергән чор аңлы рәвештә реалист булуны таләп итә. Мондый шартларда халык язмышы белән яшәүче каләм иясенең көндәлек мәшәкатьләр ягына таба авыша төшүе, аеруча шагыйрьләрнең җәмгыятьтәге теге яки бу мәсьәлә уңаеннан үз мөнәсәбәтен белдереп баруы бик табигый. Ә каләм әһеленә шулкадәр зур вазифа йөкләнгән ки, аны борчыган мәсьәләләрне санап та бетереп булмыйдыр. Шуңа күрә безнең шагыйрьләр кирәккән очракта җан авазын чәчмәдә белдерүне ниндидер шигъри сентенция иҗат итүдән күпкә өстенрәк санаган. Аларныниләр генә тынычсызламый: милли дәүләтчелегебезне торгызу зарурлыгы да, ана телебезнең тәшвишле язмышы да, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре дә, халык тормышындагы эреле-ваклы каһәгатьсезлекләр дә... Күреп торабыз, күпне колачлаган мәдәният экологиясе киләчәккә атлаган саен кискенрәк төс ала. Отыры тармакланып торган менә шундый катлаулы проблемаларны ничекләр итеп "тар шигырьләр үлчәве"нә сыйдырмак кирәк!

Икърар кылмыйча мөмкин түгел, мондый мөһим юнәлештәге эшчәнлектә дә шагыйрьләребез зур активлык күрсәтте, көндәлек матбугатта публицист буларак чыгыш ясап, көнүзәк мәсьәләләргә багышланган мәкаләләрен җыентык итеп чыгарырга да өлгерде. Ошбу раславымны мин ин беренче чиратта Айдар Хәлим,

Разил Вәлиев, Марсель Галиев, Эльмира Шәрифуллина, Рашат Низами, Шаһинур Мостафинның төрле нәшриятларда басылган китапларын күз алдында тотып әйтәм. Соңгы елларда шагыйрьләребез Мәскәүдә чыга торган газит-журналларда да һәм хәтта Интернетта да чагыштырмача ешрак күренә башлады. Кыскасы, безнең әдәби хәрәкәттә катнашуыбыз шундыйрак гамәлләребез аша күзаллана.

Әдәбият белеме классиклары искәрткәнчә, сүз сәнгате—халыкның аң-зиһене ул. Әлеге нигъмәтнең камиллеге исә иң әүвәл төрлелектә чагыла. Һәм үзенең олуг максатлары буенча социаль күренешләр җөмләсеннән саналган шигърият тә халыкның рухи асылын форма-жанрлар төрлелегендә генә тулысынча ачып бирә ала. Бу җәһәттән соңгы елларда яхшы мәгънәсендәге чуарлык күзгә ташлана, ягъни шагыйрьләребез иҗатында шигъри фикерләүнең һәрбер төре гәүдәләнеш таба: поэма да, баллада да, сонет та, робагый да... Алыйк поэма жанрын. Исегезгә төшерәм, олуг әдәбиятебез тарихына күз салсак, без анда иң элек зур күләмле шигъри әсәрләрнен—дастан, кыйсса, поэмаларның аерым биеклекләр булып торуын күрербез. Гасырдан гасырга шулай дәвам итә... Шагыйрь шәхесенең зурлык перспективасын аеруча ачык күрсәтүче поэма жанры, икеләнмичә расларга мөмкиндер, бүгенге заманда иҗтимагый янгыраш мөмкинлекләрен эзлекле рәвештә кинәйтә төште. Гомумән, сөенечле күренеш—поэма эзләнү юлыннан барып, төрле яктан янарыш кичерә. Һәм иҗтимагый чынбарлыкка мөнәсәбәт җәһәтеннән дә. Монда житди алшартларның берсе шуннан гыйбарәт булса кирәк: шагыйрь эчендә утыручы "общественный деятель" соңгы чорда күпмедер калкынып куйды.

Әдәби иҗатыбызның торышын ап-ачык итеп күрсәтеп торган "Казан утлары" журналында соңгы өч ел дәвамында җәмгысе биш поэма дөнья күрде. Болар—Әхмәт Рәшитнең "Казан", Рәсимә Гарифуллинаның "Ак сарайда серләр бар", Лена Шагыйрьҗанның "Галәм кисәтүе", Рәниф Шәриповның "Меннән бер өлеш" һәм Нур Әхмәдиевнең "Дәрдемәнд" исемле поэмалары. Шулай ук "Мәйдан", "Идел" журналларында, "Мәдәни җомга" газитендә һ. б. басмаларда да әлеге эпик колачлы жанрга караган дистәдән артык әсәр басылып чыкты. Алар арасында Ренат Харисның "Кадрия", Фәнис Яруллинның "Йөрәк тавышы", "Нурсөя", Флера Гыйззәтуллинаның "Хак-дөресен йөрәк сөйләрме?..", "Дисәнә", Эльмира Шәрифуллинаның "Әткәй күнеле" дип исемләнгән поэмалары да бар. Санап үтелгән әлеге әсәрләрнең күпчелеге безнең игътибарны халкыбызның үткәненә юнәлтә. Табигый ки, милли үзаң уянган заманда тарихка ихтыяҗ нык артты.

Поэма жанрын үстерүгә үзеннән зур өлеш кертергә өлгергән шагыйрь Әхмәт Рәшит безнең геннарыбыз авазын тыңлый алу сәләтенә ия булуын инде күптән раслады. Тарихи теманы үзләштерүдә ул эзлеклелек күрсәтеп килә. "Сөембикә" поэмасыннан соң "Кол Шәриф" язылды. Аннары "Мөхәммәдъяр"... Тарихи затларыбызга багышланган әлеге әсәрләр әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде. Чыннан да, шигъри трилогияне хәтерләткән бу поэмалар, бер-берсен тулыландырып кына калмыйча, халкыбызның күптән көтелгән тарихи сурәтенә җете шәрехләр дә өстәде. Шагыйрьнең соңрак дөнья күргән "Казан" поэмасы исә үзенчәлекле хатимә, шушы мөкатдәс теманы беркадәр гомумиләштергән эпилог буларак кабул ителә.

Югарыда телгә алынган авторларның әсәрләрен берәм-берәм "сүтеп җыярга" максат кылмыйм. Әмма кыскача гына булса да шуны әйтеп үтәсе килә: төрле каләм өслүбе белән язылган бу поэмаларда рухыбызның көнүзәк мәсьәләләре уртак җептәй сузылып бара. Бу җәһәттән Лена Шагыйрьҗанның "Галәм кисәтүе" поэмасы үзенең шигъри гомумиләштерү тирәнлеге белән аерылып тора. Яшәешебезнең бик күп якларын колачлаган әлеге катмарлы әсәрдә кешенең бүгенге халәте рухиясе галәми масштабта яктыртып күрсәтелә. Киная дулкынына корылган рентген барысын да ачып бирә. Баксаң, адәм баласының байтак күркәм сыйфатлары куркыныч дәрәҗәдә деградацияләнә икән бит. Инсан үзенең төп миссиясен дә отыры онытып бара кебек...

*Торган саен узына ул,*
*Үзен үзе зурга куеп,—*
*Куылыр чиккә җитеп Җирдән,*
*Кешелек дәрәҗәсен җуеп...*

Шунысы кыйммәт: Лена Шагыйрьҗанның homo sapiens турындагы фәлсәфи

уйлануларында ниндидер косполитик шаукымга бирелү сизелми, чөнки без шагыйрәнең милли җирлеккә нык басып торган иҗатчы булуын яхшы беләбез. Үзебезнең әхлак югарылыгыннан торып язылган "Галәм кисәтүе" поэмасында да нәкъ менә милли шагыйрә шәхесенең мөһере сугылган идея үткәрелә. Минем уйлавымча, кырыс хакыйкать сулышы бөркелеп торган әлеге әсәр, һичшиксез, соңгы еллар шигъриятенең унышы булып саналырга хаклы.

Әлбәттә, берничә ел эчендә генә ниндидер яңа тенденцияләр барлыкка килми, әмма әдәби хәрәкәтне тулаем күзәткәндә кайбер яңалыклар барыбер күренгәли. Тәгаенрәк әйткәндә, шәкел-жанр өлкәсендә онытыла башлаган искене искә төшергәндәй, тематик тупламнар соңгы чорда янә янарыш кичерде. Югыйсә эчтәлек юнәлеше ягыннан берниндн уртаклыгы булмаган шигырьләр дә әдәбият сөючеләргә чып-чын цикл рәвешендә тәкъдим ителә башлады. Шигъри тупламнарны янача терелтү турында сүз алып барганда шагыйрь Фәнис Яруллинны иң беренче итеп атыйсы килә. Соңгы өч ел дәвамында "Мәдәни җомга" газетендә генә дә ул бербөтен әсәрдәй укылышлы алты шигъри туплам бастырып чыгарды: "Без табигать балалары", "Чорлар күләгәсе", "Елмаеп көн жаны ялралды", "Җәй кызы", "Әйләнәсең дә киләсең...", "Яратыгыз әле мине, кызлар!.." Форсат чыккан чакта әйтеп үтәргә телим: миллионнарның уй-гамьнәрен күкрәгендә йөрткән шушы гаҗиз зат, гәрчә сәламәтлеккә туймаса да, үз әсәрләре аша күпләргә яшәү дәрте өләшә. Алай гына да түгел, ул безгә яшәүнең мәгънәсен һәм бәһасен аңларга ярдәм итә. "Сары тап"ны кояшка әверелдерә алучы оптимист иҗатчы мораль укымый, үзенең идея-фикерләрен укучыга үҗәтләрчә көчләп такмый, җәмгыятьтә туып торган социаль күренешләргә коры кимәлдә анализ ясамый. Ул образлы телдә сурәтли генә. Юк, аның әсәрләрендә авторның үкенечле тәкъдир сынаулары бүлтәеп чыкмый, киресенчә, күңел яктысы белән өртелгән халык язмышы үзәккә алына. Нәкъ менә шушы асыл сыйфатлар шагыйрь иҗатының әһәмиятен дә билгели.

Соңгы берничә елда үз иҗатын калкытып куюга ирешкән шагыйрь Мөхәммәт Мирзаның "Адәм баласына" исеме астында берләштерелгән бишьюллыкларын да кешенең рухи асылына "үткән, бүгенге, киләчәк" призмасы аша карап бәя биргән үзенчлекле шигъри тупламнар рәтенә куярга мөмкин. Автор тарафыннан торымнан-торымга дәвам иттерелә торган әлеге әсәр, өлешләп-өлешләп, "Казан утлары" журналында һ.б. басмаларда дөнья күрде. Шагыйрьнең 2007 елда чыккан "Тере су" исемле китабында да "Адәм баласына" тупламы игътибарны җәлеп итәрлек дәрәҗәдә бирелгән. Дөресен әйтик, эчтәлек һәм форма өлкәсендә эзләнүдән туктамаган каләм озак вакытка җитәрдәй бәрәкәтле тематик катламнарга эләккән. Тупламның үзәгендә торган кеше кайсы яктан гына ачылмый?! Нинди генә сыйфатларга ия түгел икән адәм баласы?! Алар арасында яхшысы да, яманы да хәттин ашкан. Әгәр шулай әйтергә яраса, шигъри гамәл дәфтәре күз алдына килә. Авторның максаты ачык: ул рухи энциклопедик киңлектә язылган лирик-фәлсәфи уйланулары белән кешелек җәмгыятен үз-үзен һәлак итүдән саклап калырга тели.

Борчылырлык түгел шикелле, шигърият элгәрләрдән килгән юлын табигый агышта дәвам иттерә. Аның яшәешебез нигезе белән бәйләнеше элеккечә нык булып кала бирә. Әхлакый зәмине дә саегуны белми. Ул үз заманының да бурычын үти, мәңгелекне дә шактый ук яхшы тоя. Безнең шигъриятә куркусызлык та, тәвәккаллек тә җитәрлек дәрәҗәдә. Бәс, шулай икән, без шушы кыйммәтләрне тирәнәйтүгә бүген дә үзләреннән өлеш кертеп килүче затларга, тәгаенрәк әйткәндә, Роберт Әхмәтҗан кебек асыл шагыйрьләргә олуг рәхмәтебезне белдерергә тиеш түгелме соң?!

*Тезелеп калсын иҗат тотәлләрең,*
*чәчәкләнеп шигырь Илендә!*
*Затлы орлык кебек сикереп төшәр*
*тере сүзләр булсын телеңдә!..*
("Шигырь Иле")

Әгәр сәнгатьчә матурлыкта гамьле җитдилек төсмерләнергә тиеш икән, мин моның мисалларын иң әүвәл Роберт Әхмәтҗан иҗатында күрәм. Һәм татар теленең шагыйрьләр теле булуын искәртсәләр дә, аның шигырьләре ниндидер сихри кәрван рәвешендә күңелемнән уза.

Әлбәттә инде, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гаташлар буыны шигъри жанр мөмкинлекләрен ачуда төпкә җигелеп тартучы шагыйрьләр булып кала бирә. Зур тәҗрибәле өлкәннәр хаклы: әгәр югары зәвыклы талант көчле фикер-хис юнәлешенә кертелсә, гадәттә, андыйлар үзләренең эзләнүчән иҗатында бик күп нәтиҗәләргә ирешә. Быел 19-20 яшьтә язган шигырьләрен беренче тапкыр матбугатта чыгарган Гәрәй Рәхим, әйтерсең, үзенең иҗат кыләчәге турында мондый фаразлы сүзләрен һәрбер буындашы исеменнән белдергән:

*...Шигъри дөньям бик киң минем,*
*Беркайчан да таба алмам аның чиген.*
(“Шигъри дөньям”)

Ерак Көнчыгышта яшәп алган чакта гаҗәеп урынны күрүем хәтердә тора. Янар тау итәге. Илаһи җылылык бөркеп торган мең толымлы теп-тере шарлавык. Нилэр генә үсми биредә! Мондагы яшеллек дөньясының үзгәрәк булуы, валлаһи, миндә аңлата алмаслык тәэсирләр уятты. Шигъри осталык биеклегендә торган Шәүкәт Галиев, Әхсән Баян, Флера Гыйззәтуллина, Марсель Галиев, Харрас Әюп, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулланың әсәрләрен укыганда да мин үземне бихисап хис-тойгылар өермәсе кузгаткан мөкатдәс гамь, моң һәм гүзәллек тулы үзгә бер реаль дөньяда итеп сизә башлыйм. Юк, чит түгел ул. Бу дөньяда һәрбер нәрсә дә газиз, шунлыктан, мондый шигърият күңелне үстерүгә хезмәт итә.

*Әллә кем дә түгел кебек,*
*Ә бит нинди сүзе!*
*Нинди генә булса да, ул—*
*Милләтенең йөзе.*

Белмим, Роберт Миңнуллин “Шагыйрь” исемле әлеге шигырен кемне игътибар үзәгендә тотып язгандыр, әмма бүгенге татар шигъриятендә милләтебезнең йөзе булырлык каләм әһелләре аз түгел. “Ә бит нинди сүзе!” дигәндә, әйе, шагыйрьләребез күпләп күз алдына килә: Резеда Вәлиева, Әхмәт Гадел, Госман Садә, Бикә Рәхимова, Рәфикъ Юныс, Нур Әхмәдиев, Фарсель Зыятдинов, Әмир Мәхмүдов, Нәҗибә Сафина, Рафаил Газизов, Рафис Корбан, Асия Юнысова, Җәүдәт Сөләйман, Илсөяр Иксанова, Фәйрүзә Мөслимова, Рамис Әймәт, Флера Тарханова, Рифә Рахман, Фәүзия Солтан, Рәзинә Мөхияр, Гөлнара Җәлилова, Рөстәм Зәкуан... Башкортстанда яшәп иҗат итүче Фәрит Габдерәхим, Халисә Мөдәррисова, Салават Рәхмәтулла, Дилә Булгакованы ничек инде милләт өчен җан аткан яхшы шагыйрьләр җөмләсенә кертмисең?!

Күргәнебезчә, шигъриятнең хәле алай ук зарланырлык түгел—безнең көнелләрдәге шигырь уты элеккечә исән-сау. Ул чынбарлыкка карата мөстәкыйль рәвештә үтемле сүзен әйтә ала һәм үзенең укучыларына да шундый ук мөстәкыйльлекне тәрбия кыла. Әмма шушы уңайдан кайбер күзәтүләрем белән уртаклашмау хакыйкатькә күрәлтә хилафлык китерү булып саналыр иде. Минем карашымча, соңгы елларда шигъриятебезнең профессиональ дәрәҗәсе күзгә күренеп төшә башлады сыман. Житди сәбәпләрнең берсе “кадрлар мәсьәләсе”нә, ачыграк әйткәндә, чын-асыл шагыйрьләребезнең азаеп калуына бәйледер.

“Безнең белән ул-бу була калса...” Әдәби алмаш мәсьәләләренә багышланган бер мәкаләсендә Сибгат ага Хәким шулай язган иде. Безнең белән ул-бу була калса... Шактый шомлы сүзләр. Шигъриятә көчләрнең кимиячәген, әйтерсең, аксакал алдан сиземләгән. Менә шундый тәкъдири фаразлаудан соң никадәр алтын баганабыз киселде! Соңгы берничә елда гына да без күпме асыл шагыйребезне югалттык: Илдар Юзеев, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗан... Шулай ук Наис Гамбәр белән Нияз Акмалның үлеме дә күктән бирелгән талантлар сафының сизелерлек дәрәҗәдә сирәгәюенә китерде. Каләм әһелләренең иң яхшыларын гына, гүяки, тегендә кемдер “мальчишник”ка җыеп тора. Урыннары җәннәттә булсын!.. Дөрес, изге урын буш тормый. Әмма чынлыкта аларның кабатланмас урынын үзләренә лаеклар алгандыр дип уйламыйм.

Сүз дә юк, бүгенге шигъриятебездәге үсеш сызыгының беркадәр төшүгә баруы

аерым затларның мәңгелеккә китүенә генә бәйле түгел. Соңгысы безнең ихтыярдан тормый. Сәбәпнең иң зурысы каләмдәшләребезнең профессиональлеккә игътибар биреп житкермәвенә, төгәлрәк әйткәндә, поэтика кануннарын тирәнтен аңлап эш итмәвенә кайтып каладыр. Гадирәк итеп аңлатканда, безнең ташка басылган бик күп әсәрләребез сәнгатьчә оешып житмәгән, алар төрле образлылыктагы сүзләр жыелмасыннан торган ниндидер "полуфабрикат"ны хәтерләтә. Нәтиҗәдә, ритмга игътибар чамасыз кимеде. Алама рифмаларның үрчүе тезмәнең тәмен җибәрде. Шигырьнең әүвәлге юлларын бер үлчәмдә башлап, аннары икенче төрле иҗек санына күчеп, өченче үлчәмдә төгәлләү гадәти күренешкә әйләнде. Сүз сәнгатенең иң мәһабәт формасы булган шигырьне күрәләтә ниндидер коры карикатурага авыштыра баручылар бермә-бер ишәйде. Ркаил Зәйдулла төшендереп әйткәнчә:

*Арзанайды сүзләр. Гүя томан,*
*Гүя рәшә, гүя күләгә...*
*Ә чын шигырь—Тукайдагы сыман—*
*Тишек үпкә белән түләнә.*
*("Арзанайды...")*

Чынбарлыктан шигърилекне сайлап алу тәгаен ярты талантка бәрабәрдер. Без исә нәзакәтле тезмә формасына, көчле-көчле, ниләр генә кертергә маташмыйбыз икән?! Гап-гади публицист каләме белән күтәрелергә тиешле темага да лирик жанрлардан саналган ода күлмәген кидертмәкче булабыз. Әлбәттә, "күбәләкләр турында дөресен жырлау" гына шагыйрьлек вазифасын бик тарайтып аңлау булыр иде, әмма шигырьдә "общественный деятель" икәнлегеңне калкытып күрсәтү өчен зур талант таләп ителә. Әйтик, аеруча мөһим иҗтимагый-сәяси теманы тезмә калыбына керткәндә Дәрдемәнднең "Караб"ы безгә үрнәк булып торырга тиеш.

Ярты талант, димәктән, шуны да әйтеп үтәсе килә: язу үзе дә ярты талантны гына аңлата, аның икенче яртысы начар язылганны сызудан гыйбарәт. Татар халкында язу-сызу сүзләре тикмәгә генә бергә йөрмидер. Безнең каләм әһелләренә исә нәкъ менә сызу таланты—язганын сәнгать таләпләре кушканча кат-кат төзәтү сабырлыгы җитми. Кабаланабыз. Җитмәсә, арабызда көнгә 5-6 шигырь язам дип үзләренчә мактанып алырга яратучылар да очраштыргалый. Соңгы елларда аеруча күбәеп киткән кыска шигырь тупламнарында да авторлардагы сызу талантының җитәрлек булмавы күзгә бәрелеп тора. Санның сыйфатка сугуын күргәндә, үзалдына көрсенеп куйгандай итәсең: мәдәни үсешкә китергән сәнгать әсәрләрен, юк, конвейер алымы белән ишәйтеп булмый.

Иң аянычы, шигъриятебезнең гомум дәрәжәсен төшерүгә китергән мондый хәлләр хәтта абруй казанган шагыйрьләр иҗатында да күзәтелгәли. Вазифам буенча байтак вакыт кулъязмалар белән эшләвемнән чыгып әйтәм, үзләренең язганын сәнгатьлелек ягыннан камиллек дәрәҗәсенә җиткерә алмаучылар, аерым редактор ярдәменә мохтаҗ каләм ияләре артканнан-арта бара. Гап-гади язу маһирлыгы җитмәү әдәбиятның башка жанрларында да, хәтта телче галимнәрнең хезмәтләрендә дә ап-ачык ярылып ята. Саруны кайнаткан мондый чатаклыклар беренче җөмләдән үк башлана. Авторның кулъязмасын әр-яңадан "сөреп чыгу"ның ни икәнен газет-журнал яки нәшрият мөхәррирләре бик яхшы аңлыйдыр. Менә шундый хәл. Иҗатта үзешчәнлекнең чамадан тыш көчәеп китүе исә рухи ориентирларның бозылуына, алай гына түгел, шигъриятне яшәү рәвешеннән аерылгысыз итеп санаган халыкның зәвыген түбәнәйтүгә китерә.

Француз язучысы Жан Лабрюйер искәрткәнчә, уртакуллылыкка түзеп тора алмаслык шундый өлкәләр бар: шигърият, музыка, сынлы сәнгать, ораторлык. Озак еллар макталып килгән олы шигъриятебездә профессиональлек сыйфатлары нилектән тоныклана башлады соң? Инде әйтеп үткәнемчә, әдәбиятта үзешчәнлек өлешенең кискен артып китүе дә чын әсәрләрне танып алуда кыенлык тудыра башлады. Һәммәбезгә мәгълүм, хәзер иҗат белән шөгыльләнүчеләр бермә-бер артты: балалар да, яшүсмерләр дә, урта яшьтәгеләр дә, өлкәннәр дә, картлар да тырышып-тырышып шигырь яза. Әлбәттә, бу—күңелле фал. Әмма барып чыкмаган гамәлләреннән канәгатьләнү алучыларның үрчүе мөкәммәллек үрнәге саналган шигърияткә барыбер сукмыйча калмый.

Ничек кенә булмасын, тезмә сәнгать үсешен беркадәр тоткарлауга китергән сәбәпләрнең иң зурысы гомерләрен иҗатка багышлаган каләм әһелләренең һөнәрмәндлек җаваплылыгына килеп бәйләнә. Тәҗрибәле затлар тәкрар иткәнчә, иҗат техникасын яхшы белгән чакта гына әдәби эшчәнлектә ниндидер үсешкә ирешергә мөмкин. Кешегә бирелгән талант көчлерәк булган саен, аның язу алымнары тизрәк камилләшә бара. Ә иҗат техникасының асылы, исегезгә төшерәм, тел өйрәнүгә кайтып кала. Әгәр без язучылык сәнгате стиль белән билгеләнә дибез икән, стиль үзе барыннан да элек телгә бәйле рәвештә күзаллана. Кызганыч ки, каләмгә яшьли иман китергән шагыйрьләрнең дә иҗадият техникасы ягыннан аксавы сизелә. Гомумән, шигъри иҗат белән шөгыльләнүче күп кенә авторлардан тел-өслүп камиллегенә ирешүне таләп тә итеп булмый. Аларны өйрәтергә дә мөмкин түгел. Әдәбият багы шулай чүпләнә. Һәм бүгенге көндә "шигърият экологиясе" мәсьәләсе бөтен җитдилеге белән көн тәртибенә басты. Әйе, татар теле—шагыйрьләр теле. Әгәр шулай икән, әдәби иҗатның үзәгендә торган тел-өслүп мәсьәләсендә дә иң беренче чиратта шагыйрьләребез үрнәк күрсәтергә тиештер.

*Бетермәгез татар шигъриятен,*
*Такташ кебек,*
*"Такташ үлде",—диеп башлагыз,*
*Әгәр кодрәтегез җитми икән—*
*Ташлагыз!..*

Күптән түгел арабыздан киткән Мөдәррис Әгъләмнең соңгы шигырьләреннән берсе, сизгәнегезчә, үзенә күрә шигъри васыять булырлык мәҗрух җан авазы шикелле яңгырый. Чыннан да, әгәр татар шигъриятенең гасырлар буе яуланган биеклегендә калуын телибез икән, моңа үзләре туктаусыз үсә алган талантлар белән генә ирешергә мөмкин. Шулай ук милләт балаларын олуг максатларны үтәүгә туплау өчен дә югары эстетик көчкә ия булган чын сәнгать әсәрләре кирәк. Үзең яшәгән чорның рухи ихтыяҗларын игътибар үзәгендә тоткан хәлдә мәңгелек өчен иҗат итү дә, хәтта әдәбият үсешен эчтән тоткарлаучы канәгатьлек чиреннән котылу да чын художниклар кулыннан гына килә. Димәк, бөек каләмнең дәрәҗәсен төшерергә беркемнең дә хакы юк.



Әлфәт Закирҗанов

# СӘХНӘ ӘДӘБИЯТЫБЫЗ

## ДРАМАТУРГИЯ

Әдәбиятыбызның драматургия төре, үзенең традицияләренә таянган хәлдә, ил-халык тормышы, кешене борчыган мәсьәләләр белән тыгыз бәйләнештә яши, үзгәрә. Ике корылтай арасында барлык татар театрлары, классика белән бергә, хәзерге чор пьесаларына нигезләнгән премьералары белән сөендерделәр. Соңгы елларда Ю. Сафиуллин, Д. Салихов, Аманулла, Э. Яһүдин, Х. Ибраһим, З. Хәким, М. Гыйләҗев (рус телендә) пьеса җыентыклары чыгардылар. Аларда төрле елларда язылган әсәрләре урын алса да, һәр китап драматургның бу дәвер иҗатына нәтиҗә,

йомгак булып тора һәм күпсанлы китап укучыларны үзенең серле әдәби дөньясы белән таныштыра.

Моннан тыш «Казан утлары», «Мәйдан» журналы битләрендә байтак пьесалар дөнья күрде. Шулай да ике корылтай арасындагы сәхнә әдәбиятының төп чагылышы булып «Яңа татар пьесасы»ның алты томлыгы басылып чыгу тора. Г. Камал исемендәге театр коллективы, Мәдәният министрлыгы тарафыннан 2003 елда оештырылган, «Татэнерго» ААЖнен матди ярдәме белән, шулай ук «Яңа гасыр» ТРК, «Казан утлары, «Татарстан яшьләре», «Сәхнә» журналлары катнашында алып барылган һәм һәр ел саен Театр көнендә нәтиҗә ясалучы Татар пьесалары конкурсы турында шактый күп сөйләнелде һәм язылды. Аның эчтәлеген, бурыч-максатларын, шартларын һ. б. кабатлап тормастан, шуны билгеләп үтү кирәк: беренчедән, татар театрларының заман пьесаларына кытлык кичерүенә бәйле бик тә кирәкле һәм житди эшчәнлеккә юл ачылды, шуна да бу Ф. Бикчәнтәев һәм Ш. Закировларның заман рухын тоюы, театр һәм драматургия өчен борчылып яшәвенә нисбәтле егетлек һәм игелек үрнәге булды; икенчедән, күп тапкырлар билгеләп үтелгәнчә, төрле төбәкләрдә яшәп иҗат итүче драматургларның эшчәнлеген уртак максатка юнәлтү мөмкинлеге биреп, басылып чыккан иң яхшы әсәрләрнен барлык театрларга, шул исәптән районнардагы халык театрларына тәкъдим ителүе; өченчедән, әлеге конкурсның аеруча мөһим бер сыйфаты—яшь көчләрне-иҗатчыларны барлау, аларны активлаштыру булды һәм, ниһаять, дүртенчедән, әлеге алты томлык рухи байлык хәзерге татар драматургиясенен төп көчләрен барлау, аның үсеш-үзгәреш юлларын билгеләү мөмкинлеге дә бирә. 2004 елдан башлап чыгарылган җыентыкларда 31 авторның 46 пьесасы урын алган. Журналларда һәм авторларның җыентыкларында басылып чыккан һәм театрларда премьералары үткәрелгән әсәрләрнен тагын егермеләп булуын исәпкә алсак, яна әсәрләр саны тагы да арта.

Сәхнә әдәбияты турында сүз алып барганда жанр һәм жанр формаларына бәйле эзләнүләрне билгеләп үтү кирәк. Традиция буенча комедия өстенлек итә. Бу мәсьәлә драматургия һәм театр тәнкыйтендә зур бәхәсләргә китерде. Театрлар репертуарында комедия һәм шул исем белән аталган һәртөр тамаша өстенлек итүе, шул ук вакытта уй-фикергә йөз тоткан, әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләр кыю күтәрелгән пьесалар аз булуы турында З. Зәйнуллин, Р. Зарипов, А. Әхмәдуллин, А. Хәлим һ. б. борчылып язды. Шул ук вакытта, режиссерлар Ф. Бикчәнтәев, Р. Әюпов, Ф. Ибраһимов интервьюларында аның сәбәбе дә әйтелде: татар тамашачысы, беренче чиратта, нәкъ менә уен-көлкегә, жыр-биюгә бай комедияләрне яратып карый. Моның сәбәпләрен халкыбызның милли сыйфатлары белән дә, тормыштагы авырлыклардан арынып тору, ял итү теләге белән дә, тамашачының зәвыгы түбән булу белән дә аңлатулар бар. Күп санлы комедияләр арасында «сатирик», «сагышлы», «монсу», «көнкүреш», «музыкаль» дип аталганнары очрый. Иң яхшы комедияләргә көлкеле хәлләрне, ямьсез фактларны, кешеләр характерындагы кимчелекләрне тапкыр, жор тел белән, мавыктыргыч хәл-күренешләрдә бирү хас. Аерым вакыйгаларны көлеп-елмаеп кабул итүдә татарның милли психологиясе дә ачыла. Еш кына әнә шунда авторның эстетик идеалы да чагыла. Т. Миннуллин, Х. Ибраһим, И. Зәйниев, Ф. Садриев, Н. Кәримова комедияләре заман рухын нечкә тою, милли төсмерләре, халыкчан жанлы теле белән игътибарга лаек. Шулай да жыентыкларда урын алган комедияләрнең бер өлешенә тормыш ваклыклары белән мавыгу, ясалмалылык, төче сурәтләр хас. Т. Миннуллинның «Син мине күрәсенме?» комедия-мәзәгендә, З. Минһажеваның водевильгә тартым «Бакча карачкылары» музыкаль комедиясендә, З. Гыймаевның «Бакча караклары», М. Нәжметдинованың «Ак болыт», Э. Ибраһимованың «Никтудымнар авылында» комедияләрендә тормыш-яшәешнең төрле яклары, шактый житди мәсьәләләр фаш итү ниясә көлү объекты буларак алынса да, халыкчан гыйбарәләр, жорлык, көлкеле күренешләр уңышлы гына файдаланылса да, бу әсәрләргә бөтенләй житми. Авторның эстетик карашларын чагылдырырга тиешле, һәртөр начарлыкка каршы куелган Көлү әлеге вазифаны үтәп бетерә алмый.

Комедиянең тәэсир итү, кызыксындыру, укучы-тамашачыны жәлеп итү көче, тормышның төрле якларын чыгылдыру, бигрәк тә тәнкыйть аша яналык-янарышны яклау мөмкинлеге зур булса да, драматургиянең үсеш-үзгәрешенә

тормыш каршылыкларын, аннан да бигрәк кеше характерлары драматизмын үзәккә алган драма һәм трагедия жанрындагы әсәрләр күчлерәк йогынты ясый. Бу елларда Т. Миңнуллин, З. Хәким, Р. Батулла, Ф. Садриев, Э. Яһүдин, Р. Зәйдулла, Х.Ибраһим, Ф. Галиев, Л. Лерон, Ф. Тарханова, Э. Шәрифуллина һ б.ларның драма жанрына караган пьесалары языллы. Арада «монсу», «музыкаль», «фажигале», «монодрама» кебек жанр формалары бар. З. Хәким исә әсәрен «театраль роман», Р. Батулла «драматик хикәя», «пьеса-кыйсса» терминнары белән атый. Бу жанрга караган әсәрләр арасында үткән тарихыбызга, олы шәхесләргә караган, кеше ялгызлыгын чагылдырган, яшьлек хаталары өчен борчылып яшәүчеләр турындагы, чечен сугышы фажигаләрен яктырткан, суд-прокуратура органнарында эшләүчеләр тормышын сурәтләгән пьесалар булуы игътибарга лаек. Ф. Тарханованың «Сөю газабы», Э. Шәрифуллинаның «Гомер—бер» драмалары яшәешнең каршылыклы мәсьәләләрен—яшьлек хыялларына тугры калу, иҗат кешесенең яклауга мохтаҗлыгы һ. б.—калкытып кую белән кызыксыну уята. Шулай да әлеге әсәрләр схематизмнан азат түгел, геройлар еш кына авторлар теләге белән хәрәкәт итә, алар фикере белән сөйләшә башлый. Бу урында драма жанрындагы байтак пьесаларга хас каршылыклар урын алган тагын бер әсәргә тукталып үтик. Р. Батулланың «Китек күңел» пьеса-кыйссасында мәхәббәт һәм нәфрәт, ир һәм хатын мөнәсәбәте, бәхет төшенчәсе әхлакый һәм фәлсәфи яссылыкта сурәтләнә. Бу—пьеса-дискуссия. Әсәр дәвамында «Нәрсә ул ярату?», «Ул ни өчен бетә?», «Нәрсә ул гөнаһ?», «Нәрсә ул ялган, хыянәт?» кебек сорауларга җавап эзләнә. Укучы-тамашачыны битараф калдырмый торган әсәр каршылыклы уй-фикерләр уята. Пьеса үзара таныш булмаган ир белән хатынның төн үткәрүен сурәтләү белән башлана. Вакыйгалар барышында Сәлимәнең ире булуы, яратмыйм дип аннан аерым яшәве, тагын өч ир белән яшәп алуы, хәзер инде Мостангирне очратуы һәм аны ярата башлавы ачыклана. Кызганычы шунда, борынгы һәм урта гасырлар сүз сәнгатенә хас булганча, «Мәрхәмәтле вә рәхимле Аллаһ исеме белән» башланган пьесада ир белән хатынның никахсыз яшәве, һәрдаим аракы эчү күренеше табигый яшәү рәвеше дип тәкъдим ителә. Шулай да мине иң борчыганы автор позициясе белән бәйле. «Җимерелгән бәхет» пьесасында тилергән гашыйклыкны хупламаган, гаиләне саклауны, үзең турында гына түгел, сине яраткан кешене дә кайгыртуны яклаган драматург «Китек күңел»дә капма-каршы позициягә басып, үз рәхәте белән генә яшәүче, җаваплылыктан качучы, даими рәвештә гайрәтлерәк ир эзләүче хатынны яклау юлыннан бара һәм аңлашылып бетмәгән симбиоз концепция тәкъдим итә.

Драматургиянең авыр, катлаулы жанры булып трагедия санала. Ул әдиптән житди әзерлек, бай тәҗрибә, уңышлы сайланган тормыш материалы белән бергә, эстетика кануннарын, сәхнә закончалыкларын яхшы белүне таләп итә. Сәхнә әдәбияты тарихында уңышлы үрнәкләр булса да, соңгы елларда әлеге жанрга караган әсәрләр бик аз. Дөнья күргән әсәрләрдән М. Маликованың «Сөембикә»сен, Р. Батулланың «Мур кырылышы» фажига-хроникасын атап үтәргә була. Төрле жанрлар синтезында язылган әсәр буларак А. Хәлимнең «Кияү урлау» фантастик трагикомедиясе гасырлар дәвамында яшәп килгән кануннарны кире кагучыларның эш-гамәле җәмгыятьне афәт чигенә китерүен ачуы белән игътибарга лаек.

Ике корылтай арасында аерым авторлар эшчәнлеге, иҗади табышлары турында сүз алып барганда беренче булып И. Зәйниев исемен атау дөрес булыр. Бу елларда аның пьесалары Г. Камал, Яшь тамашачылар, Минзәлә, Уфадагы «Нур» театрлары сәхнәләрендә куелды, автор драматург буларак танылу алды, Язучылар берлегенә кабул ителде. «Яңа татар пьесасы» конкурсы җыентыкларында аның «Ай кызы», «Туйга ничә көн кала», «Күкләр елмаеп караса», «Суган чәчәге» пьесалары урын алган. Сәхнә әдәбиятына ашкынып һәм ныклы адымнар белән килеп кергән яшь авторда Ходай биргән сәләт бар. Ул тормышны оста күзәтә, шуңа да сайланган тормыш материалы тирән мәгънәле булу белән бергә, гаять тормышчан һәм төрле. Аның күпчелек пьесаларында, исемнәреннән үк күренгәнчә, яшьләр үзәктә тора. Автор аларның хыял-омтылышын да, шатлык-борчуларын да яхшы белеп яза. И. Зәйниевкә яшәешнең житди әхлакый һәм фәлсәфи проблемалары да чит-ят түгел. Г. Камал театрында уңыш белән баручы «Мәхәббәт турында сөйләшик» тә

драматург ир-хатын, гаилә, яшәешнең асылы, мәгънәсе кебек мәсьәләләргә дә иркен мөрәҗәгать итә. Әсәрнең уңышы әхлакый һәм милли тамырларны барлауда, яшәү мәгънәсенең асылы яхшылык эшләп, үзең турында яхшы истәлек калдыруда дигәнне укучы-тамашачыга җиткерүдә. Автор яратуга, үзара хөрмәткә, тигезлеккә һәм гармониягә нигезләнгән дөнья моделен тәкъдим итә. Яшь драматургның эзләнүләре, сәнгати фикерләү үзенчәлеге шактый тулы чагылган, инде бәхәсләр кузгатып өлгергән «Суган чәчәге» пьесасында әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә бәйле чын һәм ялган кыйммәтләр, хакыйкатькә омтылу һәм битлек киеп яшәү турындагы уйланулар калкытып куелган. Уй-фикер көрәшенә нигезләнгән пьесаны аңлау, кабул итү һич тә бертөрле генә булалмый. Шуңа да аның А. П. Чехов иҗатына якынлыгы турында фикерләр булды. Пьесадагы хәрәкәтне тудырган каршылык икенче катламда, ягъни әйтеп бетерелмәгән фикерләрдә, теге яки бу геройның җанында барган икеләнүле, борчулы хис-кичерешләрендә, парлашырга омтылып та, берсенең дә тигез гаилә бәхетенә ирешә алмавында тагы да тирәнрәк конфликт булып оеша.

Драматургиягә беренче адымнарын атлаган яшьләрдән Д. Мөхәррәмованың «Тешләнгән алма», Р. Мөхсинованың «Кайнар токмач», Р. Сабырның «Земфирәкәй, сылуым, аппагым», З. Фатыйхованың «Иркәм» пьесалары матур тәэсир калдыра. Тәҗрибә җитеп бетмәсә дә, аларда уңышлы интрига-каршылыклар, персонажларның характер сыйфатларын ачу, сәхнәне тоемлау урын алган. Бу исә ышаныч-өмет уята.

Урта буын авторлар арасында аеруча актив иҗат итүче драматургларның берсе—З. Хәким. Аның «Телсез күке»се, «Легионер»ы, «Бит»е, «Алма бакчасында алтын бар»ы, «Гасыр моңы» конкурсларда җиңеп чыккан пьесалар рәтендә. «Телсез күке» соңгы елларда даими игътибар үзәгендә булып, шактый тулы бәяләнде. Бу очракта әсәрнең табыш-яңалыгын билгеләп үтү белән чикләнәбез: ул башкаларны кабатламаган милли характер тудыруда; катлаулы һәм күптөрле вакыйгаларны бер үзәккә максатчан һәм мәгънәле туплауда; милли проблематиканы татарның рухын билгеләүче җыр-моң төшенчәсенә һәм асылын ачучы Хәтер, Намус, Тугрылык, Игелек сыйфатларына нисбәтле ачуда.

Драматургның Бөек Ватан сугышы тудырган фаҗигале язмышларга бәйле һәм яшәешнең әхлакый, фәлсәфи, милли, иҗтимагый проблемалары калкытып куелган «Легионер» театраль романы, шулай ук элекке классташларның дуслык, мәхәббәт, яшәү мәгънәсе, бәхет турындагы җитди бәхәсенә нигезләнгән «Бит» пьесасы укучы-тамашачы тарафыннан яратып кабул ителде. Аның әсәрләре укучы-тамашачыны уйлануга, эзләнүгә, автор белән диалогка китерүе белән үзенчәлекле. Ул иҗат иткән геройлар нәкъ менә каршылыклы булулары, көтелмәгән эш-гамәлләре белән аерылып тора.

Соңгы елларда Х. Ибраһимның «икенче сулышы» ачылды. Драматургның «Газиз ярым» (2006) җыентыгы басылып чыгу, конкурсларда уңышлы чыгыш ясап, «Ялгыз каен күзе», «Нәфига ханым», «Утрау» пьесалары укучыга килеп ирешү аның иҗаты турында җитди сүз алып бару мөмкинлеге бирә. Х. Ибраһим кеше шәхесен гаилә-көнкүреш кысаларында, мәхәббәт-дуслык һәм әхлак кануннарына нисбәтле өйрәнә. Тематик төрлелеккә омтылмаса да әсәрләре бер-берсен һич тә кабатламый.

Сәхнә әдәбиятының барлык жанрларында да уңышлы иҗат итүче Аманулланың «Моңлы ядкарь» (2005) җыентыгы үзенчәлекле яшәеш фәлсәфәсе, җор һәм бай теле, диалоглар кору остасы булган авторның ныклы адымнар белән алга баруын күрсәтте. Китап укучыга килеп ирешкән пьесалар тормышчанлыгы, конфликтның ачыклыгы, сюжет-композиция төзеклеге, хәрәкәт динамикасы белән җәлеп итә. Драматургның заман проблемаларын калкытып куюда шактый кыю эзләнүләр алып баруын күрәбез. Шулай да Аманулла соңгы елларда иҗат активлыгын киметте. Конкурсларга бәйле басылып чыккан «Бер кирпеч, ике кирпеч...» көнкүреш комедиясе—шактый беркатлы, мәгънәсез, сәхнәгә куярга мөмкин булмаган әсәр.

Прозаның детектив жанрында уңышлы эшләп килүче Р. Сәгъдинең сюжет кору, вакыйга-интрига оештыру остасы булуын күрсәтә. Аның Буа театры тарафыннан сәхнәләштерелгән «Алсу томан артында» моңсу драмасындагы, Кырым татарларының

фаҗигале язмышы сурәтләнгән «Бакчасарай гөлләре» мелодрамасындагы вакыйга-күренешләрдә чын мәхәббәт, кеше бөеклеге, шул ук вакытта әхлаксызлык-кешелексезлек гамәлләре гыйбрәтле язмышлар аша гәүдәләнеш таба.

Хакимият һәм иҗатчы мөнәсәбәте борынгы һәм урта гасырларда киң эшкәртелеп тә, XX гасырда читтәрәк калып килде. Шуна да Р. Зәйдулла һәм Р. Сабировның «Хөкемдар» тарихи драмасы интеллектуаль эчтәлеге, әзерлекле укучыга атап язылган булуы белән игътибарга лаек. Гомумән, хөкемдар һәм шагыйрь үзләренә йөкләнгән миссияне үтәгәндә генә җирдә билгеле бер гармония яшәячәк дигән фикерне яклый авторлар. Р. Зәйдулланың «Мәйдан» журналында басылып чыккан «Ашина» драмасы кешенең рухи бөеклегенә китергән һәм түбәнлеккә төшергән сәбәпләр, меңьяшәр бүре Ашина хакындагы риваятьнең сурәтләнгән вакыйгалар белән бәйләнеше Ватан, Намус, Ирек төшенчәләренең мәңгелек булуы турында уйлануларга этәрә.

Урта буын драматургларыбыздан Г. Каюмов «Упкын өстендә уен» (2004), Д. Салихов «Гыйлаҗ тәрәзәләре" (2004), Ю. Сафиуллин «Әллә өйләнергә инде...» (2005), М. Гыйләҗев «Словарь любви» (2005) җыентыкларыннан соң тынычланып калдылар. Үз йөзе һәм стиле булган, үз тамашачысын, хәтта театрын тапкан әлеге әдипләр иҗаты буенча спектакльләр сәхнәләрдә куелса да, яна пьесалар белән күренмәделәр. Әлеге сүзләр күренекле драматург Р. Хәмидкә дә карый. Без алардан яна әсәрләр көтеп калабыз.

Ике корылтай арасында иң актив эшләүче авторларыбызның берсе Э. Яһүдин булды. «Мәхәббәдкә мәдхия» (2004) җыентыгы замандашлары гаме белән яшәүче, тормышта кешелеклелек, гаделлек барлыгын расларга алынучы һәм моны әхлакый һәм фәлсәфи эчтәлек белән сугарылган вакыйга-күренешләрдә, укучы-тамашачыны битараф калдырмый торган сурәтләрдә чагылдыручы драматургның олы мәйданга килүен раслады. «Яңа татар пьесасы»нда даими катнашып, ул «Бер кояш астында», «Оҗмах бакчасында өч төн», «Олуг хан ярлыгы» кебек пьесалары белән танылу алды.

Ф. Садриевның «Без китәбез, ахры» драмасы, «Тәрәзәгә егет килгән» трагикомедиясе чын мәгънәсендә тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе чагылышы булып тора. Драматург кеше дигән затның янадан-яңа якларын ача. Гыйбрәтле хәл-күренешләр аша битарафлыктан арынырга, олы тормыш гаме белән яшәргә этәрә. Үткән белән хәзерге бәйләнешен, төрле буыннар мөнәсәбәтен, гомумән, яшәеш диалектикасын ачуда әдипнең осталыгын билгеләп үтү кирәк.

Татар драматургиясе тарихында Р.Батулланың лаеклы урыны булу бәхәс уятмый. Соңгы елларда дөнья күргән «Китек күнел», «Җимерелгән бәхет», «Мур кырылышы» әсәрләре әдипнең һаман эзләнүдә булуын, татар дөньясын төрле яссылыкта өйрәнүен, драматик материалга соралып торган янадан-яңа тарихи, иҗтимагый, милли төсмерле материалларга мөрәҗәгать итүен күрсәтә. Драматургның әдәби офыгы, сәнгати фикерләве киңлегенә сокланырга гына кала. Аның эзләнүләре төрки-татар тарихы белән генә чикләнмичә, Европа киңлекләренә үтеп керә. Иҗтимагый-сәяси һәм көнкүреш мәсьәләләре дини, фәлсәфи, әхлакый сораулар белән үрелеп барган «Мур кырылышы» киләчәктә төрле планда тикшереләчәгенә шик юк. Ә инде татарның чагыштырмача якындагы тарихын—XIX йөзнең соңгы чирегеннән алып XX гасырның урталарын иңләп алган «Җимерелгән бәхет» драматик хикәясе әдипнең зур табышы булып тора. Заһидә ханым Тинчурина язмышына бәйле рәвештә үзәктә татар милләтенең каршылыклы да, фаҗигале дә язмышы, аны инкыйразга этәргән сәбәп-шартларны ачу тора. Драматик хикәянең яңалыгын түбәндәгечә билгеләп булыр иде: 1) әсәрдә хәрәкәт һәм вакыйгалылык өстенлек итми, бу—идея, фикер пьесасы. Авторның табышы да фикер көчендә, аның логик бәйлелектә, эзлеклелектә бирелүендә; 2) үткәннәр белән бүгенгенең тыгыз бәйләнешен ачуда һәм аларның гаять заманча яңгыравында; 3) безгә шактый таныш зыялыларның шәхси тормышын, характер сыйфатларын билгеләвендә. Батулла язганча, һәрбер язмыш—үзе бер поэма. Әнә шул «поэмаларның» аерым битләрен генә ачу да милләт фаҗигасен күрсәтү белән бергә, үткән чорлар авазын да ишеттерә.

Т. Миңнуллин бу елларда да татар драматургиясен әйдәп баручы олы әдибебез булып калды. Аның иҗатында чынбарлыкның янадан-яңа яклары ачылуын,

сискәндереп җибәрә торган темаларның укучы-тамашачы алдына куелуын күрмичә мөмкин түгел. Драматургның басылып чыккан яисә төрле сәхнәләрдә куелган «Галиябану, сылуым-иркәм», «Тәнзиләкәй", «Аерылабыз—хуш инде», «Син мине күрәсеңме», «Алты кызга бер кияү», «Гашыйк буласым килә», «Мулла», «Дивана» пьесалары тема-проблемалары, яшәеш мәсьәләләрен милли һәм гомумкешелек кыйммәтләре яссылыгында чагылдыруы белән, һәрберсендә дип әйтерлек индивидуаль сыйфатлары белән аерылып торган замандашыбызның характерын иҗат итүе һәм әдип кулланган сурәт чараларының, форма-алымнарының төрлелеге, байлыгы, еш кына кабатланмаслыгы белән аерылып тора. Т. Миннуллинның «Галиябану, сылуым-иркәм» пьесасында әдәбият-сәнгать дөньясы, төрле буын кешеләрнең әдәби ядкарьләргә караш-мөнәсәбәте, кеше яшәешенең тирән катламнарын ачу интертекстуальлек алымына нигезләнә, ягъни автор XX йөз башында язылган классик үрнәкләрнең берсе булган М. Фәйзинең «Галиябану»ына мөрәҗәгать итә. Төп игътибар геройларның рухи дөньясын, хис-кичерешләрен ачуга юнәлтелгән. Шул рәвешле, сәнгатьнең җәмгыятьтәге урыны, үткән гомер, яшьлек хаталары, сонарып аңлашу күренешләренә бәйле тормышчан сораулар турында уйлану, бергәләп җавап эзләү пьесаның сюжет нигезен тәшкил итә.

Драматургның «Алты кызга бер кияү» моңсу комедиясе әдипнең бөтен иҗатында үзәктә торган кешенең асылы, яшәү мәгънәсе, бәхет турындагы уйлануларының дәвамы булып тора. Т. Миннуллин яклаган төп идея, беренче чиратта, Рәхмәтулла образы белән бәйле. Ул яңа образ түгел, атаклы Әлмәндәрнең яңа шартлардагы дәвамчысы. Рәхмәтулланың тормыш принципы, А. Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән»дәге Бибинур әбинеке кебек—«Яхшылык эшлә дә суга сал, халык белмәсә, балык белер».

Т. Миннуллинның «Дивана» драмасында ике мәсьәлә калкытып куелган. Берсе—кешелекнең гармониягә омтылуы. Кешелек җәмгыятендә хыял рәвешендә андый яшәешкә омтылу һәрвакыт булган. Шуның өстенә идеаль яшәешкә омтылу бүгенге тормыш шартлары белән дә аңлатыла. Пьесаның умыртка баганасын тәшкил иткән икенче проблема җанлы һәм җансыз табигать дөньясы, аның уртасындагы авыл белән бәйле. Драматургның соңгы еллар иҗатында урын алган бер үзенчәлек монда да чагылыш таба: ул кешенең сафлыгын-чисталыгын да, гадилек-гадәтилеген дә авыл белән бәйләп карау. Әсәр геройлары «бер генә дә нормаль кеше» булмаган шәһәрне кабул итмиләр. Авыл үзенең табигате белән дә кешене дәвалау көченә ия. Кешенең табигать белән гармониядә яшәү теләге мәхәббәт хисе белән кушылып китә. Кеше шәхесенә тирән хөрмәт белән карау Т. Миннуллинның бөтен иҗатын инләп үтә. Кемнең кем булуына карамастан, диванамы, әллә сәламәт-тазамы, әдип аның иреген яклап чыга, һәркемнең үзенчәлекле, уникаль булуын билгели. Шулай да пьесага фикер ачыклыгы җитми. Ленин идеяләрен калкытып куюы белән автор аларның җәмгыятьтә яшәвен искәртәме? Әллә инде яшәеш гармониясенә омтылуның утопия генә булуын күрсәтәме? Авыл белән шәһәрне каршылыкта бирү, соңгысын кешенең рухи асылын җимерүче буларак тәкъдим итү нәрсәгә булыша? Абыйсы акчасына яшәүче Вилнең аның белән аңлашырга теләмәвен, тулысынча кире кагуын ничек аңлатырга? Җәмгыятьне үзгәртеп кору мәсьәләсе куелган икән, кеше яисә аерым милләтләр нинди идеягә таянырга, нәрсәне нигез итәргә тиеш дигән сорау да ачыклык сорый. «Янадан авылга—табигатькә» дигән караш та, бәхәсле булып, аңлашылып бетми. Дөрес, әлеге сораулар укучы-тамашачыга кала, ул үзенчә уйлап бетерсен дияр идек, әмма алар турында эзләнү-уйлану юнәлеше, автор концепциясе ачыкланып бетмәгән.

Ике корылтай арасында драматургиянең торышын күздән кичергәннән соң, гомумиләштереп нәтиҗәләр ясыйк. Татар драматургиясендә җитди эзләнүләр, аерым тәҗрибәләр баруын билгеләп үтәргә кирәк. Мин бу очракта 1990 еллар ахыры белән чагыштырганда билгеле бер сыйфат үзгәрешләре барлыкка килүне күздә тотам. Алар түбәндәгеләрдә чагыла: 1) Сәхнә әдәбиятында буыннар алмашу процессының традицияләр дәвамчанлыгы һәм яңачалык белән эзлекле бәйләнештә баруы уңай нәтиҗәләргә китерде. Өлкән буын (Т. Миннуллин, Р. Батулла, Ф. Садриев, Р. Хәмид һ. б.) һәм урта буын драматургларыбыз (З. Хәким, Аманулла, Р. Сәгъди,

Д. Салихов, М. Гыйләҗев, Ф. Галиев, Г. Каюмов, Р. Зәйдулла, Ш. Фәрхетдин һ. б.) янәшәсендә яшь авторлар мәйданга чыкты. И. Зәйниев, Р. Сабыр, Р. Мөхсинова, С. Гаффарова, Й. Миннуллина исемнәре яна буын килү турында хәбәр итте. Моңа кадәр әдәби иҗатта билгеле булсалар да, соңгы елларда гына Э. Яһүдин, Х. Ибраһим, Л. Лерон, Р. Бохараевлар драматург буларак киң танылу алдылар. 2) 90нчы елларда публицистик кайнарлык өстенлек итсә, хәзер тормыш-яшәеш турында салмак-фәлсәфи уйлану күзәтелә. Татар дөньясы, яшәеше нигездә авыл белән бәйле сурәтләнеп, моңсу-сентименталь күренешләр үзәктә торса да, яшь авторларда яна мәдәни мохитне—шәһәр культурасын—үзләштерү ачык сиземләнә. Милләт язмышы турында уйланулар гомумкешелек кыйммәтләре белән үрелеп, үзенчәлекле синтез тәшкил итә. 3) Тематик төрлелеккә омтылып, драматурглар еракта һәм якындагы тарихыбызны, әфган һәм чечен сугышы кайтавазын, авылларның бетүе һәм глобальләшү күренешен, җәмгыятьтә барлыкка килгән яңа гадәтләрне, гомумкешелек кыйммәтләренен кимүе һәм шәфкатьсезлек билгеләренең артуы сәбәпләрен, милли традицияләрне һ. б. өйрәнү аша заманның гаять мөһим мәсьәләләренә мөрәҗәгать итүнең матур үрнәкләре дөнья күрде. 4) Сәхнә әдәбиятындагы табышлар, беренче чиратта, кеше образлары, милли характерлар иҗат итү белән бәйле. Иң яхшы әсәрләрдә милли тамырлардан аерылмаган, халык язмышын үз язмышы иткән, заман сынауларына бирешмәгән шәхесләр урын ала. Милли идеалларга караш билгеле бер үзгәреш кичереп, глобализм шартларында милләтне саклап калу, Россия һәм Евразия тарихында татарларның урынын билгеләү омтылышы булып алга чыга. Бу исә аерым кешенең һәм халыкның табигать дөньясы, галәм, мөселман һәм христиан цивилизацияләре һ. б. белән катлаулы мөнәсәбәтен ачыклауга китерә. 5) Әсәрләрнең жанр һәм жанр формаларына бәйле төрлелеге сәнгати алым-чараларның баюына да юл ача. Драматурглар актив рәвештә шартлы алымнарга, символик-метафорик күренешләргә, мифологик дөнья сурәтләренә, психологизм алымнарына һ. б. мөрәҗәгать итә.

Шуның белән бергә, сәхнә әдәбиятының торышы билгеле бер борчу, канәгатьсезлек уята. «Яңа татар пьесасы» җыентыкларында конкурсларда сайлап алынган иллегә якын пьеса урын алса да, аларның унлабы гына сәхнәләргә менде. Иң күп дигәндә тагын ун-унбишенең куелу ихтималы бар, ә калганнарына режиссерлар мөрәҗәгать итмәс дип уйлыйм. Шул уңай белән пьесалар конкурсы комиссиясенә тәкъдимнәрем бар: 1) конкурсны ел саен түгел, әйтик, өч елга бер үткәрергә кирәк, чөнки сайлап алынган әсәрләрдә дә ашыгып язылу сизелә. Шуның өстенә тәкъдим ителгән һәм җинеп чыккан пьесаларга үз вакытында тулы анализ-бәя бирелми дә кала, унышлы һәм йомшак яклары күрсәтелми; 2) аерым әсәрләрне камилләштерү мөмкинлекләре, юллары шактый ачык күренеп тора. Андыйларны эшләп бетерү өчен кире кайтарырга (исемен ачмыйча) һәм икенче тапкыр катнашырга мөмкинлек бирергә; 3) комиссия әгъзаларына таләпчәнлекне арттырырга, чөнки йомшак әсәрләрне дә финалга үткәрү авторына этәргеч бирү түгел, ә бәлки, хаксыз бәя биреп, аны ялгыш юлга кертеп җибәрә.

Драматургиядәге җитешсезлекләрнең бер өлеше түбәндәгеләр белән аңлатыла: 1) әсәрләрдә авыл тематикасының киң урын алып, милләт киләчәген, традицияләр сакланышын шуның белән генә бәйләп карау. Бу исә әдипләрне тар рамкаларга кертә. Глобализация шартларында авыл йогынтысын онытмаган хәлдә, шәһәр культурасын булдыру, дөньякүләм масштабларда уйлау, фикер йөртү дә сорала; 2) күпчелек әсәрләргә киңлек, тирәнлек җитми. Әдипләр вак мәсьәләләрдән, көнкүрешнең изелгән, тапталган сорауларыннан китә алмый азапланалар. Шуның белән бәйле арзан көлүгә, тамашачыга яраклашуга йөз тоткан комедияләр күп булып, яшәешнең социаль-иҗтимагый, әхлакый-фәлсәфи сорауларын алга куйган, уй-фикергә этәргән пьесалар чагыштырмача азрак туа; 3) соңгы елларда көчле драматик һәм трагик конфликтка корылган әсәрләр бик аз дөнья күрде. Ә бит олы сәнгатьнең мөһим бурыч-вазифасы булып кеше күнеленә үтеп керү һәм аны катарсис-чистарынуга китерү тора; 4) иң борчыган мәсьәләләрнең берсе—драматургларның тормыш пычраклыгын, җәмгыятьнең «төбен» берьяклы, туры мәгънәсендә тасвирлау белән мавыгуы. Бу—әхлаксызлык яисә явызлык күренешләрен читләтеп үтү дигән сүз

түгел. Чын сәнгать әсәрендә ямьсезлек тә, эстетик категория буларак, матурлык тәрбияләүгә хезмәт итә. Әнә шуна тугры калсак иде. Татар сәхнә әдәбияты, театры гомер-гомергә әхлаклылык үрнәге, дөрес һәм матур сөйләм чагылышы булды. Заманга яраклашабыз дип, бу традицияләрдән баш тарту берничек тә аклана алмый. Тормыш-чынбарлыкны өйрәнү, анларга омтылу максатында язучы җәмгыятьнең яшәешнең түбән, ямьсез, караңгы якларына, почмакларына үтеп керергә мөмкин. Әмма ул әлеге түбәнлек, караңгылык кешесе булып калырга тиеш түгел. Бу очракта пьеса сәнгать дигән олы төшенчәгә мөнәсәбәтен югалтыр иде.

Хәзерге татар драматургиясенең эзләнү юлында булуын таныган хәлдә, аның активлашуына, кинәюенә, тирәнәюенә ышанам. Нигезендә исә милли сүз сәнгатебезнең иң матур традицияләрен саклау һәм үстерү ятарга тиеш. Аерым алганда, музыкаль драма һәм трагедия жанрларына житди игътибар сорала. Комедия жанрында исә гаилә-көнкүреш, рухи-әхлакый эчтәлек өстенлек итә, сәяси сатира бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Драматургия үсешенең тагын бер тармагы—романтик һәм интеллектуаль юнәлешкә йөз тоту белән бәйле. Шулай ук дини-рухани тармакның һаман читтә калуын күрәбез.

Татар драматургиясенең көчле традицияләре, талантлы әдипләре бар. Ул киләчәктә дә, иң яхшы сыйфатларны саклаган хәлдә, халыкның рухи ихтыяжына тугры калыр дип өметләнәм.



Айдар Хәлим

# ВАТАН ХАКЫ

ПУБЛИЦИСТИКА

## I

Публицистика—әдәбиятның иң ватани төре. Әгәр һәр әдәби жанрда Ватан хакы дигән мәгърүр хак өлешләтә генә чагыла алса, публицистика исә тулаемы белән Милләт һәм Ватан турындагы Жыр, ялкынлы вә сагышлы Риваять ул. Шуна күрә дә, безнең татар милләте кебек дәүләтсез гомер кичерергә мәҗбүр булган милләт публицистикасы—бу, гомумән алганда, ил-тел сакчысы, патриотик жанр, сәяси, икътисади, социаль һәм, беренче чиратта, милли изелү, мәдәни-мәгърифәти хокуксызлык сагышы белән сугарылып, әдәбиятыбызның иң укыла торган төренә әверелде. Публицистика—безнең исән-сау булуыбыз чамасын белгертә торган кан басымыбызның барометры. Публицистиканың төп сыйфатлары—рухи матурлык, батырлыкка, социаль гаделлеккә чакыру. Димәк, татар әдибе исемен йөрткән әдип, ул нинди генә жанрда эшләмәсен, рухы белән матур, батыр, социаль гаделлек көрәшчесе—Милләте һәм Ватаны хокуклары өчен көрәшче булып калырга бурычлы. Кайчандыр әйтелгән фикеремне янадан кабатлыйм: татарда публицист булу—ул үзеннең кәгазь битедәй кадерле, ап-ак, юка, нәфис телең белән хокуксыз җәмгыятьнең чүпле урамын милләтне яклап-ялап, чистартырга тырышу. Әгәр шагыйрьгә ватани булу өчен шагыйрьлек бер тапкыр кирәк булган булса, публицистка ватани булу өчен икеләтә шагыйрьлек кирәк, чөнки публицистиканың нигезендә саф, курку-өркүдән азат, Максим Горький әйткән акылдан яздырыр дәрәҗәдәге "безумство храбрых"ка тиң шагыйрәнә гамәл ята. Публицистика—ул

курку белмәгән йөрәк, гаделлек хакына ата-анасын, туганнарын да кызганмаган жан профессиясе. Мин бирегә мисал итеп Гаяз Исхакыйның "Ике йөз елдан соң инкыйраз" дигән публицистик романын, шул ук Горькийның 1918 елда чыккан "Несвоевременные мысли", Иван Бунинның "Окаянные дни" дигән әсәрләрен китерер идем.

Кемнәр публицист, нindirәк язмалар публицистика дип атала ала? Бездә чын публицистика һәм публицистлар бармы? Уйлана торгач, шундыйрак фикергә килдем: бездә соңгы еллардагы иң зур публицистик казаныш булып Мансур ага Хәсәнов, Гомәр ага Сабиржановлар житәкчелегендә чыккан тарихта беренче өч томлык "Татар энциклопедиясе" исәпләнергә тиеш түгел микән? Бездә теге яки бу микъдарда публицистикага дәгъва иткән ижатның биш төре бар: 1. Телче-әдәбиятчы, тарихчы, этнолог, социолог-политолог һәм башка шундый галим-белгечләребезнең фәнни публицистикасы. 2. Көндәлек матбугаттагы журналистлар, үзешчән тарихчы-телчеләр, үзешчән язучылар, хәбәрчеләр публицистикасы. 3. Халык депутатларының парламенттагы һ.б. чыгышларын соңыннан публицистика исеме астында бастырган язмалары. (Классик мисал: "Роберт Минуллин, "Шагыйрь генә булып калалмадым") 4. Язучылар, шагыйрьләр, драматурглар һ. б. публицистикасы. 5. Саф публицистлар публицистикасы. Ни кызганыч, бездә соңгысы юк, булса да бик аз микъдарда. Кино, радио-телевидение публицистикасы да юк. Бердәнбер "саф" публицистыбыз Тәүфикъ Әйди 2001 елда безне ташлап китте. "Татнефть" отчетлары белән 40-50 ел туенып яткан икенче бер урыс телле публицистыбыз Марсель ага Зарипов та әллә картая төште, әллә "Бәллүр каләм" конкурсында автомобиль алып, морадына ирешкәч, матбугат битләрендә күренмәс булды. Аллага шөкер, калган дүртесе бездә бар. Хәер, ялгышам, 2007 елда бер саф публицистыбыз ялт итеп күренеп калган икән. Ул—татарның йөз аклыгын татарның үзеннән дә ныграк яклаган немец Карл Фукс. Аның белән безне татарча Марсель Гали таныштырды. Рәхмәт аңа. Татар бит ул берсен-берсе ашый гына, ул үзен якламый, аны татар үзе түгел, урыс Худяков, Лев Гумилевлар яклады, урыс Александр Ключарев, ябрәй Натан Рахлиннар мактады. Шуңа күрә татар киләчәге өчен бүген үз милли газеталары түгел, урыс телендәге чын татар газетасы "Звезда Поволжья" көрәшә. Моның өчен үз исәбенә газета чыгарган Рәшит туганыбыз Әхмәтовка зур рәхмәт. Язучыларыбызның (темалар актуальлегенә кагылмыйча) матбугат битләрендәге активлыгын күрсәтсәк, хәл болайрак. Әлбәттә, алар якынча саннар. Миндәге мәгълүматләр нигезендә әйткәндә, 2005-2007 еллар матбугатында ижтимагый-публицистик темаларга язучыларыбыздан беренче урында Фәүзия Бәйрәмова—170, Туфан Минуллин—130, Асия Юнысова—120, Рәзил Вәлиев үзе белән әңгәмәләрне дә кертеп—79, Марсель Гали—70, Рабит Батулла—70, Рафаэль Мостафин—69, Фәнзаман Баттал—61, Айдар Хәлим—40, Ркаил Зәйдулла—30, Рәфыйк Шәрәфиев—27 тапкыр катнашкан.

## II.

Милләт язмышында аны нык кына айныткан вакыйгалар була. Безгә, егерме беренче гасырга чыккан татар язучыларына, аерым көчләрнең безнең милләтне ачыктан-ачык бетерүгә, талый-талый, күзен йомдыруга алып барган чорда яшәп газаплану миссиясе төште. Аһ, авыр нәрсә бу; хак үлем авыр, ә бу үз күзләрең белән милләтеңне үләт базына илтү күренешен күрү, кичерү хак үлемнән миллион тапкыр авыр! Нишлисең, яшисе килә бит, шайтан алгыры!.. Шул ук вакытта Казанның меңьеллыгы безне милли горурлык белән сугарып, берүк вакытта тәртипсез тәзелеш вакханалиясендә милли, Иске һәм Яңа Бистәле, Суконкалы, Бишбалталы, Печән Базарлы Казанны—Тукай, Әмирханнар, Такташлар Казанын мәңгегә югалту белән айнытты. Безне чүп китап, көнлекче язучылар басты—чын китапка, чын язучыга кадер бетте. Шулай да, айну—куаныч. Иске Казанның истәлекле корылмаларын сипләү ысулы белән саклап калу, иске Матбугат йортыннан чыкмау, аны саклау өчен бераз соңлап булса да татар матбугаты—беренче чиратта "Ватаным Татарстан", "Мәгърифәт", "Шәһри Казан", "Татарстан яшьләре", "Звезда Поволжья" газеталары, "Казан утлары", "Идел", "Эхо веков" журналлары редакцияләре, Татарстан китап нәшрияты, бигрәк тә "Мәгариф" китап нәшрияты, язучылар, журналист-публицистлар тырышлык салып карады каравын, әмма жир өчен

барган аяу белмәс капиталистик көрәштә бу мирасның сиксән-туксан проценты яндыртылган-җимертелгән иде. 2005-2007 еллар кебек фронталь, әлегә баш-акыл аңлап житкермәгән (каян, кемнән килә бу атака?!) милли чигенүләр чорында милләтнең тарихи ихтыяры—достоинствосы өчен көрәшне милли-иҗтимагый фикеребезнең авангарды булган "Казан утлары", аның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин тирәсенә тупланган татар зыялылары җитәкләде. 2004-2006 елларда журнал алып барган " Безнең заман герое" дигән әдәби бәхәс җимерелгән татар милләтендә шәхес феноменын аякка бастыруга ирешү буенча юллар-чаралар эзләүдә тарихи факторга әверелде. Бу редакциянең соңгы егерме елда кылган гамәли-публицистик батырлыкларының иң зурысы иде. Әмма, ни кызганыч, бәхәснең уртасында кызып кына барган конструктив сөйләшү азакка таба сүндерелде, татарча язып-аңлашып та, империаль амбиция кысаларында яшәүнең рәхәтлеген алга сөргән язучылар гавамының бер канаты сөйләшүне мәнәсәбәтләрне ачыклауга, буш сүзгә кайтарып калдырды.

2006 елда журналның мененче санына багышлап чыгарылган "Сүнмәс утлар балкышы" дигән капиталь хезмәт милләтебезнең мең еллык мәдәни тарихын инде тагын бер тапкыр черемәс фикер гранитында раслаган рухи капиталыбызга әверелде. Кыска гына вакыт эчендә, редакциянең үз көчләре белән генә чыгарылган мондый энциклопедик басма-фолиант Казанны саклаганда шәһит киткән бабаларыбызга һәйкәл ул. Бу гигант хезмәт өчен редакция коллективына, беренче чиратта Равил Фәйзуллинга, аның урынбасары—ару-талу белмичә, җиренә җиткереп төзегән шагыйрь, күренекле публицист Рәфикъ Юныска рәхмәтебезне җиткерәсем килә.

"Мәгариф" нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиевнең изге башлангычы белән күп авторлар тарафыннан язылган һәм нәшрият тарафыннан чыгарылган уникаль хезмәт—"Матбугат Йорты—гомер китабы" дигән уникаль хезмәт тә шундыйлар рәтеннән. Җитмеш ел буе татарның йөрәге булып хезмәт иткән атаклы Матбугат Йортының мәдәният картасыннан сызылып ыргытылуына багышланган бу китапны тетрәнмичә уку мөмкин түгел.Нинди якты сагыш!.. Гомумән алганда, соңгы унунбиш елда татар өчен "Мәгариф" чыгарган көрәшчел китаплар армиясен безгә гадел бәяләр көннәр килде. Тартынмыйк, җылы сүз әйтик!.Бу нәшриятны ачтырган өчен Президентка да рәхмәтебезне җиткерик!..

Шунысын гына әйтәм: бүгенге көндә титул эчтәлегендә "Публицистика" дигән рубрикасын саклаган һәм әдәбиятыбызның бу көрәшчел жанрын үстерә килгән бердәнбер журнал булып "Казан утлары" кала килә.

Баш мөхәрриренең Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев белән 2006 елның март санында басылган әңгәмәсе татарның күренеп яки күренмичә су астыннан тәртеп торган проблемаларын барлауда тарихи әһәмияткә ия булды. Баш мөхәрриренең "Китап гасыры бетәме?", "Мең сан—миллион уй", "Яшәр безнең журналыбыз!" кебек һәм башка шундый яңа елга кергәндә яки аерым сан өчен махсус язылган, әле яңалыгы белән жанрын да төгәл билгеләп булмаган бик тә үзенчәлекле, нечкә зәвык, уратып-уратып кызыктыру белән язылган аналитик мәкалә-мөрәҗәгатьләре бүгенге укучыга зәмзәм суы кебек кирәк.

Кызганыч, "Публицистика"дигән рубрика да, баш мөхәррирләрнең укучыларга әтрафлы мөрәҗәгатьләре дә башка бер генә журналыбызда да—"Идел"дә дә, "Мәйдан"да да, "Татарстан"да да, "Мирас"та да күренми. "Татарстан"да Разил Вәлиевнең инде мәрхүм (урыны җәннәттә булсын!) академик Мирза Мәхмүтов белән Алсу Мусинаның Валерия Порохова белән, Нияз Әхмәдуллинның Рафаэль Хәкимов белән әңгәмәләре, Азат Ахуновның Кузьма Мининның Кирилшә Миңлебаев дигән керәшен татары булуы турындагы язмалары күңелгә хуш килерлек. Тирән публицистика әлегә "Идел"дә юк дәрәҗәсендә. Шунысы шатлыклы, басмага баш мөхәррир булып Нәбирә Гыйматдинова, баш мөхәррир урынбасары булып талантлы публицист, тирән белемле кардәшебез Азат Ахунов килгәннән соң фикри торгынлык бозлары эри башлады. Себастиан Цвиклинскиның Ахунов әзерләгән "Татарлар Алманиядә", аның үзенең "Татар телевидениесе—аны күрер көн җиттеме?", "Гадел Россия—гадел түгел", "Исламмы яки мәҗүсилекме?" дигән хезмәтләре әдәбиятыбызга сирәк бер фикер иясе килүен раслый. Милләтнең бу егеттән бик күпне көтәргә хакы бар. Журналга публицистик рухны һаман да шул "Зәйдулла каланчалары"нда дөнья күргән урыс дәүләти терроризмына каршы "Карачкы",

"Китап белән хушлашу" кебек көчле чыгышлары, "Илэт", "Жәлил эзләре", "Кадерсезлек" шикелле публицистик хикәяләрен кертергә тырыша. Зәйдулланың каланчада ятып, "Эчкечелек, синнән ничек котылыйк?", "Йөгез, бер чукыныйк!" дип чакырулары һичшиксез игътибарга лаек. Әмма еш кына шәхси симпатия-антипатия принцибыннан чыгып көн күргән "Каланча"да, кайчакта тирә-юньдә ут-мазар чыкса, йә пожарникның үзен, йә шланг-гидрантын табалмыйлар, тапсалар, су мичкәсе коргаксыган булып чыга.

"Мәйдан" журналында да публицистика юк дип әйтерлек. Көне-төне архивларда утырмыйча, аннан-моннан, көндәлек матбугат битләреннән сыдырып салып, Пугачев заманнарындагы самозванный полковникларны санау белән шөгельләнү туйдырды. Матбугаи культурасы ягыннан бик түбән булып, район газетасы дәрәҗәсеннән күтәрелмәгән, житәкчелеге шәхси амбициядән чыгып, популизм артыннан куып, кем тели шуңа махсус рекламный саннар чыгару белән мавыккан, каләмдәшләрен укып бармау, башка төрдәге әдәби наданлык нәтиҗәсендә әдәби караклыкның, күчереп язу-үзләштерүнең, күптән билгеле нәрсәләрне "ачыш" итеп тәкъдим итүнең төрле ысуллары чәчкә аткан бу журналның тоткан мәсләген гомумммилли максатка ярашлылык принцибыннан чыгып ачыклар көннәр житте. Журналда әдәби тәнкыйть бөтенләй дә юк, житәкчелек, бөеклек чире белән чирләп, тәнкыйтьне кабул итми, моның нәтиҗәсе журналның түбән сыйфатында чагыла. Әгәр дә Фәүзия Бәйрәмова, Айдар Хәлим һәм башка йөкне жигелеп тарткан жирле авторларның әсәрләре бу журналда инде менә ун елга якын күренми икән, нәрсә, моның сәбәбе аларның "бик начар язуында" гына түгелдер бит? Кайчандыр без ачып биргән басмада безнең әле бер әсәребезне дә басканнары юк.

"Мирас"—фәнни-академик журнал. Аның бурычлары икенче. Шулай да, публицистика белән сугарылган хезмәтләр анда да күренгәли. Мин, мәсәлән, могътәбәр галимнәребез Әхмәт Сәхаповның Гаяз Исхакый һәм башка классиклар иҗатын публицистик яссылыктан өйрәнү, Марсель Әхмәтжановның борынгы әдәбият, эпитафика, шәҗәрәләр һ. б. ш. тармаклар буенча язылган хезмәтләрен, Рәмзи Вәлиевнең Вәисев һәм вәисевчеләр хәрәкәте турындагы гамәли эзләнүләрен татар милли-азатлык хәрәкәтенең иң ташландык, иң өйрәнелмәгән өлкәсен объектив яктыртуда мөһим адымнарның берсе дип саныйм. Күптән түгел бу журнал ("Мирас", 2008, № 3) күренекле, әмма онытылган, безнең күбебез ишетеп тә белмәгән телче-этимолог, Бөре педагогия институты профессоры Рифкать Әхмәтжановның күптән көтелгән сенсацион "Татар этнонимикасы" дигән хезмәтен бастырып чыгарды. Бу—татар-башкорт телләренең этнонимик чагыштырмасы турында тирән публицистика. Укымаган булсагыз, укырга киңәш итәр идем.

III.

Безнең публицистика бүген ике өлештән тора: аның ун-унбиш проценты гамәли публицистика, калган сиксән-туксан проценты "кирәк-кирәк" дип чәпчүдән, үзебезне мактау һәм мактаушудан узмаган мыжыклар публицистикасы.

Гамәли публицистикабызның иң авыр йөген ир-егетләргә биргесез талант, энергия һәм киеренкелек белән хатын-кыз каләмдәшебез—мөхтәрәмә Фәүзия Әүхәди кызы Бәйрәмова тартып бара. Мондый шәхес—язучы, тарихчы, көрәшче хатын-кыз Рәсәйдә бөтенләй дә юк, башка милләтләрдә—булсалар да, бармак белән генә санарлыктыр. Күптән түгел "Чит илләрдәге татар әдәбияты" дигән уникаль монография чыгарган әдәбиятыбыз тарихчысы Хатыйп Миңнегулов "Сөембикә" журналындагы Фәүзиябез турындагы мәкаләсен "Йөз ирнең эшен эшләр" дип бик дөрес атаган. Фәүзия ханым, кайчандыр, менә дигән прозаик, милләт бәхете хакына ялкынлы публицистика, татарның канлы тарихы эченә кереп, үзенең лирик прозасын корбан итте. Кыска гына вакыт арасында дистәдән артык публицистик китаплар, документаль-популяр романнар язып, "таралып яткан татар илен" бер йодрыкка туплый һәм татар этносы бердәмлегенә яңача караш тудыра алды. Татарстанны ваххабит-террористлар оясы итеп күрергә теләгән Лубянка бер гаепсез татар малайларын нефть үткәргечен шартлатуда гаепләп, җинаять эше ачкач, аларны якларга беренче булып Фәүзия күтәрелде. Диния нәзариәтендәге провокаторлар шул ук Лубянка заказын үтәп, мөселман китапларын яндырганда бу китапларны якларга

татар һәм урыс телендәге матбугатта беренче булып Фәүзия күтәрелде. Чиләбенен атом кулләрендә илле ел буе череп яткан татар Мөслимнәре һәм Чибәркүлләре фаҗигасен ул татар фаҗигасе итеп кенә түгел, бар Рәсәй, бар дөнья фаҗигасе итеп күтәреп һәм татар милләтен японнардан кала икенче булып атомнан зыян күргән милләт статусына кертү өчен атом державаларынын парламентлары эшли алмаган эшләрне эшләп, Фәүзиябез күтәрелде.

Әмма Фәүзия Бәйрәмова һәм анын иҗтимагый тормышы, әдәбияттагы роленә килгәндә күнелне күптән кырып килгән нәрсәләр бар. Шул хакта әйтеп китмичә булмый, бу татар әдибе дигән олы исемнең абруен төшерә. Кайберәүләр, менә дистә еллар инде, бу хатыннан көнләшәләр, гавамнын наданлыгы, караңгылыгыннан файдаланып, кара йөрәкле урыстан да әшәкерәк итеп пычратырга тырышалар.

Хисап чорында безне куандырган тагын бер зур публицистыбыз Рафаэль Хәкимовны мин аерым бер канәгатьлек белән телгә алам. Без аны күптән түгел Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителүе белән котлыйбыз.Урыс телендә чыккан "Где наша Мекка?" китабыннан сон анын "Казан утларында" 2006-2007 елларда басылган "Татар рухы" китабы татарнын политологик публицистикасында әлегәчә булмаган күренеш. Ул гамәли-кануни хезмәт. Минем аны укыганнан соң татарнын бигүк ерак булмаган киләчәктә дәүләтле булачагына ышанычым артты. Мин Рафаэль туганны уңышы белән котлыйм. Кем укымаган, аны кичектермичә укып чыгарга тиеш. Аны миллион данәдә урысча һәм татарча бастырып, дөнья буйлап таратырга кирәк. Дөрес, анын Татарстан Президенты ярдәмчесе вазифасыннан китүе безне хафаларга төшерде. Мәскәү державникларынын, башкортчыл шовинистларнын менә ничек куанганын күрсәгез!.. Икенче бер андый кинәшчене Президентыбыз таба алмас кебек. Президент аны барыбер дә үз тирәсеннән һәм Тарих институты белән житәкчелек итүдән җибәрмәсен иде. Чынлап та Рафаэль Хәкимов үзе дә, Президентнын Колшәриф мәчете, Татар энциклопедиясе, Тарих институты, Кремль тыюлыгы кебек берничә генә уңышлы "проект"лары арасында ин уңышлы "шәхес-проект" ларның берсе иде. Ул безнең иҗтимагый фикергә, гамәли публицистикага Әбугалисинә кебек мәгарәдән килеп чыкты һәм фикере белән барыбызны да яктыртты. Яшермим, Рафаэль Хәкимов татарнын империя иләге аша егерме беренче гасырга үтә алган иң акыллы, кабатланмас затларнын берсе. Ул, белеме белән физик булса да, үзе гел генә күләгәдә кала торган тырыш урынбасары, тарих фәннәре докторы Фәрит Солтанов кебек икенче бер могтәбәр зат белән берлектә килешеп эшләп, тарихыбызда беренче тапкыр менә дигән Тарих институты оештырып, Казаннын меңьеллыгын исбатлау, Кремльдә масштаблы казынулар алып барып, меңьеллыкны дөньякүләм үткәрүгә, үзләре тапкан акчаларга йөзләгән сирәк китаплар, "Татар тарихы", картографик "Татарика" кебек капиталь хезмәтләр , Татар энциклопедиясенең өч томын чыгаруга зур өлеш керткән һәм башка дистәләгән проектларны әтисе, сөекле шагыйребез Сибгат ага Хәким (урыны оҗмахта булсын!) кебек салмак тыйнаклык белән тормышка ашырган егетебез ул.

Хәкимов бүгенге империаль шовинизмнын Ильминские ролен башкарган Рәсәй Этнография һәм антропология институты директоры, Башкортстан татарларын башкортлаштыру теория-практикасынын атасы Валерий Тишковнын чын йөзен ача, ул аны тарихи этнографиянең манипуляторы дип, анын хезмәтләрен "Урыс этнографиясенең кояш баешы" дип атау батырлыгына ирешә.Хәкимов ниндидер мәҗүсичелек, ясалма төрки тел, чөй язулары нигезендә кире Алтайга кайту белән мавыгучыларны кисәтә. Табигый ки, бер-берсе белән житәкләшеп йөргән панславян һәм панбашкорт идеологияләренең буш сүз булуын раслаган Хәкимов дәүләти урыс һәм башкорт шовинизмынын кан дошманына әверелде...

Күренекле политолог, төркият галимебез Рафаэль Мөхәммәтдинов та нәтиҗәле эшли. Мөхәммәтдиновнын "Звезда Поволжья» да чыккан «Возрождение возможно?» дигән мәкаләсе укучыларда фурор тудырды.

Гөлчәчәк Галиеванын "Күнелемә якын затлар" дигән әдәби-публицистик китабы да укучыларыбыз күнеленә хуш килде.

Марсель Галинең бу чорда чыккан "Рух" китабын ин җылы хөрмәт белән телгә алырга кирәк. Якты маңгай. Якты тел. Рабит Батулланың "Как сохранить единство России?", "От собаки к горилле" кебек "Звезда Поволжья" да чыккан публицистик мәкаләләре укучы күнелендә яклау тапты. Анын "Урыннары җәннәттә

булсын" исемле саллы китабына карата да шул ук унай бәяләрне әйтергә кирәк. Әмма Марсель дә, Батулла да, мина калса, һәркайсы үз микъдарында бөеклек чире белән чирли кебек.

Ике съезд арасында ижтимагый халәтебездә эз калдырган чыгышлар арасында мин публицистикабызның карт зубры Фәнзаман Батталның "Ватанлылар һәм ватансызлар", аеруча "Бу дөнья кемгә кала?" дигән памфлетларын атар идем. Батталны бездә бердәнбер памфлет остасы дип атарга мөмкиндер."Бу дөнья кемгә кала?» дип бик куркыныч сорау куя автор. Кемгә кала? Безгәме, әллә тегеләргәме? Язучы 2001 елның 11 сентябрендә Нью-Йорк Сәүдә Үзәгендә булган шартлатуны нацистларның 1936 елда Германия рейхстагын яндыру белән тиңли. Моның провокацион асылын ача. Татарга мондый шартлатулар көне-төне бара, ди автор. Йоклыйбыз, эндәшмибез генә. Сәүдә Үзәгендәге шартлау төтене таралып өлгермәстән президент Буш анарда ислам террористларын гаепли башлады. Баксаң, бу яһүд рәссамнарының шәрә Мөхәммәт пәйгамбәрнең карикатураларын тарату, Иракка бәреп керү, мөселман кулы белән Сәддам Хөсәенне асу өчен кирәк булган икән. Укытучыларга 2008 елдагы хезмәт хакын күтәрү, әйтүләренчә, "эчке резерв"—мәктәпләрдән кыскартылачак татар теле-әдәбияты укытучылары исәбенә барачагын шул ук шартлатулар исәбеннән күрергә мәҗбүрбез. Татарга террорист исеме ягу өчен Кукмарада нефть үткәргечләре буйлап баганалар шартлаттыралар. Бер гаепсезгә утырталар. Чынлап та, дөнья кемгә кала? Әгәр Алексий II татарлар алдында көчләп чукындырганнары өчен гафу үтенмәсә, аның мөрәҗәгате белән урыслар якындагы 25 елда мөселманлыкка күчмәсә, Рәсәй империясе җимереләчәк, дигән фикергә килә дә, автор бу дөньяның, без йокласак, якын һәм чит күршеләргә калачагына ишарә ясый.

Безнең арада Рәфикъ Юныс дигән сирәк дәрәҗәдә талантлы, үзенчәлекле публицист һәм шәхес яши. Кайчандыр ул "Татарстан референдумы" дигән бик көчле китап язган иде. Аның "Безне санадылар" дигән баш астында тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков белән "Казан утлары"ндагы халык санын алуга багышланган әңгәмәсен яратып укыйсың. Теманы җиренә җиткереп тәфсилләүдә, фикри аныклык һәм темага житди килүдә безнең барыбызга да Рәфикъ дустыбыздан үрнәк аласы бар. Шундый ук эз калдырган публикацияләр исәбеннән карт гвардия—ветеран публицистыбыз Локман ага Закировның, Фәндәс ага Сафиуллинның "Звезда Поволжья"дагы мәкаләләр серияләре, Миргазиян ага Юныснын "Бер генә телле Россия", "Исергәпкә Мәскәүдән хат", Рәфыйк Шәрәфиевнең "Бүген кайсыбыз Татищев ролендә?", яшьрәкләрдән—үзенә бер союзда торган Зөлфәт Хәкимнең бик тә яхшы "Җинаятьче җиңгән җирдә", Рәшит Фәтхрахманның "Киләчәген бармы, туган тел?", " Тукайны укырлыкмы әлифбабыз?" ,"Иблискә гыйбадәт", Асия Юнысованың "Тын почмакта Такташка урын юк", "Татар китабын яклап", Нурулла Гарифның "Мәскәү—Казан арасы: гасырлар ярасы", бик тә өметле публицистларыбыз Искәндәр Сиражиның "Кемгә һәйкәл куябыз?", "Елак милләткә әверелеп барабыз", Рөстәм Зариповның дистәләгән мәкаләләрен атарга мөмкин.

Соңгы вакытта бездә ниндидер "эзотерик язмалар" дигән жанр, хәтта аның Сократлары да үсеп житеште. Мин эзотериканың нәрсә икәнен белми идем. Бу хакта сүзлекләрдә дә юк икән. Көчкә таптым. Баксаң, ул "яшрен, серле, дини йолалар, мистик тәгълиматләр, магия формулаларында белеме булган кешеләр өчен генә булдырыла торган махсус фән" икән. Солтан Шәмсинең "Күк капусы ачылса...", Рашат Сафинның "Татар миссиясе" дигән күп томлы эзотерик хезмәтләре дин белән мәҗүсилек арасында тирбәлсәләр дә, болай караганда, фикер массажы, фикер гимнастикасы урынына укып карарга кызык кыналар. Әмма алар, минем карашка, публицистика таләпларына җавап биреп, шул фикер гимнастикасы булудан ары үтәлмиләр кебек. Тиз арыталар. Хәрәкәт кирәк. Гамәл кирәк.

Ватан, милләт хакына публицистика белән сугарылган күп санлы хезмәтләр арасында танылган галимнәребез, шулай ук милли матбугат ветераннары Миркасыйм Госманов, Марсель Әхмәтҗанов, Хатыйп Миннегулов, Тәлгат Галиуллин, Мәхмүт Әхмәтҗанов, Рәмзи Вәлиев, Индус Таһиров, Булат Солтанбәков, Фәнис Исламов, урта буын галимнәр, чын дәрәҗәдә этнолог-социолог публицист Дамир Исхаков, төркият белгече Рафаэль Мөхәммәтдинов, археолог Фаяз Хуҗин, урыс телле политолог Марат Хәйруллин, археограф, эпиграфика белгече Раиф Мәрданов

һәм башкаларны күрү яшьләр алдында гармоник буыннар алмашын, киләчәгебез барлыгын күрсәтә.

Бер караганда публицистикабыз бар, хәтта чәчкә дә ата кебек. Әмма дә чәчкә атмый шул, кибә, корый, күбрәк картларга хас чир белән чирли—ул мыжу, чүбек чәйнәү белән мәшгуль. Публицистикабыз чәчкә аткан булса, дошманнарыбыз безне, Рәсәй белән "мактаулы шартнамә" төзегән милләтне, егерме беренче гасыр башыннан мондый методологик нигездә, мондый да котычкыч милли корыту зонасына куып кертә алмаган булырлар, милләтебезнең хәле мондый катастрофик хәлгә төшмәгән булыр иде. Җәмгыятьнең публицистика кебек мондый үткен коралы исән-аман булган хәлдә, без соңгы ун елда телевидениесез, радиосыз, Матбугат Йортсыз, газета-журналларыбыз тиражсыз, журналист-язучыларыбыз эш хаксыз, гонорарсыз, урамнарыбыз исемсез, шәһәребез савапсыз, авылыбыз әдәпсез, соңгы чиктә нә шәһәрсез, нә авылсыз, шәһәребез тормышы җисемсез, авылыбыз ирсез, атсыз, җирсез, җырларыбыз мәгънәсез, ирләребез имансыз, кызларыбыз йөгәнсез калмаган булыр иде. Әгәр без чын язучы-публицистлар булган булсак, республикабызны, милләтебезне бер юлы өч яссылыкта—федераль, үз татарыбыз кулы белән—региональ, җирле чиновниклар тарафыннан—муниципаль яссылыкта күз алдыбызда талатырга, җимерергә бирмәгән булыр идек.

Юк, без бит, бер карасаң, югалтуларыбыз турында көне-төне язабыз. Татар газета-журналлары милләтнең зары, күз яше белән тулган. Әйтик, безнең матбугатта Казан транспортында тукталышларны татарча әйттерү, оешмаларның күрсәтмә такталарын татарча дөрес язу турында меңләгән мәкалә чыккандыр. Әмма үзгәреш юк. Ни өчен? Халык укымыймы? Юк, халык укый. Фикер туа—кардәшебез безне кичерсен, Президент укымый мәллә? Югары Совет рәисе укымый мәллә? Премьер-министр, культура министры Зилә Вәлиева укымый мәллә? Иң мөһиме аларның хезмәтчеләре—пресс-секретарьләре укымый. Еш кына алар татарча "прусты" укый белмәгәнгә укымый. Туган халкың белән туган телеңне белмичә идарә итәргә тырышу—ул манкортлык кына түгел, шыр наданлык. Җитәкчелек исә шуңа юл куя. Үз күзләрем белән күреп беләм: алар, аларга өстәп, шәһәр, район хакимнәре, мәдәният бүлекләре татар газета-журналларын бөтенләй алдырмый. Сөйләр сүзләренең башын "Хөрмәтле милләттәшләр!" дип башлап, калганын ярымграмотасыз урысча сөйләп, алар үзләренең генә түгел, милләтнең зәвыгын бозалар. Оят бит!.. Пресс-секретарьләр татар матбугатының көндәлек канлы яшен хрусталь бәллүргә салып, җитәкчеләренең өстәлләренә кертеп куймый. Шуңа күрә татар матбугатында редакцион мәкалә башларының иң сөеклесе—"Татарстан монда да үрнәк". Нәкъ масоннар медитациясе: таланган саен "үрнәк", ашаган саен каз-үрдәк. Шуңа күрә безгә Федераль салым оешмасыннан, Рәсәй МВДсыннан ай саен рәхмәт хатлары килә. Бүген Татарстанда татар телендәге матбугатны иң нык укымаган, бөтенләй укымаган, укымаулары белән горурланган, халык алдындагы чыгышларында бары тик урысча гына чаптырган, татар халкының телен-гадәтен кимсеткән, бозган тәрбиясез кешеләр кемнәр?—дип сорасалар, мин бу сорауга ике дә уйламыйча "Татарстан җитәкчеләре, Татарстан хөкүмәте, аларның пресса хезмәткәрләре" дип җавап бирер идем. Әгәр миннән бүген "Җир йөзендә татар теленең иң төп дошманы кем?—дип сорасалар, мин ике дә уйламыйча "Оптимальләштерү байрагы астында татар милләтен үлемгә алып барган Татарстан хөкүмәте",—дип җавап биргән булыр идем.

Хәзер Уфа 2010 елда үтәчәк переписьтә калган татарны башкорт итеп язарга, Татарстанның Минзәлә, Чистайларга кадәр территориясен башкортныкы дип игълан итәргә җиң сызганып әзерләнә. Әгәр Башкортстанда башкорт телендә хаталы язылган бер генә вывеска тапмасаң, Татарстанда татарча дөрес язылган бер генә вывеска да табып булмый. Башкортстанда вывескада хата тапкан кешегә бер мең премия бирәләр. Бездә кайчандыр "Гәрәй хан" булган авыллар һаман да Грохань булып йөртелә килә. Минемчә, Татарстанда вывеска текстларын бозып язу буенча яшерен оешма эшли. Катастрофа—Татарстанның дәүләт аппараты манкортлар белән тулды. Алар бет таласа да татарча эндәшә белми. Татарча белмәгән шомабасарлар колоннасы татар мәдәнияте белән җитәкчелек итәргә килде.

Аптырагач, Фәндәс Сафиуллин, Дамир Исхаков, Фәүзия Бәйрәмова, Айдар Халим, Рөстәм Зарипов һәм башка кайбер авторларыбыз җитәкчеләр бәлки урысча

укыйлардыр дип урысча язып, "Звезда Поволжья"да басыла башладылар, нәтиҗәдә урыс телендәге газета татарны яклый торган иң яхшы "русскоязычный" татар газетасына әйләнде. Татар газеталары куркак. Алар халык сакчысы түгел, чиновник сакчысы. Шушындый үләт вөзгыять шартларында татар телендәге публицистика бетә, урыс телле татар публицистикасы көчәя бара. Әмма, кызганычка каршы, Президент белән халык, Президент белән пресса арасында бәйләнеш бер генә—бары Президент ягына гына эшли.

Публицистикабызның киләчәге бармы? Саф, чын публицистлар әзерләнәме?— дигән сорауга җавап эзләп, Казан университетының татар филологиясе һәм журналистика факультетларына киттем. Безнең студентларыбыз нииндирәк темаларга диплом эшләре язалар? Соңгы өч елда менә нинди "көрәшчел" темаларга дипломнар якланган. "Дамир Гарифуллинның әдәби һәм гыйльми-публицистик эшчәнлеге". "Журналист Әхәт Фазылҗанов иҗаты". "Шәмсия Җиһангирова шигырьләренең идея-эстетик үзенчәлекләре... "Образ иконы Божьей Матери". "Специфика спортивной журналистики". "Перспективы рекламы в Казани"...

Менә шулар. Ашыбыз куе түгел бит. Токмачларның да бары тик шомалары гына сайлап алынган. Татар кайгысы белән кайгыру житешми бит. Монда аерым газета-журнал, аеруча күренекле, дистә еллар буе йөкне тартып барган милли публицистлар, кино, радио-телевидение публицистикасы буенча хезмәтләр бөтенләй дә күренми. Күрәсең, алар инде жанр буларак яшәүдән туктаган. Менә шушылардан чыгып, безнең булачак публицистларыбызны кемнәр укытканы аңлашыла төшә. Аларны кемнәр генә укытмый, әмма араларында бүгенге публицистиканы тудыра торган тере классикларыбыз, мөхәррирләребез—Туфаннарыбыз, Батуллаларыбыз, Фәүзияләребез, Фәндәсләребез, Исхаковларыбыз, Дамир Шәрәфетдиннәребез, Хәкимовларыбыз, Фәнзаманнарыбыз, Азат Ахуновларыбыз, Гыйматдиноваларыбыз, Илдархановларыбыз, Фәйзуллиннарыбыз, Марсель Галиләребез генә юк. Мин үзем, мәсәлән, чакырсалар, "Татар халкының дөнья җәмәгатьчелегенә Меморандумы" дигән темага гына да ун лекция укып, аларны шактый айныта, татар, башка халыклар мәгърифәтенә якынайта алган булыр идем. Чакырмыйлар, безнең ишеләр анда урамнарда аунап ятадыр, күрәсең. Ә татар азатлыгында омоним-синонимнардан ары күрергә теләмәгән прафисыр Низамовларның лекцияләрен тыңлап кына әллә кая китеп булмый. Профессура надан һәм ул гамәлсез йокыда. Нәтиҗәдә журналистика буенча белгечләр теоретик яктан әзерлексез, белемсез, сәяси яктан тәмам да офыксыз, тәҗрибәсез булып дөньяга чыга, алар яза да, кыза да, суына да белми, бу бүгенге татар матбугатының барометры булып тора.

Яңарырга, яшәрергә вакыт!..



Рафис
Корбан

# ЗАМАН ЯҢА ГЕРОЙ СОРЫЙ

БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Безнең татар балалар язучылары дип йөртелгән әдипләребезнең күбесе башка жанрларда күбрәк һәм нәтиҗәлерәк иҗат итә. Бүген балалар өчен язган 50ләп язучыбыз булса, шулардан бары тик балалар өчен генә иҗат итә дип мин нибары алты-жиде фамилияне санап үтә алам: Вакыйф Нуриев, Алмаз Гыймадиев, Ләлә

Гыймадиева, Йолдыз Шәрәпова, Сөмбел Гаффарова, Рәшит Бәшәр, Хәлим Җәләй, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Васимә Хәйруллина. Болар—фанатлар.

Әлбәттә инде, һәрберсенең үз сәбәбе бардыр. Шәүкәт Галиев, Роберт Миннуллин, Рабит Батулла, Фәнис Яруллин кебек балалар әдипләребез өлкәннәр өчен дә шәп әсәрләр иҗат итеп, Татарстанның халык язучылары булып танылдылар. Димәк, өлкәннәр өчен иҗат итү аларга файдалырак. Рөстәм Мингалим, Ләбиб Лерон, Фәйрүзә Мөслимова, Асия Юнысова, Мәрзия Фәйзуллина, Резеда Вәлиевалар шулай ук өлкәннәр өчен иҗат итүдән күбрәк файда күрәләр. Әйе, мин файда күрәләр дип әйтәм. Чөнки файда китермәгән хезмәт, ул хезмәт түгел. Бигрәк тә бүгенге заманда. Ә шедеврларны бары тик фанатлар гына тудырырга сәләтле. Һәм, әлбәттә инде, талант иясе!

Ә безнең татар балалар әдәбиятында күптән инде шедеврлар туганы юк. Димәк... талант ягыбыз чамалырак. Шулай турысын ярып әйткәнгә хәтерегез калмасын.

Баштан ук әйтеп китим: бездә татар балалар әдәбияты гаять бай, Кол Галидән алып бүгенге көнгәчә 700 ләп язучы иҗат иткән дип исәпләп чыгарган булсак, шуның 100дән артыгының иҗаты балалар әдәбияты белән бәйле. Һәр жиденең берсе дигән сүз. Бу бүгенге саннар чагыштырмасына да туры килә. Димәк, гомер бакый 7 язучының берсе балалар өчен иҗат иткән! Ә бүгенге балалар язучыларының әдәбиятка керткән өлеше нинди? Соңгы өч елда, ике съезд арасында нәрсәгә ирешкәнбез?

Мин санап киткән чиста балалар язучыларына килгәндә, артык һаваланырлык эшләр күренми. Дөрес, Сөмбел Гаффаровадан кала алар барысы да берәр китап чыгардылар. Ләкин иң уңышлылары дип Алмаз Гыймадиев белән Вакыйф Нуриев китапларын әйтер идем. Алмаз Гыймадиев Татарстан китап нәшриятында чыккан "Ниязның рекордлар китабы" дигән китабы өчен берлекнең Абдулла Алиш исемендәге премиясенә лаек булды. Алмаз "Мәгариф" нәшриятында да "Без андый малай түгел" дигән китап чыгарды. Алмазның хикәя-повестьлары укучыны кызыклы вакыйгаларга, романтик омтылышка, мажаралар дөньясына алып керә, оригиналь стильдә язылган булуы, көтелмәгән чишелешләре белән үзләренә җәлеп итәләр. Ләкин ике нәшриятта ике китап чыгарса да, Алмаз әле үзенең мөмкинлекләрен тулысынча файдаланган, үзен 100 процентка ачып бетергән дип әйтә алмыйм. Ул утырып кына эшләсә, бөтен энергиясен һәм сәләтен әдәби иҗатка гына багышласа, балалар өчен гениаль әсәр иҗат итә алыр иде. Без аннан шундый бер шедевр көтәбез. Кызганычка каршы, шундый сәләте, осталыгы белән, мөмкинлекләре белән, ул үзенең энергиясен ваграк нәрсәләргә сарыф итә.

Былтыр Вакыйф Нуриев безне "Жиденче палата" дигән, бераз Чеховчарак яңгыраган гүзәл китабы белән шатландырды һәм үзенең шулай ук балалар өчен иҗат итүче талантлы язучы икәнен күрсәтте. Ләкин Вакыйф та гафу итмәслек дәрәҗәдә аз яза. Үзенең икенче китабын ул бары тик 50 яшьлек юбилее якынлашканда гына дөньяга чыгара алды.

Шагыйрәләр арасында ялтыраганы Йолдыз Шәрәпова булгандыр, мөгаен. Ул Татарстан китап нәшриятында "Җавапсыз сорау" дигән китабын чыгарды. Йолдыз елдан ел остара, шигырьләре җыйнаклана, кыскара бара. Ул элегрәк елларда чаманы югалтыбрак җибәрә торган иде. Бер шигырьдә ике шигырьне берләштергән чаклары була иде. Бу китабы белән Йолдыз 2003 елда аванс белән бирелгән Алиш исемендәге премиягә лаек икәнлегенниһаять раслады дип әйтергә телим.

Хәлим Җәләй балалар өчен халык әкиятләреннән поэмалар иҗат итеп, Татарстан китап нәшрияты аның "Пәриле күл буенда" дигән китабын бастырып чыгарды. Йөгерек тел, матур бизәкләр белән язылган әкиятләр нәниләр өчен бик матур бүләк булгандыр дип уйларга кирәк.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов белән Васимә Хәйруллина китаплары беркадәр бер-берсенә охшаш булып тоелдылар. Икесе дә шигъриятькә мәктәп тормышын алып керүләре белән аерылып торалар. Мәктәп дәресләрендә ни укытылырга тиешлекне белеп язулары сизелә. Икесенең дә балалар мавыгып укырлык кызыклырак әсәрләр язуларын күрәсе килә.

Ләлә Гыймадиева үзенең юбилеена "Мин аңа бәхет телим" дигән китабын

чыгарды. Җыентыкка нигездә алдагы елларда басылган китапларына кергән әсәрләре тупланганлыктан, аерым тукталып тормаска булдым. Бары тик Ләлә апаның иҗади активлыгын арттыруын гына телисе килә.

Рәшит Бәшәрнең "Мәгариф" нәшриятында чыккан "Җәй кызы" китабы бер шигырьдән торган алфавит булуы белән кызыклы.

Ике корылтай арасында балалар әдәбиятында шагыйрьләребез активлык күрсәтте. Яңа шигырьләр иҗат итмәсәләр дә, Шәүкәт Галиев, Энже Мөэминова, Резеда Вәлиеваларның шигырь китаплары дөнья күрде. Әлегә берлек әгъзалары булмасалар да, Азнакайдан Резеда Шәрипова, Түбән Камадан Илзирә Вәлиуллина кебек яшь шагыйрәләр балалар өчен шигырь китаплары чыгарып балалар әдәбиятына җитди заявка ясадылар. Ләкин балалар өчен китап чыгаручы барлык авторлар да хуплауга лаек дип әйтеп булмый әлегә. Әлмәттән Роза Солтанова исемле шагыйрә-мөгаллимәнең "Балачак сукмаклары" дигән китабы, аннотациясендә "автор яшь дусларының—кызлар һәм малайларның рухи халәтләрен, фикерләү рәвешләрен, кичерешләрен яхшы белә",—дип язылса да, шул халәт-кичерешләрне шигырьгә сала, шигырь итеп тасвирлап бирә белми икән. Аның 41 язмасы арасында бер генә шигырь дә булмавы һәм шул китапны "Сүз" нәшриятының бастырып чыгарып, укучыларга тәкъдим итүе, тыйнак кына итеп әйткәндә, йөрәкне әрнетә. Ә күзгә карап, дөресен генә әйткәндә моның ише басмалар балалар әдәбиятына каршы эшли; укытучы кулы белән язылган булуы бигрәк тә әдәбият белән кызыксынучы балалар өчен зур зыян китерә. Чөнки укытучылар гадәттә үзләре язган шигырьләр үрнәгендә балада әдәбиятка карата мөнәсәбәт тәрбиялиләр, ә бу очракта ул тискәре мөнәсәбәткә әверелә, һәрхәлдә, тискәре роль уйный.

"Рухият" нәшрияты әдипләребезнең китапларын бастырып бик зур эш башкара. 2007 елда нәшрият нәниләр өчен дә бүләк ясады—"Балаларга бүләк—Подарок детям" дигән исемдә татарчалы-урысчалы китап бастырып чыгарды. Биредә шул исемдәге әдәби конкурста катнашкан каләм әһелләренең иң яхшы дип табылган әсәрләре урын алган. Арада инде исемнәре яхшы таныш Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Альберт Хәсәнов, Рәмзия Габделхакова, Камил Гыйльмуллин, Резеда Шәрипова, Илүсә Нәбиуллина, Әхтәм Фәтхи, Таһир Шәмсуаров кебек авторлар белән бергә, әле янарак каләм тибрәтә башлаган яшьләрнең дә шигырь-хикәяләренә киң урын бирелгән. Шактый саллы, колачлы гына басма килеп чыккан. Әмма ләкин китапны укып чыккач, кызганычка каршы, балалар өчен чын мәгънәсендә бүләк булырлык искиткеч әсәр күреп сөенә алмадым.

Ике корылтай арасында прозаикларыбыз да балалар өчен азмы-күпме иҗат итте. Вакыйф Нуриев белән Алмаз Гыймадиевтан кала Эльмира Шәрифуллина, Фирдәвес Зариф, Әмирҗан Моталлапов, Әнәс Хәсәнов, Флера Тарханова, Нәкыйп Каштанов нәниләрне хикәя һәм әкият китаплары белән сөендерде. Ләкин бу китаплар берсе дә балаларның, нәниләрнең үз тормышын сурәтләгән әсәрләр түгел иде. Һәм, әйтергә кирәк, барысы да икенчел, инде әдәбиятта булган, укылган әсәрләр тәэсирендә иҗат ителгән булулары белән кызыксыз тоелдылар. Ә менә яшь язучылар, әлегә берлеккә кабул ителмәгән Лилия Закирова, Илшат Сәйфуллин, Айгөл Әхмәтгалиеваларның китаплары укучылар күнелендә бары тик җылы тәэсирләр генә уяткандыр. Аларның хикәяләрендә мәктәп укучыларының, балаларның үз тормышларыннан алынган вакыйгалар тасвирлана, балаларның үз күзәтүләре нигезендә туган сюжетлар бәян ителә. Һәм шуның белән бу авторлар китап укучыларны битараф калдырмыйча, аларның яңа әсәрләрен төрле газит-журнал битләреннән эзлисен, күреп сөенәсен, йотлыгып укыйсың. Нәкъ менә шушы авторларны мин киләчәктә Ләбибә Ихсанова, Роза Хафизова кебек балалар язучыларының алмашчылары булыр дип өметләнәм.

Яшь алмаш дигәннән, соңгы елларда балалар әдәбиятына өметле яшь каләм ияләре җитди заявка ясады дип әйтергә мөмкин.

"Шәһри Казан" газитенең узган елгы 29 июнь санында Резеда Вәлиева һәм Галимҗан Гыйльманов бик җитди кайгыртучанлык белән "балалар әдәбиятына яшьләр килми" дип интервью бирсәләр дә, аларның бу сүзләре белән һич кенә дә килешәсе килми. Чөнки, Аллага шөкер, балалар әдәбиятына яшьләр килә. Аларның

исемнәрен мин инде алда санап үттем. Әле болардан тыш та әдәбиятыбызның киләчәге булырдай өметле яшь каләм ияләре үсә. Ленар Шәех, Айсылу Имамиева, Рөстәм Галиуллиннарның иҗатлары балалар әдәбияты секциясендә тикшерелеп, китаплары басмага тәкъдим ителде. Ленар Шәех инде ике китап чыгарырга өлгерде һәм Язучылар берлегенә кабул ителде. Ижевскидан Гүзәл Исхакова Татарстан китап нәшриятында "Керпе—Ежик" һәм "Сөенеч—Радость" исемле татарчалы-урысчалы китаплар чыгарып, шулай ук берлеккә тәкъдим ителде. Чаллыда Булат Садретдинов, Азнакайда Римма Шәехова исемле өметле шагыйрьләребез үсеп килә.

Аннары, Абдулла Алишның туган көне уңаеннан татар балалар китабы атналыгы уздыруны традициягә кертә баруыбыз да яшь алмаш әзерләүгә эшли. Атналыкның беренче көнендә менә өч ел инде иҗат итүче яшь каләм ияләрен—укучыларны Казан дәүләт курчак театрына җыеп, балалар китабы бәйрәме уздырдык. Балалар язучылары белән очрашу укучыларның үз иҗат үрнәкләрен таныштырулар белән аралаштырып уза. Иң яхшы дип табылган язмаларны сайлап 2006 елда Татарстан китап нәшриятында "Алмаш" дигән китап та бастырып чыгардык.

Ике съезд арасында балалар китабына игътибар артуны билгеләп үтәргә кирәк. Матбугатта татар балалар китабы турында, дөресрәге татар балалар китабының юклыгы хакында күп бәхәсләр булып алды. Проблеманы белгәне дә, белмәгәне дә язды. "Татарстан яшьләре" газитендә Гөлнара Сабирова исемле журналистлары хәтта абсурд дәрәҗәсендәге, мәгънәсез һәм хәтәр фикерләр язып чыгуга кадәр барып җитте. Аның өчен инде матур итеп бизәп чыгарылган Тукай әкиятләре дә, Роберт Миңнуллин шигырьләре дә, татарча тәрҗемәдә чыккан "Робинзон Крузо", "Винни Пух мажаралары" да кызык түгел, балалар өчен искергән булып санала. "Тукай әкиятләре, "Танбатыр", "Үги кыз" кебек халык әкиятләре матур, әмма вакыт та алга бара бит, җәмәгать. Элек бу бала җиде класс бетереп туган дип әйткәннәр, аннан ун класс бетереп туган дия башладылар, хәзер вуз бетереп туган дисәң дә ярыйдыр. Димәк, аларның ихтыяҗлары, мәнфәгатьләре, кызыксынулары да күпкә югары,—ди Гөлнара.—...Заманчалык җитешмәү генә түгел, ул бөтенләй юк әдәбиятта. Әгәр булса, балалар китап укыр иде. "Нечкәбил", "Камырша", "Кәҗә белән Сарык" никадәр генә кызык булса да, туйдыра бит ул. Минем әти-әнием шуны укып үскән, мин шуны укыдым, хәзер минем балам да шуны укырга тиешме?" Мин бу юлларны әлеге шул Гөлнара Сабированың "Татарстан яшьләре"нең 2006 елгы 26 гыйнвар санында чыккан "Кем булырсың син бала?" дигән мәкаләсеннән китерәм, җәмәгать. Бу язманы укыгач, мин безнең газитләрдә татар әдәбиятын, фольклорын белми торган гына түгел, бәлки яратмый торган журналистлар эшли икән дигән фикергә килдем һәм куркуга калдым. "Гарри Поттер кирәк безнең заман баласына!"—ди Г. Сабирова. Ә үзе Гарри Поттерның шул ук татар әкиятләрендәге Таң батырлар, Дутан батырлар, Турай, Камыр батырлар, Дию пәриләре, убырлы карчыклар ясаган могҗизаларның янача, язучы фантазиясендә туган, заман технологияләрен файдаланып язылган варианты икәнен аңламый.

"Балалар китабы юк, балалар китабын чыгарырга теләүчеләргә нәшриятта аяк чалып утыралар" дигән сүз бары тик проблеманы һәм хәлнең бүгенге торышын белмәүче, сенсация артыннан куучы журналистлар тарафыннан уйлап чыгарылган нәрсә генә. Чөнки Татарстан китап нәшриятының Бауман урамындагы китап кибетенә генә кереп карасаң да балалар китабының күплегенә, төрлелегенә һәм затлылыгына сокланасың! Ә инде картон китаплар булмау, картоннан ясалган уенчык формасындагы китаплар күренмәү ул бары тик Татарстанда андый китап ясау технологиясенең җитешмәвенә генә бәйле. Игътибар итсәгез, андый китаплар хәтта Мәскәүдә дә басылмаган, бәлки Ростовта яисә Кытайда ук эшләнгәнлеген күрерсез. Заман әкияти тизлектә алга бара. Бездә дә картон китап ясау машиналары барлыкка килер, Алла боерса! Ләкин бер нәрсә күңелне борчый һәм—бик җитди нәрсә! Ул да булса, балалар өчен әйбәт әсәрләрнең аз язылуы. Язучыларыбызда фантазия җитеп бетми. Соңгы өч елда әдәбиятта вакыйга булырлык яңа әсәр иҗат ителмәде, яңа геройлар тумады. Мамадышта яшәп иҗат итүче Рафаэль Газизовка "Бүләгем" китабы өчен Андерсен исемендәге Халыкара Почетлы диплом бирелде бирелүен, ләкин ул да аның 2003 елда чыккан китабы һәм күпкә элегрәк язган

шигырьләре өчен булды. Әйе, соңгы еллар балалар әдәбиятында яңа Шәвәлиләр дә тумады, Кирлеманнар дә барлыкка килмәде, Камыршалар да язылмады. Мин беркемнең дә исемен атарга теләмим. Үзем дә шул исемлектә булыр идем. Бар бит дөнья балалар әдәбиятында мавыктыргыч геройлар. Пиноккио, Буратино, Карлсон, Маугли, Микки-Маус, Чиполлино, Крокодил Гена, Чебурашка, Муха-Цокотуха, Айболит, Мойдодыр, Бармалей, Бибигон, Дядя Степа, Кот Матроскин, Винни-Пух, Золушка, Красная Шапочка, Белмәмеш һәм башка бик күп әкият геройлары иҗат ителгән бит. Безнең балалар китабы юк дип чаң сугучы Гөлнара Сабировалар бәлки әнә шундый геройлар юк дип әйтергә телидер. Әгәр шулай булса, алар сүзендә хаклык бар, җәмәгать. Чыгышымны шушы урында түгәрәкләп, мин сезне, кадерле каләмдәшләрем, әнә шундый берәр герой уйлап табарга, шуның турында маҗаралы әсәр иҗат итәргә чакырам. Әйдәгез әле, күрсәтик үзебезне. Бәлки бу эш безнең хәлдән киләдер.



Мансур
Вәли-Барҗылы

## ТӘНКЫЙТЬНЕ КЕМ ЯРАТА?

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Әйе, без бүген әдәбиятыбыздагы бер генә жанрдан да тулысынча канәгать була алмыйбыз. Проза дисәк, анда үзенең катлаулы язмышы, көчле характеры белән укучыга нык тәэсир ясый алырдай колоритлы геройлар җитешми. Шигъриятебезнең поэма дигән өлеше заман мөмкинлек биргән, укучы күңеле көткән таләпләрне акламый. Драматургиябездәге җитешсезлекләр турында да матбугатта сүз булгалап тора.

Әйе, бер генә жанр да кимчелексез түгел.

Әмма бүген безне барыннан да элек әдәби тәнкыйтебезнең торышы борчый.

Дөресен әйтергә кирәк: бүгенге әдәби тәнкыйтьнең хәленнән хәтта тәнкыйтьчеләр үзләре дә канәгать түгел!

Ни өчен?

Бүген безнең иҗади берлегебездә 30дан артык әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче әгъза булып тора—ягъни якынча 10 язучыга берәү дигән сүз бу.

Ләкин шул ук вакытта искәртеп үтик: аларның һәммәсе казна эшендә эшли— институтта укыта яки редакциядә хезмәт итә. Безнең бары тик әдәби тәнкыйть белән генә шөгыльләнүче профессиональ әдәби тәнкыйтьчеләребез юк. Шуңа күрә, аларның чынлап та вакытлары бик кысан булганга күрә, тегеяки бу җыелышка докладчылар эзләгәндә яки остаханә утырышлары уздырганда кыенлыклар да килеп туа.

Әйе, бөтен яктан әзерлекле, иҗади яктан актив тәнкыйтьчеләребез җитәрлек. Әмма без ни өчен һаман-һаман "тәнкыйть юк", "тәнкыйть йоклый" диеп зарланышабыз соң?

Бу сорауга җавапны безнең намуслы һәм эшчән галимәбез, һәм әдәби тәнкыйтьче Рифә Рахман язып чыкты инде.

"...Күп кенә газета-журналларның редакторлары тәнкыйть язмасын күрүгә үк,

яисә фәлән темага языйм әле" дип әйтүгә үк, барыбер басмыйбыз дип торалар...".

Р. Рахманның дөрес фикерен дәвам итеп тагын шуны әйтәсе килә: усал,принципиаль, гадел әдәби тәнкыйть, болай караганда, һәммәбезгә кирәк, барыбыз да "әдәби тәнкыйть юк ул" дияргә әзер, ләкин әйдәгез әле, шуны йөрәк турына куеп сөйләшик: гадел, принципиаль, хәтта усал тәнкыйтьне язучыларыбызның кайсылары чын егетләрчә кабул итә ала? Матбугатта аз гына тәнкыйть булса да шундук күсәккә тотынабыз бит! Шәхси үпкәне инде әйткән дә юк!

Бу хәлдән чыгу юлы бармы соң?

Минемчә, бар!

Без ин якын арада үзебезнең "Мәдәни жомга" газетабызны жанлы тәнкыйть мәйданына әверелдерергә тиешбез.

Ни өчен нәкъ менә "Мәдәни жомга"ны? Чөнки ул атна саен чыга һәм анда әдәбият-сәнгать мәсьәләләре үзәктә торырга тиеш. Димәк, бары тик шушы басма гына безгә оператив һәм кыю әдәби тәнкыйтьне жанландыру мәйданы була ала!

Ике корылтай арасында эшләнгән эшләргә килсәк, без бу чорда әдәби тәнкыйтьнең актив формаларына, ягъни дискуссияләргә, түгәрәк өстәл сөйләшүләренә, төрле характердагы әңгәмәләргә күбрәк игътибар бирергә тырыштык.

"Казан утлары" битләрендә барган һәм ике елдан артык вакыт дәвам иткән "Безнең заман герое" дигән дискуссия озак елларга хәтердә калырдай вакыйга булды. Анда күпләгән язучылар, тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият сөючеләр катнашты. Әгәр дә бу дискуссия материалларын бергә туплап китап итеп бастырсан—саллы-саллы берничә том хасил булыр иде.

Шулай ук 2006 елда Язучылар берлеге бинасында проза остаханәсе белән берлектә уздырылган "Бүгенге хикәя турында сөйләшү" дә бик мәгънәле үтте. Анда төп докладчы итеп бу жанрның остасы Мәгъсүм ага Хуҗин билгеләнгән иде. Аның доклады мәсьәләне тирәннән алып тикшерүе, бүгенге көн өчен үтә дә актуаль булган сөземтәләр чыгаруы, кайбер әсәрләргә конкрет анализ ясап ышандыруы белән яхшы тәэсир калдырды. Сөйләшүдә яшь иҗатчылар аеруча күп иде, остазның фикерләре алар өчен бигрәк тә файдалы булгандыр.

Әдәби-тәнкыйть остаханәсе инициативасы белән редакцияләргә барып күчмә утырышлар үткәрү гадәткә кереп китте дияргә була. Шундый утырышларны без "Ватаным Татарстан" газетасында, "Казан утлары" журналында үткәрдек. Шулай ук "Мәдәни жомга" редакциясендә җыелып әдәби тәнкыйтьне ничек жанландыру турында киңәшергә уйлап торабыз.

Аерым авторларның иҗатларын үзәккә куеп сөйләшүләр дә тулаем иҗади процессны жанландыруга һәм шул исәптән тәнкыйть фикерен үстерүгә ярдәм итә. Ике корылтай арасында андый күнелле вакыйгалар да байтак булды.

Мәсәлән, яшь язучы Халисә Ширмәннең бер хикәясен укып тикшерүдә прозаиклар да, тәнкыйтьчеләр дә актив катнашты. Биредә әлеге бер әсәр турында да, тулаем хикәя жанры хакында да бик кызыклы күзәтүләр әйтелде, иҗади бәхәс минутлары да булды.

Тәнкыйтьче Илшат Вәлиулла иҗатын тикшерү исә аның соңгы елларда басылып чыккан ике китабы нигезендә барды, профессиональ дәрәҗәдә барды. Нәтиҗәдә, ул иҗади берлеккә тәкъдим ителде һәм соңрак бертавыштан узды да. Сүз уңаеннан берлеккә ике корылтай арасында 4 тәнкыйтьче алынды: И. Вәлиулла, Х. Бәдигый, Г. Арсланов, Ф. Бәширов.

Әйе, тәнкыйтьнең төрле жанрларын жанландыру өчен байтак көч куела, ләкин безнең вакытлы матбугатта әдәби тәнкыйтькә тиешенчә игътибар бирелми. Соңгы елларда без "Халыкның китапка, әдәбиятка игътибары нык кимеде" дип еш әйтәбез, әмма газета-журналларыбыз үзләре дә китап һәм әдәби әсәр турында аз язгач—бу нәрсә була соң инде?! Безнең матбугат телевидение шаукымына бирелеп, шундый ук шау-шулы темалар агымына иярде түгелме? Ә безнең матбугат нигә але тормышның, яшәешнең иң төп, иң асыл кыйммәтләре турында аз яза? Шушы житешсезлекне бетерүдә әдәбият, әдәби әсәр—иң әйбәт мөмкинлек бит инде ул!

Әдәбият бит ул мәңгелек кыйммәтләр, рухи хәзинә турында сүз йөртә. Теге яки бу китап чыгу уңае белән матбугатта әнә шул мәсьәләләр турында язу—халык,

укучы көткән җан азыгы булыр иде.

Сүз уңаенда шунысын да әйтеп китик: без элегрәк "халыкның игътибарын телевизор тарта" дип кабатлый идек, "шуңа күрә халыкның китап укырга вакыты калмый" дип әйтә идек. Әмма торган саен шул ачыклана бара—телевидениенең дә мөмкинлекләре чиксез түгел икән! Андагы тоташ шаулар, сугыш-үтереш кешене туйдыра икән! Китапны, әдәби әсәрне телевизор һич кенә дә алмаштыра алмый икән! Бу сабак безнең газета-журналларга да дөрес юл табуда ярдәм итәр дип ышаныйк. Китап турында язудан курыккан газетаны да якын киләчәктә кризис көтеп тора.

Ике корылтай арасында безнең өлкән буын тәнкыйтьчеләребез актив иҗат итте. Кабатлап әйтәм: алар бит әле бер үк вакытта югары уку йорты укытучылары да.

Фәрит ага Хатиповның "Әсәрнең эстетик җегәре" һәм "Нахактан аралау юнәлешендә", Тәлгать ага Галиуллинның Сибгат Хәким иҗатын өр-яңа яктылыкта карау үзенчәлеге белән аерылып торган "Бәрелде җан, сугылды җан ярсып" мәкаләсе, Фатих ага Урманчеевның "Фәрештәләр санап бара күз яшен", Азат ага Әхмәдуллинның Тәлгат Галиуллин иҗатына кагылган мәкаләсе, Рифат ага Сверигинның Ф. Хөсни һәм М. Әмир иҗатлары турындагы мәкаләләре яшь каләм ияләренә күп яктан үрнәк булырлык әдәби тәнкыйть әсәрләре.

Шулай ук бу чорда өлкән буын авторларыбыздан Фоат ага Галимуллинның, Азат ага Әхмәдуллинның, Фатих Урманчеевның, Тәлгат Галиуллинның саллы китаплары да дөнья күрде.

Рәфыйк ага Шәрәфиев вакытлы матбугат битләрендә үзенең актуаль эчтәлекле, кызыклы язылган язмаларын еш бастырды.

Үзләре саф тәнкыйтьче булмасалар да тәнкыйди язмалар белән Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ, Айдар Хәлим, Роберт Әхмәтҗанов һ. б. әфәнделәр истә калырдай чыгышлар ясадылар.

Ике корылтай арасында башка авторларның да житди хезмәтләре дөнья күрде. Дания ханым Заһидуллинаның "Мәгариф" нәшриятында "Дөнья сурәте үзгәрү" исемле монографиясе үзе житди бер сөйләшүгә лаек иде. Һәм бу хезмәт турында халык шагыйре Ренат Харис "Мәдәни җомга" газетасында тәфсилле мәкалә дә бастырды. Дания ханымның бу чорда бүтән китаплары да (мәсәлән, "Яңа дулкында") һәм мәкаләләре дә дөнья күрде. Факил Сафин иҗатына багышланган "Яңа юллар бәхете" исемле күләмле мәкаләсе исә иҗат портретлары тудыру юнәлешендәге житди уңыш булып тора.

Нәкъ менә шушы урында безнең шигъри җанлы тәнкыйтьчебез Мөдәррис Вәлиевнең "Милли китап" нәшриятында басылып чыккан "Визит карточкасы" исемле һәммә яктан матур китабын искә алмый үтсәк һич тә дөрес булмас. Чөнки бу китапта (ул рус телендә) милли китап тарихы да, аның авыр язмышы да, милли китапның бүгенге хәле өчен чын йөрәктән борчылу һәм эшлекле кайгырту да, шулай ук әдәбиятыбызның үткен проблемалары һәм аерым язучыларыбыз иҗаты да чагылдырыла. Әлеге китапны авторның гына түгел, ә тулаем милли китапның, халкыбызның "визит карточкасы" дип әйтергә мөмкин.

Ике корылтай арасында Илшат Вәлиулла үзенең "Һәр шагыйрь—бер дәрья" исемле тәүге җыентыгын чыгарды, "Казан утлары" журналында Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләм, Газинур Морат һәм Марат Закиров турындагы әдәби тәнкыйть язмаларын бастырды.

Филология фәннәре докторы Фәрит Бәширов бу чорда шулай ук актив иҗат итте. Аның Фәнис Яруллин әсәрләре турындагы язмасы мавыгып укыла, автор язмышы һәм иҗаты турында мул мәгълүмат бирә.

Хәнәфи Бәдигый һәм Әлфәт Закирҗановның житди эчтәлекле тәнкыйди язмалары бу чорда матбугатта шактый басылды, әдәби тормышыбызның яңа якларын ачты.

Яңа исемнәрдән соңгы елларда безне Фәридә Хәсәнова аеруча сөендерде. Аның матбугатта төрле проблемага багышланган төпле мәкаләләре дөнья күрде, шулай ук ул Ренат Харис шигъриятенә багышланган житди эчтәлекле китабын да бастырды.

Әйе, никадәр генә зарлансак та, бүгенге әдәби тәнкыйтьнең уңышлары да юк

түгел. Алда әйтеп үткәнебезчә, әзерлекле һәм актив рухи тормыш белән яшәүче тәнкыйтьчеләребез дә житәрлек.

Ә тагын да ачыграк итеп әйтсәк: бездә житди проблемаларга багышланган әдәби тәнкыйть бар, югарыда күрсәтеп узганыбызча, саллы-саллы әдәби тәнкыйть һәм әдәбият фәне буенча китаплар байтак кына чыга тора. Болары—әйбәт!

Әмма бездә оператив тәнкыйть бик аксый.

Мона ин төп сәбәпләрдән берсе—әдәби тәнкыйть үсүне чынлап та теләгән газета юк! Чын тәнкыйтьне үз иткән, аны оештырган оператив басма юк!

Без ин якын киләчәктә матбугат битләрен әдәби тәнкыйтьчеләребезнен ялкынлы һәм тирән эчтәлекле язмалары белән баетырга тиешбез.

Ә мона ирешү ул укучы, халык күнелен, рухын тәрбияләүдә көтелгән һәм мөһим адым булачак. Халыкны рухи һәм әхлакый тәрбияләү буенча башланырга тиешле зур эшнен бер мөһим өлеше булачак!



Лилия Газизова

## ЗАМАН СУЛЫШЫ

### РУС ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ ТӘРЖЕМӘ

Татарстандагы рус телле әдәбиятка игътибар юнәлтсәк, вакытлы матбугат битләрендә дә, китап нәшриятларында да, нигездә, шигъри әсәрләрнен һәм жыентыкларнын дөнья күрүен билгели алабыз. Алар күпмедер дәрәжәдә Татарстаннын әдәби йөзен дә билгели. Республикабыздагы бүгенге әдәби процесснын аерым бер тенденцияләрен билгеләү барышында мин 2005—2008 елларда—ике съезд аралыгында дөнья күргән китаплардан ин игътибарны жәлеп иткәннәренә тукталып үтәргә булдым.

### Шигърият

Шигърият өлкәсендәге ин үзенчәлекле жыентыкларнын берсе буларак Николай Алешковнын "Сын Петра и Мариши" тупланмасын атарга мөмкин. Авторнын шигырьләре рус классик поэзиясе кысаларында язылган, биредә ул Кольцов, Есениннардан килгән традицияләрне дәвам итә. Күпләгән яшь авторларнын техник яктан да, образлылык ягыннан да "яхшы эшләнгән", әмма эчке мәгънәви бөтенлеккә ия булмаган шигырьләре белән чагыштырганда, Алешковнын шигърияте үзенен хисси тирәнлеге белән аерылып тора. Авторнын һәрбер шигыре тәгалләнгән бербөтенне тәшкил итә. 2007 елда Мәскәү шәһәрендә анын "Свет небесный" дип исемләнгән чираттагы шигырь жыентыгы да дөнья күрде.

Татарстан китап нәшриятында Рөстәм Кутуйнын "Профиль ветра" дип исемләнгән сайланма шигырьләр жыентыгы басылып чыкты. Әлеге жыентыктагы күпчелек шигырьләр вакыт сынавын үткән әсәрләр, алар авторнын элеккеге китапларында да урын алган иде. Рөстәм Кутуй татар әдәбиятын рус теленә тәржемә итүче буларак та билгеле. Үткән елда Р. Акъегетнен бу автор тәржемәләреннән тупланган жыентыгы дөнья күрде.

2005 елда шагыйрә Ольга Левадная нын ике шигырь жыентыгы басылып чыкты:

"Из крика птиц вырастают воспоминания..." һәм "Поднимаясь по лестнице раздумий...". Беренче җыентык Казанның меңьеллыгына багышланган. Авторның шигырьләре дүрт телдә—рус, татар, төрек һәм инглиз телләрендә тәкъдим ителә. Икенче җыентык—"Поднимаясь по лестнице раздумий..." Бөек Җиңүнең 60 еллыгына багышлана һәм үз эченә авторның бабасының фронттан язган хатларын, фотографияләрен һәм балачак рәсемнәрен туплый.

**P. S.** Л. Янсуар тәрҗемәсе.

Озак вакыт күренми торганнан соң Фәридә Рәсүлова үзенең яңа китабын бастырды. Ул "Кончается время" дип исемләнгән. Бу җыентыкта шагыйрәнең дини характердагы лирикасы тупланган, андагы шигырьләр Аллаһ белән сөйләшү, аны тоемлау рухында язылган. Элек, совет чорында, бу төр шигырьләрнең дөнья күрүе мөмкин булмас иде. Бүген исә алар, авангард, модернистик юнәлештәге шигърият белән беррәттән, яңа сулыш алдылар. Югарыда атап үткән авторның иҗатына карата түбәндәгеләрне әйтәсе килә: Фәридә Рәсүлова сүз җегәрен, көчен тоеп яза, аның шигырьләре образлылык, мәгънәви яктан ачыклыгы белән аерылып тора. Дөрес, җыентыкта яктырак рухлы шигырьләрнең булмавы бераз сәерсенү тойгысы калдыра.

"Плутон" нәшриятында Наилә Ахунованың өч шигырь җыентыгы дөнья күрде: "Вечернее солнце", "Окно", "Чему улыбается ночь". Бу җыентыклар арасыннан соңгысы кыска шигырьләрдән тупланган: болар—"хокку" жанрындагы өчьюллыклар. Әлеге шигырьләр авторның япон шигъриятен үз итүен һәм "хокку" жанрына мөкиббәнлеген күрсәтә. Шулай да, Наилә Ахунова рус кешесе өчен ят булган бу үлчәмгә үз күзаллавын һәм җирле колоритны әйбәт сыйдыра.

Алена Кәримованың Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан "Другое платье" китабы шагыйрәнең соңгы ун ел эчендә язганнарыннан тупланган мини-сайланмасы буларак кабул ителә ала. Алена Кәримова күпчелек ир-ат шагыйрьләргә дә хас булмаган кырыс рухта яза. Аның шигырьләре киеренкелек һәм энергиягә бай.

Михаил Тузовның "Моя линия", "Амбивалентность", Взгляды" җыентыклары басылып чыкты. Инде беренче җыентыкның исеменнән үк күренгәнчә, авторның тормыш—яшәешкә карата шактый кырыс, кайчак бәхәсле дә карашта торуын тоярга мөмкин. Балачак тәэсирләре, яшьлек коллизияләре, армия чоры кичерешләре, мәхәббәт, яшәү—үлем турындагы мәңгелек темаларның калку гәүдәләнеше—болар барысы да Михаил Тузов лирикасының үзәгендә тора.

Әле чагыштырмача яшь, әмма инде танылып өлгергән шагыйрә Александра Кашинаның "Кочевница сердца" исемле җыентыгының басылып чыгуы да бер вакыйга буларак кабул ителде. Александраның иҗаты самимилек, үзирониягә корылыш, яңа формаларга тартылу, экспериментлардан курыкмау белән игътибарны җәлеп итә.

Балалар әдәбияты берьюлы өч җыентыкка баеды. Бу—Борис Вайнерның Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән "Нинзя из Самураевки", "Мәгариф" нәшриятында басылган "Чудесное зеркало" һәм "Школьные хайку" җыентыклары.

2008 елда Лилия Газизованың "В ладу с размирьем" дип исемләнгән яңа китабы дөнья күрде. Анда XXI гасырда язылган шигырьләр тупланган. Җыентыкның бүленеше һәм бүлек исемнәренең бирелеше буенча шагыйрәнең иҗатында нинди темалар үзәктә торуын күзалларга мөмкин.

Казанда яшәп иҗат итүче шагыйрьләрнең иҗатын туплаган "Как время катится в Казани золотое..." исемле рус шигърияте антологиясе дөнья күрүе (төзүчесе—Лилия Газизова) зур вакыйга буларак билгеләнергә лаеклы. Бу җыентыкка язмышлары һәм иҗаты Казан белән бәйле йөз иллегә якын шагыйрьнең әсәре керде. Аларның иҗат ителү чоры 1940—2005 еллар белән билгеләнә. Татарстан Республикасының премьер—министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева әйткәнчә, бу җыентык—"Казан шагыйрьләренең тормышка, кеше шәхесенә һәм аның бүгенге яшәешебездәге урынына карата булган карашларын туплаган кечкенә бер энциклопедия".

## Проза

Диас Вәлиев инде шактыйдан фәлсәфи проза жанрына өстенлек бирә. Үзенең “Откровение от Диаса” дип исемләнгән яңа китабында ул, мөгаен, бу жанр мөмкинлекләреннән иң югары дәрәҗәдә файдалана. Биредә автор яңа диннең хәбәрчесе буларак чыгыш ясый. Язучының фикерләре белән килешмәскә, бәхәсләшергә мөмкин, әмма китап чыннан да кызыклы булуы белән игътибарны җәлеп итә. Җыентыкка язган кереш сүзен Диас Вәлиев түбәндәге юллар белән тәмамлый: “Бүген без Ходайга карата булган яңа сүзнең тик башында гына торабыз. Киләчәктә күпме мосафир атлар әле бу юлга һәм күпме ихлас укучы, житлеккән укытучылар пәйда булыр!” Диас Вәлиевнең икенче бер китабы—”Чужой” 2007 елда дөнья күрде. Ул сюжет ягыннан үзенчәлекле “Я” романын, автобиографик “Чужой, или в очереди на Голгофу” роман-документын һәм “Приключения двух героев” исемле роман-әкиятне туплаган. Китапның аннотациясендә язылганча, җыентыктагы әсәрләр “сәерлек” “мөһере”нә, беркадәр ирреальлеккә ия.

Лев Кожевниковның үзәгендә бер герой белән бәйле вакыйгалардан торган берничә детектив повестьны туплаган “Красный прокурор” китабы дөнья күрде. Бу авторның әсәрләре һәрвакыт мавыктыргыч сюжетка ия, ул үзе исә әсәренең үзәген тәшкил иткән материалны яхшы белүе белән аерылып тора. Китап һичшиксез укучыларны кызыксындырыр дип уйлыйм.

Рөстәм Сабировның “Беглец” дип исемләнгән яңа китабында авторның ике повесте урын алган. Алар бер-берсеннән шактый аерыла: берсе “Лесоповал” дигән криминаль драмасы, икенчесе "Беглец" исемле тарихи фантазия. Шулай да әчке бер бөтенлек бу ике мөстәкыйль әсәрне бер исем астында берләштерергә мөмкинлек бирә һәм бу исем үзен аклый. Элегрәк Рөстәм Сабиров үзенчәлекле шигырьләр язучы автор буларак билгеле иде. Аның хәзерге проза әсәрләрендә дә бу сизелә. Автор сюжет төзү остасы гына түгел, ә стиль остасы да.

"Сквозняк тишины"—Салават Юзеевның повесть һәм хикәяләр тупланмасы шулай дип исемләнгән. Салават Юзеев прозасына психологизм һәм тормыш чынбарлыгын ачык чагылдыру, сюжет төзүдә оригинальлек һәм геройларының заманча бирелеше хас.

Татарстан китап нәшриятында Инга Бикбулатованың "Любви все возрасты..." исемле повестьлар һәм хикәяләр тупланмасы басылды. Инга Бикбулатова үзе—күренекле педагог, аның балалар тәрбияләү өлкәсендәге новаторларча хезмәтләре республикабызда киң кулланыла. Авторның әлеге китабы төрле буын вәкилләре арасындагы мәхәббәт һәм дуслык хисен яктыртуга багышланган. Инга Бикбулатова иҗатында дөньяга һәм кешеләргә карата миһербанлы булу идеясен үзәккә куя.

Соңгы ике ел эчендә Фәнил Галиевнең "Частный детектив" һәм "На перекрестке судеб" китаплары дөнья күрде. Китапта урын алган повестьлар һәм хикәяләр мавыктыргыч, җиңел укыла. Алар реаль фактларга нигезләнгән һәм заманыбызның актуаль темаларын үзәккә куеп иҗат ителгән. Фәнил Галиев—"Татарстан республикасының атказанган юристы", ул үз әдәби әсәрләрендә тудырган дөньяның чын асылын белеп яза.

Георгий Аристархovның "Родом из детства" романы әти-әниләрен югалткан һәм ятим калган малайның аянычлы язмышын яктыртуга багышланган. Гомумән, сугыштан соңгы еллар сабыйларының тормышы һәм яшәү шартлары—әлеге Казан прозаигының төп темаларыннан берсе. Шулай ук, Георгий Аристархovның Бөек ватан сугышы һәм аның геройлары турындагы әсәрләре дә игътибарга лаек.

Александр Архиповның "Синеокая" китабында авторның новеллалары һәм хикәяләре тупланган. Бу китапның төп темалары—мәхәббәт һәм кешенең рухи югарылыгы. Язучы үз тормышында булган мөһим вакыйгаларга туктала, алар аша аерым бер шәхесләрне дә калкыта. Мәсәлән, авторның новеллалары арасында республикабызда яшь буын язучыларны тәрбияләүдә зур эш башкарган күренекле әдип В.В. Корчагинга багышланганы да бар. А. Архипов үз әсәрендә В. Корчагинны шагыйрь буларак кына түгел, ә гаҗәеп әңгәмәдәшче һәм үзенчәлекле шәхес буларак

та яктыртырга омтыла.

Мәскәүдә Евгений Суховның тарихи-документаль, криминаль һәм тарихи-криминаль жанрдагы 18 китабы дөнья күрде. Евгений Сухов китапларының гомуми тиражы унике миллионны тәшкил итә. Татарстан китап нәшриятында аның "Волчья пасть" романы басылып чыкты.

Күренекле прозаиклар—Владимир Корчагин, Нонна Орешина, Диас Вәлиев, Владимир Лавришко, Әхәт Мушинский, Рөстәм Сабиров, Лев Кожевников, Евгений Сухов, Салават Юзеев—аларның һәрберсенең үз иҗади юнәлеше, үз йөзе бар, әмма, шул ук вакытта, бер-берсенә охшамаган һәм бер-берсен кабатламаган бу язучыларны бер бөтенгә берләштерүче чалымнар да бар. Алар иҗатына гуманистик рух хас, бүгенгенең проблемаларын хәл итүдә охшаш юллар, чараларны күрү, тоемлау үзенчәлеге бар. Заманыбыз чынлыгына нигезләнеп, язучыларыбыз аларны чагылдырып кына калмый, ә үз геройларының гамәлләренә бәя бирергә дә омтыла, ягъни билгеле бер дәрәҗәдә чор, тормыш, кеше яшәешенә психологик анализ ясауны да максат итеп куя.

## Драматургия

Күренекле язучы, драматург, эссеист Диас Вәлиевның "Пророк и черт" исемле пьесалар китабы дөнья күрде. Бу китапта авторның төрле елларда язылган ун пьесасы тупланган. Аларда Россия тормышының XIX—XX гасырлардагы драматик хаяте яктыртыла.

Бөгелмә драма театрында Борис Вайнерның "Сюрприз для волка" спектакленең премьерасы узды. Казан курчак театрында Лев Кожевниковның А. Лингреннның атаклы "Малыш и Карлсон" әсәре буенча сәхнәләштергән спектакле куелды. Шулай ук, театр репертуарында—Наилә Ахунованың "Здравствуй, ежик!", Борис Вайнерның "Алмазная гора", "Сказка волшебной ночи", "Три поросенка: новые приключения", Лев Кожевниковның "Мука-цокотуха", "Гуси-лебеди", "Щелкунчик" спектакльләре. Казанның Яшь тамашачылар театрында Александр Воронинның "Полеты в параллельных мирах" комедиясе сәхнәләштерелде.

## Тәрҗемә

Бу өлкәдә без, Татарстан Язучылар берлегенең рус секциясе кысаларында әдәби тәрҗемә бүлеге булдырылуы нәтиҗәсендә, яңа биеклеккә күтәрелдек дип әйтәсем килә (дөрес, иң беренче чиратта шигъриятне күздә тотыла).

Соңгы елларда Татарстан житәкчелегенең бу мәсьәләгә карашы унай якка үзгәрүе сәбәпле, тәрҗемә өлкәсендә дә җанлану сизелә. Әмма, ни генә дисәк тә, буш жирлектә генә берни дә шытып, үсеп китә алмый. Мин бу урында Казан тәрҗемә мәктәбенең күптәнге һәм көчле традицияләре турында әйтеп үтмәкче булам һәм кайбер исемнәргә дә тукталам: болар—Мария Елизарова, Александр Бендецкий, Геннадий Паушкин, Кыям Миңлебаев, Марсель Зарипов, Рөстәм Кутуй, Николай Беляев, Марк Зарецкий, Вячеслав Бәширов, Эльмира Блинова, Сергей Малышев, Роза Кожевникова, Борис Вайнер һ. б.

Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан оештырылган мастер-класслар Мәскәүнең танылган тәрҗемәчеләре—Россиянең Шигърият академиясе Президенты Валентин Устинов һәм "Дом Ростовых" язучылар берлекләренең Халыкара берләшмәсе журналының редактор урынбасары Денис Устинов—житәкчелегендә үткәрелде.

Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге һәм "Дружба народов" журналы редакциясе тарафыннан 2007 елның 23-25 апрелендә үткәрелгән Идел буе язучылары һәм тәрҗемәчеләренең Форумы зур вакыйга буларак бәяләнә ала. Биредә Мәскәү, Башкортстан, Чуашстан, Марий-Эл, Удмуртиянең күренекле язучылары катнашты. Форум кысаларында хәзерге әдәби тәрҗемә эшенең торышы, аның проблемалары һәм перспективалары турында житди сөйләшү барды. Шулай ук биредә "Бүгенге татар прозасы" антологиясен (I кисәк)

тәкъдир итү дә булды.

Сажидә Сөләймsecuredнан Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән "Наедине со звездами" исемле беренче тулы тәрҗемә җыентыгы әзерләнеп бастырылды. Аны әзерләүдә Лилия Газизова, Алена Кәримова, Наил Ишмөхәммәтовлар актив эш алып барды. Шул ук нәшриятта шагыйрь Мөхәммәт Мирзаның "Дорога к тебе" тәрҗемә җыентыгы басылып чыкты. Китапны әзерләүдә Сергей Малышев, Михаил Тузов, Алена Кәримова, Наил Ишмөхәммәтов, Талия Шәрәфиева катнаштылар. Аларның тәрҗемәләре Мәскәү белгечләренең дә югары бәясенә лаек булды.

Татарстан китап нәшриятында Габдулла Тукайның сайланма әсәрләр җыентыгының рус телендә дөнья күрүе (төзүчеләре—Гәүһәр Хәсәнова һәм Сергей Малышев), шулай ук, игътибарга лаек күренеш. Бу җыентыкка Мәскәүдә һәм Казанда нәшер ителгән иң яхшы тәрҗемәләр кертелгән.

Гәүһәр Хәсәнова тәрҗемәсендә "Полуденный закат" дип исемләнгән бүгенге татар прозасы үрнәкләрен туплаган янә бер җыентык дөнья күрде. Биредә рус укучысы Мөхәммәт Мәһдиев, Әнәс Хәсәнов, Әхәт Гаффар, Марсель Галиев, Ркаил Зәйдулла, Зиннур Хөснияр, Ризван Хәмид, Вахит Имамов, Камил Кәримов, Факил Сафин, Фәрит Гыйльми кебек татар язучыларының иҗаты белән таныша алачак.

Рус һәм татар телләрендәге параллель текстлардан торган "Мунаджаты" ("Мөнәҗәтләр") җыентыгы дөнья күрде. "Мөнәҗәт" сүзе гарәпчәдән тәрҗемә итсәк, ялгыз калып, Аллага ялвару, сыгыну, мактау сүзләре әйтү, гөнаһлардан чистарыну дигәнне аңлата. Бу исем белән татар әдәбияты һәм халык авыз иҗатында тулы бер жанр—дини тезмә әсәрләр аталып йөртелә. Югарыда искә алынган җыентыкта күренекле шагыйрь Сергей Малышевның тәрҗемәләре тупланган. Сергей Малышев тәрҗемәсендә тагын бер китап—Нәкыйп Каштанның "От января до декабря" дигән балалар өчен җыентыгы да дөнья күрде.

Мәркәзебездә әдәби тәрҗемә буенча конкурс үткәрелде, анда танылган олпат остазлар белән беррәттән яшь көчләр дә катнашты. Рус һәм татар шагыйрьләре, прозаикларыннан торган жюри әдәби тәрҗемәләрне түбәндәге критерийлар буенча бәяләде: бу—мәгънә һәм фонетик берелеш буенча текстның оригиналына якынлыгы, образ һәм метафораларның төгәл гәүдәләнеше. "Татар шигъриятен русчага тәрҗемә итү" номинациясе буенча урыннарны Сергей Малышев, Лилия Газизова һәм Алена Кәримова бүлеште. "Татар прозасын русчага тәрҗемә итү" номинациясе буенча җиңүчеләр буларак Наил Ишмөхәммәтов, Гәүһәр Хәсәнова, Талия Шәрәфиева танылды.

Наилә Ахунова сценариесе буенча Казан кинохроника студиясендә Казанда яшәп иҗат итүче яшь шагыйрә Ольга Овчинникованың тормышы турында "Ласточка цвета жизни" (режиссеры—Борис Максимов) дип исемләнгән фильм төшерелде. Фильм авторлары "Кино без барьеров" Республика кинофорумында лауреат булдылар. "Золотой Минбар" ("Алтын мөнбәр") Халыкара фестивалендә язучы, режиссер Салават Юзеев Тукай образын гәүдәләндерүче фильмы өчен 3нче дәрәҗәле махсус призга ия булды һәм шушы ук фильмы өчен Мисырда үткәрелгән "Красное море" ("Кызыл диңгез") Халыкара кинофестивалендә—"Гран-при", "Золотой бубен" ("Алтын кыңгырау") 11 нче халыкара телефестивалендә иң яхшы режиссура өчен бирелүче призны яулады.

Күренекле язучы Әхәт Мушинский 2006 елда "Анас—Ананас" исемле балалар китабы өчен Россиянең "Заветная мечта" милли әдәби премиясе иясе булды.

Бөтенроссия күләмендә үткәрелгән "Исламский прорыв" бәйгесендә безнең прозаигыбыз Марианна Вәлишева призерлар исемлегенә керде.

Соңгы елларда рус секциясе әгъзалары булган язучыларның һәм шагыйрьләрнең иҗаты "Татарстан", "Казань", "АНКО" журналларында даими басылып килде. Шулай да рус телендә иҗат итүче авторларның төп басылу мәйданы булып элеккечә "Идел" журналы кала бирә.

Безнең секция әгъзалары, үз әсәрләрен Мәскәүнең һәм Россиянең иң мәртәбәле әдәби журналларына да тәкъдим итәләр. "Дружба народов", "Знамя", "Октябрь", "Наш современник", "День и ночь", "Арион", "Юность", "Мурзилка", "Веселые картинки", "Простоквашино", "Литературная Россия", "Литературная газета" кебек

газета-журналларда Рөстәм Кутуй, Сергей Малышев, Борис Вайнер, Ольга Левадная, Лилия Газизова, Альбина Әпсәләмова, Алена Кәримова, Нонна Орешина, Диас Вәлиев, Айдар Сәхибзадинов, Майя Вәлиева, Салават Юзеев кебек авторларның әсәрләре даими күренеп килә. Бу хәл язучыларыбызның Россия күләмендә дә абруйлы булуы турында сөйли.

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булмаган, әмма Россия әдәби мохитендә, матбугатында исемнәре яхшы таныш авторларга да тукталып үтәсе килә. Болар— прозаик Денис Осокин, шагыйрьләр Тимур Алдошин, Алексей Остудин, Глеб Михалев, Анна Русс, Ольга Овчинникова, тәнкыйтьчеләр Рөстәм Галиев, Артем Скворцов, язучы-фантаст Сергей Челяев. Алар—Россиядә чыгып килүче газета-журналларда иҗатлары белән күренгән һәм Россия күләмендәге һәртөрле әдәби премияләргә лаек булган язучылар.



Равил
Фәйзуллин

## БЕРДӘМ БУЛСАК—ЮГАЛМАБЫЗ

Әгәр Әмирхан Еники исән булып, бу трибунадан чыгыш ясаса, мондый сүзләр әйтер иде шикелле: "Так сказать, (нигәдер бу сүзтезмәне ул еш әйтә иде) язучылык хезмәтенең кызыгы бетеп бара..." Ихтимал, бу фикергә Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахунов кебек классик әдипләр дә кушылыр иде. Чыннан да, үткән дистә еллар белән чагыштырганда вәзгыять безнең файдага түгел. Әдәбиятның җәмгыятьтәге дәрәҗәсе түбәнәйде, шул нисбәттән, тәрбияви роле дә кими төште. Язучы үзе дә социаль яклауга мохтаҗ категориягә әйләнде. Дөньяви масштабтан караганда, һәр җирдә дә бәлки алай түгелдер, әмма Россия һәм элеккеге СССРның күпчелек дәүләтләрендә хәл нәкъ әйтеп үтелгәнчә. Житди классик әдәбиятны аз уку, тиражлар кимү, шул ук матди бөлгенлек... Кеше өчен, бигрәк тә нечкә тоемга ия талантлы кеше өчен иң авыры—киләчәккә ышанычның кимүе.

Конфуций дигән акыл иясе әйткән, диләр, "Дәүләт тоту өчен өч нәрсә кирәк: ашар-эчәр ризык, ил сакларлык корал һәм халык ышанычы". Шуларның берәрсе булмаса Дәүләт тора аламы? дип сораганнар аннан. "Коралсыз да була, чөнки кеше үзе корал." Әгәр шул өченең тагын берсе булмаса? "Хәтта ризыксыз да була, кешегә барыбер бер үләсе. Ә менә халык ышанычын югалтса, бернинди Дәүләт тә яши алмый."

Язучылык хезмәте турыдан-туры халыкның тарихы, гореф-гадәтләре, теле-моңы, гомумән, рухи дөньясы белән, матди байлыктан бигрәк, ата-бабаларыбыз мирас итеп калдырган рухи байлык белән бәйле. Безнең миссия—әнә шул байлыкны мөмкин кадәр арттыру, үстерү, үз халкын бүтән халыклар арасында ким итмәскә тырышу. Тел белән бәйле безнең хезмәтебез. Тел, үзегез беләсез, милләтне милләт итүче иң төп билгеләрнең берсе. Гомумән, һәр халыкның мәдәни нигезен Сүз сәнгате тәшкил итә. Язучы кеше—турыдан-туры тел сагында торучы зат. Халык язучысы Н. Фәттах тикмәгә генә болай дип язып калдырмаган: "Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә дә нигә яратырга, балалар тудырырга, чәчәкләр үстерергә? Нигә җырлар, китаплар язарга?.. Икенең берсе: йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә. Мин көрәшергә булдым". Моны язучы кеше әйткән. Бизнесменнар, туган телен белмәгән түрәләр

әйтә алмас мондый сүзләрне. Өстәвенә, күреп торабыз, безнең телгә Ак патшаның империячел даирәләреннән соңгы вакытта эзлекле һөҗүм бара. Мәктәпләрдә укыту процессыннан милли компонентны бетерү буенча кануннар чыгардылар... Ана каләр нинди имляда язу хокукын бездән тартып алдылар... Әгәр классик мирас һәм синең язганнарың укылмый, укытылмый, өйрәнелми икән, ничекләр итеп илһамланып язмак кирәк. Менә шундый, алда әйтелгән Ышаныч дигәнең офыкта югала барган, еш кына, "колмак батып, таш йөзгән" дәвердә безнең язучыларыбыз әле дә менә дигән талантлы әсәрләр иҗат итәләр. Сокланырлык хәл. Рәхмәт аларга! Шөкер, без бүген үзебезнең арада берничә дистә классик мәгънәдәге зур язучы, шагыйрь, драматург бар дип әйтә алабыз, зур көч, зур хәзинә бу әлегә.

Нинди хәлләр, гамәлләр булды соң бу 3-4 ел эчендә? Аянычларыннан башлыйм.

Кабатланмас зур талантлар арабыздан китте. Алар урынын тутырырлык яңа көчләр килдеме? Кистереп әйтү кыен.

Ана телебездә укучылар кимеде. Китап, газета-журналларның тиражы шуны раслый. Без 300 язучыбыз бар дибез, ә киләчәктә, берәребезнең китабы чыккач, ябырылып укучы 300ләп укучы табылырмы?

Мөгаен, соңгы еллардагы зур яналык шул: республика басмаларының статусы үзгәрүе—алар ААЖга (үз көнен үзе күреп, булдыра алса, табыш алып яшәүче берләшмә) керделәр, дөресрәге кертелде. Милли басмаларның абсолют күпчелеге рәсми яктан дәүләтнеке саналмый хәзер. Ярый ла әлегә без күпмедер дәрәҗәдә дәүләт заказын үтәүче саналабыз. Ә алга таба? Гарантия юк бит! Өстәвенә, матбугат белән идарә итүчеләр арасында татар тарихын, әдәбият-сәнгатен, телен белүчеләр юк дәрәҗәсендә. Безнең мохиттә генә түгел, бүтән житәкче структураларда да шулай бу. Шунадыр да, Казанда татар тарихына кагылышлы жисми тарихи ядкарьләр бетеп бара. Ә болай читтән күзәтүчегә хәрәкәт бөтенләй юк түгел түгелен. Боратынский яшәгән йорт яңартылды, Аксенов йорты торгызыла... Ә менә Тукай яшәгән Болгар номерлары һаман хәрабә хәлендә...

Безнең хезмәт нәтиҗәсе—китап. Һәр хезмәт бәһаләнергә тиеш. Безгә кагылышлы гонорар-каләмхак турында уйланганда моннан күп еллар элек язылган сүзләр искә төшә.

*Якты йөзе...*
*Мәгънәле сүзе...*
*Талант—үзе!*

*...Илһамлы каләме өстеннән*
*гомере буе*
*карап торды ипи күзе...*

Без, нигездә, ипи телеменә ялманып иҗат итә торган кавем. Кызганычка каршы. Мохтаж кешегә масштаблы фикер йөртү кыен. Әдәбият тарихына баксаң,—гарептә булсын, шәрекътә булсын—классик әдәбиятны матди житеш, хәтта әйтер идем бай катлам тудырган. Бездә чагыштырмача мул яши торган язучылар бер кул бармакларына сыеп бетә бугай.

Мин бу трибунадан, язучы булудан тыш, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире һәм Кабул итү коллегиясе рәисе сыйфатында да чыгыш ясаганлыктан, журнал һәм берлеккә әгъза итеп алынганнар турында берничә сүз.

"Казан утлары" турында тәфсилләп сөйләп тормыйм: аны һәркем белә, чөнки журналны бергә чыгарабыз, бөтенебезнең диярлек яңа яхшы әсәрләре анда дөнья күрә. Журналның соңгы еллардагы эшчәнлеге турында корылтай делегатларына

таратылган белешмәдә дә шактый тулы мәгълүмат бирелгән. Өстәп шуны гына әйтәм: 2006 елда Россиядә һәм элеккеге СССРда әдәби журналлар арасында беренче булып 1000нче санны чыгардык. Бу безнең өчен, һәммәбез өчен горурлык! Мең сан хәзинәсеннән үзебезчә яхшы һәм гыйбрәтле дип санаган әсәрләрне туплап "Сүнмәс утлар балкышы" дигән күләмле (90 басма табак) антологик характердагы китап чыгардык. Мондый басма әдәбиятыбыз тарихында юк иде дип беләм. Бу китапны тәкъдир итү кичәләре, Татарстаннан тыш, Мәскәүдә, Пермьдә, Ижау һәм башка шәһәрләрдә гөрләп узды. Кайбер данәләре чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез кулына да барып ирешә. Белгән кешеләр "Казан утлары"н Россиядәге иң яхшы әдәби журналларның берсе дип әйтәләр. Ышанасы килә. Безнең бу корылтайда да, докладларда булсын, чыгышларда булсын, асылда, безнең журналда басылып чыккан әсәрләр анализлана.

Кабул итү коллегиясе эшчәнлеге турында. Коллегия әгъзалары—күренекле, тәҗрибәле язучылар. Күпсанлы каләм ияләре арасыннан иң өметлеләрен сайлап алырга тырышабыз. Ике корылтай арасында 39 кеше берлеккә кабул ителде (23 язучы вафат булды). Шулар арасында яше 30га җитмәгәннәре фәкать 5 кенә. Дөресен әйтергә кирәк: балкып торган талант ияләре сирәк. Язучылар берлеге—иҗтимагый оешма. Анардан массоннарныкы кебек ябык оешма ясап булмый һәм кирәкми дә. Максат—талант очкыны булган кешеләргә ярдәм итү. Татарстаннан читтә яшәүче каләм ияләре аерым игътибар үзәгендә. Бу еллар эчендә читтән 10 кешене әгъза итеп алдык. Сүз дә юк, киләчәктә таләпләрне, критерийларны көчәйтү кирәк. Безнең өлкәдә сан дигәннәре гел генә сыйфатны билгели алмый. Шунсы да борчый: Россиядә әлегә кадәр иҗат оешмалары турында закон кабул ителмәгән. Кануни тәртипләр булмау аерым әдәбият өчен дә, халыкара аралашу, бердәм туплану өчен дә һич тә файдага түгел.

Сүземне йомгаклап болай дияр идем: әлбәттә, татар язучысы алдында проблемалар хәттин ашкан. Тарих шаһит: язучылар кавеме нинди генә чорларда нинди генә авырлыклар кичермәгән, әмма көрәшкән, кулыннан каләмен төшермәгән, җиңеп килгән... Язучыга бүген дә җиңел түгел. Әдәбиятыбызның мең еллык тарихы бар дип күкрәк кагу гына аз. Кемнәргәдер бер көч куеп алынганны безгә ун көч куеп алырга кирәк. Шунсыз булмый. Шөкер, булган куәткә көч бирүчеләр бар. Республика җитәкчелеге әлегә безнең хәлләрне аңлый, булдыра алганча ярдәм итә (нәшриятлар исән-сау яшәп килә, классик әдипләребез мирасы чыгарыла, Берлек эшчәнлеге финанслана, төрле юбилей чаралары үтә, китапларыбызны төрле төбәкләрдә таратуда булыша... Өстәп кенә әйтәсе килә: СССР Язучылар берлегенең 70 еллык бәйрәме дәүләти масштабта Татарстаннан тыш тагын кайсы илдә яки республикада үткәрелде икән?). Аңлашып, бергә-бергә хезмәттәшлек итеп иҗат иткәндә хәл итмәслек мәсьәләләр юк ул. Һәрхәлдә, мин шуңа ышанам.

## "КАЗАН УТЛАРЫ" ЖУРНАЛЫ ТУРЫНДА




Берәзлексез 87нче елын нәшер ителүче "Казан утлары" журналы ике съезд арасында үзенең 1000нче санын чыгарды *(2006 ел, № 2)*. Моңа ул, татарның айлык журналлары арасында гына түгел, ә бөтенроссиянең әдәби журналлары арасында беренче булып ирешә. Бу юбилей, танылу алып, Әдәбият һәм сәнгать елының иң күркәм бер сәхифәсе булып республикада һәм Россиянең төрле төбәкләрендә дәрәҗәле итеп уздырылды да. Юбилей кайтавазы булып "Сүнмәс утлар балкышы: мең санлы хәзинәдән" дигән зур күләмле китап та дөнья күрде. "Үткәндәге мәдәни-иҗтимагый тормышыбызның куанычлы һәм аянычлы этапларын объектив рәвештә яктырткан уникаль китап-антология... Тарихи әһәмияткә ия зур бер яңалык". "Татар рухи тормышында кабатланмас күренеш". "Бөтен әдәбиятыбызга исән чагында куелган сәнгати һәйкәл". "Киләчәккә хатыбыз ул"—бу китапка матбугатта әнә

шундый бәяләр бирелде.

Журнал үзенең яуланган абруен сакларга, эшчәнлеген югары кимәлдә алып барырга омтыла.

Баш мөхәррир Р. Фәйзуллинның Татарстан Президенты М. Шәймиев белән күләмле әңгәмәсендә *("Рухи галәмдә яшәргә". 2006 ел. № 3)* әдәбият-сәнгатебез, рухи тормышыбызга кагылышлы күп кенә актуаль мәсьәләләр, четерекле проблемалар да күтәрелде. Ул әңгәмә—татар матбугаты тарихында матур сәхифә булып калырлык язма.

Соңгы елларда журналда күләмле проза әсәрләрен бастыруга мөнәсәбәт беркадәр үзгәрә төште. Чамасыз зур һәм еш кына көпшәгрәк тә булган "кирпеч-кирпеч" роман-эпопеяларга юл тарайды, әсәрләрнең тыгызлыгына күбрәк әһәмият бирелә башлады. Җыйнак повестьлар һәм хикәяләрнең кадере артты. Бу җәһәттән 2006 елда игълан ителгән "Яңа дәвер кешесе" дигән хикәяләр конкурсы бик тә кулай булды. Конкурска йөзгә якын хикәя килде, аларның утыздан артыгы журналыбызда дөнья күрде дә инде.

Журнал үзенең төп мәслəгенә һәм укучыларына тугрылык саклап, ватандарлык һәм халыклар дуслыгы идеяләрен раслап, талантлы әдипләребезнең иң яхшы яңа әсәрләрен күп меңнәр белән исәпләнгән укучыларыбызга җиткереп бара. Соңгы өч елда журналда басылган әсәрләрнең күбесе шуңа дәлил. Кайберләрен искә төшереп үтик.

Роман-повестьлардан: Ф. Садриев—"Бәхетсезләр бәхете", Ф. Бәйрәмова—"Караболак", Ф. Яруллин—"Кыйбласызлар", Н. Фәттах—"Аклан", Р. Габделхакова—"Нишләттегез Гөлкәйне?", З. Зәйнуллин—"Мәүлет гусар", М. Маликова—"Тылсым", Р. Мирхәйдәров—"Үзем хөкем итәм", Ж. Ильясов—"Еланнар әфсенләүче", В. Нуриев—"Жиденче палата", А. Хәсәнов—"Җәнбәт ыруы", З. Хөснияр—"Козгыннар йолдыз чүпли", Равил Вәли—"Канатлы татар", М. Әмирханов—"Үрбәт ханәкә гыйшкы", Р. Батулла—"Мур кырылышы"...

"Татар хикәяләре хәзинәсеннән" дигән сәхифәдә классик әдипләребезнең иң яхшы хикәя үрнәкләре бирелеп барылды. Журналның "Дөнья әдәбияты үрнәкләре" дигән циклы да уңышлы дәвам иттерелә.

Журнал документаль әсәрләргә, "тормыш документларына" урынны торган саен күбрәк бирә. 2006 елда ачылган "Тормыш язган хикәяләр" дигән яңа сәхифәдә егермеләп әсәр басылды инде. Ә. Еники хатлары, М. Мәһдиев, А. Гыйләжев көндәлекләре, М. Госмановның—Рәшат Гайнанов, Якуп Агишев, Мөхәммәт Гайнуллин, Р. Фәйзуллинның—Тәүфикъ Әйди, бер төркем язучыларның Альберт Фәтхи турындагы истәлекләре, Р. Юсупованың Шәриф Хөсәенов турындагы документаль әсәрләре әнә шундыйлардан.

Шигърият бүлегендә бүгенге поэзиябезнең күренекле вәкилләре—Ф. Яруллин, Ш. Галиев, Ә. Баян, Р. Фәйзуллин, Роб. Әхмәтҗан, Р. Харис, Р. Гаташ, М. Галиев, Р. Мингалим, Р. Миңнуллин, К. Булатова, Л. Шагыйрьҗан, З. Мансуров, Зөлфәт, Х. Әюпов, Ф. Гыйззәтуллина, Р. Идиятуллин, Г. Морат, Р. Зәйдулла, Э. Шәрифуллина, Б. Рәхимова, Х. Мөдәррисова, Ш. Гаделша һәм башкаларның шигырь цикллары, поэмалары басылып чыкты. Татарстаннан читтә яшәүче каләмдәшләребезнең әсәрләре дә даими басылып килә. Соңгы елларда Башкортстан, Ижау, Пермь, Ульяновск шәһәрләрендә яшәүче шагыйрьләргә махсус сәхифәләр багышланды. Яшьләр иҗатына даими игътибар бирелә.

Татар язмышына кагылышлы хезмәтләрдән А. Тимергалинның дүрт ел буе һәр санда чыккан "Миллият сүзлеге"н, Р. Хәкимнең "Татар рухы"н бирү, К. Фуксның "Казан татарлары"ның кыскартылган вариантын тәрҗемә итеп басу "Казан утлары"ның уңышы санала ала. Журналга яшүсмер укучыларны җәлеп итү һәм аларны заманның начар шаукымыннан аралап калу максатында "Ак җилкән" дигән яңа сәхифә ачылды.

Базар мөнәсәбәтләре заманында популяр басманың һәр юлы, һәр бите аерым бер бәһа тора. Журнал, үзенең матди мәнфәгатьләренә күпмедер хилафлык китереп булса да, исән язучыларыбызның (бүгенге вәзгыять-хаҗәт буенча ул урында калын кесәле хуҗалык җитәкчеләренең яки бай эшмәкәрләрнең сурәтләре тора алыр иде!)

портретлары һәр сан саен чыгып килә. Мәктәпләрдә татар әдәбияты укытучылары өчен алар бик кирәкле кулланма булып санала.

Һәр санда мул итеп "Казан утлары" архивыннан фоторәсемнәрне һәм иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздагы яңалыкларны биреп бару журналның тарихи әһәмиятен арттыра төшә.

Язучылар берлегенә кабул ителгән һәр яңа әгъза белән бары "Казан утлары" гына таныштырып бара...

Май аенда журналның 1028 нче саны дөнья күрде.

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XVI КОРЫЛТАЕ РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

Татарстан язучыларының 2005 елдан алып 2008 елга кадәр булган ике корылтае арасындагы эшчәнлеге Язучылар берлеге Уставына, Татарстан законнарына, Татарстан Президенты указлары, хөкүмәтебез һәм Язучылар берлеге идарәсе карарларына нигезләнеп алып барылды. Шул ук вакытта бу чорда республикабыз һәм бөтен халкыбыз тормышында булып үткән әһәмиятле вакыйгалар да язучылар иҗатына, Язучылар берлеге эшчәнлегенә унай йогынты ясады. Башкалабыз Казанга, Алабуга шәһәренә нигез салынуга 1000 ел тулу, Татарстан Президенты Указлары белән 2006 елны "Әдәбият-сәнгать елы", 2007 елны "Хәйрия елы" итеп үткәрү, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Акмулла, Муса Җәлил, Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин һәм башка бик күп күренекле шәхесләребез юбилейларын бөтенхалык бәйрәме дәрәҗәсендә уздыру чараларында Язучылар берлеге һәм бик күп әдипләребез турыдан-туры һәм актив катнаштылар.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. М. Ибраһимовның отчет докладында, әдәби жанрлар буенча ясалган докладларда, язучылар чыгышларында идарәнең отчет чорындагы эшчәнлеге төрле яклап яктыртылды.

Бу чорда Татарстан каләм ияләре иҗат эшчәнлеген киң җәелдереп, милли әдәбиятыбызны поэзиядә дә, прозада да, публицистикада да, драматургиядә дә укучы таләбенә җавап бирерлек камил, югары сәнгатьле әсәрләр белән баеттылар. Рус телендә иҗат итүче әдипләр дә отчет чорында нәтиҗәле иҗади эш алып барды. Аларның әдәби тәрҗемә өлкәсенә актив тартылуы игътибарга лаек. Язучылар берлегенең әдәби тәрҗемә мәктәбен яңадан торгызу һәм бу эшне билгеле бер системага салу өлкәсендә нәтиҗәле эшләве милли әдәбиятыбызның офыкларын киңәйтүгә юл ача.

Соңгы өч елда республикабызның әйдәп баручы Татарстан китап, "Мәгариф" һәм "Рухият" нәшриятларында гына да язучыларыбызның 400дән артык китабы басылып чыкты. Шуның белән бергә язучыларыбызның байтак әсәрләре Мәскәүдәге үзәк нәшриятларда, Уфада, Ижевскида, Төмәндә, Самарада, Россиянең башка төбәкләрендә һәм кайбер чит илләрдә дә аерым китаплар булып басылды.

Ике съезд арасында әдипләребезнең иҗатын стимуллаштыру максатында да әһәмиятле чаралар күрелде. Г. Исхакый, Ф. Хөсни, Һ. Такташ, А. Алиш, Ж. Вәлиди исемендәге әдәби премияләр Татарстан Мәдәният министрлыгы белән Язучылар берлеге бүләге статусын алдылар. Аларның акчалата күләме дә 10 тапкырга артты. "Татнефть" акционерлык җәмгыяте белән Язучылар берлегенең С. Сөләйманова исемендәге яңа төр, бик әһәмиятле әдәби премияләре һәм яшь иҗат көчләре өчен стипендияләре булдырылды. Соңгы елларда Татарстан Язучылар берлеге каршында "И. Юзеев исемендәге яшь язучылар клубы" оештырылуы, шулай ук, яшь каләм ияләрен барлау, берләштерү, аларга иҗади ярдәм күрсәтү аеруча әһәмияткә ия.

Язучыларның иҗатын пропагандалау максатыннан укучыларның каләм ияләре белән элемтәсен ныгытуда да күпкырлы һәм нәтиҗәле эш алып барылды. Отчет чорында 243 юбилей чарасы, республикабызның 12 районында, Удмуртия Республикасында, Пермь, Ульяновск, Киров, Оренбург өлкәләрендә әдәбият-сәнгать көннәре үткәрелде, урып-җыю чорында Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән берлектә 27 районга "язучылар десанты" төшерелде.

Язучыларыбызның иҗат эшчәнлекләре, туган халкыбыз һәм республикабызның рухи тормышында актив катнашулары дәүләт органнары тарафыннан югары бәяләнде. Ике съезд арасында Татарстан Язучылар берлеге идарәсе юллаган үтенечнамәләр буенча 64 язучы Татарстанның һәм Россиянең мактаулы исемнәренә һәм Дәүләт бүләкләренә лаек булды.

Соңгы 3 елда Россия Федерациясендә, шул исәптән Татарстанда уздырылган икътисади һәм социаль реформалар нәтиҗәсендә туган финанс кыенлыклары: Язучылар берлегенең турыдан-туры республика бюджетыннан финансланмавы, Халыкара һәм Россия Әдәби фондларыннан даими килә торган матди ярдәмнең тукталуы аркасында Язучылар берлеге үз эшен оештыру, шул исәптән каләм ияләрен социаль яклау өчен тарихи традицияләрне дәвам иттереп, республикабыздагы меценатлар, иганәчеләр белән тыгыз элемтә урнаштырды. Шушы игелекле эшне тормышка ашыруда "Татнефть", "Татэнерго", "Нижнекамскшина", "Татптицепром", "Татспиртпром" ачык акционерлык җәмгыятьләренең ярдәме аеруча зур булды.

Татарстан язучыларының XVI съезды Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең 2005-2008 еллардагы эшчәнлеген канәгатьләнерлек дип бәяли.

Шул ук вакытта съездагы докладлардан, чыгышлардан күренгәнчә, хәл итәсе мәсьәләләр дә күп әле. Аерым авторларның шәхси уңышларына карамастан, республикабыз каләм ияләренең иҗат активлыгы бердәй югары дип әйтеп булмый. Әдәби әсәрләрдә туган телебезгә карата булган таләпчәнлекне арттырырга кирәк. Поэзиябездә югары зәвыклылык, прозада эпиклык һәм колачлылык, драматургиябездә миллилек җитенкерәми. Татар әдәбиятын рус теленә тәрҗемә итүдә профессиональлекне үстерү, сәләтле тәрҗемәчеләрне дәүләт китап нәшриятларында даими эш белән тәэмин итү зарур.

Балаларга белем бирүдә милли-төбәк компонентын юкка чыгарып, Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни, шул исәптән әдәбиятының үсешен чикли торган федераль законга үзгәрешләр кертүне, конституцион хокукларыбызның гамәлгә ашырылуын таләп итәргә кирәк.

Бүген дәүләт нәшриятларының, "Татмедиа" ачык акционерлык җәмгыяте карамагындагы әдәби басмалар редакцияләренең китап чыгару, тарату, авторларның хезмәтенә тәңгәл гонорар түләүдәге проблемаларын Татарстан хөкүмәте дәрәҗәсендә хәл итү сорала.

Бүгенге съезд Язучылар берлегенең җәмгыятебезгә кирәклеген, халкыбызның рухи тормышында тарихи әһәмиятен тагын бер кат искәртә.

Татарстан язучыларының XVI съезды язучылар җәмәгатьчелегенең киләчәктәге һәр гамәле, беренче чиратта, туган халкыбызның милли идеясен раслауга һәм үстерүгә хезмәт итәргә тиеш дип саный. Съезд Язучылар берлеге киләчәктә республикабызның дәүләт, җәмәгать һәм башка төр оешмалары белән берлектә түбәндәге чараларны тормышка ашыруны максатка ярашлы дип таба:

—Татарстан Республикасы хөкүмәте, Мәдәният министрлыгы белән берлектә әдәбиятны һәм сәнгатьне үстерүгә юнәлдерелгән дәүләт финанславындагы озак вакытка исәпләнгән Республика Программасын төзү.

—Татарстан Республикасы хөкүмәте белән берлектә атаклы әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең исемен мәңгеләштерү буенча озак вакытка исәпләнгән план төзү. План дәүләт чыгымнары һәм хәйриячелек нигезендә тормышка ашырыла.

—Казан дәүләт университетында Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән "Әдәби хезмәткәр" һәм "Әдәби тәрҗемәче" белгечлекләре буенча елга 10 студент укырлык бүлек ачу. Яшь язучыларга иҗади ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасының Яшьләр эше, спорт һәм туризм министрлыгы исәбенә "Идел" яшьләр лагеренда һәр елны 10 көнлек әдәби семинарлар оештыру.

—Татарстан Мәдәният министрлыгы каршында әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең иҗади командировкалары өчен махсус Фонд оештыру.

—Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән яңа иҗат ителгән әдәби әсәрләр авторларына гонорар күләмен 3 мәртәбә арттыру һәм ана ел саен индексация ясау.

—Татар әдәбиятын пропагандалау максатларында һәр шәһәрдә, район үзәгендә,

зур торак пунктларда китап кибетләре ачу, бөтен китапханәләрдә китап сәүдәсе оештыру, аларның фондларын дәүләт заказы белән басылган китаплар исәбенә баету.

—Г. Тукайның 125 еллык юбилеен халыкара масштабта билгеләп үтү, шул исәптән аның тулы академик басмасын, энциклопедиясен бастырып чыгару, әсәрләренең рус телендә югары сыйфатлы яна тәрҗемәсен булдыру.

—Татар әдәбияты классиклары, халык язучыларының күптомлы сайланмаларын дәүләт исәбенә бастырып чыгаруны дәвам итү. Татарстан Мәдәният министрлыгы белән берлектә Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатларының сайланма әсәрләрен нәшер итү планын төзеп тормышка ашыру.

—Татарстан Мәдәният министрлыгы белән берлектә Татар язучылары әсәрләрен рус һәм башка телләргә тәрҗемә итеп аларны нәшер итүнең 5 еллык планын төзү.

—Мәктәпләрдә, югары уку йортларында куллану, шул исәптән чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләр өчен татар язучылары әсәрләренең аудио-китапларын чыгаруның еллык планнарын төзү. Аны Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә тормышка ашыру.



—Татарстан язучыларының торак шартларын яхшырту максатыннан Татарстан социаль ипотекасы Программасы кысаларында Язучылар берлеге әгъзалары өчен льготалар билгеләү.

—Татарстан язучылары Әдәби фондының еллык чыгымнарын республика бюджеты исәбенә күчерүне сорап Татарстан җитәкчелегенә мөрәҗәгать итү.

—Казан шәһәренең Мөштәри урамы, 14 нче йортка (Татарстан Республикасы Язучылар берлеге бинасы) тулы реконструкция эшләрен төгәлләү. Аны "Татарстан Республикасы язучылары йорты" дигән дәүләт учреждениесе итеп үзгәртеп кору. Бинаны файдалануның, эшләүчеләргә тотылган хезмәт хакының бөтен чыгымнарын дәүләт исәбеннән тәэмин итү.

—Язучыларның "Васильево" шифаханәсендәге "Иҗат йорты"нда ташламалы юлламалар белән ял итүен дәүләт гарантиясенә алу.

---

*Алхәбәр*

Нурихан
Фәттах

## БЕРЕНЧЕ ШИГЫРЬ КҮК БАЛАЧАК...

ИСТӘЛЕКЛӘР

...Безнең бала вакыт, үсмер вакыт авыр, катлаулы, михнәтле чорга туры килде. Шулай да мин уйлап куям: бүгенге заман балаларына караганда бәхетлерәк булганбыз без!..

...Безнең сабый чак, безнең үсмер чак гомумән беренче шигырь сыманрак булды. Ул шигырьдә ритм да, рифма да бик үк төгәл булмагандыр, ләкин анда тирән мәгънә булган. Без тормыштан, табигатьтән аерылмаганбыз. Ач-ялангач һәм ятим булсак та без җиргә, күккә, суга якынрак булганбыз. Без чебиләнгән ялан аяклар белән язгы кар суларын ерып йөрдек, яңа ачылган тау кашларында ябагадан әвәләнгән туплар белән уйнадык. Кайнар тузанлы юлдан тузан туздырып узыша-узыша без зәңгәр офыкларга, кичке кояшларга карап йөгердек. Болында, хуш исле чичкәләр арасында җиләк җыйдык, чикерткәләр тоттык, кошлар сайравына хәйран калып, төпсез күккә карап яттык...

***Биш ел элек дөнья куйган олуг әдибебез инде 1988 елда ук язган, ләкин беркайда да басылмаган бу истәлекләр журналның алдагы саннарында биреләчәк.***

Фәүзия
Бәйрәмова

# СЕБЕР ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

## Габдрәшит Ибраһимов укыган авылда

Тара шәһәреннән 30 чакрымнар ераклыкта, кыйбла тарафында бер татар авылы бар, Уыш дип атала. Заманында кечкенә Габдрәшит биргә өтисе белән килеп йөргән, аның беренче белем алган мәдрәсәсе дә шушы авылда булган. Бер караганда, үзе дә Тарада имам булып торган Гомәр хәзрәткә улын шәһәрдә генә укытса да булыр иде, әмма ул аны Уышка кайтарган. Безнең фикеребезчә, моның сәбәбе Гомәр хәзрәт Ибраһимовның нәсел җепләре шушы Уыш авылы белән бәйле булганга күрәдер, чөнки биредә аның бабасы ягыннан кардәшләре Габделҗәлилнең балалары яшәгән. *("Гасырлар авазы" журналы, 2002 ел, 1/2 саннар, 193 б.).* Тарихи мәгълүматлардан күренгәнчә, Уыш авылы 1650 елда барлыкка килгән, һәм ул урыс чыганакларында Туралы дип атала. Әмма авыл күпкә алданрак, Күчем хан заманында ук барлыкка килгән булырга тиеш, Уышта бохарлы нәселләре яшәгәнлеге шул турыда сөйли. Авылга Казаннан килгән татарлар нигез салган дигән фаразлар да бар, бу хакта Омск галимнәре менә нәрсә яза:

"По другой версии деревню основали татары Поволжья, которых при Иване Грозном хотели крестить, и они бежали в Сибирь. Здесь они основали д. Большие Туралы, причем еще раньше города Тары. Местные жители называют деревню Оулуш." *(Сибирские деревни: история. Современное состояние, перспективы развития.—Омск, 2006, с. 83.)*

Авыл Уыш елгасы буена урнашкан һәм шуңа күрә Уыш дип аталган, руслар исә елга исемен Оша дип язалар. Туралы атамасына килгәндә, бу якларда Тара тирәсендә яшәүче татарларның бер өлеше шулай дип атала. Ә авылның Олы һәм Кече Уышларга аерылуы бары тик егерменче гасыр башында гына булган булырга тиеш, чөнки аңа кадәр тарихи белешмәләрдә бер генә авыл—Туралы/Уж/ гына күрсәтелгән.

Авылның икегә аерылу сәбәбен төрлечә аңлаталар. Беренче сәбәп казанлы һәм бохарлы җирле татарлар тыныша алмаганнар, имеш, Курманбай исемле байның малын талаганнар, шуннан соң каракларны авылдан куганнар, алар Кече Уышка барып урнашканнар, дип языла югарыда телгә алган китапта. Бу дөреслеккә бик туры килеп бетми, шуңа күрә китапта икенче версия дә бирелә, шуны ук безгә авылда да ишетергә туры килде. Ягъни күрше авыл урыслары Уыш тирәсендәге яхшы җирләргә кызыгалар һәм шунда күчәргә уйлыйлар. Урысларны анда күчермәс өчен, Уыш халкының бер өлеше бер төн эчендә шунда күчә һәм Кече Уыш дигән авыл барлыкка килә. Бу хакта миңа Олы Уышта 80 яшьлек Әхмәт әкә Сөләйманов та сөйләде, бу хакта югарыда телгә алынган китапта менә нәрсә языла:

"В другом варианте в начале XX века русские из д. Вознесенка присмотрели

*Дәвамы. Башы узган санда.*

себе земли недалеко от Больших Туралов и привезли лес для строительства домов. В 1905 году, чтобы место не заняли русские, туда переехали татары с Больших Туралов. Сейчас деревни Вознесенка нет, а в Малых Туралах живут татары. Планировка деревни с тех пор не изменилась (одна улица)." *(Күрсәтелгән хезмәт, 84 б.)*

Бу ике авылның аерылу тарихына шулай җентекләп тукталуымның сәбәбе шул: Кече Уышка күчеп китүчеләр, нигездә, бохарлылар булган, ә казанлылар төп Уышта калган. Хәер, бу ике авыл хәзер инде яңадан кушылып беткән диярлек була, Кече Уышның бер өлеш халкы Олы Уышка күчеп килгән, чөнки мәктәп, мәчет, Мәдәният йорты кебек милли-рухи учаклар барысы да Олы Уышта, ә Кече Уышта исә егермеләп йорт һәм кырыклап кеше калган, мәчет тә, мәктәп тә юк. Аның каравы, заманында Габдрәшит Ибраһимовның бабалары йөрткән Ахун фамилиясе шушы кечкенә авылда, бохарлы Шөгеровлар, Кучаковлар да шушыннан, димәк, әгәр бар икән, Габдрәшит Ибраһимовның ерак туганнары да шушында яши, әмма алар инде берни хәтерләми...



*Олы Уыш авылы мәчете. Автор фотосы.*

Шулай итеп, кайчандыр кечкенә Габдрәшит әтисе белән җәяүләп үткән кышкы юлдан без төнката машина белән узабыз. Ул вакытта Уыш бер генә булганлыктан, төп авылга барабыз, машинабыз нигәдер начар тарта, туктар-туктамас бара. Тирә-юньдә шундый ук кышкы салкын төн, җилләп-буранлап тора, тышта ник бер ут яктысы булсын... Шулчак күңелемә Габдрәшит Ибраһимовның Уышка сәфәре турында язган юллары килә...

"Бер тапкыр кыш кыямәт суык, ата белән Уыш карьясына киттек,—дип яза ул.—Безнең булганыбыз шәһәрдән утыз чакрымда кечкенә бер авылдыр. Шул заман юлда киткәч, кар-буран булып, юлны күрмәс булдык, кич буена кар астында калдык. Ул заман, Алланың рәхмәтендә булсын, атам кар астында бер кат җиңел киемнәре белән булган хәлдә "Алла кешене мондый хәлдә саклар", дип шуның белән бер заманда "догалар кабул ителер", диярәк, һич тоткарлыксыз азан Мөхәммәди укыр иде. Иртәсе көн шул җирдән узып барган адәмнәр, азан тавышын ишетеп, безне кар астыннан чыгардылар. Ул азан тавышы хәзер дә колагыма килә." *(Габдрәшит Ибраһимов. Дәүре галәм. Тәрҗемәи хәлем.—Казан, 2001, 137-138 б.)*

Аллаһның рәхмәте белән, Габдрәшит Ибраһимов та, аның әтисе дә Уыш юлында исән кала, без дә төнгә таба исән-имин авылга килеп кердек. Безне киң урамнары, нык йортлары белән ак карга чумып утырган Уыш каршы алды, өй алларында чыршы-карагайлар чайкала, алар исә авылны тагы да серле һәм матур итеп күрсәтәләр иде. Әйе, йортлардан ук күренеп тора—монда халык бай, хәлле яши, тәрәзә-капкаларның бизәлеше Казан арты авылларын да хәтерләтә, әмма монда Себер иканлеген искә төшереп, йөз еллык чыршы-наратлар шаулаша... Авылга ямь өстәп, мәчет балкып утыра, манара башына әйтерсең лә төнге ярымай төшеп утырган... Әмма бу Габдрәшит Ибраһимов укыган мәчет-мәдрәсә түгел, анысы бераз читтәрәк булган, совет чорында ул озак еллар мәктәп вазифасын башкарган, хәзер исә юкка чыккан. Уышта укыган елларын Габдрәшит Ибраһимов менә ничек тасвирлый:

"Җиденче яшьләрем булса кирәк, атам мине кабат Уыш карьясына китереп, мәктәпкә бирде,—дип яза ул.—Ул заман югарыда әйтелгән карьяда Зәйн-әл-бәшир исемле зат мөгаллим иде. Мәктәптә миннән башка кичен беркем дә юк иде. Карья балалары бөтенесе көндезгә: көндез мәктәпкә киләләр, кояш баеганнан соң ханәләренә китәләр иде, мин ялгыз буларак, мәктәптә кала идем."*(Күрсәтелгән хезмәт, 138 б.)*

Менә без хәзер шул карья балалары—мәктәп укучылары белән очрашырга барабыз. Кулымда Габдрәшит Ибраһимовның "Дәүре галәм" һәм үземнең "Кучем хан" китаплары, татарча матбугат, күңелемдә бераз борчылу да бар, чөнки мин авыл халкы белән бераз аралашып, биредә Габдрәшит Ибраһимовны белмәүләрен аңлаган идем инде. Без авылның иң карт кешеләре Шәмсия апа Тугушева һәм Әхмәт әкә Сөләймановлар белән очрашып, болар турында бераз сорашкан идек инде. Алар икесе дә токымнары белән Казан ягыннан булып чыктылар. Әхмәт әкәнең әнисе Саба районының Юлбат авылыннан булган, революциягә хәтле үк монда килеп, Себер егетенә кияүгә чыгып калган.

—Әниебез Мәмдүхә бирегә 1914 елда килгән,—диде ул.—Ул килгәндә биредә инде ике Уыш булган. Бохарлыларның елга аръягында печәнлек җирләре булган, шуны урыслар ала дип бер төн эчендә бөтен бохарлылар шунда күчеп киткәннәр. Әнинең Габдрәшит хаҗи дип сөйләгәне бар иде, алар үзбәк ягыннан килгән Ахуновлар булган булырга тиеш.

Авыл интеллигенциясе дә Габдрәшит Ибраһимовның биредә укуы турында берни белми иде, аның үзе турында белүчеләр дә юк дәрәҗәсендә булып чыкты. Димәк, аңлатырга туры килә, алар миңа Габдрәшит Ибраһимов турында берни әйтә алмыйлар икән, бу бөек шәхесебез турында миңа сөйләргә туры килә. Әмма балаларның татарча аңлаулары ни дәрәҗәдә булыр—мине монысы да бераз борчый иде. Чөнки инде сорашып белүемчә, татар теле биредә атнага бер сәгать факультатив рәвештә генә керә икән, әдәбиятка бөтенләй вакыт бирелмәгән, калган бөтен дәресләр тоташ рус телендә үтә икән. Мәктәп коридорларында мин татарча язылган бер генә сүз дә күрмәдем, ә мәктәп китапханәсендә исә тау-тау булып Библия, христиан дине турында китаплар өелеп тора иде. Дөрес, Казаннан, "Мәгариф" нәшриятыннан кайтарылган өр-яңа татарча китаплар да бар иде монда, әмма кап-кара тышлы библияләр мине хафага салды, чөнки нигездә татар балалары гына укыган мәктәпкә нигә кирәк алар?

Әле очрашу башланганчы ук мин шушы сорауны китапханәче София ханым Таштимеровага бирдем.

—Бу библияләрне һәм христиан дине турындагы китапларны Тарадан, мәгариф бүлегеннән биреп кайтардылар, күргәзмә уздырырга,—диде ул.

—Ә нигә Библия янында Коръән дә юк, ислам дине турында китаплар юк, мәктәптә укучы балаларның 90 проценттан артыгы татарлар икән бит!—дидем мин.

—Аларны Тарадан бирмәделәр,—диде китапханәче ханым.

—Үзеңнән китереп куярга иде!—дидем мин, эчтән кайнавымны тыярга тырышып.

—Алай буламы?—диде София ханым, чын күңеленнән гаҗәпләнеп.—Ярамас бит!

—Библия ярагач, нигә Коръән ярамасын,—дидем мин.—Мәктәптәге өч урыс-марҗа өчен тау кадәр Библия тотасыз, ә йөзәрләгән татар өчен берни юк!

Аннан, миемне телеп, бер фикер килде, соң, бу библияләр татар балалары өчен тотыла бит! Алар өчен оештырыла бит бу христиан дине күргәзмәсе! һәм шулай булган да, китапханәче ханым махсус дәресләр оештырып, балаларга Библияне аңлаткан, чөнки аңа Тарадан шулай кушканнар! Болар турында ишеткәч, мәктәптән генә түгел, авылдан ук чыгып китәсем килде, татарның татар арасында Библия аңлатып йөрүен мин кабул итә алмый идем, чөнки бу мәктәпләрдә Коръән турында, ислам дине турында берни сөйләнми иде!

—Әгәр сез Библияне аңлатканнан соң берәр татар баласы христиан динен кабул итсә, моның өчен Аллаһы Тәгалә каршында да җавап бирәсегез булачак бит,—дидем мин китапханәче ханымга.

—Әйе шул, анысы да бар бит әле,—дип җавап бирде ул әкрен генә...

Олы Уыш мәктәбендә соңгы егерме елда Тарадан килгән марҗа хатыны директор булып эшләгән, ул авыл халкын утлы табада биеткән, бер миллилек күрсә, "Чечня!" дип кенә ысылдый торган булган. Ул директор булып эшләгәндә, татар укытучылары үз балаларын татар теле дәресләренә йөртмәгәннәр, исем-фамилияләрен урысча әйтүгә җайлаштырганнар, татар теле бер почмакка куып кертелгән. Марҗа киткән, әмма өргә калган, татар теле һаман шул почмагыннан чыга алмый интегә. Мәктәптә музей юк, авыл халкыннан бәет-дастаннар җыелмаган, әдәби түгәрәкләр эшләми. Бирегә моңа кадәр бер генә татар язучысының да килгәне булмаганын әйттеләр, ягъни мәктәп балаларының зур

татар дөньясы белән элемтәләре юк иде. Шуңа күрә мин, Габдрәшит Ибраһимов һәм Күчем хан темасына күчкәнче, җыелган балаларга һәм укытучыларга татар халкы, аның бөек һәм фаҗигале тарихы, Казаныбызның меңьеллыгы турында сөйләдем, Уыш авылы халкының да шушы милләтнең бер өлеше булуын әйттем. Аннары мин бүгенге көндә Татарстанда халкыбызның ничек яшәвен сөйләдем, Себер белән чагыштырганда үзебезнең бар өлкәләрдә дә ярты гасырга алда баруыбызны әйттем. Татарстан мәктәпләрендә татар телен татар балалары гына түгел, рус балалары да программа кысаларында укуларын белгәч, залда утыручылар гаҗәпкә калдылар. Аннан мин аларның татар телен ни дәрәҗәдә белүләре белән кызыксындым, берәр шигырь сөйләп бирүләрен сорадым. Балалар хор белән Габдулла Тукайның "Туган тел"ен сөйли башлагач, күзләремә яшь килде, мин үземне Татарстан мәктәпләрендә кебек хис иттем, аларга кушылып, шигырьне дәвам иттем. Шулай итеп, Уыш балалары белән ике арада күпер салынган иде, ул күпернең исеме татар шигыре иде...

Аннан инде мин үземнең төп темама күчтем, күренекле якташлары Габдрәшит Ибраһимов турында сөйли башладым. Бу шәхеснe бөтен гарәп-төрки дөньяның тануын, алай гына түгел, хәтта Япония, Германия кебек илләрдә аның хезмәтләре яңадан басылуын, Габдрәшит Ибраһимов иҗаты буенча фәнни хезмәтләр, китаплар язылуын әйткәч, балалар гына түгел, укытучылар да тынып калдылар, һәм шушы кеше беренче сабакларын шушы Уыш авылы мәктәбендә алган бит, биредә укыган! Мин Габдрәшит Ибраһимовның үз китабыннан Уыш турындагы өзекләрне укыдым, аның балачагы һәм яшьлеге турында җан тетрәткеч вакыйгаларны сөйләдем, һәм сизеп тордым—әле кичә генә аның кемлеген дә белмәгән авылга Габдрәшит Ибраһимов яңадан әйләнеп кайткан иде, ул әйтерсең лә шушы залда, балалар арасында утыра һәм үткәннәр турында үзе сөйли иде...

"Бу арада ул мәктәпне дә бераз тасвирлау бер төр файдадан хали булмаячактыр. Мәктәп исә мәсҗеднең аст каты булып, бүе сигез аршин вә киңлеге исә алты аршин бер бүлмәдән гыйбарәттер. Иртә булгач та, балалар мәктәпкә киләләр, һәр бала култыгына алып, бер агач утын китерер.... Бу мәктәптә бер кыш, ягъни, сигез ай тарафында без иң җитешкән гыйлем алдык, әмма нәрсә укыганымны һич хәтеремә китерә алмыйм. Соңыннан яз булды, Тарага кайттык." *(Күрсәтелгән хезмәт, 138 б.)*

—Күрәсез, балалар, башлангыч белемне Уыш авылы мәктәбендә татарча алып та, калган мәдрәсәләрдә укуны татарча дәвам итеп тә, Японияләргә барып җитәргә, япон принцларын ислам диненә кертергә, Төркиядә төрек солтаннары белән бер өстәл артына утырып, дөнья проблемаларын хәл итәргә була икән! Шуңа күрә үзебезнең ана телебезгә зур игътибар бирегез, татар дәресләренә йөрегез, татар китаплары укыгыз, татарлыкның, мөселманлыкның кадерен белегез, сез дә якташыгыз Габдрәшит Ибраһимов кебек дөньяга танылган бөек зат булырсыз, иншаллаһ!

Очрашу ахырында мин балаларга Күчем хан турында сөйләдем, шигырьләремне укыдым, сорауларына җавап бирдем һәм китапларымны бүләк иттем, кайберләре соңыннан Интернет адресымны да сорап алдылар. Мәктәптә, бигрәк тә бу балаларның күңелендә татар рухы уянып калуын сиздем, Габдрәшит Ибраһимов та, Күчем хан да, әле генә алар каршына басып шушы хакта сөйләгән язучы апалары да аларга инде ят түгел иде. Соңыннан исә, мәктәп директоры Эдуард Алиарбак улы Муратов белән аерым сөйләшкәндә, мин татар теленә аерым игътибар кирәклеген әйттем, шулай ук Тарадан кушалар дип христиан дине белән мавыкмаска, киресенчә, татар балаларында исламга мәхәббәт уятырга чакырдым.

Олы Уыш авылы Тара районында иң зур татар авылы икән, анда миңа якын кеше яши, төп халык—татарлар. Дөрес, моннан берничә дистә ел элек янәшәдәге Солдатово авылы белән кушылгач, авылга урыс теле һәм урыс рухы үтеп керә, урамда үзара русча сөйләшкән кешеләрне очратып, имәнеп китәсең. Кыскасы, заманында бармак башы хәтле урыс авылы Олы Уышны йота яза, мәктәп, почта да Солдатово исеме белән йөртелә башлый. Ә шул вакытта Кече Уышлар Солдатовога кушылмыйча, үзләре булып калалар, хәтта шактый еллар мәктәпләрен дә саклап киләләр. Әмма Олы Уыш халкында элек-электән килгән мәгърифәтлелек барыбер җиңә, авыл үзенең мәдәнияте һәм гыйлемгә омтылышы белән барыбер алга чыга һәм урыс авылын үзе йота. Авылда гөрләп Мәдәният йорты эшләп тора, анда берьюлы дүрт милли ансамбль эшли һәм шуларның өчесе балаларныкы һәм

үсмерләрнеке. Әйтик, "Кояш" ансамблендә кечкенә кызлар җырлый, "Сәлам"дә—яшүсмерләр, "Рузалина" ансамбле Уышның иң гүзәл кызларыннан тора, ә инде "Дуслык"та авылның хатын-кызлары җырлый. Махсус белемле Гөлнур ханым Рахмангулова Олы Уышны менә шулай җанландырып җибәрә, хәзер үзешчән артистлары Тара шәһәрендә уздырылган барлык җыр бәйгеләрендә катнашып, алдынгы урыннарны яулап килеләр икән.

Авыл китапханәсе турында да бары тик мактау сүзләре генә әйтерлек, ул чын мәгънәсендә мәгърифәт учагына әйләнгән. Киштәләрендә 11 мең китап булган Олы Уыш китапханәсенә соңгы вакытта Казаннан да йөз данә иң яхшы китап җибәргәннәр, әмма мәктәптәгеләр бу бүләктән үзләренә аз өлеш тиюен әйттеләр. Чыннан да, бәлки Казан китапларын урталай, тигез итеп бүләргә кирәк булгандыр, ул вакытта мәктәптә библияләргә урын азрак калыр иде.

Авылда Габдулла Тукай, Муса Җәлил исемендәге урамнар барлыгын да әйтеп үтәргә кирәк, мәчет тә Муса Җәлил урамына урнашкан. Авылда Хаҗга баручылар да бар икән, җомга көн картлар мәчеткә йөри, ә Рамазан аенда шактый кеше ураза тота. Авылны алай бик дини дип әйтеп булмый, әмма күзгә ташланып торган динсезлек тә күренми. Дөрес, монда да эчкечеләр шактый, шул сәбәпле үлүчеләр дә бар, хәтта хатын-кызлар арасында да эчүчеләр бар икән. Югыйсә саф табигатьтә, җәннәт кебек матур җирләрдә, үз туфрагында яшәп, ничек эчкече булырга мөмкин? Элек Олы Уышны "ризыклы авыл" дип йөрткәннәр, чөнки монда барысы да бар—тирә-якта урманнар, урманнар тулы җиләк, чикләвек, гөмбә, көз җитсә—мүк җиләге, нарат җиләге. Елга тулы балык, болынлыклар тулы чәчкә-үлән, кырларда иген үсә, мал йөртергә дә урын күп. Халыкта, игенчелек һәм терлекчелектән тыш, нинди һөнәрләр булуы белән кызыксындым. Безнең яклардагы кебек, монда да шәл бәйлиләр икән, хатын-кызлар, гомумән, бәйләү эшенә осталар, элек палас суккannар, ирләр ат чаналары ясаганнар. Кыскасы, үзләренә кирәк нәрсәне Уыш халкы үзе ясаган, үзе тапкан.

Авылда иң күп таралган фамилияләр белән кызыксындым—Сөләймановлар, Аширбаевлар, Аширмәмәтовлар, Авазовлар, Ганиевлар, Баратовлар икән, Кече Уыштан килгәннәрдә Ахуновлар һәм Шөгеровлар күп. Казанлы белән бохарлылар фамилиядә генә түгел, төс-биткә, холык-фигыльдә дә шактый аерыла. Казан ягыннан килгән татарлар ак йөзле, зәңгәр күзле, озын буйлы булсалар, бохарлы Себер татарлары бераз кысыграк күзле, каратут йөзле һәм кыскарак буйлылар. Казан татарлары яраклашырга яраталар, ә себерлеләр үз сүзле дигәнрәк фикер калды. Бәлки ялгышамдыр да, чөнки бер килеп кенә халыкның холкына тулы бәя биреп булмый.

Соңгы елларда Уыштан югары уку йортларына керүчеләр дә шактый. Ә Уыш суында коенып үскән Гариф һәм Кәшиф Тухмөхәммәтовлар, хәрби диңгез офицерлары булып, диңгез-океаннарны гизгән ир-егетләр, Петербургта аларның уллары да шушы юлны дәвам итә. Бүгенге көндә Омск һәм Тара шәһәрләрендә дә Уыштан чыккан күп белгечләр, талант ияләре эшләп ята. Әмма төп көч барыбер авылда кала, авылны яшәтә. Дөрес, биредә әле табигый газ да кертелмәгән, юл да асфальт түгел, күтәртелгән генә, халыкка эш тә юк дәрәҗәсендә. Әмма күпләр үз хуҗалыгын тәртиптә тотып, хезмәт сөючән балалар үстереп, бөтен нәсел-токымның тырышлыгы белән, авылда да менә дигән итеп яшәп ята. Әгәр бу авылга иман белән бергә ислам әхлагы да кайтса, бөтен тирә-юньгә үрнәк булып яшисе Уыш бу! Чөнки биредә Габдрәшит Ибраһимов кебек изге затлар намаз укыган, дога кылган, теләк теләгән бит...

*Ахыры киләсе санда*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Иске Масра авылы

Масра берәмлеге катнашып ясалган атамалар Арча районында очрый. Иске Масра авылы район үзәге Арча эшчеләр бистәсеннән 16 чакрымда, Казаннан—74, Югары Масра авылы район үзәге Арчадан—18, Казаннан 74 чакрым ераклыкта урнашкан.

Масра атамасы тарихи чыганакларда еш телгә алына. Арча юлындагы Масра авылы Казан ханлыгы чорында ук булган инде. Казан өязе теркәү кенәгәсендә (1602—1603 еллар) Масра атамасы искә алына. Эпиграфист Һарун Йосыпов Югары Масра авылында XVI йөзгә мөнәсәбәтле кабер ташлары тапкан. Бу ташны һәм Иске Масра авылында XVI йөзнең беренче яртысына мөнәсәбәтле кабер ташлары булган зиратны археологлар да теркәгән.

Д. А. Корсаков (XVIII йөз) мәгълүматларына караганда, Иске Масрада 105 ясаклы татар, Түбән Масрада 13 йомышлы татар яшәгән. А. Артемьев хезмәтендә күрсәтелгәнчә, Яңа Масрадагы 58 йортта 253 ир-ат һәм 238 хатын-кыз яшәгән, бер мәчет эшләгән. Иске Масра авылында 68 йорт булып, анда 348 ир-ат 312 хатын-кыз көн иткән, бер мәчет булган. Н. Н. Вечеслав җыентыгында Югары Масра авылында барлыгы 81 хуҗалык булып, аларда 327 ир-ат һәм 309 хатын-кыз яшәгәнлеге күрсәтелә. Авылда бер агач мәчет булган. Кесмәс буендагы Иске Масра авылында 416 ир-ат, 341 хатын-кыз көн иткән. Авылда бер агач мәчет, вак-төяк сата торган бер кибет, бер су тегермәне эшләгән. И. А. Износков китабында Югары Масра, икенче төрле Яңа Масра авылы турында түбәндәге мәгълүматлар бирелгән. Бу авыл Себер элемтә юлының уң ягына урнашкан. Авылдагы 81 хуҗалыкта ислам дине тота торган 331 ир-ат һәм 341 хатын-кыз яшәгән. Авыл халкы урта хәлле булган. Алар балта эше, бүрек тегү, игенчелек белән шөгыльләнгәннәр. Кесмәс ярындагы Түбән Масра, икенче төрле Иске Масра Себер элемтә трактының уң ягына урнашкан булып, авылдагы 96 хуҗалыкта ислам дине тота торган 425 ир-ат һәм 439 хатын-кыз яшәгән. Халык тегүчелек, умартачылык, иген игү белән шөгыльләнгән. Авылда су тегермәне һәм вак-төяк сата торган кибет булган. 1898 елгы китапта Иске Масра һәм Яңа Масра авылларында татарлар яши дип билгеләнә. К. П. Берстель җыентыгында Иске Масрада (Түбән Масра)—696, Югары Масрада (Яңа Масра) 532 татар кешесе яшәгәнлеге әйтелә.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, Югары Масра, Иске Масра авыллары халкы Ташкичү, Сеже, Гөберчәк, Сикертән, Казаклар, Чөмә-Елга, Иске Му, Югары Курса, Түбән Курса, Курса Почмак, Урта Курса авыллары белән бергәләшеп Му җыены бәйрәм иткән.

Олылар сөйләвенә караганда, авылга нигезне Мәккә шәһәре тирәсендәге Басра каласыннан килгән кешеләр салган. Тора-бара Басра атамасы Масрага әйләнгән.

Галиәсгар Камал Масра авылы турында түбәндәгеләрне яза.

«Масра белән Сикертән авыллары арасында халыкның типларында, бигрәк тә моннан кырык биш ел элекке вакытларда аерма бик күп иде. Масра халкының сөйләвенә караганда, Масра халкының ерак бабалары, Идел болгарлары мөселман булгач, Болгар ханнарының чакырулары буенча, халыкны сөннәткә утырту өчен

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

Гарәбстаннан килгәннәр, имеш, алар үзләре Әнәс сәхабә нәселеннән, имеш (сөннәтче бабаларның әйтүләренә караганда, аларның кулларында бу дәгъваның дөреслеген исбат итә торган, нәселдән нәселгә күчеп йөри торган шәҗәрә"ләре дә бар диләр, ләкин минем күргәнем юк). Менә, ханнарның чакыртуы буенча килгән шул сөннәтче гарәпләрдән берникадәресе Казан ханлыгына килгәннәр дә, Казан ханы аларны икегә аерып, бер өлешен тау ягына Кошман дигән авылга, икенче өлешен яхшы урманлы, җирле, сулы урын булган хәзерге Масра авылы урынына урнаштырган; алар анда казан татарлары кызларына өйләнеп, авыл булып утырганнар да, гарәпчә «Зур шәһәр» мәгънәсендә булган Мисырга охшатып, авылларына Масра дип исем биргәннәр; шуннан, балаларының телләре аналарына ияреп, татарлашып киткәннәр дип сөйлиләр һәм моның дөрес булуын исбат итәргә ярарлык татар һәм янәшәтирәдәге башка халыкка бер дә охшамаган, ләкин гарәпкә охшаган, чәч-сакаллары чем-кара кешеләр, сирәк булса да, Масрада очрыйлар».

Мөхәммәт Мәһдиев Масра авыллары турында мондый мәгълүмат бирә.

«Арча юлына таба ике Масра—Югары һәм Түбән Масра—Г. Камалның язуынча гарәпләр. Г. Камал белми язмас, ул Түбән Масрада мәдрәсәдә укыган, аның әнисе шул авылныкы. Масраны ул Мисыр сүзеннән килеп чыккан дип аңлата һәм, ихтимал, хаклыдыр. Анда ирләр озын буйлы, эре тешле, кап-кара кашлары килеп кушылган—үзенә бер аерым кешеләр. Алар, имеш, Казан ханлыгы чорында миссионерлар ролендә бу якка—мари, удмурт тулы урманлы авыллар чигенә килеп урнашканнар. Миссионерлыкның конкрет программасы да булган; мөселманлыкка чыккан халыкның ир балаларын сөннәткә утыртырга кирәк икән...

Эре тешле, куе тоташ кашлы Масра картлары... Алар—безнең бала чакта ин куркыныч кешеләр иде. Әйтик, өч-дүрт яшьтә вакытта «Масра бабай килгән» дигән хәбәр бөтен авыл малайларын котчыккыч халәткә китерә, ул хәбәр таралган көнне урамда уеннар туктала, малайлар кырга, урманга кача, кечерәкләр абзар, мунча, келәт тирәләрендә көне буе берни ашамыйча-эчмичә яшеренеп ята иде».

Иске Масра һәм Югары Масра авылларының икесе дә Кесмәс суы бассейнына утырган. Кесмәс суына тагын Тарлау, Тегермән, Мөхәммәтша, Курса Почмактан чыккан сулар кушыла. Авылдан ерак түгел Дәүләт чишмәсе челтерәп ага. Ул суын Кесмәс суына коя. Ике авыл арасында Бүртә елга дигән җир бар. Суы юк, ләкин элек булган. Бу исем күбрәк анда урнашкан күпергә мөнәсәбәтле. Бүртә елгасы күпере дип аталган күпер әле дә халык телендә. Халык хәтерендә Сапый күпере атамасы сакланган, ә күпер үзе юк. Күрәсең, монда Сафа исемле кеше күпер салган булса кирәк. Гайнулла абзый чишмәсен шул исемдәге кеше карап торган. Кызганыч, ул чишмә хәзер беткән инде. Мөрәс коесы дип аталган урында сазлык булган, хәзер ул кипкән.

Авыл янында Му зираты өсте, зиратның теге ягында Кирәмәт дигән урыннар бар. Куян сазы дигән урында куяннар күп очраган. Элекке Малмыж өязендә мари авылы Масра булган. Ул чирмешләр мондагы Масра авылыннан күчкәннәр.

Авыл тирәсе тоташ урман. Бер урманны Казан урманы дип атаганнар. Берсе аша Әби патша юлы дигән юл үтә. Ул юл Екатерина II идарә иткәндә төзелгән.

Иске Масра авылында Югары урам, Урта урам, Аргы яклар дип йөртелгән өч урам бар. Иске Масра авылында якынча 60 хуҗалык калган. Авылда клуб юк.

Авыл кечкенә генә булуына карамастан, халык матур итеп яши. Каралты-куралары төзек һәм нык.

Халык караучысыз калган олыларны игътибар үзәгендә тота, ярдәм итә.

Авыл халкы ата-ана, әби-баба яткан зиратны карап һәм тәрбияләп тора. Зиратның тирә-юне әйбәтләп тотып алынган, һәр елны язга чыгу белән чүп-чары җыела һәм чистартыла.

Авыл яши, тырышлык белән көн күрә.

*Дәвамы киләсе саннарда*



Ләбибә
Ихсанова

# ЗӨЛФИЯ ХАТЛАРЫ

Быел минем СССР язучылар берлегенә кабул ителүемә 60 ел тулды. Үземә, Аллага шөкер, сиксән биш булып килә. Шундый озын-озак гомеремдә, әдәби тормышымда бик күп вакыйгалар баштан кичте. Гаилә бәхетен татыдым, акыллы-шәфкатьле өч бала үстердем, хәзер оныкларымның оныкларын күреп сөенәм.

Бәхетемә, әдәбиятның йөзек кашлары саналган Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Фатих Хөсни, Атилла Расих, Нәкый Исәнбәт һәм башка бик күпләр, сугыштан соңгы иҗади сулышны бер булып күтәргән кешеләр—минем язучылык осталыгымны арттыруда беренче ярдәмчеләрем булды. Ирем, күренекле татар шагыйре, фронтовик Шәрәф Мөдәррис беренче китабым "Көмеш елга"ны язарга фатиха биреп, аннан соңгы әсәрләрем турында беренче фикер әйтүче иде.

Алтмыш еллык иҗади хезмәт хатын-кыз язучы өчен аз вакыт түгел. Ул елларда мин кырыктан артык исемдә китап чыгардым, балалар өчен язган китапларымның гомуми тиражы миллион ярымга җитә.

Мин—балалар язучысы. Моны мактанып һәм горурланып әйтәм. Татар балалар әдәбиятында якты эз калдырган Гариф ага Гобәйдән һәм миннән кала тормышын һәм әдәби куәтен бары тик балаларга гына багышлаган язучы безнең арада башка юк. Бала тәрбияләү, аны игелекле, миһербанлы, акыллы һәм булдыклы итүдә әдәби сүзнең көче бик югары.

Ә әдәби язмышлар, вакыйгалар, очрашуларга килгәндә... Алар бик күп. Бу язмамда мин шуларның берсен—Үзбәкстан халык шагыйрәсе, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Зөлфия ханым белән танышлыгымны искә аласым килә. Чөнки бу очрашу-танышлык ике язучының үзара дуслыгы гына түгел, ул ике зур халыкның, ике тугандаш халыкның дуслыгы иде.

Беренче тапкыр мин Зөлфия ханымны СССР Язучыларының IV съездында очраттым. Аңарчы шигырьләрен укып, "Литературная газета"дан рәсемнәрен күреп кенә белгән ханым, каршыма килеп:

—Сез Казаннан түгелме?—дип сорады. Мин, исәнләшеп, үземнең кемлегемне әйттем.

—Сажидә Сөләймānованы белмисезме, ул килмәгән, ахры, миңа хатлар язып тора иде,—диде.

Ул елларда Сажидәбез әдәби мөнбәргә яңарак кына күтәрелә, шигырьләре татар укучысына таныла башлаган иде.

—Берничә шигырен "Саодат" журналына бирергә уйлыйбыз, мин журналның баш мөхәррире,—диде. Миңа "Өрек чәчәге" дигән китабын бүләк итте.

Ниндидер гадилек, шунын белән бергә затлылык бөркелә иде аңардан.

...Бервакыт, " Казан утлары" журналында җаваплы секретарь булып эшләгән чагым бу. "Литературная газета"да Зөлфиянең яңа шигырьләре чыкты. Нури ага Арсланов журналның шигърият бүлеген җитәкли, укыдык та, тәрҗемә итеп журналда бастырырга булдык. Ул вакытта баш мөхәрриребез Зәки Нури иде, берсүзсез риза булды. "Өрек чәчәге" дигән китапны да Нури агага бирдем, китап итеп чыгарырга кирәк, дип сөйләштек. Менә шуннан китте хатлар алышу...

***

Кадерле дустым Ләбибә ханым! Сәлам. Мин иптәш Арслановка моннан ике ай элгәре үк әзерләп куйган хат вә шигырьләремне Сезнең үзегезгә җибәрәм. Башыбызга күп хәсрәтләр төште, үзем авырдым. Мәскәүгә съездга да бара алмадым. Инде тынычлык. Бу шигырьләрне тәрҗемә итеп торсалар, тагы үземә ошаган 4-5

шигырь җибәрермен. Болар барысы да тәрҗемә өчен дигән сүз түгел, сайлап алу өчен.

Сау булыгыз. Хикәяләремне җибәрегез.

*Сезне үбеп, Зөлфия. 29. VII. 71.*

***



Газиз дустым Ләбибә ханым!

Яна ел тәбрикнамәгез һәм минем шигырьләремә карата мәхәббәтегез өчен зур рәхмәт.

Мин Һиндстаннан кайткач, бераз авырдым, хәзер яхшы.

Сезгә тагы берничә шигырь җибәрәм. Үзегезгә ошаганын сайлап алырсыз. Оригиналга кушып русча тәрҗемәсен дә җибәрәм, тәрҗемәчегә шигырьнең асылына төшенергә ярдәм итәр.

Без һәммәбез—татар, үзбәк—тәрҗемәчесез аңлаша торган бер телле, бер динле кешеләр бит.

Ләбибә ханым, мин сезне, язны көткән кебек, Ташкентта көтәмен.

Сезгә, Асия ханымга *("Азат хатын" редакторы. Л. И.)* вә барча дусларга сәлам. Мин Казанда булган чакларны һичкайчан онытмамын.

*Сезнен Зөлфия. 14. I. 71.*

***

Татар әдәбияты узган гасырның 60-80 нче елларында тугандаш әдәбиятлар белән якыннан аралашып, дуслашып, иң яхшы әсәрләрне тәрҗемә итеп, китаплар алышып яшәде. Казанда тирә-күрше халыкларның әдәби бәйрәмнәре еш була иде, шулай ук алдан әзерләнеп, зурдан кубып союздаш республикаларның әдәби атналыкларын үткәрә идек. Шундыйлардан үзбәк, казакъ, украин язучыларының бәйрәмнәре аеруча истә калды.

Үзбәкстан язучыларынын Татарстандагы бәйрәменә Зөлфия ханым да килгән иде, Асия Фәридовна безнең икебезне өенә кунакка чакырды. Зәвык белән әзерләнгән татар ашлары һәм... әдәбият турында табып, гәпләшү. Асия Фәридовна нигәдер минем белән бәхәсләшеп китте дә, икебез дә сүзебезне бирмичә, кунакны онытa язганбыз, ахры:

—Утырмагыз әле маржалар төсле (чукынып, дигәнен эчендә калдырды)...—Өчебез дә көлеп җибәрдек.

Асия Фәридовна кече кызы—бәгырь кисәге суга батып үлгәч, хәсрәтеннән бераз гына булса да арынып торсын дип, Зөлфия аны Ташкентка "Саодат" журналына кунакка чакырган иде. "Менә нинди кешелеклелек, олы йөрәклелек"—дип сокланган идек без ул вакытта Зөлфиягә. Бу юлы Казанда шундый мәрхәмәтле кеше, үзбәк хатын-кызларының уртак әнисе—"Саодат"ның баш редакторы Зөлфия ханым белән очрашу безнең дуслыкны тагы да ныгытты.

***

Минем кадерле дустым Ләбибә ханым! Хамид Алимҗанның (Зөлфиянең ире, Үзбәкстан халык шагыйре. Л. И.) шигырьләре басылган журналны алганга күп вакыт узган булса да, Сезгә хат яза алмавым өчен гафу итәрсез. Бу игелегегез өчен Сезгә күп рәхмәт, мин бик шатландым.

Ләбибә ханым, хәлләрегез ничек? Нинди хикәяләр, повестьлар яздыгыз? Яна хикәяләрегезне безгә җибәреп торыгыз.

Сез журналда тәрҗемә итеп чыгару өчен шигырьләремне сорагансыз, рәхмәт, әлбәттә, җибәрермен. Сөйгән татар дусларым, татар кешеләре белән шигырь аркылы күрешү минем өчен бик күнелле.

Ләбибә ханым! Мин якын көннәрдә Һиндстанга китәмен, декабрь башларында кайтырмын. Асия ханым белән минем шәхси кунагым булып килегез. Мин Сезне Сәмаркандка алып барырмын, безнең ата-бабаларыбыз корган сәнгать әсәрләре—архитектура корылмаларын күрерсез, үзбәк дуслар белән күрешерсез. Яна дуслар кулы белән торгызылган Ташкентка сәфәр кылырсыз. Минем балаларымның, үземнең иң газиз кунагы булырсыз.

Көтәбез. Асия ханымга сәлам әйтегез.

*Сезнең Зөлфиягез.*
*12. X. 72.*

***

Бик кадерле Ләбибә ханым!

Берничә сәгатьтән Алма-Атага китәм. Шул сәбәптән хатым бик кыска була. "Өрек чәчәкләре"нең оформлениесе Сезгә ошый сыман. Мин ни әйтим? Формат яхшы, китапның исеме дә начар түгел. Бары тик чәчәк савыты—вазаның йөрәк формасында булуы миңа ошап бетми. Әгәр сезгә ошаса, бирерсез, китап булып чыксын. Миңа шигырьләрнең тәрҗемәсе яхшы булуы сөенеч. Юк, начар түгел. Әйбәт китап булачак! Тик китап эчендәге бизәкләр-оформлениесе—башкачарак булса иде. Алай да, Сез, Арслан ага вә рәссам ничек телисез, шулай булсын.

Сезләргә бик зур рәхмәт: күп хезмәт куйдыгыз. Чын күңелдән рәхмәт.

*Сәлам белән Зөлфия, июнь, 73.*

***

Кадерле Ләбибә ханым!

Мин Сезгә сирәк язсам да, Сезне яратам, сагынам, юксынам. Сез минем йөрәгемдә Татарстан булып яшисез. Кызганыч, без бик сирәк күрешәбез. Сезнең барлык хатларыгыз миңа шатлык алып килде. Минем хакта кайгырткан, мине татар дусларым, китап сөючеләр белән кавыштырган кеше сез, Ләбибә ханым!

Ләбибә ханым! Минем сәламәтлегем начар булды, башыма күп кайгылар килде. Сезгә вә Нури Газизовичка да яза алмадым. Хәзер беркадәр уңай хәлдәмен.

Китапны кулыма алдым, солидная получилась. Исемен дә яхшы тапкансыз. Фәкать яхшы дуслар гына, изге ниятле кешеләр генә шулай эшли аладыр.

"Казан утлары" журналында язылган сүз башы яхшы диделәр, үзем табып укый алмадым әле, беләм, Сез минем турыда начар язмассыз.

Инде Сезнең үзегез хакында. Безнең китап сөючеләр, журнал укучылары Сезнең яңа хикәяләрегезне үз телләрендә укый алганнары юк. Рәхим итеп безгә үз әсәрләрегездән, хикәяләрдән 5-6 хикәя һәм үзегез турында язылган мәкалә җибәрсәгез бик яхшы булыр иде. Бездәге журналларга бирер идек. Фотосурәтегезне дә онытмагыз. Кичектермичә миңа җибәрегез.

Хатым яхшы чыкмады, язучы хатына охшамады. Хәлем әйбәт түгел, һаман башым авырта. Бу ел беркая да китә алмыйм.

Обстоятельства так складываются.

*Сәлам белән Сезнен Зөлфия.*
*7. VI. 73.*

***

Күп хөрмәтле, кадерле Ләбибә ханым!

Мин Сез газиз дустымны чын йөрәктән 1 Май бәйрәме белән тәбрик итәмен, иң яхшы теләкләребезне кабул итегез.

Ләбибә ханым! "Өрек чәчәкләре" татар туфрагында чәчәк ату өчен Сез дә бик күп хезмәт куйдыгыз. Минем аңлавымча, аның инициаторы Сез булдыгыз. Мин өлкән дустыбыз Нури Арслан агабызның мәрхәмәте белән татар теленә күчерелгән шигырьләремнең татар китап сөючеләрнең йөрәгендә чәчәк атуына бик шатмын.

Шигырьләр бигрәк яхшы тәрҗемә кылынган, мин үзем дә укып рәхәтләндем. Барысы өчен рәхмәт Сезгә, күп борчылдыгыз, мин Сездән гафу итүегезне сорыйм, минем мәрхәмәтле дустым. Безнең Ташкентка килегез!

*Сезнен Зөлфия. Май. 74 ел.*

Китап чыккач Зөлфия ханым Нури ага белән мине, вакытын әйтеп, кунакка чакырды. Редакторыбыз Зәки Нури ул вакытта командировкада буласы иде, шунлыктан Нури ага Ташкентка хатыны Клавдия Николаевна белән китте. Бик зур хөрмәт күреп, кунак булып, ял итеп, миңа күп күчтәнәч-бүләкләр белән әйләнеп кайтты Нури ага. Аннан соң да Зөлфия ханым Исраиловна белән хатлар алыштык әле, тик вакыт үткән саен хатлар йөреше сирәкләнде, әмма тугандаш ике халык язучысының дуслыгы сүрелмәде. Үткән елларны, дусларны искә алып, бу хатларны журнал укучыларга тәкъдим итәргә булдым.

Әхмәт
Рәшит

# ҺӘРКЕМНЕҢ... ҮЗ СУКМАГЫ

ХАТИРӘЛӘР

## Безнең бәхетсезлеккә...

Әти авылга ул көнне гадәттәгедән иртәрәк кайтты. Безгә каршы тыкрык буенда бер төркем ирләр җыелып сөйләшеп, гапләшеп утыралар. Ни сәбәптәндер бераз "җылынып" та алганнар. Мин—һәрвакыттагыча әти кочагында. Ара-тирә "сугыш", "сугыш" диләр. Мин бернәрсә аңламасам да, ничектер куркыныч булып китә. "Безне дә иртәгәләргә алып җибәрерләр инде", диләр. Димәк, мин инде, әтигә сыенып, башка болай иркәләнеп утыра алмаячакмын—кемнәрдер әтине каядыр алып китәчәк. Кайсыдыр өлкәнрәге: "Тормышлар рәтләнә башлагач кына бит... Бу сабыйлар кем кулына кала инде", дип куя. Күзеннән эре-эре яшьләр тәгәри. Мин гаҗәпләнеп аңа карыйм. Ирләр дә елый микәнни?! Монарчы мин әтинең бервакытта да елаганын күргәнем юк иде. Шул вакыттан бирле мин, ирләрнең елаганын күрсәм, әллә нишләп китәм—ул гайре табигый хәлгә тыныч күңел белән карый алмыйм. Әнә әтинең дә күзләре дымланган—һәрвакыт көләч, мәзәкчән булса да, бу юлы чыраена мин аңламастай сагыш кунган. Мин аны-моны белештермәстән: "Әти, миңа сугыштан мылтык алып кайтырсың, яме?" дип куям. Әтинең йөзе кырыслана. Кайсыдыр: "И сабый!" дип башымнан сыйпый. Кызмача әти:

*Аргы яктан бирге якка*
*Кемнәр таяк ташлаган?*
*Без бәхетсезлеккә каршы*
*Герман сугыш башлаган,—*

дип җырлап җибәрә. Әйе, менә хәзер аңлыйм: күңелләрне тетрәндерерлек кайгылы һәм каһәрле көн булган бу. Гариф абый кесәсенә яшерелгән "бәләкәй генә урыс малае" телләрне дә чишеп җибәргән:

*Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,*
*Сау булыгыз, туганнар...*

Мин әтине сугышка озатканымны хәтерләмим. Ваемсыз балачак дип тикмәгә генә әйтмиләрдер шул. Әти җир бетереп мине эзләгән, ә мин, юләр малай, яшьтәшләрем белән кече елга буендагы куе таллыкта качыш-качыш уйнап йөргәнмен. Әгәр белгән булсам... әгәр белгән булсаммы...

Әни ул киткәч капчыкка азык-төлек, кием-салым тутырып берничә мәртәбә кайларгадыр барып та кайтты. Кайткан саен: "И мескеннәр, бөтенесе ачлар, ябыгып, бетләп беткәннәр. Тиреләрендә җаннары гына бар. Ничекләр генә исән калырлар инде..." дип елый-елый сөйли торган иде. Ул яманаты чыккан шул Суслонгер хәрби өйрәнү лагеры булгандыр, мөгаен...

Авыл моңаеп, котсызланып калды. Көн саен урамнарда сыктау, зар, елаш. Нинди каты бәгырьле ир-атлар да юашланган, нечкә күңелләнгән. Әтисе сугышка киткән һәр сабыйның башыннан сыйпап үтәләр, минем кебек малай-шалайны да зурга

*Дәвамы. Башы журналның узган санында.*

санап, озак-озак: "Атаңнан хат-хәбәр киләме? Нәрсәләр яза?" дип сораштырып торалар. Аннан, авыр итеп көрсенәләр дә, башларын түбән иеп, үз эшләре белән китеп баралар. Бәлки алар да йә үләргә, йә гарипләнергә чират көтәләрдер—бүген булмаса, иртәгә военкоматтан менә-менә повестка килеп житәр дә, алар шаулап үскән иген кырларын, гөлчәчәкле болыннарны, газиз ата-аналарын, сөйгән ярларын, назласаң назлап туймастай нарасыйларын язмыш кулына калдырып, җәһәннәм уты эченә кереп китәрләр. Ә алда—билгесезлек. Ә монда—авылда жыен гарип-гораба белән теләсә нинди судан коры чыгарга сәләтле үтә хәйләкәр әтрәк-әләмнәр генә, гүр иясе булыр вакытлары житкән карт абзыйлар гына калачак. Әнә безнең күрше Сәлимгәрәй абзый ике көннең берендә кәнсәләр тирәсендә, районнан килгән хәрбиләр янында чуала. Алар аңа игътибар итсәләр, кул биреп күрешсәләр, мөгаен, атналар буе кулын да юмый йөрер иде. Каргалган утыз жиденче елларда НКВД кешеләренә хәбәр житкереп торучы авыл куштаннарының берсе, һичшиксез, шул үзе инде. Хәер, ул моны беркемнән яшермәде дә бугай, киресенчә, күкрәк киереп гел-гел: "Милитсегә явить итәм" дип шапырына гына иде. Куркалар иде аннан. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында, немецләргә әсирлеккә төшеп, байтак вакыт Германиядә яшәгән Сәлимгәрәй абзый бик еш кына татарчаны, урысчаны, немецчәне буташтырып сөйли, хәтта безгә, малайларга ачуы килгәндә: "Фарфлюхтер, шлихтер" дип кенә жибәрә иде. Шул "шлихтер" сүзе аңа соңрак кушамат булып та ябышты. Ул, әсирлектән кайткач, тол хатын Маһисәрвәр абыстайга йортка кергән һәм гомер буе бер генә күршесе белән дә тыныша алмый, гел-гел талашып, гаугалашып яши иде. Белмим, әтигә ничек теше үтмәгәндер (бәлки авыл советында эшләгәнгә, аңа сагаеп, куркыбрак карагандыр), ул куркыныч елларда безгә зыян сала алмады. Бәлки әтинеңме, абыйныңмы аның турында:

*Мин бит кәнсәләргә барам,*<br>
*Маһисәрвәр, эшли тор.*<br>
*Кеше ни әйтсә дә әйтер,*<br>
*Сәлимгәрәй—Шлихтер,—*

дип такмак чыгаруы сәбәп булгандыр. Шулай да әти аннан шикләнә иде булса кирәк—әнинең: "Атаңның китаплары байтак иде. Кайберләрен, чүпрәккә кат-кат төреп, үзебезнең арт бакчага күмде бугай" дип сөйләгәне истә калган. Хәзер кайдан эзләп табасың инде аларны! Андый югалган хәзинәләр аз булганмыни ул заманнарда.

Әти китте. Ул вакыттагы газеталарда язылганча, "явыз немец-фашист илбасарларын аяусыз кырырга", дип, "бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинга биргән антыбызга турылыклы булырга",—дип тантаналы вәгъдәләр биреп, изге сугышка китте. Ачлыклардан, ялангачлыклардан котыла башлаган авыл, ертык-тишекләрне ямаштырганына шөкрана кылып, нәрсәләргәдер өмет итеп, бушап калды. Әтинең әле миче дә чыгарылмаган, бинаһая зур йорты калды да, без—күз яше ул чакларда бер көн дә кибеп тормаган әни, биш яшьлек мин, әле юньләп тәпи дә йөри башламаган сеңлем Фәүзия калды. Шуларның бөтенесе өстенә өелеп мең-мең төрле мәшәкатьләр калды. Әни: "Ах, атаң булса..." дип көрсенә һәм үҗәтләнеп, ул жиренә житкерергә өлгерми калган, ирләр генә башкарырга тиешле авыр эшләргә тотына иде. Яу кырыннан исә хәбәрләр никтер сирәк килде. Ә ике хатның берендә: "Улыма операцияне Туруновский ясасын, башкаларына ышаныч юк" дип кат-кат әнинең исенә төшерә иде. "Операция" дигәннән—бөтенесе тагын шул минем тик тормаслыгым, шаян-шук булуым аркасында булган инде. Моржа тирәсендә шырпы тартмалары күргәнмен дә, шуларны алам дип бүлмә такталары буйлап үрмәләп югарыга менгәнмен. Ә анда житкәч, аякларым шуып китеп, башым өстәге түшәм белән ике арага кысылып, муеныма асылынып калганмын. Әле ярый, бәхетемә күрә, кайсыдыр өйгә килеп кергән дә мине үлемнән коткарган. Сыдырылып бетүләрем бер хәл, иң куркынычы—миңа бүсер төшкән. Врачларга күрсәткәч, алар операциясез булмас дигәннәр. Ул Туруновский дигән кешенең бушаганын көтә-көтә, көн артыннан көн үтә торган. Күрәсең, әти дә, үзе утлар эчендә булуына карамастан, һаман минем турыда борчылып торгандыр. Әни Туруновский дигән ул атаклы хирургны, мине иkenче (Карман карурманындагы адашуыбыз турында әйткән идем инде!) котылгысыз үлемнән коткарып калачак Михаил Андреевичны, әллә кайлардагы кыр госпитальләреннән әйләнеп кайткач кына туры китерә алган.

Әтинең хатлары сугышның икенче елында тәмам килүдән туктады. Без билгесезлек божрасында калдык. Кайда, ничек, ни булганын белә алмадык. Әни мәрхүмә, бәлки берәр хәбәр анда килгәндер, дип, шул әти эшләгән Тутай авылына да берничә тапкыр барып кайтты. Анда да күңелне юатырлык бер хәбәр дә ишетә алмаган иде. Өмет бөтенләй өзелмәгән булса да, нәрсәгәдер ышанасы килә иде бит. Әти язмышы, инде үзем анын яшен узып киткәч тә, бүгенгәчә гел-гел борчып тора, җавабы табылмастай катлаулы сорау булып йөрәкне тырный.

*Кай илләрдә ятып калды икән*
*Асыл сөякләре атамның?*
*Үги улы иде микәнни соң*
*Рәсәй дигән юньсез ватанның.*

*Бер кайтмасак, бер кайтырбыз, диеп*
*Яулык болгый-болгый китте дә...*
*Шуннан бирле күңел заманага*
*"Сәер сорау" биреп интегә.*

*Сугыш та юк... Җиңдек тә бит инде...*
*Һәм исәннәр алды орден да...*
*Тик нигә соң адәм сөякләре*
*Җирдә аунап ята бүген дә.*

*Рәнҗиләрдер—каберләре юкка...*
*Көтәләрдер варис ирләрне...*
*Нинди игелексез ил соң бу ил?—*
*Батырларын хәтта җирләми.*

*Исемсезләр, билгесезләр булып*
*Миллионнар калган яуларда...*
*Үлгәннәргә кадер һәм кабер юк—*
*Җиңдек диеп нигә шауларга?!*

---

*Ә колакта бер чың... Сорау чыңлый...*
*Чыңлар... чыңлар... җанны кыйратыр.*
*Кай җирләрдә газиз әтиемнең*
*Асыл сөякләре—кем әйтер?!*

Сугыш—җәмгыятьнең авыру халәте, дип әйтсәләр дә, мин аны яшәеш рәвешен, тормыш принципларын чагылдыручы бер могҗизаи индикаторга тиңләр идем. Ул, Сталин бабай кистереп әйткәндәй, гадел булса да, гадел булмаса да, кемнең батыр, кемнең куркак икәнен билгеләсә дә, ахыр чиктә кеше дигән адәми затның әле моңарчы беркемгә дә, хәтта шәхеснең үзенә дә билгеле булмаган яшерен сыйфатларын, ара-тирә чак кына сиздереп куйгалаган яраларын да ача. Кемнең кемлеген ачыклау өчен дә житди имтихан иде бит ул еллар.

Без, бала-чагалар, олылар эшенә кысылырга бик атлыгып тормый идек югыйсә. Ләкин колакка керә бит. Колакка кердеме, хәтергә сеңә инде ул—кечкенә чагыңда гына аңа бик илтифат итмисең. Күңелеңдә—туйганчы ашау да, яшьтәшләрең белән, бар кайгы-борчуларны онытып, көннәр буе уйнау була. Ул бер-беребездән уздыраша-уздыраша, тешләр шакы-шокы килгәнче кат-кат су коенулар, яңгыр яуса, ермакларда кәгазь көймә агызулар, талчыбыктан дирбия ясап ат-ат уйнаулар, йоннан әвәләнгән шарга-мүскәгә эләкмәскә тырышып әле анда, әле монда йөгерүләр, бәләкәй-бәләкәй уентылар уртасындагы зур чокырга шар ташларга маташучы "көтүчене" якын җибәрмәс өчен җәһәт кенә (югыйсә ул синең уентыгыңны яулап алачак!) аны үз һөҗүмең өр-яңадан башларга мәҗбүр итүләр, кыекбаш дигән, "кара таяк" дигән качыш уены, "ат карагы" дигән уеннар... Үзебезнең күңелне күрер өчен нәрсә генә уйлап чыгармый идек без?! Ул вакытта бит хәзерге матай дигән, велосипед дигән нәрсәләрне күргәнебез юк. Әлбәттә, кайчагында ачуланыша, үчекләшә-үртәшә

начар сүзләр әйтешә, хәтта кыйнаша да торган идек, ләкин кайбер малайларның авызы-борыны канавын иртәгәсен үк онытa, озаклап үч тотып йөрми идек.

Мондый "бәләкәй-бәләкәй гражданнар сугышы" бик еш кабатлана башлагач, үзе эшкә киткәндә, әни мине өйдә бикләп калдыра торган булды. "Әнә, сеңлеңне кара, югыйсә, әнә мич акшарын да кимереп бетерде",—дип мина каты-каты күрсәтмәләр бирә дә, икебезне калдырып, эшкә чыгып китә иде. Мин инде: "Ярый, әни, ярый",—дигән булам, аннан, ул күздән югалуга—чорма башына үрмәлим, аннан үзем әллә кайчан кадакларыннан ычкындырып куйган тактаны каерып, лапас башына төшәм һәм мин... иректә. Урамда, малайлар янында. Әнинең, кояш кайсы җиргә житкәч кайтасын чамалыйм. Безнең сәгать шәүләбезнең ничә адым озынлыкта булуы белән үлчәнә. Мин, берни булмагандай, шул ук юл белән нәкъ үз вакытында өйдә булам, нәрсәләрдер биреп, елап-шешенеп беткән сеңелне юмалыйм. Сатмый тагын үзе мине.

Шулай да минем иң мавыкканым—самолетлар. Чын самолетларны китапларда яки ара-тирә авыл клубында "бисплат" күрсәтелгән киножурналларда гына күрсәм дә, "стрибителен" дә, "бамбардировщигын" да ясыйм. Өй кыегында да минем "самалүт", лапас башында да... Агачтан төп өлешен юынам, канатлары өчен өстәл капкачындагы фанерларны каерам. Әнидән бу тәртипсезлегем өчен еш эләгә инде эләгүен. Ләкин анысына түзәргә була. Аның каруы малайлар алдында үз "самалүтең" белән мактану үзе ни тора.

Ара-тирә авыл өстеннән чын "самалүтләр" дә очып үтә. Кайчагында биектә, бик биектә бәләкәй генә булып тәрәзә рамын хәтерләткән тагын ниндидер очкыч күренә. Безнең шуңа ис китеп караганны күрсә, әлеге дә баягы шул күрше Сәлимгәрәй абзый: "Малайлар, качыгыз тизрәк, бу немец самалүте. Разведчик... бөтенесен күреп тора..." дип безнең котларны ала. Сәлимгәрәй абый белә торгандыр инде... Әнә ул немесчә дә сөйләшә",—дип төрлебез төрле якка шылу ягын карый.

Ә шулай да иң кызыгы—"парашут". Кайдан башыма килгәндер инде ул җүләрлек. Әни әрли тора, мин аның сүзен колакка да элмим. Ул әйткәнне чыгып китүенә онытам. Өстәл җәймәсенең оч-очына юкә җепләр белән таш кисәге бәйлим дә як-ягын бөкләп көчем җиткән кадәр биеккә ыргытам. Җәймә һавада кабарып, нәкъ парашют кебек акрын гына җиргә төшә. Үзем якын күргән малайларга да "парашут төшерергә" рөхсәт итәм. Аларның сөенеченә, ах-вахына чик-чама юк. Әни күрше хатыннарына гел-гел зарлана: "Әллә юләр инде бу малай..." ди. Аннан: "Әрләсәм дә тыңламый, кыйнасам да файдасы юк... Шул атасы гына артык иркәләп азындырды..." дип уфтанып куя. Эләгә әнидән, шактый еш эләгә. Ә минем төзәлергә уемда да юк. Ваемсыз балачак бит—бер колактан керә, икенчесеннән шунда ук чыгып та китә. Сугыш сугыштыр да инде ул—ә безгә, малайларга кызык кына. Авылыбыз зур булгангамы, тирә-якның—Тәүгелдәнең, Әхмәтнең, Кужакның, Лашчы Башының, Исәкнең егетләре сугышка китәр алдыннан беренче хәрби күнекмәләр үтәргә безгә җыелалар. Һәрберсендә—агач мылтык, көн саен командирларның: "На плечо", "К ноге", "Штыком коли" дигән тавышлары яңгырап тора. Ул абыйлар юан агач ботакларына беркетелгән карачкыларга—салам тутырылган капчыкларга ике-өч тапкыр тиз-тиз генә төртеп алалар да, шулай "немец фашистын үтереп", яңадан чиратның соңына китеп басалар. Көннәр буе шулай дәвам итә.

Без бигрәк тә "әфисәр" абыйларның бөтен гәүдәсен урап алган каешларга—тимерләре елтыр-елтыр килеп торган портупеяларына, наганы булмаса да уң якларында кабарып торган кобураларына, погоннарына, йолдыз сурәте төшерелгән бил "риминнәренә", билләренә кадәр асылынып төшкән сумкаларына кызыгабыз. Кайчагында үзара шул тәтиләрне чәлдерү турында баш ватабыз. Чәлдерден ди. Әнә олылар: "Аның өчен катыр җибәрәләр икән",—дип сөйлиләр. Бик куркыныч җирдер ул "катыр" дигән нәрсә—безнең беребезнең дә "катыр китәсе" килми. Бу авылыбызда "сугыш уены" уйнаган йөзләрчә егетләрнең соңыннан күпмесе генә туган якларга әйләнеп кайтты. Ә ул вакытта "үлем" дигән нәрсәләр безнең ике ятып бер төшебезгә дә керми иде бит!

1942 ел авылга зәмһәрир суыклар алып килде. Колхозның җиләк-җимеш бакчасы, без качып-посып угрылыкка йөрергә яраткан алмагачлар өшеп харап булды. Терлек-туар, кош-корт абзар-кураларда жылыга тилмергәнне әйткән дә юк, кешеләр дә, бик ашыгыч эшләре булмаса, урамга чыкмау ягын карыйлар, баштанаяк чүпрәк-чапракка төренеп, өшеп-күшегеп җан асрыйлар иде. Безнең әтидән калган зур йортны да салам белән генә җылытып бетерешле түгел, әни эшкә киткәндә, мине

һәм сеңлемне кат-кат юрганга төреп, урын өстендә калдырырга тырыша иде. Колхоз идарәсендә дә, күрәсең, жылы диган нәрсә аз булгандыр, житәкче абыйлар бер заман үз утырышларын безнең өйдә үткәрергә күнектеләр. Иркен дә, якты да. Ягарга да ул кадәр үк күп кирәкми. Әмма жыелышлары булып ике-өч көн үтүгә өй кабаттан суынып, тагын шул каһәр суккан салкын кереп оялый иде. Аптырагач, әни каршы яктагы күршегә өйдәшкә керәсе итте. Аларның бәләкәй генә ызбасында инде ничә еллар урыныннан кузгала алмыйча чирләп яткан Шамил абый һәм яше илледән узган Әминә абтый, алтынчыдамы-жиденчедәме укучы Садыйк исемле төпчекләре белән торалар. Кысан инде, кысан. Без дә өч жан бит әле. Ләкин нишлисең... Һавалар үзәккә үтәрлек булып суыткач, түзәр хәлләр калмагач, кызы Наилә белән Халисә абтый да шул бәләкәй почмакка кереп сыенды. Күңелең киң булса, торган жирең тар дип зарланмыйсың икән ул. Хәзер генә мәдәният Сарайлары кебек коттеджларга хәтта газиз ата-аналарын сыйдырырга теләмәгән игелексез балалар күбәйде. Монысын гыйбрәт өчен, сабак өчен язам.

Шул зәмһәрир суыклар да, бәлки кирәге чыгар, дип окоплар, траншеялар казып йөргән карт-корылар, хатын-кызлар турында шигырь чыгарганымны хәтерлим.

*Күптәннән үткәннәр ул көннәр—*
*Уйларга, аңларга вакыт бар.*
*Кояшта күз яшен киптерә*
*Әниләр казыган окоплар.*

*Окоплар... әйтерсең яз саен*
*Йөрәктә яралар уяна.*
*Туасы таңнарга өметтәй*
*Мөлдерәп карыйлар дөньяга.*

*Хәтердә,*
*Солдатка аналар*
*Бәгырен кискәләп җил исте.*
*Моң иде күңелләр түрендә,*
*Туң иде, туң иде җир өсте.*

*Тик ломнар, кәйләләр, көрәкләр*
*Җырлады бер көйгә тәкрарлап:*
*—Юлбасар дошманнар якында,*
*Илеңне, өеңне кал саклап.*

*Онытылды арулар-талулар,*
*Онытылды назланыр вакытлар.*
*Шәһәрләр, авыллар читендә*
*Ишәйде дотлар һәм окоплар.*

*Хәтердә терелтеп үткәнне,*
*Ничә ел тоташтан һәр таңда*
*Толлар һәм ятимнәр шикелле*
*Ятсынып карыйлар дөньяга.*

Ә бит бу шигырьне озак еллар буе бер жирдә дә басмадылар. Ул турыда язарга ярамый, диделәр. Бу—дәүләт сере, аның турында әле хәзер дә тел тибрәтү тыела, диделәр. Заманнар үзгәреп, ул "ярамыйлар" үз көчендә калган булса, мөгаен, бөтенләй дөнья да күрмәгән булыр иде. Андый шигырьләр тагын бар бит әле минем...

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Вера Минкинага 90 яшь



Халык мәхәббәте лауреаты дигән титул булса, аны беренчеләрдән булып, һичшиксез, артист Вера Минкинага бирерләр иде. Иң элек аның биографиясен күздән кичерик.

Вера Минкина 1918 елның 9 сентябрендә Татарстанның Чистай районы Бахта авылында туа. Гаиләдәге алты баланың өлкәне, иң беренчесе буларак, кечкенәдән өйдәге, йорт-курадагы күп кенә вазифаларны башкарып үсә. Театр училищесына укырга дип килгәч, әлеге хезмәт мәктәбе бик тә ярап куя үзенә. Кер бәләкләү, кер чайкау кебек этюдларны башкаруы имтихан алучыларның күңеленә шундук хуш килә. Кечкенәдән авыл сәхнәсенә менә ул, төрле җыр һәм биюләрне башкарып, авылдашларыннан күп алкышлар һәм мактау сүзләре ишетә.

Имтихан вакытында аңардан: "Үсәрсең микән син, балам?"—дип тә сорыйлар. "Әлбәттә!",—дип катгый җавап бирә ул, кулларын өскә күтәреп.

1939 елда Казан театр училищесын тәмамлаганнан соң Республика күчмә театрында 13 ел эшли. ТАССРның атказанган артисты дигән исемгә лаек була. 1952 елдан—Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында. Халыкчан, үзенчәлекле, таланты белән күпкырлы күренекле артист ханым сәхнәдә төрле характердагы йөзләрчә образларны иҗат итә, күңеле аша уздыра. Аларны санап чыгу мөмкин түгелдер. Безнең очрашу вакытында: "Иң яраткан рольләрегез кайсы булды икән?"—дигән сорауга ул Миңнекамалны (Мирсәй Әмирнең шул исемдәге әсәре), Таҗи Гыйззәтнең "Чаткылар"ындагы Гыйльменисаны атап китте. "Зәңгәр шәл"не дә онытмады: әйе, бу данлы спектакльдә В. Минкина малай ролен башкарган иде заманында. Исеме дә юк бу "малай"ны тамашачылар заманында бик тиз яратып өлгерде.

1967 елны Бөтенроссия смотрында, "Чаткылар"да Гыйльмениса ролен башкарганы өчен, ана I дәрәҗәдәге диплом бирелде. Вера Минкина—Татарстанның һәм Россиянең халык артисты.

Сәхнә карьерасын ул, "Әлдермештән Әлмәндәр"дә Хәмдебану ролен башкарып, 85 яшендә тәмамлады. Сүз дә юк, озын гомерле, бәрәкәтле иҗат юлы бу.

—Вера апа, озын гомерле булуның сере нәрсәдә?—дигән сорауга ул, канатланып китеп, болай дип җавап бирде:

—Тормыштан, эшемнән ямь табып яшәдем. Сәхнә юлыннан төшмәвем, халкымның мәхәббәте миңа һәрчак илһам бирде...

Афәрин, безне шатландырып шулай озак яшә, Вера апа!

**Рашат НИЗАМИ**

## "Салмак кына еллар шулай узып бара..."



Шагыйрә Фәүзия Солтанның "Гомер китабы" исемле шигыреннән бу юллар. Гомернең мәгълүм бер чорына килеп житкәч, вакытның узганы үзен сиздерә, үткәннәр турында уйландыра башлый икән. Хәер, бер чорга житкәч кенәме? Көнелен ижатка биргән жан иясе уйланмый яши аламы? Уйланудан, уй янудан гына туа ала бит шигырь дигән хикмәт. Битарафлар, жаннары йокымсыраганнарны үз итми бит ул. Әнә бит шагыйрә дә:

*Язмыш белән бәхәсләшеп үткән гомер,*

—дип яза.

Бәхәстә исә хакыйкать ярала. Шагыйрь өчен хакыйкать ул—шигырь.

"Ф. Солтан олы сәяси проблемаларны күтәрергә омтылмый, фәлсәфи-рационалистик фикер шагыйре булуны да дәгъва итми. Ул хатын-кыз язмышына төшкән катлаулы, иң гади һәм гадәти төшенчәләр турында уйлана, шигъри сүзнең үтемле һәм сурәтле булуына омтыла, үзенә бер самими һәм жылы халәт тудыруга ирешә",—дип яза аның ижаты турында галим Нурмөхәммәт Хисамов. *("Идел", 2007. № 4).* Шагыйрьләр Ә. Мәхмүдов *("Шәһри Казан", 2005),* М. Миңшин да *("М. Ж." 2004)* аның ижатына унай бәя биреп үз фикерләрен укучыларга житкерделәр.

Мәктәптә дә тырышып укыган кызның шигърияткә килүе китапка, әдәбиятка мәхәббәт булудандыр мөгаен.

1958 елның 1 сентябрендә—белем көнендә туган Фәүзия—1965 елны Балык Бистәсе районының Олы Солтан урта мәктәбенә укырга керә, аны 1976 елда гел "5"ле билгеләренә генә тәгәлли. Шул ук елны әлеге авыл китапханәсе мөдире булып эшли башлый. Читтән торып Алабуга китапханәчеләр әзерләү техникумында укый. 1984 елда Казанга килә, 1984 елда Казан дәүләт сәнгать академиясенә укырга керә, 1998 елда аны "кызыл" диплом белән тәмамлый. Гомеренең күп елларын "Казан" санаториясендә китапханә мөдире булып эшләүгә багышлый. Үзенең тормыш юлын китап белән башлаган кызның язмышында да китапның төп урыннарның берсен алып торуы гажәпмени? Фәүзия Солтан—ике китап авторы. "Учларымда—жиләк"—1989 елда "Матбугат йорты" нәшриятында дөнья күрсә, "Үзәк өзелгән чакта" исемлесе 2003 елда "Татарстан китап нәшрияты"нда чыккан. 2000 елда Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителә.

Ф. Солтанның шигъри тәхәллүсе туган авылына хөрмәт йөзеннән алынуы да табигый хәл. Бу төбәк әдәбият-сәнгатькә талантларны мул биргән. Шуңа да туган ягына, ана белән бала мөнәсәбәтенә багышлап язылган шигырьләре шактый. Хатын-кыз бәхете, сөю-сөелү кичерешләре—аның шигъриятенең үзәге. Авыр чакларында ул шигырь белән юана, күңелен шигырьдә бушата.

*Ут күргәндәй булам адашкан чагымда.*
*Сүзләр килә күңелемә. Шигырь туа.*
*Гүя үлән таш астыннан шытып чыга.*

Без исә Фәүзия Солтанны гомер бәйрәме белән котлап, тормышында якты көннәренең күбрәк, ижатының мул булуын, исәнлек-саулык теләп калабыз.

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**



*Г. Камал театрының бер төркем артистлары К. Тинчуринның "Беренче чәчәкләр" спектакленнән соң. Сулдан уңга (утырганнар): Галимә Ибраһимова, Галия Нигъмәтуллина, Рәшидә Җиһаншина, Асия Мәсәгутова; арткы рәттә: Кәрим Гыйльманов, Фатих Шәрәфиев. 1950 ел.*



*Драматург Туфан Миңнуллин актриса Тәслимә Фәйзуллина (сулда) һәм язучы Нәбирә Гыйматдинова белән. 1993 ел.*



*Театр бинасында очрашу. Әхсән Баян, Мөдәррис Әгъләмов, Гариф Ахунов. 1997 ел.*



*Мәскәүдән кунаклар килгәч. Сулдан уңга—Мөхәммәт Садри, Михаил Львов (Рифкать Габитов), Николай Доризо. 1982 ел.*



*Үткән гасырның 80нче елларындагы "Саз" ансамбле җитәкчесе, музыкант Рифкать Гомәров (1942–1996).*



*"Казан утлары" журналы редакциясендә Германиядән килгән милләттәшебез Салиха ханым белән очрашу. Сулдан уңга (арткы рәттә): Җәүдәт Миңнуллин, Тәуфикъ Әйди, Мансур Вәлиев, Флүс Латыйфи, Рәдиф Гаташ, Нияз Акмал, Шамил Маннапов, Мәдинә Маликова; алда утырганнар: Рашат Низамиев, Салиха ханым, Кояш Тимбикова. Июнь, 1989 ел.*

## ЖИТДИ БЕЛДЕРҮ

2008 елның 2 августында Казанда Идел буе—Урал халыкларының милли конгресслары һәм ассоциацияләре житәкчеләренең очрашуы булып узды. Биредә «Удмурт кенеш» Бөтенудмурт ассоциациясе президенты В. Тубылов, Бөтендөнья башкорт корылтае башкарма комитеты рәисе Р. Азнабаев, РФ фин-угор халыклары ассоциациясе рәисе В. Мосин, Чуаш милли конгрессы президенты Г. Архипов, Бөтенмари шурасы рәисе урынбасары В. Воронцов, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Р. Закиров катнашты.

Милли оешма житәкчеләре Идел буе һәм Урал жирләрендә яшәүче төп халыкларның этнокультура үзенчәлекләрен, туган телләрен, милли мәгарифне саклау кебек уртак мәнфәгатьләрен искә алып, ассимиляция, милләтләрне юкка чыгару сәясәтенә каршы чыгып, Россия Федерациясе халыклары арасында бердәмлекне һәм хезмәттәшлекне ныгыту максатыннан, Идел буе һәм Урал халыклары Координацион шурасын оештырдылар.

Милли хәрәкәт лидерлары Россия һәм халыкара жәмәгатьчелеккә мөрәжәгать итеп, алардан милли үзенчәлекләрне, туган телне, мәгариф системасын саклауда теләктәшлек сорап белдерү кабул иттеләр.

«Советлар берлеге һәм Көнчыгыш Европа илләрендә тоталитар режимның жимерелүе күп халыкларның, шул исәптән Россия Федерациясе халыкларының да иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади тормышында демократик үзгәрешләргә, милли күтәрелешкә юл ачты. Яңа Россиядә демократия һәм ачык жәмгыять шартларында XX гасырның 90 нчы елларында безнең халыкларыбыз туган тел, милли мәктәпләр, мәдәният, ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү өлкәсендә шактый уңышларга иреште. Ул елларда милли сәясәт федератив дәүләтнең иң әһәмиятле мәсьәләләреннән берсе булып торды.

Ләкин соңгы елларда федерализм, халыклар тигезлеге, аларның милли хокуклары саклану принципларыннан кире кайту күзәтелә. Болар барысы да Россия Федерациясендә күпмилләтле халыклар мәнфәгатенә, илнең мәдәни һәм цивилизацияле күптөрлелегенә жавап бирерлек төпле милли сәясәт булмавын күрсәтә.

Илнең Төп канунында «Россия Федерациясе барлык халыкларга туган телләрен саклау, аны өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру хокукларын гарантияли» диелгән булуга карамастан, соңгы вакытта мәгариф өлкәсендә Россия Федерациясе Конституциясе һәм халыкара хокук нормаларын бозучы канунннар кабул ителә. Хәзерге вакытта жәмәгатьчелектә укыту стандартының милли-төбәк компоненты һәм аларны тәнгәлләштерү турында бәхәс бара. Безнең фикеребезчә, монда сүз уйнату гына күзәтелә. Ә асылда федератив дәүләттә һәр халыкның туган телендә үз милли мәгариф системасын булдыру турында гына сүз барырга тиеш. Моңа кадәр Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгында милли мәктәпләр проблемалары белән шөгыльләнүче бүлек һәм хәтта махсус фәнни-тикшеренү институты да бар иде. Россиядә демократиянең аякка баскан елларында илдә Милләтләр эшләре һәм төбәкләр сәясәте буенча министрлык та эшләде. Бу структураларны бетерү илнең бүгенге житәкчелеге Россия халыкларын тиз арада ассимиляцияләү һәм унификацияләнгән милләтсез халык тудыру юнәлешендә хәрәкәт итә башлавы турында сөйли. Бу вазгыять бездә нигезле хәвеф уята.

Без, Идел буе һәм Уралның төп халыклары вәкилләре, Россия һәм халыкара киң жәмәгатьчелеккә мөрәжәгать итеп, алардан милли үзенчәлекләребезне, туган телебезне, мәгариф системабызны, милли мәдәниятебезне, ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен саклап калуга омтылышыбызны яклап чыгуларын сорыйбыз. Без халыкара жәмәгатьчелеккә таянырга мәжбүр, чөнки Россия Федерациясе хакимият структураларына күпсанлы мөрәжәгатьләребез тиешле жавап алмады.

Россия Федерациясе халыкларының мәдәни һәм цивилизацияле күптөрлелеген саклап калыйк! Туган илебезнең прогрессив үсешен һәм чәчәк атуын без шушы юлда гына күрәбез»,—диелә белдерүдә.

## ПРЕЗИДЕНТ ШАГЫЙРЬНЕ КОТЛЫЙ

Россия Президенты Дмитрий Медведев Татарстанның халык шагыйре, ТР Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы Роберт Миннуллинны 60 яшьлек юбилее белән котлады.

"Хөрмәтле Роберт Мөгаллим улы! 60

яшьлегегез унаеннан эчкерсез котлауларны кабул итегез! Талантлы шагыйрь, публицист һәм тел белгече буларак, сез үз әсәрләрегез белән Россиянең мәдәни күптөрлелеген баетасыз, татар теле һәм әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертәсез, ә балалар өчен язылган китапларыгыз белән нәни укучыларга шигъриятнең гүзәл дөньясын ачасыз.

Татарстанда яшәүчеләр файдасына актив иҗтимагый һәм мәгърифәтчелек эшчәнлегегез дә зур ихтирам-хөрмәткә лаек.

Сезгә нык сәламәтлек, яңа үрләр, гомумән, иң изге теләкләр телим",—диелә котлау телеграммасында.

### ШАХМАТ САРАЕ ДА БУЛЫР

Татарстан Президенты М. Шәймиев Казан Кремлендә Халыкара шахмат федерациясе (ФИДЕ) президенты, Калмыкия башлыгы К. Илюмжинов белән очрашты. Сөйләшүләр барышында Татарстанда Шахмат сарае төзү, FISU җитәкчелегенә, өстәмә спорт төре буларак, шахматны 2013 елгы Универсиада программасына кертү турында тәкъдим ясау, шахмат уенын киләчәктә тагын да популярлаштыру һ. б. мәсьәләләр күтәрелде.

Казанда Шахмат сарае төзелгән очракта чыгымнарны Халыкара шахмат федерациясе күтәрәчәк.

### АЛТАЙГА СӘФӘР

Татарстан һәм Алтай Республикасы тыгыз хезмәттәшлеккә өметләнә.

Рәсми визит белән Алтайда булып кайткач, ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева журналистларга әнә шулай дип белдерде. Татарстан делегациясе составында Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендә тәңгәллеген билгеләү буенча комиссия рәисе Роберт Миңнуллин һәм «Зенит» банкы ачык акционерлар җәмгыяте идарәсе рәисенең беренче урынбасары Рәшит Гобәйдуллин бар иде.

Татарстан делегациясе әлеге визит кысаларында Алтайның Чемал районында, шулай ук Таулы Алтайга керү юлында урнаштырылган истәлек билгесе (анда төрки халыкларның киләчәк буыннарына мөрәҗәгате урын алган) янында булды. Истәлек билгесе, белгәнебезчә, ТР Президенты Минтимер Шәймиев ярдәмендә урнаштырылган иде. «Бу билге әлеге төбәкнең күренекле урынына әйләнергә өлгергән дә инде. Аның янәшәсендә булганда, артында бик күп буыннар басып торгандай тоела. Истәлек билгесенең алтайлыларга да бик кадерле булуы күңелгә хуш килә»,—диде Зилә Вәлиева.

### КАЗАНГА ТУРИСТЛАР АГЫЛСЫН

Казан туризм тармагында Россиянең башка шәһәрләре һәм чит илләргә көндәш була алсын өчен башкаланы тагын да ныграк таныту мөһим. Бу хакта кала мэриясендә эшлекле сөйләшү булды. Тышкы элемтә һәм туризм комитеты башлыгы Владимир Леонов 2008—2011 елларда Казанда туризмны үстерү программасын тәкъдим итте. Шәһәр җитәкчелеге киләчәктә башкалада ел саен 1,5 миллион турист кунак булыр, аларның бередә сарыф иткән акчасы—45 процентка, ә бу тармакта эшләүче хезмәткәрләр саны 15 процентка артыр дип өметләнде. Программа Универсиадага әзерлек чаралары кысаларында тормышка ашырылырга тиеш.

### ДЕРЖАВИН—ДЕРЖАВА ШАГЫЙРЕ

Соңгы елларда күренекле шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе, якташыбыз Г. Державинның туган көне республикакүләм бәйрәм рәвешендә билгеләп үтелә. Күркәм традиция быел да дәвам итте.

Бәйрәм Казанда—Г. Державин һәйкәле янында башланып китте. Шигырь сөючеләр, язучылар шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салды. Аннары бер төркем әдипләр, Мәдәният министрлыгы, Милли китапханә һәм Милли музей хезмәткәрләре, югары уку йортлары галимнәре шагыйрьнең туган төбәгенә—Лаешка юл тотты һәм анда башкала кунакларына район мәктәпләре укытучылары, укучылар килеп кушылды. Лаешның үзәк мәйданында бәйрәмне кереш сүз белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов ачып җибәрде.

Каләм әһелләренә Г. Державин исемендәге әдәби бүләкләр тапшыру, мөгаен, бәйрәмнең төп бизәге булгандыр. 2000 елда Татарстан Язучылар берлеге һәм Лаеш районы хакимияте тарафыннан булдырылган премиянең дәрәҗәсе тагын да үсте. Аны гамәлгә куючыларга былтыр Татарстан Мәдәният министрлыгы да кушылып, ул республика күләмендәге әдәби бүләк статусын алды. Лауреатларга махсус танıклык һәм истәлек медале тапшырыла.

Быел Г. Державин исемендәге әлеге бүләккә шагыйрь һәм прозаик Рөстәм Сабиров ("Беглец" дигән китабы өчен) һәм моннан 20 ел элек арабыздан киткән шагыйрь Геннадий Капранов ("Я чист, как родниковая вода" исемле китабы өчен) лаек булды. Даһи Пушкинга шигъри фатыйхасын биргән бөек якташыбыз исемендәге мәртәбәле бүләкне Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева тапшырды. Аннары Лаеш районы мәктәпләрендә укучыларның традицион шигъри конкурсында җиңеп чыккан яшь каләм ияләренә махсус диплом һәм истәлекле бүләкләр бирелде.

Жыр, музыка, театрлаштырылган тамаша белән аралашып барган бәйрәмдә Татарстанның халык шагыйрьләре Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Роберт Миңнуллин, күренекле галим Хатыйп Миңнегулов, шагыйрьләр Николай Алешков, Ольга Левадная, Наилә Ахунова, Борис Вайнер һ. б. чыгыш ясады.

Шигъри җыенны Г. Державин исемендәге әдәби бүләк иясе, шагыйрә Лилия Газизова алып барды.

### ГАЗЕТА ЮБИЛЕЕ

Моннан 15 ел элек Мәскәүдә "Татарские новости" дип исемләнгән яңа газета нәшер ителә башлады. Ул татар энтузиастлары көче белән татар эшкуарлары акчасына басылып чыкты, Мәскәүнең Җәмигъ мәчете дә ярдәм күрсәтте. Әмма басма озак еллар җәмәгать башлангычында гына чыгып килде.

Газетаның хәле берничә елдан соң, "Папирус" фирмасын оештыручылар һәм аның җитәкчеләре—яшь татар эшкуарлары Р. Абдуллин һәм И. Мөслимов аны үз канаты астына алгач кына уңай якка үзгәрде. Алар аны гомумроссия иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни-агарту басмасы буларак теркәтте, үз офисларында редакция өчен бүлмә бирде, логотибын үзгәртте, төсле итеп чыгара башлады. Шуннан соң "Татарские новости" газетасының популярлыгы саннан-санга арта, эчтәлеге яхшыра, авторлар даирәсе киңәя, тиражы да үсә барды.

Дәүләт Думасы депутаты И. Гыйльметдинов җитәкләгән федераль татар милли-мәдәни мохтарияте, Төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте тарафыннан газетаның 15 еллыгы уңаеннан оештырылган бәйрәм чын мәгънәсендә федераль дәрәҗәдәге вакыйгага әйләнде. Бәйрәмгә илнең төрле төбәкләреннән—Свердловск, Астрахань, Волгоград, Санкт-Петербург һәм Татарстаннан газетаның укучылары һәм аны ихтирам итүчеләр җыелды. Редакция коллективын Татарстан Президенты М. Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Мәскәү мэры Ю. Лужков, Россия Федерациясенең Үзбәкстандагы илчесе Ф. Мөхәммәтшин, РФ Матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы, Төбәк үсеше министрлыгы җитәкчеләре, Мәскәүдә чыга торган милли басмаларның мөхәррирләре тәбрик итте.

Газета бәйрәмендә ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Журналистлар берлеге рәисе Р. Ратникова, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Р. Закиров, Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары А. Фәйзуллин һ. б. катнашты.

Тантана кысаларында Татар мәдәнияте үзәгендә фәнни-гамәли конференция узды. Анда халыкларны берләштерү, тынычлыкны һәм дуслыкны ныгытуда милли матбугатның роле хакында сүз барды. Чыгышлар редакцияләрнең тәбрикләү хатларын уку, "Татарские новости" газетасының ветераннары һәм бүгенге хезмәткәрләренә бүләкләр, Рәхмәт хатлары тапшыру белән үрелеп барды. И. Шакиров, А. Әсәдуллин. С. Фәтхетдинов, Р. Хәбибуллина, Н. Фатехова, бию ансамбльләре һ. б. чыгышлары бәйрәмгә тагын да ямь өстәде.

### БӨЕК ӘДИПНЕ ХӨРМӘТЛӘП

***

4 июль көнне Чистай районының Яуширмә авылы республикабызның әдәбиятсәнгать әһелләрен "Исхакый уку"ларына җыйды. Бу чара 1999 елдан алып быел дүртенче тапкыр үткәрелде. Бәйрәмне Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Айрат Җаббаров ачып җибәрде.

"Быелгы очрашуыбыз аеруча әһәмиятле: бөек язучы, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулды. Шул уңайдан Татарстанда бик күп чаралар үткәрелде. Яшьләр арасында Гаяз Исхакый иҗатын өйрәнү максатында оештырылган "Югалмас мирас эзеннән" республика конкурсы, Казан дәүләт университетында галимнәр, укучылар катнашында искә алу кичәсе һ. б. уздырылды. Г. Исхакый—XX гасыр башы татар мәдәниятендә үзәк фигура, бу чор әдәбиятына нигез салучыларның берсе, иҗатының байлыгы, күтәргән проблемаларының әһәмияте буенча ул энциклопедик масштабтагы галимнәр белән беррәттән тора",—диде ул.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, Гаяз Исхакыйның якташы Ринат Закиров болай диде:

"Бу бәйрәм безне киләчәккә карап эш итәргә өнди.—Без халкыбызның үткән шанлы юлы белән горурланып, бирегә җыелабыз. Шөкер, моңарчы исемен дә атарга ярамаган әдәби җәүһәрләр, югалып бара торган динебез кире кайтты. Авылларыбыз өстендә мәчет манаралары, ярымай балкый, халкыбызның рухы яңара. Гаяз Исхакый шулар өчен үзенең тормышын багышлаган... Соңгы елларда милләтебез тарафына салкын җилләр исә башлады. Моңа каршы тору өчен гаиләләребезне, динебезне ныгытсак иде. Бүген милләтебезгә шактый кыенга туры килсә дә, бабаларыбызга, Исхакый чордашларына күпкә авыррак булган. Иң мөһиме—рух ныклыгын сакларга кирәк".

Аннан соң Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, галимнәр Хатыйп Миңнегулов, Лена Гайнанова һ. б. чыгыш ясады. Чистай шәһәре һәм районы башлыгы урынбасары Әнисә

Мөэминова Казаннан һәм Татарстанның төрле төбәкләреннән килгән кунакларга рәхмәт әйтте, бу бәйрәмнең алга таба бездә генә түгел, чит илләрдә дә үткәреләчәгенә ышаныч белдерде.

«Исхакый укулары" чын мәгънәсендә зур әдәбият-сәнгать бәйрәме булды. Язучының музей-утары янында корылган җәйге сәхнәдә Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, А. Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татар фольклор ансамбле, "Сәйдәш" бию театры, Г. Камал, Г. Кариев исемендәге театрлар артистлары, Резеда Галимова, Рөстәм Маликов, Рафаэль һәм Нариман Сәхәбиевләр, Салават, Илназ Минвәлиев, Эльвира Сәләхова, һ. б. чыгыш ясады. Шагыйрьләр Лена Шагыйрьҗан, Шәмсия Җиһангирова, Флера Тарханова, Ркаил Зәйдулла, яшь каләм ияләре Ленар Шәех, Рүзәл Мөхәммәтшин, Резедә Гобәева, Рифат Сәлахов үзләренең шигырьләрен укыды. Башкортстаннан килгән аккордеончы егетләр Роберт Хәлилов белән Илнур Саттаровларның чыгышы күпләр өчен яңалык булды.

Бәйрәмне Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Луара Шакирҗан алып барды.

***

Чирмешәнлеләр Лашман авылында бөек әдип Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган тантаналы бәйрәм уздырды.

Фәнни-гамәли конференцияне хакимият башлыгы Минсагыйть Шакиров ачып, юбиляр турында тирән эчтәлекле доклад белән чыкты. Докладчы үзе дә Лашманда туып-үскән Исхакыйлар нәселеннән.

Кунакка чакырылган күренекле галимнәр Казан дәүләт университеты профессоры Хатип Миңнегулов һәм Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының элеккеге фәнни хезмәткәре Лена Гайнанова Гаяз Исхакый турында тирән эчтәлекле чыгышлар ясадылар.

Исхак мулла варисы, заманында Лашман мәхәлләсе имам-хатыйбы, Сталин репрессиясендә гомере өзелгән мулла углы Тәлгат Исхаков чыгышын да алкышлап каршыладылар. Тантанага чакырылган кунаклар үзләренең юлларын иң әүвәл Лашманнан башладылар. Лашман зиратында җирләнгән Исхакыйлар нәселенең күренекле заты Лотфулла хәзрәт кабере янында туктадылар. Ул әтисе Исхак мулладан соң мәхәлләне җитәкләп дистәләрчә еллар буена халыкка дин, гыйлем эчте. Кунаклар шунда ук сугыш алдыннан районда оештырылган беренче татар урта мәктәбе белән таныштылар. Конференциядән соң районның үзешчән сәнгать осталары Гаяз Исхакый әсәрләреннән төзелгән концерт күрсәтте. Конференцияне төп оештыручыларның берсе "Чаян" журналының җаваплы сәркатибе Минвәгыйз Зәйнетдинов Гаяз Исхакый кызы, Анкара университеты профессоры Сәгадәт Чагатайның тавышы язылган кыйммәтле дискны чирмешәнлеләргә бүләк итте.

## "АЛТЫН МӨНБӘР" ЯКЫНЛАША

16-22 октябрьдә Казанда узачак IV халыкара "Алтын мөнбәр" мөселман киносы фестивалендә 37 ил катнашачак. Бүгенге көндә бәйгегә 196 әсәр тәкъдим ителгән. Алар арасында нәфис, документаль фильмнар, телепрограммалар бар.

Конкурстан тыш, фестивальдә "Сталкер" (Мәскәү), "Звезды Шакена" (Алматы), "Арсенал" (Рига) дигән картиналар да күрсәтеләчәк.

Кинофестивальнең жюри әгъзалары исемлеге дә ачыклана башлады. Алар арасында танылган сценарийлар остасы һәм кинорежиссер Болотбәк Шәмшиев (Германия), Россия Кинематографиячеләр берлеге әгъзасы, "Ника" киноакадемиясе академигы Марина Разбежкина бар. Фестивальгә шулай ук Голливуд актерлары, Төркиядән, Ираннан, Һиндстаннан һәм башка илләрдән дә кунаклар килүе көтелә. Анда шулай ук Россия кинойолдызлары Эльдар Рязанов, Владимир Хотиненко, Алексей Гуськов, Алексей Булдаков, Сергей Безруков та катнашыр дип хәбәр итә оештыручылар.

## БӘЛӘКӘЙ ҖЫРЧЫНЫҢ ЗУР УҢЫШЫ

Яшь җырчыларның Икенче халыкара конкурсында унбер яшьлек Нариман Сәхәбиев (күренекле җырчы Рафаэль Сәхәбиевнең улы) җиңеп чыкты—лауреат булып беренче урынны яулады. Мәшһүр җырчы Елена Образцова җитәкләгән бу конкурста ундүрт илдән җитмешләп яшь җырчы катнашкан булган.

Нариман Сәхәбиевнең бу җиңүе беренчесе генә түгел инде: ул моңа кадәр дә Австриядә һәм Чехиядә узган конкурсларда да лауреат исеменә лаек булган иде. Нариманның таланты турында дөньякүләм билгеле шәхесләр—Владимир Спиваков, Александр Пахмутовалар да зур фикерләр әйткәннәр.

## ИСКӘР ҖЫЕНЫ

Төмән өлкәсенең Тубыл шәһәрендә һәм районында Себер ханлыгының борынгы башкаласы Искәргә багышланган милли-мәдәни чаралар булып үтте. Шул уңайдан бу тарихи урында беренче халыкара фестиваль—Искәр Җыены уздырылды, анда Казакъстан һәм Россиянең төрле төбәкләреннән галимнәр, милли-мәдәни оешма әгъзалары, җирле хакимият

житәкчеләре, профессиональ һәм үзешчән артистлар, матбугат вәкилләре катнашты. Бу чараларны Тубыл шәһәрендә урнашкан «Мирас» татар оешмасы үткәрде. Тубылдан 20 чакрым ераклыкта, Иртыш елгасы буенда таралып яткан тарихи җирләргә, Себер ханлыгының борынгы башкаласы Искәр урынына якын-тирә авыллардан һәм районнардан да бик күп татарлар килгән иде.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзалары, тарихчылар Дамир Исхаков һәм Фәүзия Бәйрәмова җыелган халыкка Себер ханлыгы турында сөйләде, татар тарихын торгызуда мондый милли чараларның әһәмияте турында әйтте, милләттәшләребезне нинди шартларда да татар-мөселман булып калырга чакырды. Дамир Исхаков шулай ук Тубыл шәһәрендә яшәүче милли активистларга Бөтендөнья татар конгрессы исеменнән мактау кәгазьләре тапшырды.

### ЗАТЛЫ БИНАДА—ЗАТЛЫ ЭШЛӘР

«Кол Шәриф» мәчетенең «Ислам» музеенда Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы, каллиграф Нәҗип Нәккашның «Коръән-Кәрим һәм Тукайдан илһам алып» дип исемләнгән шәхси күргәзмәсе ачылды. 60 яшьлек юбилее уңаеннан рәссам-хаттатны тәбрикләргә гаиләсе, ул эшләгән Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, сәнгать институтыннан хезмәттәшләре, Рәссамнар берлегеннән иҗатташлары, сәнгать белгечләре, бик күп дуслары, якыннары җыелган иде. Алар иҗатчының татар сәнгатендә үзгә бер урын алып торуын ассызыклап әйттеләр.

Затлы күргәзмәнең шундый ук затлы бинада үтүе үзе үк шәмаилләр, тугралар ясауда үз иҗат мәктәбен булдырган остаӊын иҗатына зур бәя.

### ТӨРЕК КАРДӘШЛӘРЕБЕЗ БҮЛӘГЕ

Казанның Мәскәү районындагы «Сөләйман» мәчете күрүдән мәхрүм булган дин кардәшләребезгә рухи белем бирү юнәлешендә эш алып бара. Биредә ел әйләнәсендә махсус курслар оештырыла һәм анда Татарстанның шәһәр-районнарыннан, шулай ук Россиянең күп кенә төбәкләреннән мөселманнар җыела.

Күптән түгел "Сөләйман" мәчетенә Төркиядән 30 Коръән кайтарылды. Брайль системасында нәшер ителгән бу басмалар мәчеткә бүләк итеп бирелде. Изге Китапның һәр комплекты 6 томнан гыйбарәт.

Төркиядән җибәрелгән әлеге Коръәннәр Татарстанда гына түгел, Россиядә дә сирәк очрый торган басмалардан санала.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

***

Татарстан Республикасы дәүләтен һәм мәдәниятен үстерү өлкәсендәге зур казанышлары, нәтиҗәле әдәби һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен шагыйрь, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендәге текстлары тәңгәллеген билгеләү комиссиясе рәисе **Миңнуллин Роберт Мөгаллим улы** "Фидакарь хезмәт өчен" медале белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы дәүләтен, социаль өлкәсен һәм мәдәниятен үстерүдәге зур казанышлары, нәтиҗәле җәмәгать эшчәнлеге өчен "Бөтендөнья татар конгрессы" иҗтимагый берләшмәләренең Халыкара берлеге башкарма комитеты рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты **Закиров Ринат Зиннур улы** "Фидакарь хезмәт өчен" медале белән бүләкләнде.

***

Фәнни һәм җәмәгать эшчәнлегендәге казанышлары өчен "Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты" дәүләт учреждениесе директоры урынбасары **Сабирҗанов Гомәр Салих улына** "Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе" дигән мактаулы исем бирелде.

### *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Көзге урман.


*Тышлыкның дүртенче битендә:* тәнкыйтьче **Әлфәт Закирҗанов**.

# Яңа китаплар




**Салим Фатыхов.** Мировая история женщины (Хроно-культурологическое и фактографическое осмысление). Екатеринбург, 2008.—943 б. Тиражы—3000 данә.

Милләттәшебез Фатыйхов Сәлим Галим улы танылган шәхес; ул—күренекле журналист, язучы, галим. Аның тормыш юлы күбрәк Урал һәм Урта Азия яклары белән бәйле. Рус телендә язылган "Мировая история женщины" китабы аның гомерлек иҗади хезмәте. Автор Кешелек тарихында хатын-кыз турында төрле илләрдә, төрле телләрдә чыккан материалларны туплап, мәгълүм бер системага салган. Ун бүлектән торган бу фундаменталь хезмәт дөньяның теләсә кайсы кыйтгасында яшәүче укучы өчен гаять гыйбрәтле һәм файдалы булачак. Безнең укучыларыбызда да бу олуг хезмәт кызыксыну уятыр дип ышанабыз.




**Габделбәр Ризванов, Кафил Әмиров.** Сәйдәш аланында. Китап-буклет. Казан: "Идел-Пресс", 2008.—91 б.

Инде тугыз ел рәттән Югары Ослан районында урнашкан Кызыл Байрак авылында бөек композитор Салих Сәйдәшев истәлегенә багышлап "Сәнгать бәйрәме" үткәрелә. Ул елдан-ел масштаблырак оештырылып, күпләрнең, сабантуй кебек, көтеп алынган мәдәни бәйрәменә әверелә бара. Журналист Г. Ризванов һәм Татарстан Республикасы прокуроры К. Әмиров (күп кенә китаплар һәм фотоальбомнар авторы) бу китапта әнә шул бәйрәмнең оештырылу көненнән башлап бүгенгесенә кадәр тарихын фотосурәтләрдә чагылдырганнар. Китапта шулай ук дистәләгән кешеләрнең Сәйдәш һәм шул авыл белән бәйле бүтән мәшһүр шәхесләр турында истәлек язмалары да урын алган.



Әлфәт Закирҗанов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)